КАЗАН УТЛАРЫ
www.kazanutlary.ru
ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Габдулла ТУКАЙ. Алла гыйшкына. *Шигырь.* ....3
Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Гөләйза. *Тарихи роман.* ....5
Сирень ЯКУПОВА. Карашымда хөрлек чагыла... *Шигырьләр.* ....61
Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Әфган тауларын кичеп... *Повесть.* ....66
Ирек САБИРОВ. Без – милләтнең ерак илчеләре... *Шигырьләр.* ....99
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Алтын басуы. *Хикәя.* ....103
Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. Ефәк юлы чатында. (Төркестан дәфтәреннән). *Шигырь.* ....121
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....125
Фатыйма ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА. *Хикәяләр.* ....126

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ – ДӨНЬЯ КИҢЛЕГЕНДӘ

Дөнья – иксез-чиксез симфония... *(Нурия ИЗМАЙЛОВА, Алсу НУРГАТИНА, Камил ТАҢГАЛЫЧЕВ, Ибраһим БИЕКТАУЛЫ, Шәмси ШАХМАЕВ, Физәлия ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВА, Равил НАСЫЙБУЛЛИН, Әдһәм ӘСКӘРОВ, Равил ШӘФИГУЛЛИН, Эльвера КӘРИМОВА, Гөлфия ИСХАКОВА шигырьләре).* .... 132

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Ник керәсең төшләремә? *Хакыйкый бәян.* ....140

ТАҖЕТДИН ЯЛЧЫГОЛНЫҢ ТУУЫНА – 255 ЕЛ

Дамир ГАРИФУЛЛИН. Табышмаклы гомер иясе. ....161

ЮБИЛЕЙЛАР

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Әдәбиятның йөрәк тибешен тоеп... *(Тәлгат Галиуллинга 80 яшь).* ..... 167

ПУБЛИЦИСТИКА

Айсылу ИМАМИЕВА. Гамәлләрендә – корыч ныклыгы. ....173

ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Дастаннар ватаны син, Себер! ....176

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

«Нәккаш – бизәк остасы ул...» *(Нәҗип НӘККАШ белән Айсылу ИМАМИЕВА әңгәмәсе).* ......... 182

ШАЯН СӘХИФӘ

Уены-чыны бергә. Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде. ....185
*Печән базары:* Рөстәм АРИФУЛЛИН. *Юморескалар.* ....187
Фирдәвес ЗАРИФ. Зарифизмнар. ....189

«Казан утлары» архивыннан. ....138
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
➁: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.06.2018, график буенча 29.06.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-1645. Тираж 5547.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел

Габдулла
Тукай

## Алла гыйшкына

Өлфәт илә без дә итик өлфәт Алла гыйшкына;
Тәрк улынсын кибре, газбе көлфәт Алла гыйшкына.

Тәэлиф улынсын колүбе милләт Алла гыйшкына;
Дәүрулынсын иске гыйлләт, зилләт Алла гыйшкына.

Бу юла һиммәт итик, и өммәт, Алла гыйшкына;
Бөйлә һиммәт безгә җөмлә сөннәт Алла гыйшкына.

Измәсен безне җәһаләт бөйлә Алла гыйшкына;
Чарасын яз йә шифаһән сөйлә Алла гыйшкына.

Улмасын гыйльмә тәгассыб пәрдә Алла гыйшкына;
Җанланыйк, баш кузгатыйк һәр йирдә Алла гыйшкына.

Тәрке өлфәт илә милләт кәлде ушбу халә кем, –
Гыйбрәт, и өммәт Мөхәммәд! Гыйбрәт Алла гыйшкына.

Без дә инсан, без дә итик гайрәт Алла гыйшкына;
Калдырыйк бу галәми дәр хәйрәт Алла гыйшкына.

Милләти тәрфига күңлем ашыгадыр, ашкына;
Итмәсен пәрваз күңелем, бастырып куй таш кына.

Лязем улды безгә билне бугмак Алла гыйшкына;
Мәгърифәтме йә һөнәрме? –
тугъмак Алла гыйшкына.

Бар һөнәремезгә канигъ улмыйк Алла гыйшкына;
Тәңренең лотфына манигъ улмыйк Алла гыйшкына.

*Хәзерге әдәби телдә*

## Аллаһ гыйшкы хакына

Без дә бер кешедәй дус булыйк Аллаһ гыйшкы хакына;
Эрелек, төче теллелекне ташлыйк Аллаһ гыйшкы хакына.

Милләтнең күңеле аңа юнәлсен Аллаһ гыйшкы хакына;
Иске чир, түбәнлек юк булсын Аллаһ гыйшкы хакына.

Шул юлга омтылыйк, и диндәшләр, Аллаһ гыйшкы хакына;
Мондый омтылыш, тырышлыклар керсен гадәткә Аллаһ гыйшкы хакына.

Болай итеп, наданлык безне измәсен Аллаһ гыйшкы хакына;
Чарасын яз яки телдән сөйлә Аллаһ гыйшкы хакына.

Гыйлемгә керелек пәрдә булмасын Аллаһ гыйшкы хакына;
Җанланыйк, кузгалыйк һәр җирдә Аллаһ гыйшкы хакына.


Дуслык булмау сәбәпле, милләт шушы хәлгә килде, –
Гыйбрәт ал, и Мөхәммәд өммәте! Аллаһ гыйшкы хакына.

Без дә кеше ич, итик гайрәт Аллаһ гыйшкы хакына;
Бу дөньяны хәйран калдырыйк Аллаһ гыйшкы хакына.

Милләтне күтәрергә күңлем ашыга һәм ашкына;
Китмәсен күңлем очып, бастырып куй таш кына.

Тиеш булды безгә билне буу Аллаһ гыйшкы хакына;
Мәгърифәт, һөнәр туамы? – бар да Аллаһ гыйшкы хакына.

Бар һөнәребезгә канәгать булмыйк Аллаһ гыйшкы хакына;
Тәңре мәрхәмәтенә каршы килмик Аллаһ гыйшкы хакына.



Фәүзия
Бәйрәмова

# ГӨЛӘЙЗА

ТАРИХИ РОМАН*

## Автордан

*Татар әдәбиятында бик аз яктыртылган өлкәләр бар, көчләп чукындыру темасы әнә шундыйлардан. Бигрәк тә XIX гасырда булган фаҗигале хәлләр аз өйрәнелгән. Монда бары тик Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасы гына нигез булып тора. Татарларны көчләп чукындырулар Явыз Иван чорында һәм XVIII гасырда гына булган, дигән ялгыш караш яшәп килә. Имеш, Екатерина II заманында дин иреге килгән, чукындыру беткән, диләр, әмма бу өлешчә генә дөрес. Әби патша фәрманы белән, һәркемгә үз динен тотарга рөхсәт ителсә дә, элек көчләп чукындырылганнарга үз диннәренә кайту тыелган, моның өчен каты җәза каралган. Ә инде Николай I патшалык иткән чорда (1825-1855) хакимият белән чиркәү берләшеп, яңадан үз диннәренә кайтырга теләгән татарлар өстенә ябырылган. Бу чорда Россия җирлегендә, татар тарихында, «отпавшие» – мәкруһлар дип аталган дини катлам барлыкка килгән.*

*XIX гасырның беренче яртысында татарлар арасында яңадан исламга кайту хәрәкәте бигрәк тә Кама аръягында, тарихи Биләр-Болгар төбәгендә, Чистай һәм Спас өязләрендә зур көч ала. Архив документларыннан күренгәнчә, бары тик 1827-1864 елларда гына да бу ике өяздә өч мең ярым татар-мишәр, берниндк рөхсәтсез, ачыктан-ачык яңадан ислам динен тота башлый! Һәм, әлбәттә, судлар аларга каршы эшләр белән тула, татар авылларын пыр туздырып, мәкруһларны чиркәүле урыс авылларына күчерәләр, керәшеннәргә хәерхаһ булган муллаларны, исламга кайтырга өндәүчеләрне, аяк-кулларын богаулап, Себергә сөрәләр. Моңа җавап итеп, Чистай-Спас өязләрендә йөздән артык татар авылы баш күтәрә... Бу милли һәм дини күтәрелешне оештыруда һәм җәберләнгән халыкка ярдәм итүдә Чистай өязенең мишәр*

* Журнал варианты.

Фәүзия БӘЙРӘМОВА (1950) – *язучы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе; Гаяз Исхакый һәм Һади Атласи исемендәге премияләр лауреаты. «Кырык сырт», «Күчем хан», «Соңгы туранчы» һ.б. иллегә якын китап авторы. Чаллыда яши.*

*морзалары катламы һәм тәрикатьче-суфыйлар да зур ярдәм итә, әлеге тема да бик аз өйрәнелгән.*

*Халык телендә «Гөләйза тарихы» дип аталган бу эш архив документларында «Об отпадении от православия в магометанство крещённой из татар девки деревни Степной Шенталы Пелагеи, по отцу не известной» дип атала. Мөселман-татар хатыны Гөләйзага (аларча – Пелагеяга) каршы җинаять эше Биләрнең өлкән рухание Михаил Лавровның 1837 елның 18 ноябрендә Казан консисториясенә язган әләгеннән башлана.*

*Архив документларыннан күренгәнчә, Гөләйза-Пелагеяга каршы судлар 1838 елның февраленнән 1844 елның мартына кадәр дәвам итә. Ул шушы мәхкәмәләр юлында егылып үлгәннән соң, аның ата-анасын, балаларын, туганнарын, муллаларны хөкем итә башлыйлар, бу эшкә 1850 елда гына нокта куела.*

*Әсәрдәге вакыйгалар, тарихның үзендәге кебек, хәзерге Чистай районының Чирүле Шонталасы авылында, Гөләйзаның туган авылы Кыр Шонталасында (хәзерге Алексеевск районы), керәшен татарлары авылы Актауда (Чистай), Биләрдә (Спас районы), Чирүле Шонталасында (хәзер – Югары Татар Майнасы, Алексеевск районы), Чистайның үзендә һәм бу тирәдәге татар-мишәр авылларында бара. Әсәремнең төп каһарманы Гөләйза эзләре буйлап, мин аларның барысында да диярлек булдым, төбәкнең болгар-татар тарихы белән бәйле истәлекле урыннарын өйрәндем.*

*Шулай ук бу чорга караган бик күп тарихи чыганакларны барладым, урыс миссионерларының татарларны чукындыру турында том-том хезмәтләрен укып чыктым, алар арасында Лука Конашевич, Евфимий Малов, Аполлон Можаровский, Пётр Знаменский, Николай Ильминский хезмәтләрен аерып әйтер идем. Шулай ук А.Н.Григорьевның чукындыру турында инде совет чорында басылып чыккан хезмәтләре, 1936 елда Мәскәү-Ленинградта дөнья күргән «Аграрный вопрос и крестьянское движение 50-70 годов XIX в.» китабы бу тема буенча бик күп яңа мәгълүмат бирде. «Гөләйза» романын язганда, өстәл китабым булып Галим Хисамиевның «Гөләйза кыйссасы» фәнни-популяр хезмәте торды. Үзе дә Кыр Шонталасы авылыннан булган техник фәннәр галиме, төбәк тарихчысы Галим Хисамиев миңа бик күп ярдәм итте, аңа Алланың рәхмәтләре яусын! Шулай ук тарих фәннәре кандидаты, Кама аръягы татар авыллары тарихы буенча зур белгеч, Түбән Татар Майнасы урта мәктәбе директоры Рафик Насыйров та миңа күп мәгълүмат бирде, аңа да рәхмәтләрем чиксез! Казаннан татар галимнәре Ирек Һадиев һәм Раиф Мәрданов, әлеге четерекле темага алынуымны белүгә, миңа ярдәмгә килделәр, чукындыру буенча сирәк хезмәтләр белән таныштырдылар, юнәлеш бирделәр. Шулай ук тарихчы Радик Исхаковның «Миссионерство и мусульмане Волго-Камья» китабы да зур ярдәмче булды, бу кешеләрнең барысына да рәхмәтләремне әйтәм!*

*Шушы чорны өйрәнгәндә һәм бу әсәремне язганда, Гөләйза язмышының Гаяз Исхакыйның «Зөләйха»сына бик охшаш булуын да ачыкладым, моңа Галим Хисамиев та игътибар иткән. Гөләйза белән Зөләйха икесе дә бер төбәктән, авыллары янәшә генә, Гөләйза – Кыр Шонталасында, Зөләйха күршедәге Яуширмәдә туып-үскән. Икесе дә бер чорда яшәгәннәр, икесенең дә язмышлары уртак, хәтта ике авыл арасындагы «Керәшен зираты» да уртак!*

## БЕРЕНЧЕ КИТАП

### «Гөләйзаны алырга килделәр!»

«Гөләйзаны алырга килгәннәр икән! Иртәгә Чистайда суд буласы, ди. Балаларын да алып китәләр икән, анасын да монда китергәннәр. Барысын да чиркәүгә алып барып чукындырасылар, ди...»

Бу куркыныч хәбәр авылда тиз таралып өлгерде, бигрәк тә чукындырылган татарларның эчләренә шом төште. Дөрес, аларның күбесе поп кенәгәләрендә генә керәшен дип язылган, ә чынлыкта мөселманча яшәп яталар – намазын укыйлар, уразасын тоталар, чиркәүгә йөрмиләр, тәре такмыйлар, икона-такталарын өйгә кертмиләр. Моңа кадәр Кызылъяр побы да, Актаунықы да аларга әллә ни бәйләнмәде, Кызылъяр урысына бу татарлардан акча гына кирәк иде, ә Актаунықы – шушы як кешесе, элек-электән керәшен татары, күп нәрсәне күрмәмешкә салышты. Соңгы вакытта Кызылъярда поп алышынган, диделәр, яшь кенә урысны куйганнар, эчәргә дә ярата ди, бәлки шул бу татарлар өстеннән әләк язгандыр, чиркәүгә йөрмиләр, балаларын чукындырмыйлар, мәетләрен җирләргә попны чакырмыйлар, дип тиешле урынга хәбәр иткәндер?

Авыл халкы нәрсә уйларга да белмәде, һәркем бу хәлләрнең үзенә дә килүеннән курыкты. Чөнки алар тарихында инде төрлесе булды – әби-бабаларын, бозлы суларга куып кертеп, үлем куркынычы астында көчләп чукындырулар да, яңадан исламга кайткан өчен тереләй яндырып үтерүләр дә... Әби патша заманында бу мәхшәр туктатылып, бераз дин ирегe дә килде. Шуннан файдаланып, керәшен татарлары авыллары-авыллары белән яңадан исламга кайта башладылар, инде рәсми рәвештә дә христиан диненнән, поп кенәгәләреннән чыгу өчен яңа патшалар исеменә меңәрләгән прошение-үтенечләр язылды... Моны күреп, чиркәү әһелләре дә кубарылды, алар исламга кайтырга теләгән керәшен татарлары каршына кыя булып бастылар, яңа патшаны да бу мәкруһларга каршы бордылар. Әйе, аларны мәкруһлар дип йөртәләр, ягъни, поп кенәгәләрендә христиан булып теркәлеп тә, ислам динен тоткан татарлар, рәсми кәгазьләрдә «отпавшие» дип язылган кешеләр... Менә хәзер аларга да чират җитте ахры...

Югыйсә, заманында Болгар-Биләр олылары, Кырым ханы Гәрәйнең оныкчыгы Морат морзалар нигез салган затлы, тарихлы, динле авыл иде бит ул – Чирүле Шонталасы! Хәтта патша заманында да алардан бүләккә җирләр алган, үз динендә калган, уникe баласы тирә-юньдәге уникe авылга нигез салган затлы Морат морза нәселе бит ул! Яуширмә һәм Мөслим, Талкыш һәм Әдәмсу, Нарат-Елга һәм Урман асты Шонталасы, тагы дистәләгән татар авылларына тарала бу нәсел. Моның өстенә Чирүле Шонталасында Мортаза морза Янгилде, Нүркәй морза Сюнәй, Морат морза Кадрәк, Акай морза Дәүләткилде, Сәит морза Килдеш, Әсәнали морза Аганиннар да яшәгән бит, бу хәлләр дә бик күптән булган, ул нәселләр дә инде таралып беткән. Әйе, патшалар үзгәрә, илдәге вазгыять үзгәрә, элеккеге хезмәтләр онытыла, мишәр-татар морзаларын да көчләп чукындыру турында яңа фәрманнар чыга. Ул арада Кадермәт улы Морат мулла да үлеп китә, борынгы Биләр төбәгендә яңа чукындыру, чукынмаганнарны юк итү фаҗигасе башлана. Морат мулла нәселе, алар яшәгән зур-зур мишәр-татар авыллары шушы афәт чоңгылына чумалар...

Чирүле Шонталасы авылында, бу керәшеннәрдән тыш, мөселман татарлар да яши, авылның бер башына урысларны да китереп тутырдылар, алар урыс алпавытларының кол-крепостнойлары булып исәпләнә. Заманында мишәр

морзалары нигез салган затлы Шонтала, зиратында Морат мулла яткан дини татар авылы, менә шулай кулдан-кулга китте, урыска, мөселман-татарга, керәшенгә бүленде. Аларның зиратлары да, тормышлары да аерым иде. Әмма авыл халкын сөендергәне шул булды: урыслар яшәсә дә, Шонталада чиркәү салмадылар, ә мәчет һәрзаман булды. Теге заманда патша хакимияте җимергәннәре урынына халык яңасын салды, ул да юкка чыккач, башкасын торгызды. Әле дә Чирүле Шонталасында мәчет эшләп тора, авылның указлы мулласы, мөәзине бар. Алар да керәшен татарларының мәчеткә намазга йөрүенә сүз әйтмиләр, балалары туса, мөселманча исем кушалар, яшьләргә яшереп никах укыйлар, үлгән мәкруһларны, поп килгәнче, тизрәк мөселманча җирләп тә куялар. Югыйсә, бу эшләре беленә калса, аларның үзләрен дә төрмә, Себер көтә бит!

Гөләйзаның балаларына да Әхмәт мулла үзе мөселманча исем кушты, аларны мәчет кенәгәсенә теркәде, олысына – Габделвахит дип, яңа туганына Габделҗәббар дип исем бирде. Хәер, Гөләйзаның никахлы ире Габделхәким мөселман кешесе бит, аның балалары да мөселман буларак теркәлергә хаклы, дип уйлады ул. Ә менә урыс түрәләре алай уйламый икән, әнә, атларга төялеп, шул бичара хатынны һәм балаларын алырга килгәннәр, болай булса, Әхмәт мулланың үзенә дә чират җитәргә мөмкин, чөнки аларга никахны ул укыды, балаларына мөселманча ул исем кушты... Кышкы көн дип тормаганнар, әнә, Чистайдан полицае да, приставы да төялеп килеп җиткән. Икенче ат чанасыннан Гөләйзаның анасы Гөлзада төште, дилбегәне Ишмөхәммәт тоткан иде. Алар моннан ун-унбиш чакрымнар булган Кыр Шонталасыннан килгәннәр, анда да, монда да Ишмөхәммәт һәм Гөлзаданың никахлы ир белән хатын икәнен яхшы беләләр, әмма поп кенәгәләрендә, рәсми кәгазьләрдә алар аерым теркәлгән, шуңа күрә хөкүмәт кешеләреннән ирле-хатынлы икәнлекләрен яшерәләр. Югыйсә шушы Ишмөхәммәттән Гөлзада биш бала тапты, уллары Бикмөхәммәтне аңа тәрбиягә биргән итеп яздырырга мәҗбүр булды, керәшенлектән качу өчен, калган балаларын да төрлечә яшерде, ә менә барыбер эзгә төштеләр, Гөләйзасы артыннан килеп җиткәннәр...

Гөләйзаның ире Хәким ишегалдында кар көрәп йөри иде, капка төбендә ят тавышлар ишетеп, ул, кулындагы көрәген дә куеп тормыйча, урамга ашыкты. Аңа таба абыйсы Абуталип килә иде, ул шушы авылда хуҗа булып тора, өяз түрәләре тарафыннан йөзбашы итеп билгеләнгән. Чистайдан килүчеләр дә иң башта аңа мөрәҗәгать иттеләр, ул аларның барысын да җыеп, энеләре өенә алып килде. Алып килми кая барасың – кулларында мөһерле кәгазь, мәхкәмәгә, диелгән! Моның шулайрак бетәсен Абуталип үзе дә сизенеп йөри иде инде, энесенә дә әйтә килде, керәшеннәргә тагы закон катыланды, итәк-җиңнәрегезне җыеп йөрегез, диде. Ул Гөләйзаның Кыр Шонталасыннан килгән керәшен кызы икәнлеген белә иде, әмма әти-әнисе, үзе дә диндә-намазда булгач, керәшен дип кире бора алмады, энесенең аңа өйләнүенә каршы килмәде. Әхмәт мулла аларга качырып кына никах укыды, балаларына мөселманча исем кушты, шулай итеп, керәшенлектән котылдык, дип уйладылар. Юк икән шул, юк икән, бабайлар әйтмешли, кара сакалың, кая барсаң да, артыңнан ияреп йөри икән!

– Гөләйза киленне алырга килгәннәр! – диде ул, энесенә иелә төшеп. – Биләр побы Казанга жалу язган, балаларын чукындырмады, дигән… Иртәгә Чистайда суд буласы икән, үзен дә, балаларын да шунда алып килергә кушканнар. Кодагыйны да чакыртканнар...

Бу сүзләрне ишеткәч, Хәкимнең кулындагы көрәге төшеп китә язды, ул

бер абыйсына, бер капка төбендә торган җигүле атларга карады. Ул арада хатынының ата-анасы да алар янына килеп туктады, алар да бу куркыныч хәбәрдән телсез-аңсыз калган иде.

– Бар, син Гөләйза янына керә тор, әзерләнсен, – дип, Ишмөхәммәт хатынын өйгә кертеп җибәрде.

Елаудан бите-күзе шешенеп беткән Гөлзада, тун чабуларына абынып, капкага таба атлады, ирләр шунда басып калды. Гөлзада өйгә килеп кергәндә, кызы Гөләйза баласын имезеп утыра иде. Әнисен күргәч, ул урыныннан ук сикереп торды, шатланып, аңа каршы атлады. Әнисенең әле яңа туган оныгын күргәне юк иде, бәби ашы китергәннәрдер, дип уйлады.

– Әти белән килдеңме, әни? Әллә сеңелләрем дә килдеме?

Гөләйза, әнисе аша үрелеп, ишеккә карады, әмма анда берәү дә күренмәде. Ул хәзер генә әнисенең елудан шешенеп беткән йөзенә игътабар итте, куркып китте.

– Әллә берәр нәрсә булдымы, әни? Әллә ...берәрсе... үлдеме?

– Юк, кызым, барыбыз да исән-сау, Аллага шөкер! Әйе, әтиең белән килдек...

Гөлзада башкасын әйтә алмады, кызын кочаклады да тагы елап җибәрде.

– Мин бу хәлләрне инде беткәндер, дип уйлаган идем бит, кызым! Инде минем күргәннәрем дә җиткән, син боларны күрмәссең, дигән идем... Юк икән, юк... Ничекләр түзәрсең, балам-бәгърем!

Әнисенең бу сүзләреннән Гөләйзаның эченә шом төште. Ул кулындагы баласын бишеккә алып барып салды, аяк астында уралып йөргән улын күтәреп сәкегә утыртты.

– Нәрсә булды, әни? Минем тормышым түзмәслек түгел, Аллага шөкер!

– Безнең өстән язганнар, кызым! Керәшенлекне казып чыгарганнар... Мин бу хәлләрне бетте дип уйлаган идем бит инде! Сине мөселман кешесенә кияүгә биргәч, эзне яшердек, эзләмәсләр, төпченмәсләр, дип уйлаган идек... Тапканнар, язганнар, сине эзләп, әнә, Чистайдан урядниклар килеп җитте, иртәгә икебезне дә анда хөкемгә алып китәләр, балаларны да алырга кушканнар... Аларны чиркәүгә алып барып чукындырасылар, ди...

Гөләйзаның аяк астында идән селкенеп куйды, ул, чайкалып, улы янына сәкегә барып утырды.

– Син нәрсә сөйлисең, әни? Нинди керәшен, нинди чукындыру? Без бит мөселманнар, син үзең мине туганнан бирле ислам динендә тәрбияләдең, намазга өйрәттең!

– Әйе, кызым, без, әлхәмдүлиллаһ, мөселманнар... Әмма теге вакытларда минем ата-анамны көчләп чукындырдылар, безне христиан, дип, поп кенәгәләренә яздылар... Аллаһ шаһит – без беркайчан да урыс динен тотмадык, үз динебездә калдык, шуның өчен әби-бабаңны кара урыс мунчасында төтенгә тончыктырып үтерделәр... Инде безнең нәсел күрәсен күргән иде бит, инде дөньялар үзгәрде, бу хәлләр яңадан кабатланмас, дип уйлаган идек... Инде сине эзләп килгәннәр, балам! Чөнки поп кенәгәләрендә мин чукындырылган, дип язылгач, миннән туган балалар да шулай дип теркәлеп куела икән... Кичер, балам, нәселебездәге бу кара тап сиңа да килеп иреште... Балама ярдәм ит, и Раббым!

Бу сүзләрдән Гөләйза башта тораташ кебек катып калды, мәрмәрдәй йөзе тагы да агарды, аннан калтыранган куллары белән ул әнисен кочаклап алды, сулкылдап елый башлады.

– Әти нәрсә дип әйтә соң? Ул да бу хәлләрне белгән бит инде...

– Атаң юата ул, хәзер элекке заманнар түгел, судта мөселманлыгыбызны исбатларбыз, берни эшли алмаслар, ди... Шуңа күрә, юлга да үзе чыкты. Ул да бит инде мондый хәлләрне күп күрде, кызым, дин-ислам өчен бармаган җире, язмаган урыны калмады. Ул да шул поп кенәгәсеннән төшә алмый интегә, хөкүмәт өчен һаман керәшен исәпләнә. Шуңа күрә менә утыз елга якын инде ир белән хатын булып яшәвебезне хөкүмәт кешеләреннән яшерәбез, яшерен никах белән генә торабыз. Урыс дине ике хатын белән яшәүне тыя, ә атаң мине теге вакытта урыс авылыннан урлап алып кайтты бит...

Әйе, Гөләйзаның болар турында бераз ишеткәне бар иде, аталарының аерым гаилә белән яшәвен дә белә иде ул. Әмма Шонталада ике хатын белән яшәүче башка мөселманнар да бар иде, шуңа күрә, моңа гадәти нәрсә итеп карады. Гөләйзаның ата-анасы да, барлык туганнары да ислам динендә, күрше авылдагы чиркәүгә йөрмәделәр, муеннарына тавык тәпие асмадылар, сурәт ясалган такталарын өйгә кертмәделәр. Бәлки атасы сөйләшә белгәндер – Кызылъяр побы да, Актауныкы да аларга әллә ни бәйләнмәде, чиркәү өчен тиешле акчаларын алдылар да тынычлыкта калдырдылар. Әмма бу тынычлык вакытлыча гына булган икән, менә хәзер аларның да эзләренә төштеләр...

Хәер, Шонталада керәшен дип язылган барлык татарлар да диярлек нәкъ алар кебек яши, әле мөселманлыкта башкаларны да уздырып җибәрәләр иде. Муллалар да аларның мәчеткә йөрүенә сүз әйтмәде, әмма никахларны яшерен укыды, кеше үлсә, поп килеп җиткәнче, мөселманча җирләп куярга ашыгалар иде. Керәшеннәр өчен иң шомлы, иң куркыныч вакыт бала тугач һәм кеше үлгәч була, чөнки поп алдан килеп яки белеп өлгерсә, йолалар урыс динендә булачак, мулла өлгерсә – ислам динендә. Шуңа күрә кайбер авырлы хатыннар, бала табуларын поп белмәсен өчен, авылдан чыгып китәләр, айлар, хәтта еллар буе читтә йөриләр, аларның кайберләрен полиция белән эзләтеп табалар һәм балаларын чиркәүгә алып барып чукындыралар иде. Поп кенәгәсенә эләктең икән – беттең инде, рәсми рәвештә яңадан үз динеңә кайту закон белән тыелган, син аны кача-поса гына тота аласың. Үзеңне килеп тотканчы... Яки патшага үтенеч-прошениеләр язып кына, судлар аша яңадан үз динеңә кайтырга мөмкин, әмма мондый хәлнең әле булганы юк диярлек. Хәер, янәшәдәге Акъяр авылы татарлары патшаның үзенә барып җиткәннәр, дип сөйлиләр, алар поп кенәгәсендә керәшен дип язылган булсалар да, Казанга бу хәбәр китмәгән, консисториядә бу мәгълүмат бөтенләй юк икән. Имеш, Казан идарәсе Акъяр татарларын керәшен дип танымаган, имеш, аларга яңадан үз диннәрен тотарга рөхсәт биргәннәр икән...

Менә шуннан соң бөтен Чистай өязе, юк, бөтен Казан, Сембер губерналары татарлары күтәрелде, урыс диненнән чыгарга мөрәҗәгать гариза язылды, әмма инде хөкүмәт тә аңга килеп өлгергән иде, капкаларны тиз яптылар. Ул гына да түгел, чиркәү белән хакимият берләшеп, мәкруһлар өстенә ябырылдылар... Мескен Гөләйза да шул туфанның бер корбаны иде... Иртәгә аңа Чистайда суд булачак, пристав белән полицай аны алырга килгәннәр иде...

Әйе, пристав белән полицай бирегә үз эшләрен эшләргә килгәннәр иде. Алар мөһерле кәгазьне Хәкимгә күрсәттеләр. Хәким аны алып, әйләндергәләп карады, гарәпчә укый-яза белсә дә, бу урыс хәрефләрен танымый да, аңламый да иде. Ул, ярдәм көткәндәй, абыйсына текәлде, Абуталип, мөһерле кәгазьне кулына алып, тагы шул сүзләрне кабатлады:

– Шул инде... Гөләйза киленне Чистай судына алып килергә кушылган... Тик монда аның исеме Пелагея дип язылган, кодагый да Гөлзада түгел, Фекла

Тимофеева икән... Балаларны да үзләреннән калдырмаска кушылган... Чиркәүгә алып барып чукындырырга, диелгән.

– Нинди Пелагея булсын ул, Гөләйза, Гөләйза аның исеме! Ул беркайчан урыс исемен йөртмәде, урыс динендә булмады, мөселманнар без, барыбыз да мөселманнар! Балаларыбыз да мөселман! Аларның мулла кушкан исемнәре бар!

Чистайдан килгән урыслар Хәкимнең ни әйткәнен аңламасалар да, кызып-кызып сөйләвеннән аның ризасызлыгын белделәр. Бу татарлар белән алар инде төрлесен күрде, авылы-авылы белән җыйналып, казна кешеләрен кыйнап җибәргән чаклары да булды. Аннан соң үзләре дә авылы-авылы белән яткырып суктырылды, башбирмәсләре Себергә сөрелде, монастырьларга ябылды. Барысы да шул чукындырылган татарларның үз диннәрен тотулары аркасында килеп чыкты, поплар алар өстеннән туктаусыз язды, хөкүмәт бу татарларны бастырырга хәрбиләрне җибәреп торды. Ә алар һаман баш күтәрде, үз диннәренә теш-тырнаклары белән ябышты, аның өчен хәтта үлемгә дә бардылар. Әнә монда да әкренләп җыела башладылар, кара урман кебек халыкны күреп, йорт хуҗасы да батырая төште.

– Ул нинди закон – хатынны һәм балаларны иреннән, аталарыннан аерып, хөкемгә алып китә торган?! Аларның нинди гаепләре бар? Бирмим мин аларны сезгә! Җибәрмим беркая да! Сезне дә өйгә кертмим! Исән чакта китегез моннан!

Хәким шулай диде дә капкага аркылы басты, авыл ирләре дә, шаулашып, аны сырып алды. Чистай урыслары мондый ук хәлне көтмәгән иде, алар, ярдәм эзләгәндәй, Абуталипка карадылар, чөнки авылдагы тәртип өчен ул җавап бирә. Абуталип та башта аптырап калды, ул да энесеннән мондый ук каршылыкны көтмәгән иде. Икенче караганда, Хәким дә хаклы кебек – ничек инде яңа туган сабыеңны һәм яңа теле ачылган балаңны, бала имезгән хатыныңны шулар кулына бирергә мөмкин? Кышкы көндә, кичкә каршы, аларны ни намусың белән озын юлга чыгарып җибәрәсең? Анда нәрсә булыр? Чиркәүгә алып барып, барысын да чукындырырлармы, Гөләйзаны – никахлы иреннән, балаларны аталарыннан аерып алып, монастырьларга ябарлармы, кяферләр кулына бирерләрме? Моны сизенеп, халык та шаулашырга тотынды:

– Бирмибез беркемне дә!

– Бүген – Гөләйза, иртәгә безнең хатыннарны да алырга килерсезме?!

– Безнең хөкүмәт каршында бер гаебебез дә юк суд юлларында йөрерлек! Салымын түлибез, чирү хезмәтен башкарабыз, кая җибәрсәләр, шунда барабыз!

– Урманын да кисәбез, лашман булып та изеләбез, игенен дә игәбез, җирен дә эшкәртәбез – тагы нәрсә кирәк бездән?!

– Барысын да алдыгыз, таладыгыз, җирләребезгә урысларны китереп утырттыгыз, авылыбызны шулар белән тутырдыгыз, инде иманыбызны, хатын-кызларыбызны, балаларыбызны да алырга килдегезме?!

– Бирмибез беркемне дә! Динебезне дә бирмибез! Себер китсәк китәрбез, үлсәк үләрбез, әмма үз динебезне бирмибез!

Эшләрен җиңел генә башкарып чыгарга җыенган Чистай урыслары да шикләнә калдылар. Пристав әле җәй көне генә үзен Биләр тирәсендәге бер татар авылында кыйнап җибәрүләрен исенә төшерде, ирексездән, шинель кесәсендә яткан револьверын капшап куйды. Дөрес, аларга корал кулланырга рөхсәт итмиләр, әмма бу кыргый халык өере өстеңә килә башласа, башкача котылу юлы юк! Әзмәвер кебек зур гәүдәле, аю кебек көчле, тоткан җирләрендә сындыра торган мишәрләр

бит болар, чирүле-гаскәри татарлар! Әнә бит, йонлач бүрек асларыннан нинди нәфрәт, үч белән карап торалар, кодрәтләреннән килсә, хәзер ботарлап ташларлар иде! Биләр янындагы авылда шулай эшләделәр дә бит – христиан динен тотмаган һәм салымнарын түләмәгән өчен, андагы татарларның җирләрен, мал-мөлкәтен, атларын алырга килгәч, халык аларга каршы сәнәк күтәреп чыкты! Пүнәтәйләр шунда ук качып бетте, моңа кадәр гел татарларга каршы котыртып йөргән поп та каядыр тайды, бөтен тукмак приставка эләкте. Ул да бу хәлләр башлангач, атына утырып, авылдан чыгып качмакчы булган иде, артыннан куып җитеп, арбасыннан өстерәп төшереп кыйнадылар татарлар. Әле ничек үтермәделәр... Соңыннан үзләренә дә эләкте эләгүен – өяз үзәгеннән солдатлар килеп, бөтен авыллары белән яткырып суктырдылар, башлап йөрүчеләрен Себергә сөрделәр, каторгага катырып үтерергә җибәрделәр. Менә бу Чирүле Шонталасы авылы да Биләрдән кул сузымында гына, андагы хәлләр турында ишеткән булырлар, хөкүмәткә каршы китүнең дә ни белән бетәсен белергә тиешләр.

Пристав Ишмөхәммәтне үз янына чакырып алды, чөнки Кыр Шонталасында берниниди каршылык булмады, шушы кеше ярдәмендә, әнә бер карт хатынны судка алып бара, мондагысын алып китәргә дә ул ярдәм итәргә тиеш.

– Что будем делать, Измаил Ефремов? – дип, ул аңа чукындырылган христиан исеме белән эндәште. – Драться будем? Яман, очень плохо!

– Яман, әйе, очень плохо! Но драться не будем... Аллага тапшырдык инде...

– Тогда скажи своим – пусть угомонятся! Мы на государственной службе!

– Беләбез, артында шул государстваң булмаса, без сөйләшеп тә тормас идек сездәйләр белән, – дип, Ишмөхәммәт, сукрана-сукрана, авылдашлары янына юнәлде.

– Хәзер болар белән бәхәсләшеп торудан мәгънә юк, җәмәгать, – диде ул. Ишмөхәммәт барысы арасында да иң өлкәне, үз гомерендә мондый хәлләрне күп күргән, аның нәрсә белән бетәсен дә яхшы белә иде.

– Болай бармаса, канвай белән килеп, аяк-кулларга богау салып, мылтык астында ристан итеп алып китәчәкләр... Боларында коралы да, богавы да бар... Биләр тирәсендәге авылларны нишләткәннәрен дә онытмыйк – андагы татарларның яшәрлекләрен калдырмадылар, кайсы төрмәдә, кайсы монастырьда ята хәзер, кыйналып үлүчеләрне инде әйтеп тә тормыйм. Мин сезгә дә, үз гаиләмә дә андый афәт килүен теләмим. Шуңа күрә барырга кирәк Чистайга, мәхкәмәдә исбатларга кирәк үзебезнең хаклы икәнне...

Ишмөхәммәтнең бу сүзләреннән соң җыелган халык гөжләп алды, аннан әкренләп капкадан читкә киттеләр. Хәким бер абыйсына, бер бабасына карады. Авыл халкы «аһ»-«уһ» килеп таралды, бу хәл кешеләрне кайгыга салды, бер килеп, Гөләйзаны һәм балаларын жәлләсәләр, икенче яктан, үзләре өчен борчылдылар, чөнки чират аларга да җитәргә мөмкин... Тыныч-имин генә кышны чыгып барган авыл өстенә яңа афәт килде – тагы керәшеннәрне тикшерә башладылар. Моның шаукымы барысына да кагылырга мөмкин иде. Һәм ул шулай булды да...

Хәкимгә шикләнеп карый-карый, пристав белән полицай өйгә уздылар, Ишмөхәммәт белән Әбуталип та аларга иярде. Ир-атлар килеп кергәндә, Гөләйза өзгәләнеп елаган имчәк сабыен юата, икенчесе дә аяк астында шыңшып йөри, әнисе исә юлга кирәк-ярак әйберләрне төйни башлаган иде. Чит ир-атларны күргәч, алар шундук чаршау артына кереп киттеләр, пристав кулындагы кәгазен тагы Гөләйзаның иренә бирергә мәҗбүр булды. Аннан тагы сотник Әбуталип белән сөйләшеп алдылар.

– Гөләйза килен мәхкәмәгә бер баласы белән генә чакырылган, яңа туганын поп белмичә калгандыр, – диде Әбуталип, суд чакыруын кулында әйләндергәләп. – Хәзер пристав икесен дә алып барырга куша, күрде бит инде... Әзерләнергә бераз вакыт бирделәр, бүген кичтән ярты юлда булган Актауга кереп куначаклар икән, аннан попны да алачаклар... Шуңа күрә тизрәк кузгалырга ашыгалар. Хәзер алар урысларга барып, капкалап киләчәкләр, атларын ашатачаклар... Мин дә аларны озата барам, сез әзерләнә торыгыз, вакыт аз калды.

Әбуталип Чистай урыслары белән чыгып китте, өйдә үлем тынлыгы урнашты. Сүзне, эшне нәрсәдән башларга белмичә, башта барысы да телсез-өнсез калды, әйтерсең лә башларына сугып миңгерәтелгәннәр иде...

– Без күрәсен башкалар күрмәс, канәтләрем! – дип, башта Ишмөхәммәт аңга-телгә килде. – Димәк, тәкъдиребездә шулай язылган булган. Беләсез булыр, безнең әби-бабаларыбыз моннан яманрак хәлләрне дә күргәннәр, дин-ислам хакына бозлы суларга батып үлгәннәр, терелә утларда яндырылганнар... Бу Аллаһның безгә бер сынавы инде, аңа сабыр итәргә кирәк, газизләрем! Һәм иманны саклап калу өчен көрәшергә! Кайгырма, кызым, Аллаһ аларга бу яманлыкларын ирекле кылмас! Судларыннан да курыкма, синең яныңда без – атаң-анаң булырбыз... Син, Хәким кияү, өйдә калырсың, мин Гөлзаданы да, Гөләйзаны да, туруннарны-оныкларны да үзем алып барырмын Чистайга. Ә хәзер, әйдәгез, юлга чыгар алдыннан намазыбызны укып алыйк, Аллаһ безгә исән-имин яңадан монда әйләнеп кайтырга насыйп итсен, шуны сорыйк!

Азан әйтеп, камәт төшерделәр, ирләр – алга, хатын-кызлар алар артына басып, бергәләп намаз укыдылар. Гомер буе, үзләрен белгәннән бирле шулай – поплар күпме генә котырсалар да, урыс үрядникләре күпме генә куркытсалар да, бу татарлар намазда булды, үз динен бирмәде, аларныкын алмады. Менә хәзер дә шулай... Өсләрендә палач балтасы эленеп тора, мәхкәмә карары белән, иртәгә аларның төрлесен-төрле якка аерып ташларга мөмкиннәр, бәлки алда төрмәләр һәм монастырьлар көтәдер – ә алар намаз укый... Югыйсә, шушы дәрәҗәдә кыйналмас һәм кагылмас өчен, исән калыр өчен бу татарларның бер гамәле җитә – исламнан, иманнан баш тарту. Үз ирегең белән муенга тәре асу, алар кылынганны кылану, алар кебек булу. Әмма бу гамәлнең бөтен нәселеңне, хәтта ки туачак балаларыңны да кяферлеккә һәм көферлеккә, мәңгелек җәһәннәмгә дучар итү булачагын бу татарлар яхшы аңлый... Шуңа күрә дин сәбәпле нинди генә газаплар күрсәләр дә, иман аларга барысыннан да, хәтта гомерләреннән дә кадерле... Шуңа күрә кара урманнар, кар көртләре арасында күмелеп калган бер татар авылында, кыйблага карап торган бер татар өендә, меңьеллык ислам тарихы булган борынгы Биләр төбәгендә мөселман-мишәрләр тезләнеп намаз укый... Дәүләтен югалткан, кяфер тарафыннан җиңелгән, урыслардан күргән җәбер-газаплары сәбәпле, җир йөзендә үк терелә сират күпере кичкән бәхетсез милләтнең ятим балалары һәр намазларын соңгы намаз, дип укыйлар... Чөнки иртәгә алар белән ни була, тагы нинди бәла-казалар, кимсетүләр көтеп тора – бу мәкруһ татарлар белми... Бәлки белмәүләре белән бәхетлеләрдер дә... Аларның бөтен өметләре һәм ышанычлары – Аллаһка, бөтен көткәннәре – Аллаһтан, бөтен таянычлары – бары тик Аллаһ!

Әнә Гөләйза да, сәҗдәләргә китеп, елый-елый дога кыла... Бәлки ул бу йортка яңадан әйләнеп тә кайта алмас, бәлки ирен, балаларын, ата-анасын да яңадан күрә алмас, бәлки язмышы аны чит-ят җирләргә, чит-ят кешеләр арасына илтеп ташлар... Әти-әнисе, әби-бабалары да шушы газаплы юлны

үткән бит, әмма барыбер иманда калганнар, кяфергә әйләнмәгәннәр, үз диннәрен бирмәгәннәр. И Раббым, елый-елый дога кылган бу яшь хатынга да Син аларның сабырлыгын һәм тәкъвалыгын бир, аңа терәк бул, ярдәмеңнән ташлама! И Раббым, бу хатынның иманын һәм гомерен кяферләргә иреклә кылма, аңа бу дөньяларда мөселман хәлендә яшәп, синең каршыңа да мөэмин-мөселман булып килеп басарга насыйп ит! Аның нәселен көферлектән сакла!

Моңа кадәр гел әнисенең намазлыгында аунарга яраткан Габделвахит та бүген нигәдер тынып калган, бала да, алда нindидер шомлы үзгәреш буласын сизенгәндәй, моңсуланып киткән. Аңа бит әле нибары өч кенә яшь, ә бишектә ятканына исә өч ай да юк, ә аларның язмышларын инде Казан һәм Биләр чиркәүләрендә хәл итеп куйганнар... Имеш, чукындырылган хатыннан тугач, балалары да чукындырылырга, христиан динендә булырга тиеш икән! Менә хәзер аларны да киендереп, кышкы юлга алып чыгып китәчәкләр, ә анда инде аларның язмышын бары тик бер Аллаһ кына белә...

Намазларны укып бетергәч, сәкегә ашъяулык җәеп, ашарга утырдылар. Гөлзада аш салып җибәргән иде, үзе белән Кыр Шонталасыннан алып килгән итен-маен, камыр ризыкларын да табынга куйды. Гөләйза белән иртәгә юлга да ризыклар әзерләделәр.

– Әллә кечкенәсен үзебез белән алмыйбызмы соң? – диде Ишмөхәммәт, бишектә изрәп йоклап яткан оныгына карап. – Ул бит пристав кәгазендә язылмаган, анда олысы гына бар... Мондый кышкы озын юлга яңа туган сабыйны алып чыгып китү дөрес булмас, әле анда да ни белән бетәсен белмибез... Үз кулыбыз белән китереп тоттырган кебек килеп чыга бит...

– Миннән торса, икесен дә җибәрмәс идем, Гөләйзаны да капкадан чыгармас идем, бабай! Үзегез шулай хәл иттегез бит абый белән... Ичмасам, алдан да сизенмәдек, качырып та өлгерә алмадык... Берәр авылга илтеп куйган булсак, таба да алмаслар иде, эзләп тә тормаслар иде... Алдан сиземләп өлгермәдем, алдан!

– Мондый хәлләрнең шактыйдан булганы юк иде шул, кияү! Без дә артык тынычланып киткәнбез, кемлегебезне онытып җибәргәнбез... Менә хәзер искә төшерделәр... Күрше авылларда да керәшен мәкруһларына каты тотынганнар, дип ишеттем, Кызылъярда поп алышынган, барыбыз өстеннән дә Биләрдәге атакаена язып биргән, ди. Ә анысы Казанга жалу җибәргән, Казанның карары каты – барысын да чиркәүгә! Суд аша! Юк икән – төрмәгә. Монда хәзер безгә бер генә юл кала – Чистайга барып, мәхкәмә каршында үзебезнең хаклыкны раслау, мөселманлыгыбызны исбатлау. Бармый калсак, богау кидереп алып китәчәкләр, барыбер алып китәчәкләр.

– Имчәк баланы ничек анасыннан аерып калдырасың? – дип, сүзгә Гөлзада да кушылды. – Берничә көнгә китәбез бит, бәлки әле күбрәккә дә булыр, Аллаһ белә... Яхшылап төрербез, толып эчендә генә тотарбыз, туңдырмабыз, мин дә шунда булам бит әле... Инде суыклар да бераз сындырды, көннәр дә язга таба авышты...

Шулай килештеләр – ике баланы да алырга, юлга җылы киемнәрдән тыш ризык та салырга, чөнки кайда, кемнәрдә туктыйсылары билгесез. Ишмөхәммәтнең әле моннан кала да әйтәсе җитди сүзләре бар иде, приставлар килгәнче, ул шуларны сөйләргә ашыкты.

– Син, кызым, судта анаң белән бер сүздә бул – атамны белмим, дип бар, чөнки алар безнең никахны танымый, законсыз дип таба. Хәким кияү белән никах укытканыгызны да әйтмә, чөнки моның бәласе аңа да, сезгә никах укыган

Әхмәт муллага да булачак, хәзер моның өчен Себер җибәрәләр. Никахсыз яшибез, диген, кяферне шулай алдаларга да була, гөнаһ түгел. «Әни мине кияүгә бирер алдыннан Кызылъяр побына барып әйтте, ул минем исемне кенәгәсеннән тапмады, мөселман кешесенә кияүгә чыгарга рөхсәт бирде», диген. Бу бик мөһим. Моны оныта күрмә! Балаларыңа мулла исем кушканны әйтә аласың, чөнки аларның аталары мөселман кешесе, шулай булырга тиеш тә. Әниеңнең Фекла икәнен дә әйтә аласың, чөнки ул шулай теркәлгән инде, аны яшереп булмый. Үзеңнең туганнан бирле ислам динендә тәрбияләнүеңне, урысның динен дә, телен дә белмәвеңне әйт. «Беркайчан чиркәүдә булмадым, миннән моны таләп тә итмәделәр», диген.

– Ул чыннан да шулай бит инде, әти, – дип җавап бирде Гөләйза. – Әни мине исламда тәрбияләде, син поплар һөҗүменнән аралап тордың, сезгә Аллаһның рәхмәтләре булсын! Мине мөселман кешесенә кияүгә бирдегез, балаларыбыз да мөселман, әлхәмдүлиллаһ! Иремә дә Аллаһның рәхмәтләре булсын – керәшен, дип какмады, үзе белгәнне өйрәтте, тормышымда бер авырлык та күрсәтмәде... Аллаһтан шуны гына сорыйм – иманымнан, ирегемнән, иремнән, балаларымнан аермасын иде, исән-имин шушы куышыма әйләнеп кайтырга насыйп булсын иде!

Гөләйза шулай диде дә, әнисенең күкрәгенә йөзен яшереп, елап җибәрде, аңа Габделвахит та кушылды, бишектәге сабый да уянып, сулкылдый башлады. Әйтерсең, бөтен өй эче аерылу сагышын тоеп әрни, өзгәләнә иде. Бу хәлне күреп, Хәким түзмәде, кискен бер карарга килде:

– Юк, бабай, мин үзем барам Чистайга гаиләм белән! Мин аларны болай чыгарып җибәрә алмыйм! Бәлки без соңгы тапкыр күрешәбездер... Юк, үзем барам! Өйне күршеләр карап торыр, әзи дә килгәләр.

– Сиңа анда күренеп йөрү дөрес булырмы соң, кияү? Алар хәзер кемгә килеп ябышырга, татарларның күпләп исламга кайтуына кемне гаепләргә белмиләр. Сине дә керәшен кызын юлдан яздырган, үз диненә керткән, дип гаепләргә, хәтта тотып утыртып куярга мөмкиннәр. Юк, күренеп йөрмә син анда!

– Соң, бабай, ике сабый бала белән ничек ялгызын чыгарып җибәрим мин аны кышкы юлга? Ни булса да, янында булырмын, ни күрсәк тә, бергә күрербез...

– Анда мин дә бар бит әле, кияү, минә, әбиең дә бар... Минем Чистайда да, Актауда да таныш-белешләрем шактый, үз баламны һәм оныкларымны якларлык кына җаен табармын, Алла теләсә!

Аларның бу бәхәсенә урамнан кергән Әбуталип чик куйды. Хәким аңа үзенең дә Чистайга барырга җыенуын әйтә генә башлады, абыйсы аны шунда ук бүлдерде.

– Юк, энем, монда эшләр без уйлаганнан да начаррак әле, – диде ул, борчулы тавыш белән. – Сине авылдан чыгармаска куштылар, шул хакта миннән кул куйдырдылар. Син дә хәзер шикле кеше саналасың икән, әле үзеңә дә эш ачып куюлары бар, Аллам сакласын! Әхмәт мулланы да бик сораштылар, аларга никах укыганмы, юкмы, дип тәфтишләделәр. Балаларыгызның икесен дә алып барырга куштылар. Алар хәзер килеп җитә, әзерләнә торыгыз.

Хәзер инде барысы да эшнең ни дәрәҗәдә җитди һәм куркыныч икәнен аңладылар. Әйе, кәгазьдә генә керәшен булып, ә чынлыкта мөселманлыкта йөргән вакытлар үтеп бара, патша хөкүмәте бу мәкруһларга ныклап тотынган иде. Һәм аның беренче ядрәсе ерак бер мишәр авылында яшәп яткан татар хатынына – Гөләйза язмышына килеп бәрелде... Биләр атакаеның әләге белән,

Казан чиркәү суды кушуы буенча, хәзер урыс хәрбиләре бу мөселман хатынын сабый балалары белән Чистайга алып китәчәкләр... Аны ислам диненә кире кайтканы, балаларын чукындырмаганы өчен хөкем итәргә җыеналар. Бу бичара хатынга Аллаһы Тәгалә ярдәмче, фәрештәләр юлдаш булсын иде...

Бу хәлләр 1838 елның февраль азагында, Казан губернасының Чистай өязендә бара...

## Керәшен авылы Актауда

Актауга алар эңгер-меңгер вакытта килеп җиттеләр, приставлар аты артыннан авыл уртасындагы зур чиркәү янына килеп туктадылар. Чиркәү каланчасыннан тирә-юньгә чаң тавышы яңгырый, әйтерсең лә ул татарлар өстеннән каһкаһә белән көлә, тантана итә иде. Бала чагы урыс авылында үткән Гөлзада бу тавыштан куырылып килде, ата-анасын һәм үзен җирле халыкның чиркәүгә өстерәп алып барганын исенә төшерде. Анда кермәс өчен җан тартыштылар, чиркәүдә таш идәнгә тезләндереп тоталар иде, ә алар барыбер башкалар кебек чукынмады, эчләреннән генә Коръән укыды, дога кылды...

Әнә хәзер дә бөтен авыл өстендә чиркәү чаңы шашынып бии, тагы кемнәрнеңдер башына ашкына... Бу шомлы тавыштан балалар куркынып уянды һәм елый башлады, Гөләйза да, коты чыгып, шул якка борылып карады. Гомерендә чиркәүгә кергәне булмаса да, әнисе сөйләве буенча, аның нәрсә икәнен белә иде, ул иманнан, телеңнән һәм динеңнән язу урыны икән. Нигә аларны монда китерделәр соң, әллә, Ходаем, хәзер үк шунда алып кереп, берәр нәрсә эшләтергә җыеналармы?! Юк, юк, атасы моңа бармас, Гөләйзаны алай алдамас, оныкларын күрәләтә харап итмәс! Кызының борчылганын күреп, Ишмөхәммәт аны тынычландырырга ашыкты.

– Курыкма, кызым, монда кермибез без, Якуб атакайны күреп сөйләшерләр дә, кунарга китәрбез.

Алар белән килгән урыслар ишек төбендә үк чукына-чукына чиркәүгә кереп киттеләр, анда бераз булгач, Якуб атакайлары белән бергә кире чыктылар. Атакай дигәннәре шушы авылда поп икән, аны Ишмөхәммәт тә, Гөлзада да яхшы беләләр. Биредә аны Яков Алякринский дип йөртәләр, әмма шонталалылар өчен ул – Якуб инде. Бу Актау авылында яшәүчеләрнең күпчелеге – теге заманнарда ук Кыр Шонталасыннан күчерелгән иске керәшеннәр, ягъни, чукындырылган татарлар. Әле бу Әби патшага кадәр үк булган хәлләр, халыкны Поп елгасына куып кертеп, мәҗбүри чукындырганнан соң, Шонталадан башка авылларга күчереп утырта башладылар. Якубларның ата-аналары да Актауга шулай итеп килеп эләкте, аннан бирегә урысларны да китереп утырттылар, зур чиркәү салып куйдылар, татарларга борылырга да урын калдырмадылар. Урыс арасында, чиркәүле авылда яшәү, җитмәсә, өяз үзәгенең дә ерак булмавы, гел попларның күзәтүе астында торулары сәбәпле, Актау керәшеннәре яңадан исламга кайта алмады, чукынган килеш калды. Якуб та шушы авылда туып-үскән, Зөядә чиркәү мәктәбе бетергән, татарчасын да, урысчасын да камил белгән бер керәшен татары иде. Хәер, бу авылда барлык керәшеннәр дә татарча сөйләшә, динне бирсәләр дә, алар телне бирмәгәннәр иде...

Ишмөхәммәт белән дә Якуб татарча килеп күреште, алар бер-берләрен электән үк беләләр икән. Сөйләшүне тирәнгә җибәрмичә, башта кемнең кайда кунасын ачыкладылар, чөнки пристав белән полицайга да кайдадыр

тукталырга кирәк иде. Ул арада алар янына авылның старостасы да килеп җитте, ул урыс кешесе икән, киңәш-табыш иткәч, казна кешеләрен ул үзләренә алып кайтып китте. Иртәгә таң белән кузгалырга, дип килештеләр, чөнки Чистайга мәхкәмәгә вакытында барып җитәргә кирәк иде. Якуб атакай да анда барачак, ул судта тылмач булачак икән. Ул Ишмөхәммәт белән Гөлзаданың ирле-хатынлы икәнлеген, Гөләйзаның аларның кызы булуын яхшы белә, әмма моны башкаларга сиздерми иде.

– Син хатының белән кызыңны Василийларга илтеп куй, Афанасьевларга, үзең миндә кунарсың, сөйләшәсе-киңәшәсе нәрсәләр бар, – диде ул Ишмөхәммәткә. – Мин Бәчилгә әйткән идем, алар белә.

– Бәчил-Василларгамы? Беләм мин аларны, яхшы кешеләр, әбиләре безнең авылдан иде бит! Алайса мин хатын-кызларны урнаштырыйм, аннан сиңа кайтырмын.

Ишмөхәммәт, атын борып, икенче урамга кереп китте, аннан Бәчилләр капка төбенә килеп туктады. Тун-толыпларына кунган карны каккалап, өйгә үттеләр, аннан бала-чаганың чыр-чуы, татарча сөйләшкән тавышлар ишетелде. Гөләйзаның күңеленә бераз җылы кереп китте, чит-ят җирдә шушы татарча сөйләшү дә аңа батып барганда тотынырга бер терәк булып тоелды. Җылы өйгә керүгә, балаларны тун-толып эчләреннән чыгардылар, аптырап басып торган Габделвахитны шунда ук балалар сырып алды, аны төрле яклап үзләренә тарткалый башладылар. Габделвахит яшьләрендәге сары чәчле бер кызчык аны кочаклап ук алды, шатланып, «минеке, минеке!», дип өй яңгыратып кычкырып җибәрде.

– Чүгегез, балалар, юлчылар чишенсен, урнашсын, кунак малай белән дә уйнап өлгерерсез әле, тарткаламагыз, Мәрьям кызым, син дә азаплама аны, – дип, Гөләйза яшьләрендәге бер татар хатыны юлчыларны каршы алды. – Түрдән узыгыз, авылдашлар, читенсенмәгез, үз өегездәге кебек булыгыз.

– Мин аларны биредә төн кунарга калдырам, Нәчтүк сеңлем, ә үзем Якуб атакайларга китәм. Бәчил энекәш кайда соң әле?

– Абзар тирәсендә йөри иде, хәзер кереп җитәр.

Ул арада ишектә хуҗа үзе дә күренде, ул утыз-утыз биш яшьләрдәге, зур, таза гәүдәле бер татар иде. Ул да ачык күңел белән гөрләтеп күреште, әйтерсең лә иң кадерле кунаклары килгән!

– Сез, хатын-кызлар, иркенләп урнашыгыз, мин дә Ишук әзи белән Якуб атакайларга барып киләм, – диде ул. – Син, Нәчтүк, канәтем, кунакларны яхшы кара, мин соң гына кайтырмын.

Ирләр чыгып китте, хатын-кызлар өйдә үзләре генә калдылар. Гөләйза беренче эш итеп иркенләп сабыен имезергә тотынды, ул йотлыга-йотлыга әнисенең күкрәгенә капланды, әйтерсең лә көне буе ач торган! Гөлзада кышкы авыр киемнәрне ишек төбендәге чөйгә алып барып элде, Нәчтүк-Настя исә аларның дымлы итекләрен киптерергә җылы мичкә тезәп куйды. Габделвахит башта бераз ятсынып торса да, кайда икәнен дә онытып, балалар белән тәгәрәп уйный башлаган, әйтерсең лә монда гомер буе яшәгән! Тагы ун елдан бирегә килеп яши башлыйсын бу бала гына түгел, әле беркем дә белми иде шул...

Гөләйза да бераз тынычланып, сабыен янәшәдәге мамык мендәр өстенә салды, өй эченә күз ташлады. Һәм карашы почмактагы икона-тактага килеп төртелде, аннан бала тоткан хатын-кыз карап тора иде. Мондый такталар Кыр Шонталасы авылында да бар, әмма чукындырылган татарлар аларны өйгә кертмәделәр, чоланда яки берәр алачыкта гына тоттылар. Бөтенләй дә

утка ягырлар иде – Кызылъяр побы килеп тикшереп йөри, ул авыл башында күренүгә, бу такталар почмакка менеп кунаклый, ул китүгә, тагын сарайга чыгарып ташлыйлар. Гөләйзаларда да кайдадыр ауный иде ул такта, әмма әнисе аны беркайчан да өйгә кертмәде, ә монда, әнә, түрдә кукраеп утыра! Як-ягында шәмнәр янып тора, шул сәбәпле, тактадагы хатынның йөзе да, кулындагы баласы да ачык күренә...

Гөләйзаның почмактагы иконага шомланып карап торуын күргәч, хуҗабикә аны юатырга ашыкты.

– Изге Мәрьям Ана ул, Алла улы Гайсә пәйгамбәр белән... Аның турында Коръәндә дә бар икән.

– Әстәгъфируллаһ, сеңлем, Гайсә галәйһиссәлам нишләп Аллаһ улы булсын!

– Әби дә моны кире кага иде, әмма монда поплар башкача сөйли шул, түткәй! Аны коткаручыбыз, Аллабыз, дип өйрәтәләр...

Өй эчендә кинәт салкын, шыксыз булып китте, әмма бер кичкә кергән җирендә әйткәләшеп утырып та булмый иде. Моны хуҗабикә дә, юлчылар да яхшы аңлады, алай да Гөлзада, олы кеше буларак, әйтергә кирәк тапты.

– Гайсә галәйһиссәлам зур пәйгамбәр, сеңлем, әмма Алла түгел, ялгыша күрмә! Ул да ислам динендә булган, бер Аллага табынган, кыямәт көне алдыннан да җиргә ул киләчәк һәм ислам динен урнаштырачак. Миңа боларны урыс кулыннан шәһит киткән ата-анам сөйләп калдырды, мин балаларыма шушыларны аңлаттым.

Нәчтүк кинәт моңсуланып китте, башын аска иде.

– Миңа да әби-бабаларым шушыларны сөйләп калдырды, түтекәй! – диде ул. – Мин аларны беләм, әмма монда башкача яшәп булмый... Йә, ярар, һәркемгә үз дине, дия иде әти-әни! Сез ерак юлдан килгән, ашым пешкән, чәем кайнаган, табынга утырыйк!

Шулай диде дә Нәчтүк, тиз генә сәке өстенә ашъяулык җәеп, табын әзерләде, аңа үсмер кызы йөгерә-йөгерә булышып йөрде. Гөләйза шуңа да игътибар итте – почмактагы тактадан кала, монда барысы да башка татар өйләрендәге кебек иде. Җылы бәреп торган акшарлы мич, нәкъ Шонталадагы кебек, ике якны бүлеп торган чәчәкле чаршаулар, тәрәзәләрдә – чиккән кашагалар һәм ап-ак пәрдәләр, ярты бүлмәне алып торган зур агач сәке, аның теге башына тау кебек өелгән мамык мендәрләр, түшәк-ястыклар... Нәкъ алардагы кебек – өстәлдә зур корсаклы җиз самавыр гөжләп утыра, агач савыт-сабалар, тәтәй чынаяк-чәшкеләр... Хуҗабикә дә кайсыдыр ягы белән Гөләйзаның үзенә охшаган – Биләр хатын-кызларына хас алтындай чәч, зур яшькелт-зәңгәр күзләр, озынча ак йөз, сылу-зифа гәүдә... Аның да өстендә Гөләйзаныкы кебек итәге бөрмәле озын күлмәк, башында яулык, әмма ул башкачарак бөркәнгән.

«Нәчтүк», дип әйтергә уңайсызланып, алар аның тулы исемен сорадылар.

– Чиркәүдә поп кушкан тулы исемем – Анастасия, – диде ул. – Ә әбием мин тууга Коръән укып, колагыма «Нәгыймә», дип кычкырган. Шулай итеп, ике исемле мин, хәтта – өч, чөнки керәшеннәр исемне кыскартып әйтәләр, Анастасия дә чиркәү кенәгәсендә генә калды, ә болай – Нәчтүк инде мин... Миңа Нәгыймә дип әбием генә дәшә иде.

– Үземдә дә шул хәл, сеңлем – мулла бабай Гөлзада дип исем куйган. Чиркәү кенәгәсенә Фекла дип теркәгәннәр, Фекла Тимофеева...

– Ә минем исемем Гөләйза...

– Бик матур исем, беренче тапкыр ишетәм!

– Әбисе, ягъни, минем әни Гөләйзар исемле иде, шуңа охшатып Гөләйза дип куйдык...

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Нәгыймә-Нәчтүк сәкедәге ашъяулык өстенә ашарга чыгарып куйды, Гөләйза да аңа булышты. Әмма Гөләйза да, әнисе дә ризыкка үрелергә ашыкмадылар, уңайсызланып, астан гына бер-берләренә карап алдылар. Нәчтүк тә эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлады.

– Уңайсызланмагыз, курыкмый ашагыз, – диде ул. – Без чучка тотмыйбыз, бу – әби-бабаларыбыз әманәте, малны да алар өйрәтеп калдырганча суябыз. Керәшен дигәч тә, без бисмилласын да, татар гореф-гадәтләрен дә беләбез анысы...

Юлчылар да үзләре белән өйдән алган ризыкларын уртак табынга тезделәр, ашъяулык ат казысы, пешкән елкы ите, бавырсак һәм кош теле ише тәм-томнар белән тулды. Чәй дә нәкъ аларча куе һәм сөтле иде, янына бал да куелган, Нәчтүк кунакларын татарчалап кыстый-кыстый сыйлый... Уйнап туйган балалар да сәкене сырып алды, әниләре аларга да күчтәнәчләрдән өлеш чыгарды.

– Әбием Әкълимә дә нәкъ шушындый ризыклар пешерә иде, – диде Нәчтүк, моңаеп. – Шул чаклар исемә төште... Син дә минем әбиемә охшагансың, Гөлзада түтекәй! Сез килеп керүгә, йөрәгем өзелеп төшкәндәй булды, әбием кайтып кергән кебек тоелды... Шундый охшагансыз!

– Бер авыл кешеләре бит, сеңлем, бер як кешеләре! Бәлки әле ерак туганнардыр да, Аллаһ белә... Үзем дә күңелемә бик якын иттем, рәхмәт, балам!

Ул арада балалар идәнгә җәелгән түшәк-ястыклар өстендә тәгәрәп йокыга киттеләр, Габделвахит та алар арасына барып ауды, әйтерсең лә туганнан бирле шулар белән яшәгән! Кечкенә Мәрьям исә йоклаганда да аның кулын ычкындырмаган, бәхет кошын тоткан кебек, нәни учларына кыскан. Моны күреп, хатын-кызлар елмаешып куйдылар, Нәчтүк аларга да сәкедә урын әзерли башлады.

– Ятканчы, безгә намазларыбызны укып алырга кирәк иде, балам!

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Нәчтүк сөлге белән почмактагы иконаны каплап куйды, әбисенең намазлыгын кыйблага турылап җәйде дә, үзе чаршау артына кереп китте. Ана белән кыз намазга бастылар, соңыннан үзләре өчен дә, кабере билгесез Әкълимә әби өчен дә, Нәчтүкнең үзе, гаиләсе өчен дә Аллаһның рәхмәтен сорап, дога кылдылар. Иртәгә иртүк тагы юлга кузгаласы бар иде, алай да Нәчтүктән әбисе турында күбрәк сорыйсылары килде. Нәчтүкнең үзенең дә аларга әбисенең бәхетсез язмышын сөйлисе килә иде, бу бичараларның да аны кабатлавын теләми иде ул...

– Иң куркынычы авыл халкын көчләп чукындырулардан башлана... Әкълимә әбием ул вакытта үсмер кыз була, ул барысын да бик яхшы хәтерли. Ямьле җәй көнендә була бу хәлләр, авыл халкы печәнгә төшәр алдыннан бераз ял итеп ала, атлар җигеп, бала-чагаларын төяп, бер-берләренә кунакка йөри, бәйрәм итә. Әкълимә әбиләрдә дә Иске авылдан кунаклар була, алар элеккеге гадәт буенча, бала-чагаларын алып, кырга чыгып, җәймәләр җәеп, самавырлар куеп, бәйрәм итәләр... Шул вакытта Кызылъяр ягыннан атлы җайдаклар күренә, алар артыннан кешеләр төялгән атлы арбалар да килә икән... Башта аларны Шонталага кунакка килүчеләр, дип уйлыйлар, әмма якынлашкан саен, аларның чит-ят тавышлар белән кычкырып җырлауларын ишетеп, шомланып калалар, чөнки мондый чиркәү җырларын күрше урыс авылларында ишеткәннәре бар. Арбада утыручыларның кулларында чиркәү

байраклары һәм икона-такталары була, бу хәл татарларны тагы да куркыта... «Берәр урыс авылына үтеп барышларыдыр», дип үзләрен юатырга тырышсалар да, атлы хәрбиләрнең Шонталаны урап алуларын күреп, эшләрнең начар икәнен сизенәләр, әмма инде соң була. Аларның барысын да авыл башындагы елгага таба куалар, соңыннан ул елганы «Поп елгасы» дип атап йөртә башлыйлар. Самавырлар җирдә аунап кала, кайберәүләр урманга кереп качарга тырыша, әмма казак камчылары белән аларны кире боралар. Ир-атлар, шул исәптән Әкълимә әбинең әтисе дә атлы казакларга каршы төшеп карый, әмма аларны тиз тезләндерәләр, кулларына шартлатып богау салып куялар... Ул арада авылда да качкан кешеләрне берәм-берәм өйләреннән өстерәп алып чыгып, атлы казаклар елгага таба куалар, беркемгә дә яшеренергә ирек бирмиләр, алай да соңыннан кайберәүләрнең качып котылулары билгеле була. Халык ахырзаман җиткән икән, дип уйлый, үләргә әзерләнә, бабайлар тәкъбир әйтә башлый...

Әкълимә әбинең әти-әнисе балаларын үз яннарына җыя, үлсәк, үтерсәләр, бергә үләрбез, дип уйлыйлар, белгән догаларын укыйлар. Халыкны елга буена җыеп бетергәч, яхшы атларда Чистайдан зур түрәләр дә килеп төшә, исправник һәм приставлар эшкә керешә. Яр буена өстәл куялар, анда урыс түрәләре һәм язып баручы писарьны да утырталар, поплар исә иконаларны елга ярына тезеп чыга. Башта алар пумала белән су бөркеп, елганы чукындыралар, аннан халыкны суга куып кертә башлыйлар. Елгага керергә теләмәгәннәре тояк астында калып изелә, бала-чагалар, карт-корылар куркуларыннан шунда ук тончыгып, су төбенә китә, аларның кайберләрен урыс хәрбиләре чәчләреннән өстерәп чыгара, кайберләре шунда җан бирә... Әкълимә әбием сөйли иде, без, балалар, чытырдатып әнинең ботына ябыштык, кечкенә энемне ул кулына алды, әтинең исә куллары богаулы иде, дип... Бер хәрби килеп, әнисенең кулыннан кечкенә улын тартып ала һәм башы белән өч тапкыр суга чумдыра. Бала күгәреп ката, тончыга, буыла башлый, соңыннан ул гомер буе өянәк чирле булып кала... Аннан елгадагы кешеләргә яр буенда торган поп пумаласы белән су бөрки башлый, үзе нәрсәләрдер сөйләнә... Татарлар, урысча белмәсәләр дә, моның чукындыру икәнлеген сизенеп алалар, судан чыгар өчен, тагы яр буена ыргылалар, атлы казаклар аларны яңадан елгага этеп төшерә... Аннан кешеләрне берәм-берәм елгадан өстерәп чыгаралар, ирләрнең түбәтәйләрен салдырып суга ыргыталар, хатын-кызларның яулыкларын тартып төшерәләр, чыккан беренең муенына чукындырып калай тәре асалар. Юеш киемнәрдән дер-дер калтырап торган Әкълимә әбиемнең дә муенына сүс бау белән бәйләп шундый тавык тәпие тагалар. Әбием әйтә иде, шул тәрене көчләп муеныма асканчы, пычак салсалар яхшырак булыр иде, дип... Аннан аларның барысына да урыс исемнәре бирәләр, писарь бөтенесен язып бара, ундүрт яшьлек Әкълимә дә чиркәү кенәгәләрендә, хөкүмәт язуларында Акулинага әйләнә, әтисе Мөхәммәткә – Иван, әнисе Мәрфугага Марфа дип яңа исем кушалар... Шушыннан соң безнең керәшенлек чоры башлана...

Нәчтүк авыр сулап, сөйләвеннән туктап калды. Гөләйза белән Гөлзада, тын алырга да куркып, бу шомлы кыйссаны тыңладылар, тарих пәрдәләре артында үзләренең дә шәүләләрен күрделәр. Идәндә балаларның мыш-мыш килеп йоклавы, йокы аралаш авыз чәпелдәтеп куюлары ишетелә, урамда җил улый, яртылаш кар астында калган карындык тәрәзәләрне шыгырдата... Чиркәүле керәшен авылы Актауда татар тарихы актарыла, хәтер күзәнәкләрендә тамгаланган иң куркыныч вакыйгалар яңара...

– Әйе, безнең әти-әниләр дә ул вакытта үсмер бала булган, әмма бу хәлләрне

яхшы хәтерлиләр иде, миңа да сөйләп калдырдылар, – дип, сүзгә Гөлзада да кушылды. – Поп елгасын беләм мин, аның суы кипкән инде, язларын гына тула... Ә менә ул чакта күргәннәрдән безнең күз яшьләребез һаман кипмәгән, керәшенлек шул чаклардан нәселебезгә ябышып калды бит, һаман җибәрми...

– Сез аннан киткәнсез инде, Гөлзада апа, керәшенлекнең исеме генә калган сездә, җисеме юк. Сез бит әнә яшермичә намаз укыйсыз, ислам динен тотасыз, ә без – юк инде, без беткәнче керәшен инде, татардан телебез генә калды...

– Анысы шулай, сеңлем, Аллага шөкер, күпме кыссалар да, күпме газапласалар да, без үз динебездә калдык! Әмма моның өчен күпме корбаннар бирүебезне үзебез генә беләбез. Әле алда тагы нәрсәләр булыр... Без чиркәү кенәгәләрендә һаман керәшен булып исәпләнәбез бит, бала туса да, шунда теркәтергә тиешбез, кеше үлсә дә, аларча күмәргә тиешбез. Без гомер буе качып-посып, ике тормыш белән яшәдек, шушы кара язмыш хәзер балаларыбызны да эзәрлекли... Менә хәзер дә дин өчен хөкемгә барышыбыз бит, аның нәрсә белән бетәсен белмибез.

Гөләйзаның бу турыда артык сөйләшәсе килми иде, чөнки ул үзе дә курка, үзе дә борчыла. Шуңа күрә сүзне тагы Әкълимә әби тарихына борды, аның ахырын беләсе килде.

– Ә сез ничек бу авылга килеп эләктегез соң, Нәчтүк? – диде ул. – Нигә Шонталада гына калмадыгыз, анда күбесе ислам динен тота бит, кәгазьдә генә керәшен.

– Калдырмаганнар шул, мәҗбүри монда күчергәннәр. Халыкны көчләп Поп елгасында чукындырганнан соң, сулар бөркеп, авылдагы бөтен өйләрне чукындырып чыкканнар, чишмәләргә, авыл капкаларына зур-зур тәреләр утыртып киткәннәр. Аннан халыкны, палицайлар белән саклап, Кызылъяр чиркәвенә куа башлаганнар, кешеләрнең бер өлеше юлда качып беткән, бер өлешен чиркәүгә өстерәп тә кертә алмаганнар, мәҗбүри кергәннәре дә кулын күтәреп чукынмаган, эчтән гел мөселман догалары кылып басып торган. Әкълимә әбинең эти-әнисе дә үз динендә каты торган, үзләре дә, балалары да тегеләр көчләп аскан тәрене такмаган, икона-такталарын өйләрендә тотмаган, ачыктан-ачык намаз укыганнар. Мөхәммәт зурбабай әле башкаларны да исламда калырга өндәп йөргән, урыс поплары аны җиңә алмаган. Берничә ел шулай азаплангач, һаман үз диннәренә кертә алмагач, кайбер гаиләләрне урыслар арасына яки чиркәүле авылларга күчерергә булганнар, Мөхәммәт бабайлар бу исемлеккә беренче булып эләккән. Ул әле монда килгәч тә үзенчә яшәргә тырышкан, чиркәүләренә үзе дә йөрмәгән, гаиләсен дә анда кертмәгән, курыкмыйча намазын укыган, әле башкаларны да шуңа өндәгән. Бу хәбәр Чистайга, Биләргә дә барып ирешкән, Мөхәммәт зурбабайны, христианнарны диннән яздырырга тели, чукындырылган булса да, чиркәүне санга сукмый, һаман үз динен тота, дип, кулга алалар. Аны, кул-аякларын богаулап, башта Чистайга алып киткәннәр, аннан – Казанга, шуннан бабабызның эзе югалды, Себергә сөргәннәр, диделәр. Мәрфуга зурәбием гомер буе аны көткән, гомер буе намазын ташламаган, урыс диненә кермәгән, балаларын да шулай өйрәткән, чөнки бу зурбабамның соңгы васыяте булган. Әмма Актауда алардан башка мөселманнар булмаган, халык керәшенлеккә каршы көрәшә алмаган, әкренләп үз язмышы белән риzалашкан. Мәрфуга зурәби өчен иң зур кайгы – үлгәч ничек һәм кайда күмүләре булган, чөнки Актауда мөселман зираты юк, поп мәетләрне үзенчә күмәргә көтеп кенә тора. Авырый башлагач, ул гел Шонталаны гына сөйли, анда туганнары барлыгын искә төшерә, үзен шунда кайтарып куюларын

сорый. Әкълимә әби ул вакытта инде буй җиткән кыз була, атын җигеп, әнисен чанага төреп салып, кышкы төндә Шонталага чыгып китә, чөнки көндез булса, поп авылдан җибәрмәс иде. Алар анда ничек исән-сау барып җиткәннәрдер – бер Ходай үзе генә белә! Әкълимә әби Шонталада туганнарын эзләп таба, әнисен шунда калдыра һәм яңадан Актауга, эне-сеңелләре янына әйләнеп кайта. Ул ике нәрсәгә гомере буе үкенеп яшәде, беренчесе – әнисенең соңгы минутларында аның янында булмавы, ташлап диярлек кайтып китүе, икенчесе – ятим туганнары хакына үз аягы белән яңадан шушы керәшен авылына кайтып керүе. Хәер, куанычы-юанычы да бар иде – зурәбине Шонталада туганнары мөселманча күмгәннәр...

– Ә ник монда кайткан икән соң, нәрсә буласын белә торып?

– Монда авыру энесе белән сеңелләре калган бит! Ул аларны кайда куйсын? Алар барысы да чиркәү кенәгәләрендә керәшен дип язылган булган бит, кая китсәләр дә, барыбер эзләп табарлар иде. Хәер, сеңелләрен ул каядыр татарлар арасына алып барып урнаштырган, мөселманнарга кияүгә биргән, алар шулай котылды керәшенлектән.

– Ә үзе ничек, кемгә кияүгә чыккан соң, иманда шулхәтле нык була торып, чукынган татарга чыга алмый бит инде ул, моны динебез тыя!

– Әйе, Әкълимә әбием кияүгә шактый соң, теге өянәк авырулы энесе үлгәч кенә чыга. Башта ул шулай кыз килеш картаерга уйлый, кем генә соратса да, кире бора, кяфердән нәсел калдырганчы, үлүең артык, ди, чыксам, мөселманга гына чыгам, ди... Моны ишетеп, Түбән Шонталадан татарлар килә, алар сезнең кебек мәкруһлар була, ягъни, чиркәү кенәгәсендә керәшен, дип язылган, ә үзләре ислам динен тота. Әкълимә әбине олыгаеп бара торган Абдулла исемле татарга димлиләр, Шонталага китеп, яшерен никах укыталар һәм шунда яши башлыйлар. Әмма Биләр атакайлары әбиемнең эзенә төшәләр, иреннән кычкыртып аерып, авырлы килеш канвай белән Актауга кайтарып ташлыйлар. Ирен, Абдулла бабакайны, христиан динендәге хатын-кызны аздырган, дип, кул-аякларын богаулап, Казан ягына, Идел буендагы Зөя монастырена алып китәләр. Соңыннан, безнең авылның чиркәү мәктәбендә укучылары күргәннәр анда Абдулла бабакайны, ул аларның янына үзе килгән, минем сезнең авылда хатыным булырга тиеш иде, ни хәлләрдә икән, дип сораган. Абдулла-Андрей шул монастырьда үлгән, соңыннан аның киеменнән гарәпчә догалар язылган бөтиләр тапканнар, яка асларына, күлмәк чабуларына тегеп куйган булган, ул гел шуларны укып йөргән икән... Ул вакытта Әкълимә әбием инде ир бала тапкан, ярдәм итәргә кеше булмагач, кендеген үзем чәйнәп өздем, дип сөйләгән иде безгә...

– Авыл хатыннары ярдәм итмәсләр идеме икәнни бер бичара хатынга?

– Итәрләр иде, әлбәттә, халык яхшы безнең, кешене алай керәшенгә-мөселманга бүлми, кулыннан килгәнчә ярдәм итә, артыгын күрми, сатмый... Монда шул Биләр-Чистай атакайлары барыбызның да теңкәсенә тия, ул вакытта бигрәк тә котырганнар... Әкълимә әби дә бит, баласын чукындыртмас өчен, аны авылда тапмаган, авырлы килеш тагы чыгып качкан. Әйтәм ич, андый хәлләр еш булган, чиркәү кенәгәсенә эләкмәс өчен, хатыннар балаларын үз авылларыннан читтә табарга тырышкан.

Шулай да поп белән пристав нәни Мөхәммәтне алып китәргә киләләр, әмма әбекәй аны аларга бирми, улын күтәреп, үзе чиркәүгә китә. Бу хәлне карарга бөтен авыл йөгереп урамга чыга – моңа кадәр беркемгә дә баш бирмәгән Акулина-Әкълимә баласын чукындырырга чиркәүгә алып бара! Башындагы

ак яулыгының чит-читләре, каерылган кош канатларыдай, салкын җилдә җилферди, өстендә бер кат юка күлмәге кар каплаган авыл урамы буйлап яланаяк чиркәүгә таба атлый... Юк, атламый, ә кара язмышы буйлап өстерәлеп-шуышып бара, мамык шәленә төргән сабыен үз куллары белән үлемгә илтә, башын бүкәнгә сала...

Чиркәүдә аны, авып китмәсен өчен, як-яктан тотып торалар, ә нәни Мөхәммәтне әнисе кулларыннан тартып алып, табактагы суга чумдыра-чумдыра чукындыралар, Михаил дип яңа исем бирәләр. Шул көннән соң Әкълимә әбием бик нык үзгәрә, беркем белән аралашмый-сөйләшми башлый, үз эченә йомыла. Әйе, кеше белән бергә чиркәүгә йөри, әмма анда кулын күтәреп чукынмый, ә таш сын кебек басып кына тора. Ә бер көнне ул, урыс диненең зур бәйрәмендә, бөтен чиркәү халык белән тулган көнне, атакай җырлый-җырлый Инҗил укыганда, аңа кушылып кычкырып Коръән укый башлый. Тирә-юнендә беркемне күрмичә, беркемгә игътибар бирмичә, ул башта көчле күкрәк тавышы белән «Фатыйха» сүрәсен укый, аннан «Ихлас»ка күчә, «Фәлак», «Нәс»ләрне башкарып чыга. Аны туктата алмыйлар, янына килергә дә куркалар, чөнки ул үзен алышынган кеше кебек тота. Иң соңыннан ул «Аятелкөрси»не укый, аннан чалгы белән чапкан кебек идәнгә ава, башы бәрелеп, күзләрен кан каплый, ул әбекәемнең күз яшьләре белән кушылып, саргайган бите буйлап агып төшә... Соңыннан сөйләп йөрделәр, «Акулина канлы күз яшьләре белән елады чиркәүдә, шулхәтле авыр кичерә икән үз диненнән аерылуны», дип... Хәер, ул үз диненнән аерылмады да, мин әле һаман хәтерлим – төннәр буе намаз укып чыга иде, аяклары тота алмаслык хәлгә килгәнче, ауганчы укый иде ул төнге намазларны! Кайвакытта мине дә үз янына бастыра иде, мин тиз арый идем, намазлык өстендә йокыга китә идем, бала бит...

Ул арада авылга Чулман аръягыннан яңа керәшеннәрне китереп тутырдылар, имеш, алар үзләрендә яшереп кенә ислам динен тотып ятканнар, хәзер җәза йөзеннән аларны монда җибәргәннәр. Әбекәй, бу хәбәрне ишетүгә, җилтерәп алар янына чыгып китте, кичкә таба берничәсен ияртеп тә кайтты.

– Алар да каты торыр, сез дә каты торыгыз, – дип өйрәтте ул аларны. – Тыштан алар кебек кылансагыз да, эчтән үз динебезне бирмәгез! Кеше саен урядник куя алмаслар, һәр тәрәзәдән карап тормаслар – төннәрен булса да укыгыз намазларыгызны! Чиркәүләрендә дә гел үзебезнекен укып торыгыз, аларныкын күңелегезгә кертмәгез. Аллаһ – белүче һәм күрүче, дөньялар гел болай бармас әле, исламга да бер ирек килер, күңелләрдә булса да иманны саклагыз!

Шулай яңа керәшеннәр янында йөри торгач, ул этигә бер ятим татар кызын җитәкләп кайтты, алар өйләнешеп яши башладылар. Мария-Мәрьям әнидә әле татар дине чыгып бетмәгән иде, ул әби әйткәннәрне тиз алдырды, алар бергәләп кача-поса намаз укый башладылар, кайвакытта мин дә кушыла идем. Авылда тагы сүз таралды – «Җенле Акулина инде яңа киленен боза башлаган, качып үз диннәрен тотып яталар икән», дип, атакайга да җиткергәннәр. Әмма Мария әни дә эти белән һәр атнада чиркәүгә йөри, поп әйткәннәрне үти, шуңа күрә атакай аңа бәйләнерлек сәбәп тапмый иде.

Ул арада мин дә буйга җиттем, әбекәйнең бөтен кайгысы мине иманлы бер татарга кияүгә бирү иде. Әмма Актауда андый татарны кайдан табасың? Әбием күптән Мария әнинең энесе Васил-Бәчилне карап-күзәтеп йөри икән, тагы үзе ике арада димче булды. Бәчилгә дә безгә әйткән сүзләрен әйтте, күңелдә булса

да иманны саклагыз, Алланы онытмагыз, бисмилласыз йөрмәгез, намазны белегез, диде.

Әмма әбекәйгә безнең туйны күрергә насыйп булмады, шуның алдыннан гына ул авырый башлады. Башта барыбыз да бу чире үтеп китәр, әбекәй тагы элеккечә йөгереп йөри башлар, дип уйладык, әмма ул көннән-көн сулды, аннан урынга ук ятты һәм башка тора алмады.

Кайдан белгәннәр диген – әбекәй соңгы сулышын алып ятканда, өйгә Чистай һәм Биләр атакайлары килеп керде, аларга үзебезнең авылның керәшен побы да ияргән иде.

Биләр атакае әбекәй кулындагы дисбегә ташланды, аның ярсып тартуыннан дисбенең җебе өзелде һәм төймәләре идән буйлап тәгәрәп китте (без аны соңыннан җыеп алып, яңадан тездек)... Шул чакта әбекәйнең дә җаны өзелде ахыры, ул авыр итеп соңгы сулышын алды да, котылдым бу кайгылы дөньядан, дигәндәй, мәңгегә күзләрен йомды. Аның йөзе бик тыныч иде, матур иде, нурлы иде... Әйе, әйе, әбинең йөзеннән нур сирпелеп тора, үзе тыйнак кына елмайган, әйтерсең лә күктән төшеп килгән җәннәт фәрештәләрен күргән... Әбекәй, әле үлгәнче үк, үзен йөзе белән кыйбла якка – Шонталага таба борып куйдырган иде, поплар аны почмактагы иконага каратып борырга куштылар. Әти аларны тыңламады, атакайларның моңа бик нык ачулары килде. «Акулинаны иртәгә, христианча отпевать итеп, Актау зиратына күмәчәкбез, әзерли торыгыз», дип чыгып киттеләр. Без, нишләргә белмичә, бер-беребезгә карап, идән уртасында басып калдык...

Нәчтүк туктап калды, ул хикәятенең иң авыр, иң куркыныч урынына килеп җиткән иде. Ул чагында күргән-кичергәннәрен сөйләп тә, аңлатып та бирерлек хәлдә түгел иде. Гөлзада үзе аңа ярдәмгә килде.

– Шонталага алып кайтып күмгән булсалар, без белмичә калмас идек, ул вакытта инде авылда яши идек. Насыйп булмаган инде Әкълимә әбигә туган авылы зиратына кайтып ятарга, минем әти-әни дә шулай чит-ят җирләрдә ятып калды...

– Әйе, әбекәйне туган авылына алып кайтып җиткерә алмый әти... Өйдән поплар чыгып китүгә, без Мария әни белән әбине ул өйрәткәнчә юып-кәфенләдек, балалар кебек, ак биләүгә биләдек. Әти ул арада авылны әйләнеп кайтты. «Авылны чыгып китәрлек түгел, баш-башына каравылга кешеләр куйганнар, поплар шулай кушкан, – диде ул, гасабиланып. – Ә мин аны барыбер аларга бирмим, үзем күмәм, ул кушканча, мөселманча күмәм! Үземнең ишегалдына күмәм!»

Шулай диде дә, әти әзерләнә башлады, әбекәй белән Шонталага баргалаганда, ул барысын да карап, өйрәнеп йөргән икән, мәет күмү тәртибен дә белә булып чыкты. Үзенә ярдәмгә минем булачак ирем Бәчилне чакырып китертте, алар төнге якта бергәләп ишегалдының алма бакчасы ягында кабер казыдылар, ләхет алдылар, бергәләп җеназа намазы укыдылар, бергәләп әбекәйне җир куенына салдылар. Әмма икенче көнне иртүк атакай килеп җитте, атылып өйгә керде, ә анда Әкълимә әби юк! Ул кычкырына, дулый, каргана башлады, этигә төрмә белән янарга тотынды һәм атылып чыгып та китте. Бераздан ул көрәкләр күтәргән авыл ирләре белән яңадан әйләнеп кайтты, янында Чистайдан килгән этле хәрбиләр һәм пристав та бар иде. Алар әбекәйнең мәетен таптыра башладылар, чөнки аны авылдан алып чыгып китмәүләрен беләләр иде, авыл сакланды. Хәрбиләр этне ишегалдына җибәрделәр, ул шунда ук әбекәйнең кабере янына барып тырнаша, күккә карап улый башлады. Поп та

эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды, аның инде керәшеннәр арасында мондый хәлләрне күргәләгәне булган. Ул хәрбиләргә каберне казырга кушты, әти каршы килеп карады, аны читкә бәреп кенә аттылар. Бу – коточкыч күренеш иде, мин мунча почмагыннан качып карап тордым. Әбинең җәсәден кабереннән өстерәп чыгардылар, чиркәүдән алып килгән агач табутка салдылар, өстенә «изге суларын» бөрки-бөрки чукындырдылар, атакай озаклап чиркәү догаларын башкарды. Аннан соң табутны күтәреп, урыс зиратына юнәлделәр, әти дә, башын иеп, алар артыннан атлады, мин бармадым...

Әти төнлә атын җигеп, тагы өйдән чыгып китте, ул миңа да, Мария әнигә дә берни әйтмәде. Мин аның нәрсәдер эшләргә җыенганын сизендем, әмма аңламадым, чөнки ул беркем белән дә сөйләшмәде. Әмма арбасындагы тимер көрәкне, балтаны күреп, йөрәгем жу итеп китте, зиратка бармыймы икән бу, дип уйладым. Нәкъ шулай булган да, моны мин иртәнге якта әти өйгә кайтып кергәч кенә аңладым. Аның өс-башы, куллары кызыл балчыкка баткан, әмма йөзе бик канәгать иде.

– Әбиеңне Бахта елгасының биек яр буенда җирләп кайттым, кызым, – диде ул. – Шонталага барып җитә алмадым, арттан куа чыгарлар, дип уйладым. Мондыйга киткәч, Шонталага барып та актарып алырлар иде, аны мөселманча күмгән өчен башкаларны гаепләрләр иде... Ә болай – җаным тыныч, яңадан җеназа намазы укып күмдем, анамның соңгы васыятен үтәдем. Тегеләр бераз тынычлангач, сиңа да урынын күрсәтермен әле, моннан шактый ерак ул, кеше эзләп таба торган түгел.

– Алар әбинең мәетен эзләп, тагы монда килеп җитәчәкләр бит инде, әти! Сине төрмәгә алып китәргә мөмкиннәр!

– Китсеннәр... Миңа инде барыбер... Үзеңчә яши алмагач, үз динеңне тота алмагач, шул ук төрмә инде ул, кызым!

Мин дөрес курыкканмын икән – әти өс киемнәрен дә алыштырып өлгермәде, тагы кичәге хәрбиләр һәм атакай килеп керде, алар аннан әбинең мәетен таптыра башладылар. Әти дәшмәде, аны кул-аякларын богаулап, Чистайга алып киттеләр. Әтине анда камчы белән суктырганнар, тәнендә тетелмәгән җире калмаган иде, өстендәге киеме канга баткан, ертылып беткән... Әти йөткереп, берничә көн кан косып ятты да, дөньялыктан үтте. Үләр алдыннан ул миңа киңәшләрен дә әйтеп өлгерде:

– Болар барыбер безгә үзебезчә яшәргә ирек бирмәсләр, кызым... Без аларны җиңә алмыйбыз, ә алар безне берәм-берәм кабергә кертәчәк... Зурбабам Мөхәммәт дин-ислам хакына Себердә юкка чыкты, атам Абдулла Зөя монастыренда үлде, анама үлгәч тә тынгы юк, хәтта үзе теләгән зиратта ятарга да рөхсәт бирмиләр... Инде менә мин шушы хәлдә, сизәм – озак яшәрлегем калмады... Син шушылар арасында берьялгызың каласың... Беренче киңәшем – Бәчил белән никахлашыгыз, яхшы егет ул, миннән сезгә хәер-фатыйха... Икенче киңәшем – боларга каршы барып, безнең кебек харап булмагыз. Алла – алар өчен дә, безнең өчен дә бер, ул безнең хәлебезне күрә, ул рәхимле, безне кичерер... Әмма тыштан аларның диннәрен тотсагыз да, күңелләрегездә исламны саклагыз, дөньялар гел болай бармас әле, иркенлек килү белән, үз динебезгә кайтырсыз... Безне догадан калдырмагыз.

Гөлзада белән Гөләйза Нәчтүкнең сөйләгәннәрен тетрәнеп тыңладылар, бу ишеткәннәре янында үз кайгылары кечкенә булып күренде. Әйе, хәтерли алар, моннан ун-унбиш еллар элек Шонталага атлы казаклар, пристав һәм атакайлар килеп, этләр белән нindидер Актау карчыгының каберен эзләп йөргәннәр

иде. Бөтен авыл халкыннан – керәшененнән-мөселманыннан каравыл өенә җыеп сорау алдылар, зиратларны тикшереп чыктылар, әмма шикле нәрсә тапмадылар. Шул Әкълимә карчыкның каберен эзләп йөргәннәр икән...

– Әни, мине дә шушы хәлләр көтәме инде?

Кызының шулай дип соравыннан Гөлзада сискәнеп китте, нәрсә дип җавап бирергә дә белмәде.

– Исламда калсам, мине һәм балаларымны да Әкълимә әби язмышы көтәме?

Бу сорауга җавап юк иде... Бу авыр хәлдән чыгу юлы да юк иде...

– Без керәшенлек белән ризалашырга мәҗбүр булдык, чөнки исән калуның башка юлы юк иде, – дип җавап бирде аңа Нәчтүк-Нәгыймә. – Әгәр мин исламда калган булсам, балаларымны тартып алырлар иде, үземне йә монастырьга ябарлар, йә Себергә сөрерләр иде... Минем боларга каршы торырлык көчем юк, мин исән калу өчен үзем дә чукындым, балаларымны да керәшен иттем. Аллаһы Тәгалә кичерсен, башка юлым юк иде... Дөрес, безнең хәзерге побыбыз Якуб атакай тегеләре кебек явыз түгел, әмма яшерен генә ислам дине тотып ятучылар да юк инде хәзер.

– Безне әле, бәлки, иртәгә мәхкәмәдә акларлар, Гөләйза беркайчан да чукынмаган, бер көн дә урыс динен тотмаган бала бит! Ул гомер буе исламда булды, мөселман кешесенә никах белән кияүгә чыкты, балаларына да мулла мөселманча исем кушты. Иртәгә шушыларны сөйләрбез, борчылма, кызым!

Шундый уй-теләкләр белән йокларга яттылар, иртәгә иртүк юлга чыгасы бар.

Урамда буран купкан ахры, карындык тәрәзәләргә учлап-учлап кар сипкәне ишетелә. Бу яз киләсенә хәбәр инде, соңгы бураннар...

Балалар җылы өйдә идәндә таралып йоклыйлар, нәни Габделҗәббар вакыт-вакыт уянып, әнисенең сөт тулы күкрәкләрен чәпелдәтеп имәргә тотына, аннан икесе дә йокыга китәләр... Гөлзада гына һаман йоклый алмый, Поп елгасына куып кертелгән Шонтала халкы күз алдына килә. Аның әти-әнисе дә шулар арасында булган бит... Әле карлы урам буйлап яланаяк килеш баласын чиркәүгә чукындырырга алып барган Әкълимә каршына килеп баса, Себергә сөрелгән Мөхәммәт, Зөя монастырена ябылган Абдулла, анасын мөселманча күмгән өчен кыйнап үтерелгән икенче Мөхәммәт караңгыда күз алдыннан үтеп китәләр... Алар Гөлзаданы да бөтереп үзләре арасына алып кереп китәләр, Гөләйзаны да эзләп йөриләр... Юк, бу бит Гөлзаданың урыс авылында мунчада тончыктырып үтерелгән әти-әнисе, кара төтен арасыннан балаларын эзлиләр... «Минем исемем Гөләйзар! Минем исемем Гөләйзар!» Бу бит әнисенең тавышы, ул үзен камчылап чиркәүгә алып барган попларга шулай дип тәкрарлый... Юк, бу янында сабыен кочып яткан кызы Гөләйза шулай саташа икән бит, бөтен өйгә ишетелерлек итеп: «Минем исемем Гөләйза! Минем исемем Гөләйза!» дип ыңгыраша... Ул әле бу исемне күп тапкырлар кабатлаячак, мәхкәмәләр каршында да, поплар алдында да, сорау алганда да, җан биргәндә дә, ул «Минем исемем Гөләйза!» дип әйтәчәк...

## Мәхкәмә алдыннан...

Авылның икенче башында, Якуб атакай йортында да җитди сөйләшү бара, иртәгә мәхкәмәдә нишләргә кирәген киңәшәләр. Якуб атакайның өе зур һәм җылы, әллә ничә бүлмәле, шәмдәлләр белән яктыртылган, түбәсе дә Бәчилләрнеке кебек салам түгел, такта белән ябылган. Балалар да аяк астында

буталмый, күрше бүлмәләрдән тавышлары гына килә, анакайлары өстәлгә ризыкларны чыгарып куйды да алар янына кереп китте. Кайнар чәй эчеп, анысын-монысын капкалап, тагы мәхкәмә турында сөйләшә башладылар. Актау побы анда тылмач буларак чакырылган, моннан тыш Биләрнең баш атакае иерей Михаил Лавров үзе катнашачак икән, чөнки бу эш шуның әлеге буенча башланган. Әлеге бәндә бөтен тирә-юньне дер селкетеп тора, татарларга тын алырга да ирек бирми, мәкруһлар өстеннән Казанга гына түгел, Петербургның үзенә туктаусыз шикаять-әләкләр язып ята. Керәшеннәрне ул козгын кебек саклый, аз гына читкә тайпылганнарын, ислам ягына борылганнарын ишетсә, аларны урыс авылларына күчереп газаплый, хәрбиләрне ияртеп килеп, алар кулы белән җәзага тарттыра. Гөләйза өстеннән дә ул инде узган ел ук Казан консисториясенә рапорт язган булган, имеш, Шонталадан керәшен кызы Пелагея үзенең законсыз туган улын чиркәүгә алып килеп чукындырмый, моңа чара күрергә кирәк икән! Казан һәм Зөя архиепискобы Владимир бу эшне Чистай судына тапшыра, алар исә Гөләйза белән баласын, анасы Гөлзаданы мәхкәмәгә алып килергә пристав белән полицияне җибәрәләр. Инде бу эшкә Казан губернасының архиепискобы үзе кушылган икән, бер татар хатыны өчен мәхкәмә хәтле мәхкәмәләр уздырып яталар икән, димәк, алар Гөләйзаны болай гына ычкындырмаячаклар...

Моны ирләр сизенә, әмма шул хакта Гөләйзаның үзенә әйтмиләр.

Әйе, Ишук – Ишмөхәммәт бик яхшы белә, яңа патша килгән саен яңа тәртипләр урнаша, әмма татарга, бигрәк тә мөселманнарга мөнәсәбәт һаман бертөрле – начар белән бик начар арасында. Алай да Ишмөхәммәтнең күңелендә бер өмет пыскый – моннан ун еллар элек халык дәррәү кубарылып, ак патшага прошение-үтенечләр яза башлагач, бераз үзгәреш булды бит! Күрше Акъяр белән Кадыйдан гына да кырык дүрт татар рәсми рәвештә яңадан исламга кайтты! Диңгез ерылды, меңләгән кеше үтенеч яза башлады, аның хәтта рәсми үрнәкләре һәм шуларны язып-күчереп бирүчеләре дә барлыкка килде. Бигрәк тә Тубылгытауда мишәрләр кайнады, заманында Болгар-Биләр каласы булган, урыслар басып алгач, көчләп чукындырылган бу татар авылы, аз гына дин иреге килү белән, яңадан исламга кайтты, башкаларны да үз артыннан ияртте. Ишмөхәммәт үзе дә булып кайтты ул авылда, урядникләр мөһерләп киткән мәчетләренең ишекләреннән кермичә, түбәсеннән төшеп намаз укуларына шаклар катып кайткан иде. Муллалары хәтта Чистайдан килгән урыс приставын да сугып еккан, ди, тегесе аны түбәгә менеп барганда баскычтан тартып төшергән. Ул мулланы соңыннан Казан янындагы Раиф монастырена яптылар, халыкны куркыту өчен, чылбырлар белән бәйләп, авылга алып кайтып урам әйләндерделәр. Әмма аңа карап Тубылгытау халкы иманын бирмәде, намазын ташламады, түбәтәен салмады, тирә-як халкы хәзер дә киңәшкә аларга бара. Ишмөхәммәт үзе дә аннан ак патшага үтенечнең күчермәсен алып кайткан иде, шуның буенча Шонталада да күпләр Петербургка прошениеләр язып җибәрде, әмма әле һаман җавап кына килмәде. Ишмөхәммәт менә шул үтенеч-прошениеләренә зур өмет баглый иде, бу турыда Якуб атакайга да әйтте.

– Без бит Микулай патшага үтенеч яздык, үз динебезне тотарга рөхсәт сорадык, димәк ки, аннан җавап алганчы, безне бернинди дингә дә ирексезләү булырга тиеш түгел! Мәхкәмәдә моны да әйтергә кирәк булачак, Якуб энем! Миндә аның бер күчермәсе дә бар, анда менә нәрсәләр язылган бит! «Олуг Галиҗәнап! Рәхимле Падишаһ! Без, яшебез-картыбыз, шулай ук безнең хатыннарыбыз, күз яшьләребезне түгә-түгә, сиңа ялварабыз! Борын-

борыннан, ата-бабаларыбыз дәвереннән башлап бүгенге көнгә кадәр үзебезнеке саналган динебезне тотарга рөхсәт итсәң иде! Безнең ата-бабаларыбыз ислам динендә булган, ә хәзер, билгесез сәбәпләр аркасында, безне керәшенлеккә күчергәннәр, урыс-грек динен тотарга көчлиләр. Әмма без урысның телен дә, динен дә белмибез, безне палицай белән мәҗбүриләп чиркәүләргә куып кертсәләр дә, анда берни аңламыйбыз, керәшен динен тотмыйбыз. Шул ук вакытта без үз динебезне дә закун юлы белән, рәсми рәвештә тота алмыйбыз – безнең өстә чиркәү әһелләре һәм палицайлар көне-төне каравыл тора, алар мәчетләребезне җимертәләр, муллаларыбызны Себер сөрәләр, чукынырга теләмәгән татарларны монастырьларга ябалар, гомерлек солдатка алалар, халыкны, яткырып, чыбык белән суктыралар. Олуг Галиҗәнап! Рәхимле Падишаһ! Без дә синең тугры колларың бит, ярдәм ит безгә! 1764 елның 20 февралендә чыгарылган, «Россия империясендә һәркем үз динен тотарга хокуклы», дигән указның көченә өмет тотып, шушы өметебезнең аклануына ышаныч белән калырга җөрьәт итәбез».

– Беләм мин ул прошениеләрне, Ишук әзи, миндә аның урысчасы да бар! Аларны син генә түгел, меңләгән татар язган инде, әмма әле берсенең дә җавап алганы юк.

– Менә шул җавап килгәнче безгә тимәсеннәр инде, бәлки яхшы җавап килер, ак падишаһ татарларга үз диннәрен тотарга рөхсәт итәр!

Якуб атакай моңа җавап бирмәде, ул дөресен әллә белми, әллә белеп тә әйтәсе килми иде. Ә дөреслек шуннан гыйбарәт: татарларның бу үтенечләре башта Изге Синодның обер-прокуроры, князь Мещерскийга бирелә, аннан Изге Синод дигәннәре карар чыгара, татарларның үтенече кире борыла, аларга христиан диненнән чыгу тыела. Ул гына да түгел, заманында көчләп чукындырылган татарларны христиан динендә, чиркәү карамагында саклап калу өчен, өр-яңа юллар эзли башлыйлар, җәза алымнары белән бергә үгет-нәсихәт юлына да басалар. Шул нисбәттән, христиан дине китаплары татарчага тәрҗемә ителә һәм бушка таратыла, авылларга татарча белгән попларны җибәрә башлыйлар яки керәшеннәрнең үз араларыннан шундый дин әһелләре әзерлиләр. Якуб атакай да Зөя чиркәү мәктәбендә махсус укытылып, керәшен татарлары арасына эшләү өчен кайтарылган әзерлекле белгеч иде, шушы як кешесе. Ул ак патшаның да, чиркәүнең дә татарларга үз диннәренә кайтырга беркайчан да рөхсәт бирмәсен белә, башлары белән таш диварга бәргәләнгән милләттәшләрен кызгана, аларга үзенчә ярдәм итәргә тырыша иде. Әмма аның ярдәме күп очракта керәшенлектә калуга өндәүгә кайтып кала... Бу юлы да ул үзенә тугры булып калды.

## «Минем исемем Гөләйза!»

Иртән мөсафирлар үз өйләрендәге кебек уянып киттеләр, торып намазларын укыдылар, ул арада Нәчтүк чәй кайнатып та өлгерде, сәке өсте тагын ризык белән тулды.

– Кайтышлый да керегез, – диде хуҗабикә, кунакларын сыйлый-сыйлый. – Сез килгәч, өй эчләре яктырып китте, төнлә дә нур сирпелеп торды... Әкълимә әбекәемне төшемдә күрдем, ул да бик сөенгән иде! Дисбесен сиңа бирергә кушты, Гөләйза, ул безнең нәселләрне берләштерәчәк, диде...

– Әйе, мин дә күрдем аны төшемдә, ап-актан киенгән иде, «Исемеңне онытма, иманыңны бирмә!» диде, дисбесен учыма салды... Төнлә саташып уянып киткәндә, кулымда шул дисбе иде...

– Хикмәтле төшләр бу, балалар, бик яхшы төшләр, Аллаһ безгә Әкълимә карчык аша хәбәр бирә, – дип, сүзгә Гөлзада да кушылды. – Эшләребезнең дә ахыры хәерле булыр, Алла теләсә!

– Бу дисбе сиңа булсын, Гөләйза! Әбинең Коръәнен дә сиңа бирәм, ул сиңа кирәгрәк, миннән барыбер алып чыгып китүләре бар, шуңа күрә мин аны җыеп кына тотам.

Шулай диде дә Нәчтүк чиккән ак сөлгегә төргән Коръән китабын Гөләйзага алып килеп бирде, ул аны күкрәгенә, мамык шәле астына яшерде. Сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр, Габделвахитны да уятып яннарына утырттылар. Кечкенә кыз Мәрьям аңа чат ябышкан иде, ул да Габделвахитка ияреп торды, күзләрен уа-уа, сәке өстенә үрмәләде. Инде юлга әзерләнә башлагач, ул Габделвахитны килеп кочаклап алды, «ул минеке, китмәсен!» дип елый башлады.

– Елама, кызым, кайтышлый алар тагы керә безгә, менә шунда туйганчы уйнарсыз, – дип, атасы аны күтәреп алды. – Чана шуарга чыгарсыз, Габделвахитка куяннарыңны күрсәтерсең, яме?

Бала, тынычланып, әтисенең көчле күкрәгенә башын төртте, аңа кунак малай да, әтисе дә бик якын һәм кадерле иде.

– Чистайдан кайтышлый туп-туры безгә керегез, Гөлзада түтекәй, – диде Бәчил. – Ял итеп, кунак булып китәрсез. Кайтышыгызга мунча ягарбыз, Нәчтүк балан бәлеше пешерер, шулай бит, әнисе?

– И, Бәчил җаным, берне түгел, бишне пешерер идем, исән-имин әйләнеп кайтсыннар гына! Синең өчен догада булырмын, Гөләйза кардәшем! Әкълимә әбинең дисбесен ал, син дә зекер әйтеп утырырсың...

– Алланың рәхмәтләре булсын сезгә, иң якын туганнар кебек каршы алдыгыз, яралы йөрәкләребезгә дәва булдыгыз! Инде шул суд дигәннәреннән исән-имин котылып кайтырга язсын. Әйдә, кызым, төр Габделҗәббарны, мин олысын җитәкләрмен...

Шулай бер-берләрен юатсалар да, һәрберсенең күңелендә шом иде – ә бәлки бу соңгы очрашудыр, бәлки алар бу йортка яңадан әйләнеп кайта алмас, кяферләрнең тоткыны булыр... Моны тел белән әйтмәсәләр дә, бу хәвеф күзләреннән сагыш булып сирпелә, күңелләреннән моң булып түгелә иде... Күпме кеше шулай киткән җиреннән яңадан әйләнеп кайтмады бит, аларның кайда икәнлекләрен дә белмиләр хәзер... Раббым, Гөләйзаны андый фаҗигале язмыштан сакла, үзенә дә, анасына, балаларына да яңадан йорт-җирләренә әйләнеп кайтырга насыйп ит!

– Миңа берәр нәрсә булса, балаларымны ташлама, Нәгыймә! – диде Гөләйза, аны кочаклап. – Аларны урыс кулына бирә күрмәгез – васыятем шул...

– Борчылма, кардәшем, синең балаларың – минем балаларым булыр, Алла ташламасын! Бергә әйләнеп кайтыгыз, без догада булырбыз...

Ул арада капка төбенә Ишмөхәммәтнең җигүле аты да килеп туктады, ул үзе дә, аты да ял иткән, тагы ерак юлга кузгалырга була иде. Ишмөхәммәт тә өйгә кереп, хуҗаларга рәхмәтләрен әйтте, Гөлзаданың әйберләрен күтәреп, урамга чыкканда инде яктырып беткән иде.

Авылның аргы башыннан Якуб атакайны һәм приставларны алып, олаулар юлга кузгалды, мәхкәмә билгеләгән вакытка Чистайга барып җитәргә кирәк иде... Кичтән бераз явып торса да, инде олы юлдан атлы чаналар узган, эз төшкән, инде Ханнар юлыннан шәп кенә җилдерергә дә була иде...

Әйе, Ханнар юлы, Биләр белән Җүкәтауны тоташтырып торган олы юл...

Ханнарны һәм акыл ияләрен, кораллы яу ирләрен һәм йөк төягән кәрваннарны күргән Татар юлы...

Хәзер аннан коллар һәм каторжаннар, атлы казаклар һәм урыс алпавытлары үтә...

Кайчандыр шушы ил-җирләрнең хуҗасы булган, дистәләгән бәйсез дәүләтләр тоткан, Болгар, Биләр, Җүкәтау, Тубылгытау кебек йөзләгән таш калалар салган, меңләгән мәчет-мәдрәсәләр төзегән татарлар хәзер моннан тоткын булып үтә...

Әнә Чистай үзе дә күренде...

Шәһәр читендәге агач өйләрнең морҗаларыннан ак төтен күтәрелә, ул, ак болытлар белән кушылып, шәһәр өстенә тарала. Эчкәрәк кергән саен, агач өйләр кимеп, таш йортлар арта бара, урам саен диярлек чиркәүләр калкып чыга. Алар зурлар, өскә авып диярлек торалар, гөмбәз саен алтын тәреләре ялтырый... Урыс авылында яшәгәндә, Гөлзаданы мәрхүмә әнисе тәрегә туры карамаска өйрәтте, күзеңнең нурын алыр, дия иде. Хәзер дә Гөлзада ул тәреләргә текәлеп карый алмый, попның шуны ярсып-ярсып борын төбенә төрткәнен гомерендә дә оныта алмый...

Чистай, чыннан да, таш кала икән, ул рәт-рәт тезелеп киткән кибетләре, әллә ниләр ясап чыгара торган заводлары, ул яр буена тезелгән тегермәннәре, ул җәйне көтеп зарыккан пристань-пароходлары дисеңме – Гөлзада белән Гөләйза өчен барысы да яңа иде. Шәһәрне карау белән мавыгып, алар хәтта мәхкәмәгә барганнарын да оныттылар шикелле. Шулчак авыл өйләре арасыннан манаралы агач мәчет күренде, хатын-кызлар хәтта шатлыкларыннан кычкырып җибәрделәр.

– Мәчет! Монда мәчет тә бармыни, әти?! Керәшеннәргә мәчет тотарга рөхсәт итәләрмени?

– Монда мөселман-татарлар да яши, кызым, керәшеннәр дә шактый. Менә хәзер Татар бистәсеннән үтеп барабыз, бу судларыннан исән-сау котылсак, кайтышлый мәчетләренә тукталырбыз әле, Алла теләсә!

«И Раббым, мәхкәмә дигәннәреннән исән-имин котылып, шушы мәчетләргә кереп, намаз укырга насыйп ит!» дип, Гөләйза мәчет манарасы күздән югалганчы дога кылды. Менә приставларның алдан барган атлары суд бинасы каршына килеп туктады, ул асты таш, өсте агач ике катлы бина булып чыкты. Өяз һәм земство суды да, полиция дә, пристав дигәннәре дә шушында икән, әле үзләренең төрмә кебек ябып тота торган урыннары да бар, ди. «Инде аларын күрергә язмасын, инде биредән үз аякларыбыз белән чыгып китәргә насыйп итсен!» дип, хатын-кызлар бу куркыныч йортка аяк басуга теләк тели башладылар. Ул арада балалар да арып кыймылдарга тотындылар, Габделҗәббар мәхкәмә бинасын яңгыратып, елап ук җибәрде. Бала тавышына бүлмәләрдән чыгып карадылар, мәхкәмәгә чакыртылган кешеләр килгәнлеген белгәч, берәм-берәм керергә әзерләнә торырга куштылар. Ул арада атын бәйләп, Ишмөхәммәт тә кереп житте, Якуб атакай да аның белән иде, бер почмактан төлке туннарга төренгән Биләр побы да килеп чыкты. Атакайлар шунда ук суд буласы залга кереп киттеләр, Гөләйза, бер читкә барып, баласын имезеп килде, чөнки анда кергәч, күпме торасын, кайчан чыгасын белми иде, сабые ач ятмасын, дип уйлады...

– Пелагея! – дип дәшүләренә, Гөләйза сискәнеп китте, шикләнеп як-ягына карады, суд сәркатибенең үзенә текәлеп карап торганын күреп, куырылып килде. Ишектә Якуб атакай да күренде: «Сине чакыралар, Гөләйза, балаңны

әниеңә бир, монда чиратлап керәчәксез», – диде. Гөләйза, ярдәм сорагандай, әти-әнисенә карады, аннан, баласын күкрәгеннән аерып алып, әнисенә илтеп бирде, олысы исә этисе Ишмөхәммәт кулында иде. Ишеккә җиткәч, ул тагы аларга бер борылып карады, әйтерсең лә соңгы тапкыр күрә, әйтерсең лә аны башка бу ишектән чыгармаячаклар...

«Раббым, сабырлыклар бир, көч бир, иман ныклыгы, тел ачкычлары бир, – дип ялварды ул күңеленнән. – Кяферләрнең телләрен йозакла, күңелләрен мөһерлә, миңа зыян салырга ирек бирмә! И Раббым, бөтен таянычым бер Син генә, бөтен өметем бары тик Синдә генә!

Киез итек кигән аякларын авырлык белән өстерәп, ул мәхкәмә каршына кереп басты. Карадан киенгән урыс судьялары, тәреләре күкрәкләрен каплаган поплар, ялтыр төймәле кительләр кигән хәрбиләр, урядниклар һәм приставлар, ишек төбен саклап торган палицайлар, тотып ашардай булып, ак яулыклы бу татар хатынына текәлделәр. Алар монда күп иде, ә ул – берүзе. Алар барысы да урыслар, ә ул – татар хатыны. Алар барысы да православлау динендә, ә ул – исламда. Һәм алар аны хөкем итә...

Гөләйза, хәтта шушы кышкы киемнәреннән дә күз явын алырлык чибәр иде, ул килеп кергәч, караңгы бүлмә эчләре яктырып китте. Мәрмәрдәй ак йөзеннән нур сирпелеп тора, карлыгач канатыдай сызылып киткән кап-кара кашлар, озын кара керфекләре зур яшькелт күзләрен каймалаган, уймактай иреннәре ут кебек яна... Башында зур ак өрпәк, аның астындагы энҗеле кашбавы ак маңгаен урап алган, иңендә җылы мамык шәле, өстендә бала итәкле озын күлмәк, ул Гөләйзаның зифа буен талчыбыктай күрсәтә, күлмәк өстеннән бәрхет камзулын киеп куйган... Хан кызларыныкыдай кечкенә ак куллары, озын, нечкә бармаклары бераз дерелди, курыкканы, каушаганы күренеп тора... Таза, симез марҗа хатыннарын күреп өйрәнгән урыс ирләре патшабикәдәй гүзәл бу татар хатынына сокланып та, кызганып та карадылар. Алар аны хәзер хөкем итәргә, законсыз татар иреннән аерып алырга, чиркәүгә барып чукынырга ризалык бирмәсә, үгетләү өчен монастырьга ябарга, аннан бер исерек урыска кияүгә бирергә тиеш иделәр.

Мәхкәмә башланганчы, Гөләйзага «Библия» китереп бирделәр, ул, шуны тотып, дөресен сөйләргә ант итәргә тиеш иде.

– Нәрсә бу? – дип сорады Гөләйза, аны кулына алырга куркып.

– Бу – «Инҗил», христианнарның изге китабы, – диде аңа Якуб атакай, татарчалап. – Син, христиан кешесе буларак, шуны тотып присяга бирергә, ягъни, суд алдында ант итәргә тиешсең.

– Мин урыс динендә түгел бит, мин – мөселман, ничек бу китапны тотып ант итим?! Минем үз китабым бар!

Якуб атакай Гөләйзаның сүзләрен хөкемчеләргә тәрҗемә итте, алар әле башланмаган да эшнең болай борылыш аласын көтмәгәннәр иде. Әмма кешегә көчләп «Библия» дә тоттырып булмый бит!

– Нинди «үз китабы» бар, шуны сора!

Гөләйзаның нәрсә әйтәсен белсә дә, судтагы тәртип буенча Якуб атакай моны да сорады.

– Мин сүзләремнең хаклыгына, үземнең ислам динендә икәнлегемә Коръән тотып ант итә алам!

Судта әле мондый хәлнең булганы юк иде – ничек инде ул, христиан кешесе Коръән тотып ант итә алсын?! Мондый вәхшилекнең булуы мөмкин түгел! Моны фанатик татарлар гына уйлап чыгара ала – хөкемчеләр шулай

дип уйладылар. Киңәш-табыш иткәннән соң, Гөләйзага «Инжил» дә, Коръән дә тоттырмаска булдылар, шулай итеп, мәхкәмә башта ук канунсыз, антсыз, присягасыз башланып китте. Бу эшкә бигрәк тә Биләр атакае Михаил Лавровның ачуы килде, бер татар хатынының урыс өчен изге булган китапны кулына алырга да чиркануы аны ярсытты, гарьләндерде, ул үзен чакка тыеп утырды. Башта Биләр побы Михаил Лавровның Гөләйзага карата дәгъвасын укыдылар, аннан атакайның үзенә дә сүз бирделәр. Ул «Библия»не тотып, бары тик дөресен генә сөйлим, дип ант итте һәм сүзгә керешге:

– Кыр Шонталасы авылыннан чукындырылган Пелагея үзе дә законсыз туган, атасы кем икәнлеге билгесез, хәзер улын да чиркәүгә алып килеп чукындырырга теләми. Бу хакта аны урындагы поплар да, полиция хезмәткәрләре дә кат-кат кисәттеләр, әмма ул безне тыңламады. Шуннан соң мин, чара күрүләрен сорап, Казанга, чиркәү суды булган консисториягә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдым. Архиепископ Владимир атакай Пелагеяне җирле суд аша чиркәү кануннары буенча яшәргә мәҗбүр итәргә, дип әмер бирде. Ул олы баласын чиркәүгә алып килеп чукындырмаган, ул арада инде икенчесе туган, аны да чукындырмаган, безнең изге христиан кануннарыбызны бар дип тә белмичә, керәшен көенчә басурман ире белән яшәп ятуын дәвам итә. Бүген юлдан язган татар хатынына карата дөньяви суд үз сүзен әйтергә тиеш, бу башкаларга гыйбрәт өчен кирәк, башкалар да шулай азынмасын өчен кирәк! Калганын үзебез христиан дине кысаларында хәл итәрбез.

Якуб атакай Биләр побының сүзләрен Гөләйзага тәрҗемә итә барды, аларны ишетеп, ул тынсыз калды, бу кадәр ялганны, нахакны башына сыйдыра алмады. Инде килеп Гөләйзаның үзенә дә сүз бирелде.

– Минем исемем – Гөләйза, – дип башлап китте ул сүзен, каушавын җиңәргә тырышып. – Мин беркайчан урысча Пелагея дип аталмадым, әни мине һәрчак татарча исем белән – Гөләйза дип йөртте... Әнинең үзенең урысча да, татарча да исеме бар иде, урысчасы – Фекла Тимофеева, татарчасы – Гөлзада, аны бөтен кеше Гөлзада, дип йөртә. Әтиемне белмим, әни мине кечкенәдән мөселман-татар динендә тәрбияләде, урыс динен өйрәтмәде, мин беркайчан да насари дине йолаларын үтәмәдем, аларның нәрсә икәнен дә белмим. Кәнисәдә булганым, чукынганым юк, моның өчен мәхкәмәгә дә тартылганым юк... Мин урысча белмим, аның динен дә белмим, белергә дә теләмим, чөнки мин – мөселман кешесе, әлхәмдүлиллаһ!..

Гөләйза шушыларны сөйләде дә туктап калды, Якуб атакай аны мәхкәмә өчен тәрҗемә итте. Гөләйзаның соңгы сүзләреннән Биләр атакае куырылып килде, ул ниндидер бер авыл хатыныннан шушы сүзләрне ишетермен дип башына да китермәде! Кара син аны, юк кына бер татар хатыны, хөкемдарларның күзенә туры карап, мин мөселман кешесе, дип чәчрәп торсын әле! Баш өстендә балта эленеп торганда, үзен шушы мәхкәмәдән үк монастырьга озатасыларын белгәндә, ике баласының язмышы кыл өстендә булганда – ничек һаман үз диненә ябышып ятарга мөмкин?! Ирләре дин өчен үлемгә бара, төрмәләрдә, монастырьларда җан бирә, хатын-кызлары балаларын чукындыртмас өчен дөнья буйлап сукбайлыкта йөри, Себер китсә китә – христиан дине алмый! Кайдан көч таба бу халык?! Казанны алганга, дәүләтләрен юк иткәнгә, үзләрен кол иткәнгә дә өч йөз ел тула бит инде, ә алар һаман татар булып калган, ислам динендә.

Яшь кенә бер татар хатынының судта үзен тыныч тотуы, үз-үзенә ышанып сөйләве хөкемдарны да гаҗәпләндерде. Ул инде бу хатын елый башлар,

балаларыма гына тия күрмәгез, дип ялварыр, үкенеп тәүбә итәр, нәрсә кушсаң, шуңа ризалашыр, дип уйлаган иде. Юк, ул, әнә, почмакка куып кертелгән, канаты каерылган кош кебек, талпынып-талпынып үз-үзен, алай гына да түгел, үз динен яклый! Хөкемдар аңа өстәмә сорау биреп карарга булды:

– Чиркәү документларыннан күренгәнчә, анаң Фекла Тимофеева – чукындырылган булган, син аны үзең дә шул исем белән атадың. Чиркәү кануннары буенча, анасы христиан булгач, аның балалары да христиан динендә исәпләнә, ягъни, алар чукындырылырга һәм чиркәү кенәгәләрендә теркәлергә тиеш. Әниең моны белгән, әмма белә торып, сине – христиан динендәге кешене мөселманга кияүгә биргән. Ә бу исә – бик зур гөнаһ һәм олы җинаять санала. Шушыларны белә торып, син, Пелагея, нигә мөселман кешесенә кияүгә чыгарга ризалык бирдең?

– Мин боларны белмәдем, чөнки мин туганнан бирле ислам динендә тәрбияләндем, үземне мөселман дип санадым. Мине Чирүле Шонталасыннан Хәким Камаев исемле татар хатынлыкка сораткач, әни, алай да, Кызылъяр атакаена барып, киңәшеп килде, үзенең урысча исеме булгач, шикләнгәндер, бәлки. Попның исемен белмим, ул мине чиркәү кенәгәләреннән тапмаган, татар кешесенә кияүгә чыгарга рөхсәт биргән. Шулай итеп, мин моннан дүрт ел элек Хәким Камаевка кияүгә чыктым...

– Никахны ничек, кайда укыттыгыз – чиркәүдәме, әллә мулла укыдымы?

Гөләйзаны атасы алдан өйрәтеп куйды, мулла никах укыганны әйтмәскә кушты, чөнки моның өчен аны төрмәгә утыртырга мөмкиннәр икән.

– Фәкыйрьлегебез сәбәпле, никах укытмадык... Бу ирдән ике балабыз туды: Габделвахитка – өч яшь, Габделҗәббарга – ике ай ярым.

– Ә нигә аларны чиркәүгә алып барып чукындырмадыгыз?

– Чөнки аларга исемне авылыбызның мулласы Әхмәт хәзрәт куйды, мөселманча йола үтәп, мәчет кенәгәсенә теркәде. Без шул җитте, дип уйладык, чөнки балаларымның аталары да мөселман, мин дә ислам динендә, Аллага шөкер! Шушы вакыт эчендә бер генә поп та миңа килеп, балаларымны чукындырырга кушмады, мин кайсы чиркәүгә барасымны да белмәс идем, чөнки гомеремдә дә анда йөргәнем юк.

Гөләйза дөрес сөйли иде, аны Кыр Шонталасында торганда да, Чирүле Шонталасына кияүгә чыккач та поплар борчымады, бәлки бу әтисе Ишмөхәммәтнең алар белән эш йөртә белүеннән килгәндер. Кыр Шонталасында, гомумән, гаярь мишәрләр яши, алар хәзер поплардан курыкмый, кубызларына биеми, керәшенлектән качу өчен мең төрле юлын таба. Инде Гөләйзаны да әллә кайдагы Чирүле Шонталасыннан бөтенләй дә эзләп тапмаслар, әкренләп кемлеген, кайдан килгәнлеген онытырлар, дип уйлаганнар иде, нәкъ менә аны эзләп табып, суд каршына бастырдылар. Бу да Аллаһның бер сынавы инде, тәкъдирендә шул язылган булгандыр...

Әмма аның бу дөреслеге мондагыларга кирәк түгел иде, хөкемдар рөхсәте белән, тагы Биләр побы телгә килде.

– Ялган, бар да ялган! – диде ул, үз сулышына буылып. – Бик яхшы белә бу хатын үзенең чиркәү кенәгәсендә теркәлгәнлеген! Шуңа күрә туган авылыннан әллә кая олаккан! Безгә ничә ел кирәк булды аның эзенә төшәргә! Хәзер барысы да закон кушканча булачак, үзе дә, балалары да чиркәү карамагына күчәчәк, мин мәхкәмәнең гадел хөкем чыгарачагына ышанам!

– Юк, Аллаһ шаһит – мин ялган сөйләмим! Мин беркайчан чукынмадым, чиркәүдә булмадым, урыс динен тотмадым, үз динемдә булдым! Кулыма

Коръән тотып ант итәм – мин мөселман! Минем исемем Гөләйза! Мин Пелагея түгел, мин урыс түгел, мин – татар кешесе!

Гөләйза, күкрәгенә яшергән Коръәнен кулларына күтәреп, шушы сүзләрне кабатлады, Якуб атакай тәрҗемә итеп өлгермәсә дә, аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңладылар. Гөләйзаның зур яшькелт күзләреннән энҗедәй күз яшьләре тәгәрәп төште дә, кулындагы Коръән өстенә тамды. Ул изге китапны күкрәгенә кысты, аннан ут булып янган йөзен аңа куйды, төшендә Әкълимә әби өйрәткән дога исенә төште. «Бисмилләәһиррахмәәниррахииим. Үә биһии нәстәгиину үә биһил хәүлү үәл кууәтү рабби сәһһил үә йәссир гәләйнәә йәә мүйәссира күлли әмрин гәсиир» – «Раббым, авырайтма, җиңеләйт! Көч-куәт бары тик Синдә, ярдәмеңнән ташлама!» дип пышылдады. Шушы догадан соң Гөләйза тынычланып киткән кебек булды, үзен кулга алды. Әкълимә әбинең төшендә әйткән сүзләрен хәтерләде: «Син мөселман башың белән кяферләрдән куркып торма! Алар бездән курыксын, чөнки гаделлек безнең белән, Аллаһ безне яклаячак!»

– Бу поп ялган сөйли, – диде ул, үзен тәмам кулга алып. – Мин аны гомеремдә беренче тапкыр күрәм, Кызылъяр атакаен да күргәнем булмады. Мин ак патшаның, диндә көчләү булмаска тиеш, дигән сүзләрен дә беләм. Татарларның ак патшадан ярдәм сорап, меңләгән үтенеч язганын да беләм! Һәм мәхкәмәнең миңа карата гадел булуына, балаларымны аерып алмавына, безне чукынуга хөкем итмәвенә өметләнәм...

Шулчак ишек артында сулкылдап сабый бала елый башлады, әйтерсең лә ул да әнисенә кушылып өзгәләнә иде... Ул арада ишектән икенче бала йөгереп килеп керде һәм әнисенең аякларына килеп ябышты, «әниемне бирмим!» дип кычкырып еларга тотынды. Мәхкәмә бүлмәсендәгеләр бу хәлләрдән шашып калды, аларның судта мондыйны күргәне юк иде! Урысның телен дә, динен дә белмәгән һәм белергә дә теләмәгән бер татар хатыны, баш очына Коръән күтәреп, мәхкәмә алдында үзенең мөселманлыгына ант итә! Үлемнән, төрмәләрдән курыкмыйча, кемлеген яшермичә, ислам диненә шәһәдәтлек бирә! Илсез, җирсез, хокуксыз калган бер татар хатыны бүген үзе өчен дә, дине өчен дә ана арыслан кебек көрәшә!

## «Минем исемем Гөлзада!»

Бу хәлләрдән соң мәхкәмә эшендә тәнәфес ясап алдылар, Гөләйза белән баласын бүлмәдән чыгарып җибәрделәр, Гөлзадага әзерләнә торырга куштылар. Гөләйза әнисе янына кисеп аткан тал-тирәк кебек чыгып ауды, аның җаны актарылган иде, әйтерсең лә тәненнән бөтен җелеген суырып алдылар! Кызын бу хәлдә күреп, Гөлзада аны диварга сөяп утыртты, башына берсеннән-берсе куркыныч уйлар килде, Гөләйзаны хәзер үк төрмәгә җибәрәләр икән, дип уйлады.

– Юк, әни, мәхкәмә бетмәде әле, хәзер сине чакыралар, – диде Гөләйза, бераз сулу алгач.

Аннан хәлсез куллары белән сабыена үрелде, баласыннан килгән җылы тән исен, сөт исен күкрәгенә тутырып сулады, «Аллага шөкер, без бергә!» дип куйды. Аннан мамык шәл астындагы Коръәнен әнисенә бирде, анда кергәндә, үзең белән булсын, диде. Ул арада Гөлзаданы да мәхкәмә бүлмәсенә чакыртып алдылар, Гөләйзадан әйттерә алмаган сүзләрне аннан әйттерергә өметләнеп, эшкә керештеләр. Гөлзадага да ант итәргә «Библия» китереп бирделәр, әмма ул аны кулына алмады, мин мөселман кешесе, диде.

– Исемең ничек? – дип сорады аннан гаҗәпләнгән хөкемдар.

– Урысча исемем – Фекла Тимофеева, татарча атым – Гөлзада.

– Фекла булгач, син нинди мөселман буласың инде? Документлар буенча да син – чукындырылган керәшен татары, Тимофей кызы...

– Әйе, мин чиркәү кенәгәләрендә шулай язылган, әмма минем беркайчан да кәнисәдә тәүбә-истигъфарда булганым, аруландырылганым юк... Үзем дә, нәселем дә дин ирегә килү белән, исламга кайттык, мөселманча, намаз укып, ураза тотып яшибез, әлхәмдүлилләһ!

– Екатерина патшабикә заманында дин ирегә килү – ул әле христиан динен ташларга ирек килде, дигәнне аңлатмый, андый хәлнең гомер булганы юк, булмаячак та! Син, Фекла Тимофеева, тумыштан христиан динендә булган, ата-анаң христиан, балаларың да шушы диндә булырга тиеш!

– Минем атам-анам да, мин үзем дә, балаларым да тумыштан насарилар түгел, без – мөселманнар, шушы җирләрдә мең ел буе ислам динен тоткан болгар-татарларның нәсел дәвамчылары! Атам-анамны моннан йөз ел элек Кыр Шонталасы авылында Поп елгасына куып кертеп, көчләп чукындырганнар, әле алар ул вакытта үсмер балалар гына булган. Судан өстерәп чыгарып, муеннарына тәре асканнар, чиркәү кенәгәләренә урыс исемнәре белән теркәп куйганнар. Бәхетләренә, башта аларны туган авылларыннан сөрмәгәннәр, алар шунда буй җитеп өйләнешкәннәр, без туганбыз. Чиркәү кенәгәләрендә керәшен дип язылсалар да, атам-анам яшереп ислам динен тоткан, яшерен никах укытканнар, безгә дә мулла мөселманча исем куйган, минем исемем – Гөлзада, Фекла түгел...

– Син үзеңне кем дип тә атый аласың, әмма закон каршында син – чукындырылган христиан хатыны Фекла Тимофеева! – дип, аны бүлдерде хөкемдар. – Атаң-анаң да христиан! Аларның да чиркәүгә йөрү-йөрмәүләрен тикшерергә кирәк булачак, христиан динен тотмыйлар икән, чиркәүле урыс авылына күчерергә кирәк, басурманнар арасында азып ятмасыннар!

– Алар юк инде, алар мәрхүмнәр... Кыр Шонталасында ислам динен тотып ятканыбыз өчен, безнең гаиләне Болгар ягында урыс авылына күчерделәр, бер кечкенә генә өйгә урнаштык. Әти-әни анда да нык торды, үзләре дә чиркәүгә йөрмәде, безне дә йөртмәделәр. Поп килеп көн дә үгет-нәсихәт биреп карады, әти-әни «суйсалар да урыс динен алмыйбыз!» диделәр. Шуннан соң аларны, аяк-кулларын бәйләп, кара мунчага яптылар, үзләре белән аз гына су һәм ипи бирделәр. Без, балалар, урыслардан кача-поса гына, ул мунча янына барып, ишек аша гына әти-әни белән сөйләшә идек, алар безгә ни булса да үз динебезне тотарга кушалар иде. Бер килгәндә, коточкыч хәл күрдек – мунча ишеге йозакка бикләнгән, ә бөтен тишек-ярыклардан ургылып кара төтен чыга... Эчтән әти-әнинең буылып ютәлләүләре, ыңгырашулары, «Аллаһ! Аллаһ!» дигән сүзләре ишетелә... Тышта без үкереп елыйбыз, бикле ишекне тырныйбыз, эчтә аларның бәхилләшү авазлары ишетелә... Соңыннан билгеле булды – аларны чи карабодай саламына ут төртеп, төтенгә тончыктырып үтергәннәр икән... Аларны күмүче дә булмады, хәтта поп да баш тартты, алар урыс диненә килмәде, диде. Без, балалар, аларны Идел буендагы бер калкулыкка алып барып күмдек, елый-елый үзебезчә дога кылдык. Аннан соң безне урыс гаиләләренә бирделәр, алар үзләре белән көчләп чиркәүгә йөртергә тырыштылар, без тыңламадык, шуның өчен күпме кыен алдык, газап күрдек, кимсетүләр кичердек...

Гөлзада тынып калды, урыс авылында үткән бәхетсез балачагы күз алдына

килде... Әйе, монда аның өчен бөтенесе дә чит-ят иде – өйләре дә, үзләре дә, ашаулары да, киемнәре дә, телләре-диннәре дә... Гөлзада аларның телләрен аңламады, диннәрен кабул итмәде, кара мунчада төтенгә тончыгып үлгән ата-анасы күз алдыннан китмәде, колагында гел «Иманны саклагыз!» дигән сүзләре яңгырап торды. Ул аларның ризыкларын ашый алмады, дуңгыз итеннән пешкәндә үк күңеле болгана башлый иде, җәйләрен болын-әрәмәләрдә төрле үләннәр, җиләкләр, шомырт-миләшләр ашап үткәрде, кышларын ач була иде... Туганнары төрле авылларга таратылганга, ул аларны да күрә алмый, хәлләрен белми иде. Язын калкулыкларда кар эрү белән, ул Идел ярындагы әти-әнисе кабере янына йөгерә, аның өстенә капланып ятып, салкын туфракны кочып, үксеп-үксеп елый иде...

Ул, кайдадыр еракта, шушы урман артларында, туган авылы барлыгын да белә, шунда чыгып йөгерәсе, бу тәмугтан качасы килә, әмма курка, чөнки арттан куа чыгып тотсалар, кыйнаячаклар, әти-әнисен газаплаган кебек, әле кара мунчага да ябып куюлары бар... Инде буй җиткән кызга әйләнеп бара, аны берәр урыска кияүгә биреп куюлары да бар, ул чагында инде төрмәсенең ишекләре мәңгегә бикләнәчәк, үзе кяфер колына әйләнәчәк... Гөлзаданың иң курыкканы шул иде, чөнки ул күпме татар кызларын, көчләп чукындырылганнан соң урысларга кияүгә биреп, харап булганнарын, юкка чыкканнарын белә иде. Аны да күзәтәләр ахры, өйдән ерак җибәрмиләр, кичке якта урамга чыгармыйлар, башкалар белән аралаштырмыйлар. Хәер, кем белән аралашсын соң монда Гөлзада-Фекла, телләрен белми, үзләрен сөйми, сөйләшмәгәч, инде үз телен дә онытып бара... Аның каравы, бөтен авыр эш аңа, бу бит әле яшь, буыннары да ныгымаган, дип тормыйлар, ирләр белән бергә урман да кистерәләр, печән дә чаптыралар, ябык иңнәрендә капчык-капчык бәрәңгесен дә ташыталар, көтү дә көттерәләр, җир дә казыталар... Бәлки шулай егылып үлгәнен көтәләрдер, бер кашык ким булачак бит!

Гөлзада үзе дә шулай уйлый башлаган иде инде, чөнки бу коллыктан бүтәнчә котылу юлы күренми. Ул инде күптән мәңгегә күзләрен йомган булыр иде, әмма мөселманлыгы тота, чөнки үз-үзеңә кул салуның бик зур гөнаһ икәнлеген белә. Әнисе Гөләйзар әйтә иде, кызым, тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан, бу адәм баласына зур сынау, нинди хәлдә калсаң да, Аллаһтан өметеңне өзмә, язмышыңны Аңа тапшыр, дия иде. Шуңа күрә Гөлзада да ниндидер могҗиза булыр һәм кемдер аны бу коллыктан коткарыр, дип көтте. Һәм Алланың рәхмәте белән, ул могҗиза булды.

Ул көнне Гөлзаданы Идел буендагы болынлыкка печән җыярга җибәрделәр, үзләре ни сәбәп беләндер өйгә кайтып киттеләр. Алар инде телсез бу татар кызының беркая да китмәсенә ышана башлаганнар иде, аның барыр җире юклыгын да беләләр иде. Гөлзада, кипкән печәнне күбәләргә өеп куйгач, Иделгә төшеп, юынып менәргә уйлады, чөнки өйдә аңа мондый мөмкинлек юк иде диярлек. Ул, өстендәге киеме белән елганың сайрак урынына кереп, башта бит-кулларын юды, аннан түзә алмыйча, бөтен гәүдәсе белән суга чумды. Рәхәт, бик рәхәт иде аңа, әйтерсең лә тәнендә еллар буе ябышып яткан кара корымны юып ташлады, җаны сафланып китте, күңелендә ниндидер яктылык, өмет пәйда булды. Ул яшь, сәламәт, үз акылында, нигә әле бу урыс авылында череп, үлем көтеп ятарга тиеш? Качачак, һичшиксез, качачак ул моннан, берәр татар авылына килеп чыгар әле, алардан Шонталаның кайда икәнен сорар, шунда кайтып егылыр, авылдашлары тотып бирмәсләр әле...

Шундый уй-ниятләр белән, Гөлзада судан чыкты, озын күлмәк итәкләрен

сыгып, киемнәрен өстендә килеш кенә кояшлы җилдә бераз киптереп алды. Тирә-якта кеше юклыгына ышангач, алтындай озын чәч толымнарын да яулык астыннан чыгарып, җил-кояш иркенә бирде, бу рәхәтлектән үзе балалар кебек сөенде... Шулай бераз мавыккач, чиста тәне белән намаз укып алырга булды, чөнки монда беркем дә юк, иркенләп укырга була, өйдә исә ул юрган астында, яткан килеш кенә намазларын укырга мәҗбүр була иде. Башындагы ике кат яулыгының берсен намазлык итеп җәйде, кояшка карап, кыйбланы һәм вакытны чамалады да намазга басты. Намазын укып бетергәч, озак итеп дога кылды, Аллаһтан бары тик бер нәрсә – үзен бу коллыктан коткаруын сорады...

Ә аның коткаручысы яр буенда басып тора иде...

Ишмөхәммәт ул көнне, атына атланып, Болгардан Биләр ягына кайтып бара иде. Сәфәренең сәбәбе – теге куркыныч елларда Шонталадан урыс авылларына күчерелгән авылдашларын барлау, аларның хәлләрен белү, кулдан килгәнчә ярдәм итү иде. Әлбәттә, мондый хәвефле юлга ул үз белдеге белән генә чыгып китмәде, авыл картлары җыелып сөйләшкәннән соң, Чистай морзалары киңәше белән, шул фикергә килделәр. Ишмөхәммәт яшь иде, гайрәтле һәм иманлы ир-егет иде, ил картларының сүзен үтәргә ул алынды. Биләрдән Болгарга хәтле күп авылларда булды ул, күп хәлләр күрде, русча аз-маз белүе, ялган булса да, керәшенлеге дә ярдәм итте, алар арасында – Измаил Ефремов булып, татарлар янында Ишмөхәммәт Уразманов булып йөрде. Һәр авылда диярлек Чистай-Биләр төбәгеннән сөрелгән татарлар бар иде, Ишмөхәммәт аларның кайберләре белән очрашып сөйләште, күп нәрсәләрне хәтеренә сеңдерә барды, мәгълүмат туплады. Күпләрнең кире үз авылларына кайтасы килә иде, әмма куркалар, моның өчен Себергә сөрерләр, дип хәвефләнәләр.

Идел буендагы бу урыс авылына Ишмөхәммәт елгада юынып чыккач керергә булды. Яр буенда атын төшерергә җайлы урын тапкач, аска карады һәм телсез калды – суда өс киемнәреннән бер кыз коена, ә алтындай чәч толымнары дулкын өстендә тибрәлә иде... Ишмөхәммәт күзләрен читкә борды, кызны куркытмас өчен, аска төшмәскә булды, атын болынга җибәреп, үзе намазын укып алды. Инде эшен бетереп, яңадан атына менеп атланды һәм китәр алдыннан, түзә алмыйча, тагы яр астына карады – кыз бала, кыйблага карап, намаз укый иде. Ишмөхәммәткә аның йөзе таныш кебек тоелды, әмма кем икәнлеген исенә төшерә алмады, бу урыс авылы тирәсендә мөселман кызы нишләп йөри икән, дигән уй башына килде. Нидер сизенгәндәй, Гөлзада да башын күтәреп, өскә карады, ак атка атланган яшь ир-атны күреп, башта куркып китте, аннан бу кешенең йөзе таныш кебек тоелды, ул, тал-чыбыкларга тотынып, яр өстенә үрмәләде. Әйе, Гөлзада аны белә иде, бу – алар авылыннан Ишмөхәммәт абый бит, Әминә апаның ире!

– Ишук әзи! – дип кычкырып җибәрде ул, үзе дә сизмәстән. – Мин – Гөлзада, Шонаталадан!

Ишмөхәммәт сикереп атыннан төште, кызга текәлебрәк карады.

– Син Бикмөхәммәт әзи белән Гөләйзар апайның кызы түгелме соң?!

– Әйе, шуларныкы, Ишук әзи!

– Танымаслык булып үзгәргәнсең, үскәнсең, сеңлем! Сезне Шонталадан урыс авылына сөргәндә, үсмер бала гына идең кебек... Әти-әниең, башка туганнарың да шул авылда яшисезме?

Гөлзаданың күзләренә яшь бәреп чыкты, авылдашының күкрәгенә капланып, үксеп елыйсы килде, әмма уңайсызланды. Аның инде ничә еллар үз телендә сөйләшкәне юк иде! Аның инде ничә еллар үз авылдашын, үз

милләттәшен, дин кардәшен күргәне юк иде! Һәм ул бу кешедән калмаска тиеш иде...

– Әти-әни юк инде, Ишук әзи, аларны урыслар кара мунчага бикләп, төтенгә тончыктырып үтерделәр, чөнки алар ислам динен ташламадылар... Туганнарымны башка авылларга тараттылар, кайда икәнлекләрен дә белмим... Мине дә урыска кияүгә бирергә җыеналар... Ишук әзи, Аллаһ ризалыгы өчен, калдырма мине монда! Телләрен белмим, диннәрен кабул итә алмыйм, ризыкларын ашамыйм, инде ничекләр шул кяферләрдән нәсел калдырыйм, мин мөселман кешесе бит! Коткар мине бу тәмугтан!

Шулай диде дә, уңайсызлануын да онытып, ул Ишмөхәммәтнең күкрәгенә капланып елап җибәрде. Аны өзелеп кызганудан, бу бәхетсез кыз балага ярдәм итәсе килүдән, тагы әллә нинди кайнар хисләрдән Ишмөхәммәтнең бөтен җаны актарылып китте, ул Гөлзаданың курчакныкыдай нәфис кулларыннан тотты һәм өздереп:

– Елама, сеңлем, мин сине монда калдырмыйм! – диде. – Мөселман кешесе буларак та, авылдашың, милләттәшең буларак та, мин сине бу явызлардан araларга тиеш! Риза булсаң, мин сине моннан алып китәм, хәзер үк алып китәм!

– Риза, Ишук әзи... Ишмөхәммәт абый... Мин бит Аллаһтан сорадым, мине бу тәмугтан коткарырга ярдәмче, сәбәпче бир, дидем! Кая алып китсәң – шунда китәм, хәзер үк китәм, чөнки мин сиңа ышанам!

– Болай эшләрбез, сеңлем... Тегеләр арттан куа чыкмасын өчен, бераз хәйлә корыйк... Бу тишек чабаталарыңны яр астына ыргыт, бер кат яулыгыңны талтирәкләргә элеп калдыр. Яулыгыңнан эзләп табарлар, яр буенда чабаталарыңны күреп... суга батып үлгән, дип уйларлар, эзләп йөрмәсләр.

Гөлзада ул әйткәнчә эшләде – әле генә намаз укыган олы яулыгын яр буендагы куакларга элеп куйды, ә тишек чабаталарын болгый-болгый аска атты. Аңа Шонталадагы бала чагы әйләнеп кайткан кебек булды, шатлыгы эченә сыймады, шушы мизгелләрдә тормышында иң зур үзгәрешборылышлар буласын ул сизенә иде... Ул күк йөзедәй саф зөбәрҗәт күзләрен тутырып Ишмөхәммәткә текәлде, һич сәбәпсезгә йөрәге оеп киткәндәй булды, үз хәлен сиздермәс өчен, кыз бала уңайсызланып читкә карады... Ишмөхәммәт абыйсы аны нечкә биленнән тотып, атка менгереп утыртты, иярен аның астына салды, аннан бер җилпенүдә үзе дә атның биленә менеп атланды. Һәм алар, Биләр ягына карап, чаптырып кузгалып та киттеләр, кара төтенгә батып утырган урыс авыллары, Гөлзаданың анда үткән кара, бәхетсез көннәре артта калды, алда аны туган авылы, үз милләттәшләре, дин кардәшләре көтә иде... Алда аны шәхси бәхете, олы мәхәббәте, гаилә тормышы, балалар куанычы көтә иде...

Ишмөхәммәт Гөлзададан ун яшьләргә олы, инде гаиләсе, балалары бар, әмма аңа да яшьлек дәрте, гаярь егетлеге әйләнеп кайткан кебек булды, ул, йөгәнне кысып тотып, тузаннар туздырып, аты белән бергә киләчәгенә томырылды... Юлдагы вак ташлар чәчрәп читкә очты, каршы искән тыгыз җил битләрдән иркәләде, Гөлзаданың алтындай толымнары, җил уңаена яулык астыннан шуып чыгып, Ишмөхәммәтнең муенына уралды... Аның язмышы да шулай итеп шушы гаярь ир-егетнең тормышына уралды, уртак язмышка әйләнде... Киләчәкләренә томырылып очып барган уңайга, алар күпме генә бер-берләреннән читкә тартылырга теләсәләр дә, тәкъдирләре тәннәрен дә, җаннарын да бергә кушты... Ишмөхәммәт зәңгәр күзле, алтындай озын толымлы бу кыз бала өчен дөнья кадәр җаваплылык тойды, шул ук вакытта

ул аны бөтен дөнья байлыгына да алыштырмаячагын аңлый башлаган иде. Гөлзада исә балалар кебек чыркылдап көлә, ат кушаяклап чапканда, куркып аның ялларынаябыша, Ишмөхәммәт абыйсына сыена... Ул гомерендә беренче тапкыр үзенең артында терәк барлыгын аңлады, арка терәген тойды, яклаучысы, саклаучысы барлыгын сизенде, кыз бала гомерендә беренче тапкыр сөю хисләре кичерә иде...

Көннең икенче яртысында Көек авылына якынлашканда, Ишмөхәммәт бер фикергә килгән иде инде, әмма моны Гөлзадага ничек җиткерергә белмәде. Ул бу авылның мулласын яхшы белә, бу якка килешли дә аларда тукталып, кунып чыккан иде. Менә хәзер икәүләп кайтып киләләр, кем дип әйтер ул Гөлзаданы аларга? Хәер, анысы ничек бар – шулай әйтә ала, эш анда да түгел, ул Гөлзаданың үзе өчен юлаучы бер кыз гына булмыйча, иң якын кешесе, гомерлек юлдашы булуын тели, тик ничек әйтергә моны аңа? Әйе, Ишмөхәммәт гаиләле, балалары бар, әмма татарда берничә хатын белән тору гадәте дә юк түгел, моны ислам дине рөхсәт итә. Гөлзаданың хәзер авылда беркеме дә юк, яклаучысы юк, ул ятим бала, аны теләсә кайсы вакытта эзли килергә мөмкиннәр. Шул вакытта кемнәргә сыеныр ул? Ишмөхәммәт тә, гаиләле кеше буларак, һаман-һаман янында булмас, яклый алмас, Гөлзада аның никахлы хатыны булса, ул аны яклап, утка да, суга да керәчәк... Әмма ничек әйтергә моны аңа, аңлармы, санлармы, тыңлармы?

Ишмөхәммәт авылга җиткәнче туктарга булды, атын елга буендагы әрәмә ягына борды. Кызны ул тагы күтәреп төшерде, су белән чистарынып, юл тузаннарын юдылар, бергәләп намазларын укыдылар. Ишмөхәммәтнең үзе белән алган ризыгы да бар иде, табын җәеп, аны ашап алдылар, чишмә суы белән сусауларын бастылар... Әйтерсең лә алар менә шулай гомер буе бергә булганнар, бу чишмә буена да үтеп барышлый гына туктаганнар, әйтерсең лә киләчәктә дә гел шулай бергә булачаклар...

Һәм Ишмөхәммәт сүз башларга батырчылык итте.

– Гөлзада сеңлем, сиңа бик җитди әйтер сүзем бар, – дип башлады ул, бераз уңайсызланып. – Дөрес аңларсыңмы икән, дип борчылам... Син ятим бала, атаң-анаң, туганнарың юк, авылда да беркемең юк... Тагы андый-мондый хәл була калса, яклаучың да юк...

Шулай диде дә туктап калды, иң кирәген әйтергә батырчылык итмәде. Гөлзада куркып аңа карады, күз карашлары очрашкач, икесе дә эсселе-суыклы булып киттеләр.

– Әллә син мине монда калдырып китәргә уйлыйсыңмы, Ишмөхәммәт абый?! Атыңнан төшерсәң, мин җәяү артыңнан кайтырга да риза, монда гына калдырма!

– Юк, сеңлем, мин сине җәяүләп авылга хәтле кулларымда күтәреп кайтырга да риза, нинди калдыру ди ул?!

– Алайса ник алай дип әйтәсең соң?

– Ничек башларга белмим, ничек әйтсәм дә, дөрес аңламассың кебек... Сеңлем... Гөлзада... Мин сине гомер буе бөтен авырлыклардан саклап яшисем килә...

Гөлзада аның ни әйтергә теләгәнен сизенә башлады, диңгездәй зур, серле күзләрен тутырып, Ишмөхәммәткә карады, сүзенең дәвамын көтте.

– Минем никахлы хатыным булырга риза бул, сеңлем, чык миңа кияүгә!

– Әминә апа, балаларың бар бит, Ишмөхәммәт абый!

– Булсын, татарда ике хатын белән тору гадәте бар, безнең авылда да бар

андыйлар... Дөрес, урыс попларыннан моны яшерәләр, чөнки алар динендә ике хатын белән яшәү тыелган, ә бездә ярый.

– Ә Әминә апа нәрсә дияр, рәнҗемәсме?

Ишмөхәммәтнең эченә җылы кереп китте, кырт кисеп, «юк» димәде бит әле, һаман Әминә апасы өчен борчыла!

– Юк, Әминә апаң сүз әйтмәс, мөселман хатыны бит ул, Аллаһ рөхсәт иткәнгә каршы бармас. Монда синең сүзең, синең ризалыгың мөһим, сеңлем!

Гөлзада бу мизгелләрдә үзенең язмышы хәл ителгәнен аңлады, аңа дөрес фикергә килергә кирәк иде. Бу кешене ул бер күрүдә ошатты, аны тормышында бер яктылык, терәк, яклаучысы дип кабул итте, әмма хатыны булу турында башына да китермәде! Ә ул хәзер җавап көтә, бу сүзләрне уйнап сөйләми...

– Син риза булсаң, бүген үк Көек мулласыннан никах укытырбыз, мин аны беләм, ул ризалашыр, – дип дәвам итте Ишмөхәммәт. – Авылга да ир белән хатын буларак кайтып керербез, халык аңлар. Ә болай... мин Көек мулласына сине кем дип әйтермен, озын юлны тагы кемнәр буларак дәвам итәрбез? Без болай да артык якынайдык, сиңа тартылудан күңелемне тыя алырмынмы? Ризалаш, сеңлем, иң кадерле кешем булырсың! Атаң-анаң урынына да мин булырмын, туганнарың урынына да мин булырмын, ирең дә булырмын, балаларыңның атасы да булырмын, ризалаш, Гөлзада сеңлем!

– Мин риза, Ишмөхәммәт абый, – диде Гөлзада, калтыранган тавыш белән. – Мин үзем дә сине бер күрүдә ошаттым, әмма моның нәрсә икәнен белмәдем... Хәзер дә күп нәрсәләрне аңлап, белеп бетермим, әмма мин сиңа ышанам, Ишмөхәммәт абый!

Ишмөхәммәтнең өстеннән тау төшкән кебек булды, шул ук вакытта ул Каф таулары биеклегендә җаваплылык алганын да аңлады. Әмма ул – ир кеше, тормышта җаваплылык алудан куркырга тиеш түгел, иле, милләте, гаиләсе өстенә төшкән авырлыкларны күтәрергә, хәл итәргә тиеш! Авыр хәлдә калганнарга ул ярдәм итәргә, ул юл күрсәтергә тиеш! Ә Гөлзада аңа авырлык түгел, Аллаһ биргән бәхет, юлында очраган асылташ иде...

– Рәхмәт, сеңлем, сүземне аяк астына салмадың, моның өчен үкенмәссең, иншаллаһ! Мин сиңа терәк булырмын, тормышның бөтен авырлыкларын үз өстемә алырмын, без бәхетле булырбыз, Гөлзада!

Алар Көек авылына җәяү генә килеп керделәр, ат исә артларыннан атлады... Ишмөхәммәт муллага эшнең нәрсәдә икәнен аңлатты, аның исә мондый яшерен никахларны шактый укыганы бар иде, шунда ук ризалашты. Гөлзаданы абыстай тиз генә үз ягына алып чыгып китте, сандыгыннан берсеннән-берсе матур күлмәкләр, яулыклар чыгарды, чиккән калфакларын, читекләрен тезеп куйды, бу ятим кызны үз баласы кебек киендерде. Болгар ягындагы урыс авылында ирле-хатынлы татарларны төтенгә тончыктырып үтергәннәре турында ишеткәннәр иде алар, балалары өчен бик борчылганнар иде. Менә хәзер шуларның кызлары үз аягы белән аларга килеп керде, моны Аллаһның рәхмәте дими, ни дисең? Ул арада якын-тирәдән дә татарлар җыелды, заманында Шонталадан бирегә күчерелгән берничә гаилә булган икән, алар да йөгереп килеп җитте. Көек мулласы бөтен шартын китереп никах укыды, Ишмөхәммәт курчак кебек киенгән кәләшеннән күзләрен ала алмады, бу җәүһәрнең үзенеке булуына һаман ышанып бетмәде... Бөтен авыл аларга фатихасын бирде, бөтен авыл аларга бүләкләрен күтәреп килде, бөтен халык алар өчен дога кылды...

Икенче көнне ак юртакны Көек мулласының сиртмәле арбасына җиктеләр,

Ишмөхәммәт белән Гөлзаданы, кочак-кочак күчтәнәч-бүләкләр белән, Биләр ягына озаттылар... Алда аларны өр-яңа тормыш, өр-яңа сынаулар көтә иде... Ишмөхәммәт Гөлзаданы башта үз өенә – беренче хатыны янына алып кайтты, Әминәсе бу хәлләрне тәкъдир сынавы дип кабул итте. Гөлзада бик тыныч, күркәм холыклы, гаять тырыш булгач, алар гаиләсенә тиз кереп китте. Әмма Ишмөхәммәт чиркәү кенәгәләренә керәшен дип теркәлгәч, аңа ачыктан-ачык ике хатын белән тору тыелган иде, шуңа күрә ул Гөлзадага аерым өй салып бирде, аны шунда чыгарды. Хәер, мөселман тәртибе буенча да һәр гаилә үз йортында яшәргә тиеш иде.

Гөлзада Ишмөхәммәттән биш бала тапты, Гөләйза иң олысы иде, аннан – Бикмөхәммәт, Шәрифҗамал, Хупҗамал, Миңҗамал... Гөлзада аларның берсен дә чиркәүгә алып барып чукындырмады, рәсмиләр бәйләнмәсен, дип, Ишмөхәммәт улын үзенә теркәтте, барлык балалары да дин-исламда тәрбияләнделәр, мөселманлыкны тоттылар. Поплар да аларга әллә ни бәйләнмәде, алар белән эшне Ишмөхәммәт үзе йөртте, керәшенлек сәбәпле, гаиләсенә авырлык китертмәде. Хәер, ул елларда диндә хәзерге кебек кысу сизелми иде, Александр патша дигәннәре әбисе Екатеринадан калган сәясәтне дәвам итте, мәкруһларга артык бәйләнмәделәр. Менә бу яңа патша Николай дигәннәре барысын да яңадан өстерәп чыгарды – кем керәшен, кем урыс диненнән киткән, кем мәкруһ-отпавший... Гөлзаданың да Фекла Тимофеева икәнлеген казып чыгардылар, имеш, олы кызлары Гөләйза да Пелагея икән, инде башка балаларына да чират җитәргә мөмкин.

### Иман өчен көрәш

– Фёкла Тимофеева! Син мәрткә киттеңме әллә? Син суд каршында басып торасың – шуны онытма һәм сорауларга ачык җавап бир!

Бу тавыштан Гөлзада сискәнеп китте, Актау атакае татарчага тәрҗемә итеп биргәч кенә, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлады. Әйе, ул суд каршында басып тора, әйе, аннан кызы Гөләйза турында сорыйлар, әйе, аңа хәзер газиз баласын бу афәттән ничек тә йолып калырга кирәк!

– Кызың Гөләйза, мине чукындырмадылар, мин үземнең керәшен икәнлегемне белмәдем, шуңа күрә балаларымны да чукындырмадым, дип бара. Ник син аңа кемлеген әйтмәдең, атасының да кемлеген белми, чукыну-чукынмавын да белми, моның өчен синең үзеңне дә хөкемгә тартырга кирәк!

Гөлзада аларга дөресен әйтә алмый иде – Гөләйзаның атасы Ишмөхәммәт булуын мәхкәмәгә дә, попларга да әйтергә ярамый, чөнки урысларда ике хатын белән тору тыелган гамәл, ул чагында ирен хөкем итәчәкләр. Шуңа күрә, «балаларымның атасы билгесез», дип, болар каршында зиначы кебек басып торырга туры килә, и Раббым, дөресен үзең беләсең!

– Әйе, менә шул «атасы билгесез» булганга күрә Кызылъяр попы Гөләйзаны чукындырмады, үземне дә «зинадан туган», диде... Гөләйзадан соң туган улымны үзебезнең авылның керәшене Ишук тәрбиягә алды, поп аңа Иван дип исем бирде.

Гөлзада һәр сүзен бик уйлап, ашыкмыйча гына әйтергә тырышты, Ишмөхәммәтнең никахлы ире, ә Иван дип чиркәү кенәгәләрендә генә теркәлгән улының чынлыкта Бикмөхәммәт булуын, ислам динен тотуын әйтеп ычкындырырмын дип курыкты. Әйе, ревизия кенәгәләрендә Бикмөхәммәт Ишмөхәммәтнең тәрбиягә алган улы, керәшен татары, дип теркәлгән, әмма

бу ир баланы гаскәргә алмасыннар, лашманлыкка алып китмәсеннәр өчен эшләнгән мәҗбүри гамәл булды. Ни әйтсәң дә, керәшеннәрне солдатка алмыйлар иде, ә бу алар өчен бик мөһим, чөнки анда киткән кеше инде бөтенләй урыс булып кайта, алар динендә була. Боларның барысын да Ишмөхәммәт җайлады, әмма болай булгач, бу мәхкәмә дигәннәре Бикмөхәммәткә дә килеп җитәргә мөмкин, Гөлзаданың башка балаларын да тикшерүләре бар...

– Фекла Тимофеева! Тагы бер тапкыр исеңә төшерәм – син чиркәү кенәгәсендә чукындырылган керәшен, дип язылган, шуңа күрә дә балаларың да үзеннән-үзе христиан динендә булып исәпләнә! Ә син, шушыларны белә торып, аларга христиан тәрбиясе бирмәгәнсең, ислам белән башларын катыргансың! Кызыңны басурманга кияүгә биргәндә, син моның нәрсә белән бетәсен яхшы аңларга тиеш идең! Христиан хатын-кызын аздырган өчен, ireңә – төрмә, кызыңны исә монастырь яки яңа гаилә – урыс кешесе белән чиркәүдә венчание көтә! Шушыларны белә торып, нигә кызыңны басурманга бирдең?

– Мин боларның берсен дә белмәдем! Беркайчан да урысларның телләрен дә, диннәрен дә белмәдем, миңа боларны беркем, беркайчан аңлатмады. Мәрхүм әти-әнине көчләп чукындыру сәбәпле генә мин чиркәү кенәгәсенә керәшен дип теркәлгән, әмма ул динне тотмадым бит! Мин аны белмим дә! Ничек итеп мин балаларыма белмәгән нәрсәне өйрәтим ди? Алай да күңелемә шик килде, Гөләйзаны Чирүле Шонталасына мөселман кешесенә кияүгә бирер алдыннан, Кызылъяр попы белән киңәштем мин, ул вакытта инде анда яңа атакай иде. Ул чиркәү кенәгәләреннән кызымның исемен эзләде, әмма тапмады, ул керәшен буларак теркәлмәгән булып чыкты. Ничек теркәлсен – ул бит чукындырылмаган иде! Шуннан соң Кызылъяр попы Гөләйзаны мөселман кешесенә кияүгә бирергә ризалыгын әйтте.

– Кызылъяр попы ризалыгын бирдеме?

– Әйе, кызыңның атасы билгесез, үзе чиркәү кенәгәләрендә керәшен буларак теркәлмәгән, аның безгә бернинди катнашы юк, диде. Шуннан соң кызымны тынычлап мөселман кешесенә кияүгә бирдем.

Хөкемдар, бу хәлгә ышанырга теләмәгәндәй, Биләр атакаена карады, ул исә атылып торып басты һәм кулларын болгый-болгый сөйли башлады:

– Ялган! Бу мөмкин хәл түгел! Христиан дине әһеле андый әмер бирә алмый! Үзеңнең керәшен икәнлегеңне белә торып, поптан рөхсәт сорарга да кирәкми иде – чукындырылганның баласы да керәшен була! Фекла Тимофеева! Кызың да керәшен синең, Пелагея ул, бернинди дә Гуляйзя түгел, аның балалары да керәшен! Христиан динендәге кызыңа мөселман кешесе белән яшәү язык, сезнеңчә – хәрам! Аларны аерырга, ирен – төрмәгә, хатынын монастырьга ябарга, балаларын чиркәүгә алып барып чукындырырга һәм урыс гаиләләренә тәрбиягә бирергә кирәк! Судья галиҗәнапләре, сез бүген шул турыда карар чыгарырга тиешсез! Югыйсә бу татарваны берничек тә акылга утыртып булмаячак, бөтенләй азындылар, распоясались! Чиркәүгә йөрмиләр, исповедь-тәүбә кылмыйлар, причищение үтмиләр, христианча венчаниене танымыйлар, балаларын чукындырмыйлар, тәре такмыйлар, өйләрендә икона тотмыйлар, ә үзләре крещёный-керәшен дип атала! Моңа чик куярга вакыт!

Гөлзада кызының баш очында кара болытлар куера башлавын тәрҗемәсез дә сизенде, чөнки бу урыс попының йөзе дәһшәт чәчә, йодрыклары һавада уйнап тора иде. Якуб атакай аның сүзләрен тәрҗемә дә иткәч, Гөлзадада боларга карата бөтенләй ышаныч калмады, алар Гөләйзаның башына җитәргә җыеналар кебек иде. Ул, ана арыслан кебек, баласы өчен соңгы яуга ыргылды...

– Син моның шулай икәнлеген ник безгә баштарак әйтмәдең соң?! Биләр белән Шонтала арасы кул сузымында гына, нигә килеп, үз телебездә менә шушыларны аңлатмадың? Мин каян белим, керәшеннән туган балаларның да керәшен дип языласын? Ник килеп урыс динен аңлатмадың, мин каян белим аны ничек тотарга? Үзем белмәгәнне мин балаларыма ничек өйрәтим? Ник Кызылъяр побы ни элеккегесе, ни хәзергесе боларны аңлатмады, палицай белән чиркәүгә куудан башканы белмиләр, ә халык ярты юлда ук качып бетә?! Аларга бары тик чиркәүне һәм үзләрен тоту өчен акча гына кирәк, авылга килеп, егылып эчеп яталар... Сез үзегез гаепле татарларның динегезне яратмавында, кабул итмәвендә! Сездә мәрхәмәт юк, кешегә кеше итеп карау юк, хәзер дә җиңел генә гаиләне ботарлап ташларга уйлыйсыз! Аллаһ бер бит барыбыз өчен дә, моның өчен җәһәннәм утында янудан курыкмыйсызмы?!

Инде Гөлзаданы туктатырлык түгел иде, ул кемгә, ни өчен сөйләгәнен дә аңламыйча, эчендәгеләрне чыгарып түкте, еллар буе җыелган әрнүен һәм рәнҗүен җиткерде. Якуб атакай аның сүзләрен курка-курка гына тәрҗемә итте, чөнки мондый гаепләүләрне үзе дә көтмәгән иде. Бер авыл хатынының үзләренә болай һөҗүм итүен Биләр побы белән хөкемдар да көтмәгәннәр иде, шуңа күрә Гөлзада иркенләп сөйләп бетерә алды. Хөкемдар, мәхкәмәне тиз генә тәмамлап, Биләр побының шикаяте сәбәпле, Казан архиепископы таләп иткәнчә, Гөләйзаны приставлар озатуында чиркәүгә җибәреп эшне бетермәкче иде, әмма алай барып чыкмады. Хөкемдар күреп тора – очы-очка ялганып бетмәгән нәрсәләр шактый, һәм бу тиз генә карар чыгарып куюга комачаулый. Аның икеләнеп калуын сизгәндәй, Гөлзада тагы телгә килде, ире Ишмөхәммәт өйрәтеп керткән сүзләрне кабатлады:

– Без ак патшага үтенеч яздык, безгә яңадан үз динебезгә кайтырга рөхсәт итүен сорадык... Безнең әти-әниләребез моннан йөз ел элек урыс диненә көчләп кертелгән, үз ихтыярларыннан башка муеннарына тәре тагылган, чиркәү кенәгәләренә исемнәре керәшен дип язылган. Әмма алар беркайчан да урыс динен тотмады, үз динебезне ташламады, безгә дә шуны васыять итеп әйтеп калдырдылар. Без гомер буе ислам динен тоттык, балаларыбызга да шуны тапшырдык. Әмма әти-әниләребез чиркәү кенәгәләрендә керәшен дип язылгач, без дәүләт өчен мөселман дип саналмыйбыз, һәм безне христиан дине күзлегеннән хөкем итәләр. Шушы гаделсезлекне туктатыр өчен, безгә рәсми рәвештә ислам диненә кайтырга рөхсәт сорадык. Без хәзер авылыбыз белән җавап көтәбез, тирә-күрше авыллардан да күп үтенеч хатлары язылган. Шул хатыбызга җавап килгәнче, кызым Гөләйзага карата хөкем карары чыгармыйча торсагыз иде! Кызылъяр побыннан да сорагыз, ул безнең сүзләребезнең хаклыгын раслар, Шонтала авылы мулласы да Гөләйзаның балаларының мөселман икәнлеген әйтер, чөнки ул үзе аларга исем кушты. Шулай булгач, алар ничек керәшен булсын? Әби патшаның диндә көчләмәскә, дигән әмере бар бит, урыс поплары безне дә үз диннәренә көчләмәсеннәр иде!

Бу татар хатыны әйтмәсә дә, хөкемдар ул указларны яхшы белә иде, шул ук вакытта ул Николай патшаның христиан диненнән чыгуны катгый рәвештә тыя торган әмерләрен дә белә иде. Бәлки бу татарлар белмидер, әмма Петербургтан – Сенаттан да, Синодтан да әмер бар – христиан диненнән чыгуны туктатырга, беркемгә дә яңадан ислам диненә кайтырга рөхсәт итмәскә, киресенчә, ике арада йөрүче керәшеннәргә каты җәза бирергә. Бу Пелагея-Гөләйза эше башкаларны да куркыту, кисәтү өчен бер гыйбрәтле дәрес булып торырга тиеш иде. Әмма болай, очы-очка ялганмаган килеш, эштер-өштер карар да чыгарып

булмый, аннан соң бу татарлар суд өстеннән шикаять яза башларлар. Шуңа күрә, карар чыгарганчы, ул тәнәфес игълан итте, капкалап, чәй эчеп алырга да кирәк иде.

Сәркатип бу турыда әйткәч, Гөлзада да мәхкәмә бүлмәсеннән чыгып китте, аның хәле беткән, аяклары тотмый башлаган иде. Ул ишектә күренүгә, Гөләйза аның янына ашыкты, авып китмәсен өчен, анасын тотып алды, агач эскәмиягә алып килеп утыртты. Ишмөхәммәт белән Габделвахит урамда булганнар икән, алар да кереп җитте. Барысы да, хәвеф белән, Гөлзадага текәлделәр. Ул арада суд залыннан Якуб атакай да чыкты, яннарына килеп басты.

– Карар бераздан чыгарылачак, – диде ул. – Ялга туктадылар...

– Карар бүген чыгамы? Нинди карар? – Гөләйза тилмереп анасына карады.

– Белмим, балакаем, башларында нидер аларның... Инде Аллаһтан сорарга, кызым, бу хөкемченең күңеленә мәрхәмәт салсын, сине балаларыңнан аермасыннар иде...

Ирләр аерымрак сөйләшәләр иде.

– Бераз өмет юкмы соң, Якуб энем? – дип сорады Ишмөхәммәт. – Биләр побының тавышы монда ишетелеп торды, шулай ук ул әйткәнчә булырмы икәнни?

– Нәрсә әйтим, Ишук әзи? Суд бит бу, карарны алар чыгара... Биләр атакае шулай әйтергә тиеш инде ул, безнең эшебез – православлау дине сагында тору. Падишаһыбыз, хөкүмәт тә шушы юлда... Сез генә аркылы килдегез, үзегезгә күпме авырлык тудырдыгыз! Менә безнең кебек керәшенлекне тотсагыз, бу хәлләр дә килеп чыкмый иде...

– Һәркемгә үз дине, энем, хәзер бу турыда сөйләшергә соң инде!

– Гөләйза да, Гөлзада түтекәй дә нык тордылар анысы, үзенекен бирмәделәр... Хәтта хөкемдар да бер мәлгә икеләнеп калган кебек булды. Әмма мин әле мөселманнарны яклап хөкем карары чыгарганнарын хәтерләмим. Хәзер керәшеннәргә таләпләр бик катыланды, борыла да алмыйсың – йә ул динне ничек бар – шулай тотасың, кереп-чыгып йөрсәң – төрмә. Менә бераздан билгеле булыр инде... Суд карарын тыңларга икесен дә чакырачаклар, әзер булып торсыннар, анда-монда китә күрмәсеннәр!

– Кая китсеннәр – күрмисеңмени, мылтыклы сакчылар арлы-бирле йөреп торалар! Шушы хатын-кызларны күзәтә бит алар!

– Нишләтәсең – тәртибе шундый, суд бит бу, казна йорты!

Ишмөхәммәт хатын-кызларга Якуб атакайдан ишеткән сүзләрен ирештерде, тәнәфестән соң икесенең дә мәхкәмәгә керергә тиеш икәнлеген әйтте. Кул астында булган ризыкларны капкалап алдылар, балаларның икесен дә Ишмөхәммәт белән калдырып торырга булдылар. Әмма соңгы мизгелдә генә Габделҗәббар көйсезләнә башлады, әллә урын алыштырганга, әллә йокысы туймаганга, өзелеп-өзелеп еларга тотынды. Гөләйза аны, бер читкә китеп, имезеп тә карады, кулларында тирбәтте, әмма сабый тынычланмады. Баласын күкрәгенә кысып, Гөләйза аны өшкереп карады, дога кылды, улы бераз тынычланган кебек булды. «Раббым, шушы балаларым хакына, мине кяферләрнең явызлыгыннан сакла, аларга мине балаларымнан аерырга ирек бирмә, төрмәләреннән сакла, тәреләреннән сакла! Бу хөкемдар дигәннәренең күңеленә миңа, балаларыма карата мәрхәмәт сал, Раббым, каты карарлар чыгармасын иде! Монда килгәндә ничек үз ирегебездә, үз динебездә булсак, моннан да бергәләп, үз ирегебездә, үз динебездә чыгып китәргә насыйп ит, Раббым Аллам! Син кодрәтле, Син шәфәгатьле, Син мәрхәмәтле, ташлама

мине һәм балаларымны рәхмәтләреңнән! Атам-анамны ташлама, нәселемне кыямәт көненә кадәр ислам динендә калдыр!»

Мәхкәмә бүлмәсендә дә аерым сөйләшүләр бара иде.

– Тизрәк эшләрен бетерергә кирәк боларның, Савелий Аркадьеч! Аларның ялганнарын тыңлап торырга да кирәкми иде...

– Тыңламыйча да булмый, атакай, тәртибе шундый бит... Очы-очка ялганып бетмәгән урыннары да бар.

– Татарлар – бик хәйләкәр халык, махсус шулай бутыйлар! Судан коры чыгасылары килә. Чиркәү кенәгәсенә син христиан буларак теркәлгәнсең икән – христиан бул инде, уйнаклама, ике дин тотарга азапланма! Үзең беләсең, йөз ел элек моның өчен тереләй утта яндырып үтерәләр иде, хәзер генә законнар йомшарды, ә алар моннан файдалана! Каты тормасак, берсе дә изге динебездә калмаячак, басурманлыкка чыгачак. Каты торырга кирәк, Савелий Аркадьеч! Башкаларга гыйбрәт булсын!

– Алай да тагы бер кат тикшереп чыксаң, зыян итмәс иде, чөнки мондый эштә ашыгырга ярамый.

– Аларга шул гына кирәк – сузу кирәк, аннан тагы берәр хәйлә уйлап табачаклар! Син монда яңарак кеше, Аркадьеч, татарларны белеп бетермисең, үзенекен итү өчен алар җир ашарга да риза! Өерләре белән яңадан исламга кайталар бит, әле үзләре белән чуваш-чирмешләрне дә өстериләр! Тегеләре, христиан динендә калмас өчен, үзләрен татар дип яздырырга да ризалар, алары да көтүләре белән ислам диненә керәләр! Син ул татарларның ни дәрәҗәдә фанатиклыгын белсәң, алар белән сөйләшеп тә тормас идең! Үз динен, үз телен, хәтта үз киемен бирмәс өчен, ул синең бугазыңа ябышырга әзер, Себер китсә китә – үзе булып, татар булып кала алар! Ачка үлсәләр үләләр – менә бу безнең ризыкларга борылып та карамыйлар, хәрам, диләр, шул ук вакытта үзләренең ат итләрен әнә ничек сыптыралар! Безнең постларны тотмыйлар, ә үзләренең уразаларын чилләдә дә тәүлек буе бер тамчы су йотмыйча тоталар! Фанатиклар! Боларга ирек бирсәңме?! Боларга ирек бирсәң, Казан губернасын гына түгел, бөтен Рәсәйне татарлаштырып һәм исламлаштырып бетерәчәкләр – менә нәрсәсе куркыныч аның!

Шулай сөйләшә-сөйләшә, сәркатип әзерләгән чәй өстәлендә капкалап алдылар, аннан Биләр побы каршыдагы чиркәүгә кереп китте, земство судьясы аны тәрәзәдән карап калды. Әйе, Чистай уртасына патша сараедай зур чиркәү төзеп куйдылар, андыйны хәтта Казанда да юк, диләр. Хәер, Казанның бөтен чиркәүләре элеккеге мәчетләр өстендә утыра бит, гөмбәзләрендәге ярымайлары бәреп төшерелеп, алар урынына тәре менгереп куелган. Чистайның менә бу мәһабәт чиркәвен дә Биләрдәге Җәмигъ мәчете ташларыннан салынган, дип сөйлиләр, бәлки янәшәдәге болгар-татар шәһәре Җүкәтаудан да ташылгандыр...

Кечкенә генә Чистайда чат саен чиркәү булса да, халык анда әллә ни күп йөрми, моның яшерен сәбәпләре дә бар. Керәшен татарлары, мәҗбүр итмәсәң, йөрми дә йөрми, урысларның да бер өлеше чиркәүгә йөрми бит, чөнки алар – «иске диндәге» халык, ягъни, «староверлар». Чистай урысларының чиреге, шул исәптән земство судьясы үзе дә шулардан, әмма ул аны артык сиздерми, чөнки эше шундый. Унҗиденче гасырдагы Никон реформаларыннан соң икегә ярылган христиан дине әһелләре менә йөзләрчә еллар инде бер-берләрен танымый, бер-берләренә дошман булып яши. Бары тик Әби патша заманында һәм аның оныгы Александр вакытында гына иске диндәге «староверларны» эзәрлекләүләр бераз туктап торды, югыйсә, аларны да тереләй утларда

яндырган вакытлар бар иде бит! Хәзер исә дәүләт дине булган праваслау әһелләре иске диндәгеләрне тагы кыса, эзәрлекли башладылар, шуңа күрә алар ил буенча таралырга, үзләренең кемлекләрен яшереп яшәргә мәҗбүр.

Земство судьясы да иске диндәге урыслардан, аның ата-бабалары да чиркәүгә йөрмәде, аларның попларын танымадылар, чукынмадылар, тәре такмадылар, өйдә иконалар тотмадылар, бары тик дога гына кылдылар. Ул үзе исә чиркәвенә дә йөри, кеше белән бергә чукына да, әмма боларның берсен дә күңеле барып эшләми, иске диндә булуын яшерер өчен генә кылырга мәҗбүр. Шуңа күрә ул татарларны да аңлый, мең еллар буе синең нәселең бөтенләй башка диндә – исламда булсын да, ничек инде поплар кушты, дип, тиз арада христиан диненә күчәргә мөмкин?! Синең бөтен кан күзәнәкләрең, тарихи хәтерең ислам нуры белән мөлдерәп торганда, бөтен яшәү рәвешеңә, тормышыңа, холкыңа, ризыгыңа, киемеңә мөселманлык сеңгәндә, ничек инде аны бер буында үзеңә дошман булган чит-ят дингә алыштырырга мөмкин?! Әнә бит, татарларның хатын-кызларына хәтле үз диннәре өчен утка керергә, Себер китәргә, хәтта үләргә әзер, ничек итеп бу халыкны үзгәртеп булсын?! Һәм үзгәртергә кирәкме? Шушы сораулардан Чистай хөкемдарының башы каткан иде, ул аларга җавап таба алмады.

Тагы бер нәрсәгә игътибар итте хөкемдар – Чистайда татарлар саны арткannan-арта бара, бигрәк тә Екатерина патшабикә заманында бистәгә шәһәр дәрәҗәсе бирелгәч, монда татарларга яшәргә рөхсәт ителде. Һәм алар әйләнеп кайтты, элеккеге үз туган туфракларына, таш калаларына кире кайтты алар. Морзалар, укымышлы дин әһелләре, акчалы бай татарлар әйләнеп кайтты Чистай шәһәренә. Бүгенге көндә биредә сәүдәгәрләрнең күпчелеге – иске диндәге урыс староверлары һәм морза нәселеннән булган мөселман-татарлар. Әлеге татарлар Чистайга килеп урнашу белән, узган гасыр азагында ук биредә мәчет салдырганнар, ул әле дә эшләп ята, кайбер керәшен татарлары да шунда йөри, дигән хәбәрләр килә.

Бу татарлар, динне кысалар, дип елап утырмыйлар – укымышлы муллалары да бар, алар һәрберсе китап яза, шул китаплар буенча хәтта керәшеннәрне дә яшереп кенә ислам диненә өйрәтеп яталар. Әле шуның өстенә, Петербургка төрле шикаятьләр язарга остардылар, моның буенча махсус төркемнәр барлыкка килде, авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә, хәтта губернадан-губернага барып җитеп, алар керәшен татарларын, көчләп чукындырылган чуваш-чирмешләрне христиан диненнән чыгарга өндәп йөриләр. Аерым урыс байлары, хөкүмәт кешеләре белән эш алып баралар, аның үзенә дә татар морзалары аша сиздереп-чыгып карадылар һәм хәзер бу эшнең нәрсә белән бетәсен көтеп торалар... Бу Пелагея-Гөләйзаны, хәзер кул-аякларын бәйләп, монастырьга җибәрсәң, Чистайның бөтен татарлары кубарылырга мөмкин, аларның динендә бер мөселман хатын-кызын кяфер коллыгыннан коткару өчен бөтен гаскәр кузгалырга тиеш икән... Бар, җиңеп кара мондый динне, буйсындырып кара мондый милләтне!

Хөкем ителүчеләрне сәркатип аша мәхкәмә бүлмәсенә чакырдылар. Гөләйза кулындагы баласын атасына бирергә җыенды, әмма сабый, аерылырга теләмәгәндәй, сыны катып елый башлады, ул әнисенең күкрәгендә генә тынычланды. Ул арада Габделвахит та әнисенең аякларына килеп сарылды, аның да аерыласы килми иде. Сәркатип тагы бер тапкыр чакыргач, Гөләйза үзенә сарылган балалары белән суд каршына кереп басарга мәҗбүр булды, ул аларны үзеннән аерып ала алмады. Бу хәлне күргәч, олы яшьтәге хөкемдар

каушап китте, ул хәзер аларны мәңгелеккә аеру турында карар чыгарырга тиеш иде. Бу хатынның һәм аның сабый балаларының язмышы турында соңгы сүзне ул әйтергә тиеш иде. Балаларны чукындырырга инде каршыдагы чиркәүдә көтеп торалар, аннан үзләрен бередәге берәр урыс гаиләсенә тәрбиягә тапшырырлар, ә анасын... Яшькелт күзле, зифа буйлы бу татар гүзәлен йә берәр урыска кияүгә бирерләр, йә мәңгегә монастырьга ябып куярлар... Коридордагы пристав-урядниклар аның сүзен көтә, алар да әзер...

Шул чакта нәни Габделҗаббар сулкылдап-сулкылдап елый башлады, әйтерсең лә сабый аерылу ачысын тоеп өзгәләнә иде. Аңа Габделвахит та кушылды, ул түбәтәйле башын әнисенең итәгенә төрткән, әрнеп-әрнеп, шыңшып-шыңшып елый... Ә Гөләйза, аягүрә басып, сындай катып, хөкем карарын көтә, калтыранган иреннәре изге дога сүзләрен пышылдый, күзләрендәге чиксез хәсрәт сары сагыш булып бөтен бүлмәгә түгелә... Гөлзада исә, егылып китмәс өчен, кызына тотынган, аны беркемгә дә бирмәс өчен, беләгенә чытырдатып ябышкан, аларны хәзер бу дөньяда аерып алыр көч юк иде сыман...

Карт хөкемдарның үз милләттәшләре күз алдына килде – иске динне тоткан өчен генә утта яндырылып үтерелгән протопоп Аввакумнар, асты-өскә китерелгән, утка тотылган монастырьлары, йортсыз-җирсез калдырылган әби-бабалары, ил буенча качып йөрергә мәҗбүр булган туганнары... Себернең кара урманнарында, төпсез сазлыклары арасында, Алтайның тау куышларында кача-поса үз диннәрен тоткан «староверлар»... Бу ил, бу патшалар хәтта үз урысларына карата да мәрхәмәтсез булдылар, бөтен кешене, камчы белән, рәсми дингә куып кертергә ашкындылар, риза булмаганнарны юк иттеләр. Менә хәзер ул, шул куылган һәм сөрелгән иске дин тарафдарларының бер вәкиле, үзе кебек үк эзәрлекләнгән икенче бер дин-милләт вәкиленә хөкем карары чыгарырга тиеш. Әмма Аллаһ бар бит әле, Ул бар кешеләр өчен бер һәм бердәнбер, аның каршында ни дип җавап бирер? Бу бәхетсез хатынның, бу ятим балаларның күз яшьләре һәм рәнҗеше аның нәселенә дә төшәчәк бит! Һәм хөкемдар бер карарга килде...

– Дәлилләр җитмәү сәбәпле, бу эшне яңадан карау һәм җентекләбрәк тикшерү сорала, моның өчен кимендә бер ай вакыт кирәк булачак, – диде. – Шулардан чыгып, суд карар бирә – 19 март көнне Пелагеянең эшен Чистай мәхкәмәсендә яңадан карарга, аңа кадәр Кызылъяр һәм Шонтала авылларында дин әһелләре белән очрашырга, чиркәү һәм мәчет документлары белән танышырга кирәк булачак. Шушы вакыт арасында яшәгән урыннарыгызда булуыгыз, аннан читкә чыкмавыгыз сорала. Ә хәзергә – сез irekле.

«Сез хәзергә ирекле! Сез ирекле!» Караңгы залда яңгыраган бу сүзләр алар өчен иң кадерле сүзләр иде! Сез ирекле! Сезне хәзергә аермыйлар! Сез бүген дә бергә, иртәгә дә бергә, ай буе ана һәм балалар бергә булачак! Төрмә көткән, мәңгелек аерылышу көткән бу бәхетсезләр өчен моннан да зур бәхет була аламы?! Гөләйзаның мөлдерәп тулган күзләре бу карары өчен хөкемдарга сүзсез рәхмәт укыйлар иде...

Гөләйза коридорда атасының кочагына ауды, икенче яктан аны анасы кочып алды, алар бергәләп шатлыктан елыйлар... Әйе, хәзер иректә булган өчен, хәзер бергә булган өчен дөньяда алардан да бәхетле кеше юк иде! Югыйсә, әнә чаңнарын сугып, каршыдагы чиркәүдә Гөләйзаның балаларын чукындырырга көтеп торалар, аның үзен этап белән монастырьга озатырга атлар җигелгән, каравыл куелган иде... Ә Аллаһы Тәгалә аны иректә калдырды, әле бәлки бер

айдан соң бөтенләй дә аклап куярлар, киләчәккә өмет белән яшәргә кирәк! Шулай шатланышып, җыенып урамга чыктылар, Якуб атакай каршыдагы чиркәүгә кереп китте, бу хәбәрне андагыларга да җиткерергә, чукындыруны кичектерергә кирәк иде. Ул бүген Актауга кайтмаячагын да әйтте. Гөләйзалар исә, ат чанасына төялеп, Татар бистәсенә юнәлделәр, атасы андагы татарлар белән сөйләшеп куйган булган икән. Чиркәү чаңнары аларны ярсып озатып калды, бүген алар бу татарларны үзләренең пәрәвезенә урый алмады, юкка, бушка чаңгылдыйлар иде...

## Татарларның мәңгелек хыялы

Гөләйза хәзер генә, бөтен күкрәге белән тын алып, тирә-ягына карады, мондагы зур матур йортларга, урам тулы кешегә, чаптырып үткән атларга шаккатты, аның шәһәрне беренче күрүе иде. Монда өйләр дә, кешеләр дә бөтенләй башка төрле икән, йортлар күбесе таштан, араларында агачлары да күренә, ә кешеләр үзләрен бик иркен тоталар, алар авылындагы кебек түгел. Күбесенең киемнәре, сөйләшүләре дә татарча түгел, болар урыслардыр инде – хатын-кызлары биле бөрмәле бишмәтләрдән, яхшы туннардан, ирләренең өстендә биле пута белән буган постау казакилар, җонлы бүрекләр. Ара-тирә татарлар да очрый, алары күбрәк ир-атлар – башларында кырпу бүрек, өсләрендә кайсында кайры тун, кайсында сырган бишмәт, аның өстеннән озын җилән киеп куйганнары да бар. Барсының да аякларында киез итекләр, таякка таянган картлар да очрый, урамда татар хатын-кызлары юк диярлек, булсалар да, ирләре белән бергә генә...

Ул арада яралы бәгырьләрне телеп, күзләргә бәхет яшьләре китереп, тирә-юньгә азан тавышы яңгырады, ул әллә күктән, әллә җир астыннан, әллә кар каплаган урман-кырлардан ишетелә иде... Бу – могҗиза иде, урыс шәһәре дип йөрткән бер урында, татарлар ут һәм кылыч аша уздырылган җирдә, чукынмас өчен бозлы суларга ябышып каткан Чулман буйларында ... тагы азан тавышы яңгырады! Бу бит – татарлар яңадан монда әйләнеп кайткан, борынгы зиратлары алдында тез чүккән, мөселманнарның каны дәрья булып аккан урыннарда сәҗдәләргә китеп, алар рухына дога кылган, биредә мәчетләр салган, яңадан ислам байрагын күтәргәннәр дигән сүз! Бу бит җәннәтнең кәүсәр чишмәсеннән мәңгелек әбелхәят суын эчкән милләт исән, милләт яши, милләт бер Аллаһка гыйбадәт кыла дигән сүз!

Менә мәчет янына да килеп җиттеләр, атны ишегалдына алып кереп туктаттылар. Аның өстенә палас ябып, үзләре тун-толыпларын алып, балаларын күтәреп, мәчет эченә үттеләр, биредә икенде намазына халык җыела башлаган иде. Алар ишектә күренүгә, каршыларына ак сакаллы хәзрәт атлады, ул Ишмөхәммәтнең җилкәсе аша артыннан кемнәр килүен карады, хатын-кызларны күреп, җиңел сулап куйды, битләрен сыпырып, дога кылды. Хатын-кызлар, балаларын күтәреп, шунда ук намаз бүлмәсен бүлеп куйган чаршау артына кереп киттеләр, ирләр бер-берләре белән күрешеп чыктылар.

– Аллага шөкер, Раббыма мең шөкер – кызың иректә икән, Ишмөхәммәт кордаш! – диде хәзрәт. – Без монда көне буе аңа һәм оныкларыңа догада булдык, алар өчен ут йоттык, Аллага шөкер, алып калмаганнар!

– Бер айга мәхкәмәне кичектерделәр, хәзрәт! Очы-очка ялганмый, урынга барып, поп белән мулладан да сорарга, чиркәү һәм метрика кенәгәләрен тикшерергә кирәк, диделәр.

– Тикшерсеннәр, бер ай да тикшерсеннәр, бер ел да актарсыннар – берни тапмасалар, инша Аллаһ! Хәзер иң кадерлесе – кызың иректә, оныкларың чукындырылмады! Аллаһның рәхмәте инде бу...

Мәчеткә җыелган халык моңа бик куанды, бу хәл бөтен Чистай өчен, юк, бөтен өяз өчен зур вакыйга иде! Әле судның моңа кадәр үз дигәнен эшләми калганы юк иде, алар тырнагыннан исән-имин котылган кеше аз, ә менә бер татар хатынына тешләре үтмәгән! Аллаһ аны ул явызлар кулына бирмәгән. Шундый сөенечле уйлар белән намазга бастылар, тәннәре һәм җаннары белән сәҗдәгә китеп, Аллаһны олыладылар, Аңа рәхмәтләрен әйттеләр. Хатын-кызлар намазларын чаршау артында, имамга оеп укыдылар, балалар исә җылы толып эчендә арып, изрәп йокыга киткәннәр иде... Намазны тәмамлап, догалар кылгач, тагы бераз сөйләшеп утырдылар, аннан Ишмөхәммәт юлга җыена башлады.

– Якты күздә без кузгалыйк инде, җәмәгать, – диде ул. – Ярты юлда Актауга кереп кунарбыз дигән идек... Безнең өчен шулай борчылганыгызга, кылган догаларыгызга, теләгән теләкләрегезгә зур рәхмәт, бу гамәлләрегез үзегезгә изгелек булып кире кайтсын! Әле безнең дә эш башлана гына, сезнең ярдәм, сезнең догалар алга таба да бик кирәк булачак...

Чаршау артыннан хатын-кызлар да чыкты, юлга әзерләнә башладылар. Шулчак Ишмөхәммәт янына урта яшьләрдәге, нык бәдәнле, олы гәүдәле, яхшы бәрхет җилән һәм кара бәрхет түбәтәй кигән ир-ат килеп басты, аның әйтер сүзе бары күренеп тора иде.

– Мин Мөслим авылыннан Исмәгыйль морза булам, – диде ул. – Хәзер гаиләм белән Чистайда яшим, бередә сәүдә итәм, авылда да җирләрем бар... Бүген безнең мосафирыбыз булсагыз, җәмәгатебез белән шат булыр идек, безгә дә савап эшләргә мөмкинлек туар иде.

Бу көтелмәгән тәкъдимнән Ишмөхәммәт аптырабрак калды, Чистайның зур байларыннан саналган Исмәгыйль морзага ни дип җавап бирергә дә белмәде. Шулчак сүзгә хәзрәт тә кушылды.

– Мин дә сезне бүген бик теләп үземә кунарга чакырыр идем, Исмәгыйль морза өлгеррәк булып чыкты, – диде ул. – Без инде сөйләшеп-киңәшеп куйган идек – мәхкәмәдә эш ничек кенә тәмамланса да, сезне кунарга бередә калдырырга, дип. Инде болай уңай да тәмамлангач, бергә җыелып гәпләшеп утырырга, сөхбәт корырга бигрәк тә форсат бар.

– Сезне мәшәкатьләү булмасмы соң, Исмәгыйль энем?

– Нинди мәшәкать ди, Ишмөхәммәт әзи?! Өем иркен, күңелем киң, җәмәгатем мосафирпәрвәр! Сезнең кебек дин-ислам өчен авырлыклар күргән кешеләрне кунак итү безгә савап кына!

– Ярар, алайса, энем, килештек... Үзебез дә, сабый балалар да бик арыган идек бүген, төнгә каршы Актауга ничек кайтып егылырбыз, дип тора идек... Аллаһ менә сезне сәбәпче итте монда тукталырга, зур рәхмәт!

Исмәгыйль морзаның өе мәчет янында гына икән, җәяүләп кенә шунда киттеләр, ирләр ахшам намазына мәчеткә килергә, халык белән шунда бераз сөйләшеп-киңәшеп алырга, дип килештеләр. Исмәгыйль морзаның йорты ике катлы булып, асты – таш, өсте шыңгырдап торган агачтан иде, югарыда әле курчак өедәй чарлак-балконы да бар. Аста аларның үз кибетләре икән, анда чәй-шикәре, тозы, ите-мае, икмәге, тәмле-төмлесе, кипкән җимеше, тагы әллә нинди ят ризыклар сатыла, шулай ук йорт кирәк-яраклары да бар. Өстә исә Исмәгыйль морзаның ишле гаиләсе яши, олыларның һәм балаларның

бүлмәләре аерым, алар затлы җиһазлар белән бизәлгән, диварларда һәм идәннәрдә йомшак келәмнәр, аларга аяк белән басарга да куркыныч иде. Киң агач баскычтан менгәндә үк, каршыларына Исмәгыйль морзаның хатыны чыкты, Гөләйза белән Гөлзаданың кулларындагы әйберләрне алып, аларны үзе белән өскә алып менеп китте, ирләр исә кибетне карый калдылар.

Гөләйзаның гомерендә дә мондый матурлыкны күргәне юк иде, ул үзен җәннәт бакчасында кебек хис итте. Кыш көне булса да, зур залда идәннән түшәмгә хәтле биек гөлләр үсеп утыра, аларның кайберләре шау чәчәктә, бу истән башлар әйләнә... Диварлар буйлап агачтан сырлап эшләнгән биек тартмалар тезелеп киткән, аларның пыяла ишекләре артында калын-калын китаплар күренеп тора. Түрдә, иң кадерле урында – Коръән китабы, затлы урындыкларда намазлыклар өелеп тора, шунда ук дисбеләре дә... Тәрәзәләрдә аллы-гөлле пәрдәләр, өрфия челтәрләр, өстәлдә чиккән ашъяулык, аның өстендәге матур савытта кипкән җимешләр өелеп ята... Әле караңгы төшмәсә дә, бүлмәләрне бәллүр шәмдәлләр яктырта, диварның дәвамы кебек итеп салынган киң, ак мичтән җылы бәреп тора. Гөләйзаны иң гаҗәпләндергәне – читлекләрдә сайрап утырган сәер кошлар булды, аның мондый хәлне гомерендә дә күргәне юк иде.

Кунакларга зур аерым бүлмә бирделәр, монда элеккеге тәртип буенча киң сәке дә, шул ук вакытта заманча карават-өстәлләр, урындыклар да бар иде. Балаларны, толып эченнән чыгарып, сәкегә салдылар, көне буе кулда булганга, алар арып йокыга киткән иде. Хатын-кызлар да үзләрен бераз тәртипкә китерделәр, көндезге кичерешләреннән һәм тетрәнүләрдән соң алар да хәлдән тайган, әмма барыбер шат иделәр. Хуҗабикә тиз генә ирләргә һәм хатын-кызларга аерым табын әзерләде, аның ашы пешкән, чәе кайнаган, өстәле тулы ризык иде. Хуҗабикә дә, ире кебек, Мөслим авылыннан икән, Хәлимәбану исемле, кул астында буй җиткән кызлары булышып йөри, хезмәтчеләре дә бар. Ирләр, ашап-эчкәч, яңадан мәчеткә киттеләр, чөнки анда ахшамга кадәр халык белән очрашып-сөйләшеп аласы бар иде, хатын-кызлар исә үз бүлмәләренә җайлап урнаштылар. Хәлимәбану кунаклар өчен мунчасын да өлгерткән икән, юлдан һәм мәхкәмәдән алҗыган хатын-кызлар, ирләр мәчеттән кайтканчы, юынып чыгарга да өлгерделәр. Аннан сәке өстенә җиз самавырларны утыртып, тагы чәй эчтеләр, тагы үз хәлләре турында сөйләшергә тотындылар.

– Бөтен Чистай мөселманнары сезнең өчен догада булды, – диде Хәлимәбану, Гөләйзаның кулларыннан тотып. – Инде, Раббым, бу кяферләрнең явызлыкларыннан бөтенләй котылырга насыйп итсен! Бигрәк җаннарына тиделәр бу бичара мәкруһларның! Алар күргәннәрне дошманыңа да күрергә язмасын!

– Әйтерең бармы, Хәлимәбану абыстай! – диде Гөлзада. – Безнең як кешесе булгач, син беләсең инде – көчләп чукындырылмаган бер авыл калмады бит, татары-мишәрен, чувашын-чирмешен рәттән чукындырып йөрделәр. Һәр нәселдә диярлек шушы кара тамга бар, инде балаларыбыз, оныкларыбыз да шуннан зарар күрә...

– Менә сез мөселман булып кала алгансыз бит, Хәлимәбану апай, – дип, Гөләйза да сүзгә кушылды. – Урыс арасында курыкмыйча рәхәтләнеп үз динебезне тотып яшәп ятасыз. Безгә дә шул көннәр килерме икән?

– Килер, акыллым, һичшиксез, килер, дин-ислам хакына бу хәтле күргән газапларыгыз бәрабәренә Аллаһ нәселегезгә барыбер иман бәхете бирер! Аллага шөкер, ул вакытларда безнекеләргә чукындыру давылы кагылмаган, ирем ягы

да, минекеләр дә бу афәттән ничектер читтә кала алганнар. Аннан, мишәр морзаларының патшаның үзеннән бу җирләр белән идарә итәргә ярлыклары бар бит, попларның андый күренекле кешеләргә куллары күтәрелмәгәндер.

– Әйе, безнең Шонталада да морза нәселләре исән-имин калды, аларга кагыла алмадылар. Әмма мәкруһларга ярдәм итәсез, аларны исламга кайтырга котыртасыз, дип, бу морзаларны да гел гаепләп торалар...

– Монда да шул ук хәл, Гөлзада апай! Минеке, Исмәгыйль морза, Чистайда икмәк сәүдәсен, ит-май, тире-яры эшләрен үз кулында тота, казнага зур салымнар түли, әмма аңа да тынгы юк, борын төпләрендә яшибез бит... Үзе дә тик тормый, бу мәкруһлар буенча кая гына язмады, кем белән генә сөйләшеп карамады, Әби патша дин иреге дигәч, нигә аларга яңадан исламга кайтырга рөхсәт юк, дип күзләренә терәп сорый. Поплар бер дә яратмыйлар үзен, әмма аңлаган урыслар да бар. Биредә бит ярты Чистай – куылып-качып килгән иске дин урыслары, алар башка төрлерәк – безнең мәкруһ керәшеннәр кебегрәк – чиркәүгә дә йөрмиләр, чукынмыйлар да, тәре дә такмыйлар, икона-такталарын да тотмыйлар...

– Абау, шундый урыслар да бармы? Аларны ничек өтермәнгә япмыйлар соң?

– Алар да күпне күргән – чиркәүгә буйсынмаган өчен, утта да яндырганнар, суга да батырганнар, төрмәләргә дә япканнар, хәзер дә ил буйлап качып йөриләр, чит илгә чыгып китүчеләре дә байтак икән... Әмма аларның бер өлеше динен яшерә, алар янында алар кебек булырга мәҗбүрләр, ди... Ирем әйтә, бүгенге мәхкәмә казые да шул иске дин урысы иде, ди.

– Әйтәм аны башка төрлерәк иде! Ниндидер кызгану бар иде аның карашында... Ә Биләр побы ерткыч җанвар кебек ташланды өстебезгә, кодрәтеннән килсә, шунда ук бәйләп салып чукындырасы иде барыбызны да! Алла саклады инде ул явыздан, аны яңадан күрергә язмасын!

– Әйе, Гөлзада апай, шушының белән бетсен иде инде!

– Бер айга, дип әйттеләр шул, Хәлимәбану апай! – диде Гөләйза, судтагы хәлләрне искә төшереп. – Авылдагы мулла белән поплардан сораштырасылары икән... Аның мулласы безгә каршы сөйләмәс инде, ә побына бернинди ышаныч юк, эчеп ята торган бер кеше, диләр.

– Ирләр берәр нәрсә уйлап табар әле, сеңлем, шуны киңәшәләр бит! Сине һәм балаларыңны күрәләтә ул явызлар кулына биреп җибәрмәсләр, Аллаһ моны ирекле кылмас! Юк, кылмас!

– Амин, шулай була күрсен! Безгә дә сезнең кебек үз динебезне курыкмыйча тотарга, балаларыбызга да шуны әманәт итеп биреп калдырырга язсын!

Шулай дип дога кылдылар, ул арада ахшам вакыты да кергән иде, бергәләп намаз укып алдылар. Хәлимәбану ирләр кайтасына тагы табын әзерли башлады, мондый утырышулар аларда еш була, дин-милләт өчен күп кенә мөһим эшләр шушында хәл ителә иде. Гөлзада исә, оныкларын кочаклап, изрәп йокыга китте, аның бүгенге көне ярты гасырлык гомеренә тиң иде... Әнисе һәм балалары йокыга киткәч, Гөләйза Актауда Нәчтүк биргән Коръән китабын кулына алып утырды. Кыр Шонталасында яшәгәндә, Гөләйза абыстайга йөреп, Коръән укырга өйрәнде, аларны беркем дә кире бормады, югыйсә керәшеннәргә ислам динен өйрәтү ул вакытта да катгый тыелган иде. Әмма муллалар да, абыстайлар да моңа карамады, керәшен балаларына ислам динен өйрәтүне үзләренең изге бурычлары, дип санадылар, аларга кечкенәдән иман орлыклары салып калдырырга тырыштылар...

Менә бу изге Коръәнгә дә Әкълимә әбинең күз нурлары сеңгәндер, яшьләре

тамгандыр, ул тау куышларында качып баласын тапканда, бу Коръән дә аның янында булгандыр, мәҗбүри чиркәүгә куылганда, изге китапны күкрәгенә яшергәндер... И Раббым, инде хәзер Гөләйзаны да шушы юл, шушы язмыш көтәме? Бер айдан нәрсә булыр? Гөләйзага да, Коръәнен күкрәгенә яшереп, кар өстеннән яланаяклап чиркәүгә өстерәлеп барырга туры килмәсме? Раббым, шул көннәрне күрсәтмә! Раббым, андый аянычлы язмыштан үзең сакла... Раббым, бу изге китабыңны нәселемә дә әманәт ит!

Ул арада мәчеттән ирләр дә кайтып керде, чөнки анда төрле кеше бар, кайбер нәрсәләрне ачыктан-ачык сөйләшеп булмый иде, ә сөйләшергә кирәк! Алга таба милләткә, өммәткә нишләргә? Бөтенесен дә чукындырып бетергәнне көтеп утырыргамы, әллә теге вакытлардагы кебек күтәрелеп карарргамы? Дөрес, менә бу абруйлы, акчалы морзаларга, рәсми дин әһелләренә тимиләр хәзергә, әмма халык кан елый бит! Кая барып бәрелергә, кемнән ярдәм сорарга белми? Илең булмасын, дәүләтең булмасын, патшаң булмасын, гаскәрең булмасын, шуның өстенә, баш очында һәрвакыт балта күтәреп басып торсыннар! Юк, милләт озак түзә алмас бу хәлләргә, әнә, халыкның да бер өлеше, язмышы белән ризалашып, чынлап керәшен булып китте инде. Бер өлеше, менә бу бичара авыл хатыннары кебекләре, әле тарткалаша, иманы өчен көрәшә, әмма алар да япа-ялгыз бит!

Бу кичтә Исмәгыйль морзаларга Чистайның иң абруйлы татарлары җыелган иде, хәтта сукыр Гомәр абызны да алып килгәннәр. Олы як, диндарлар чалма-чапаннардан, морзалар затлы бәрхет җиләннәрдән һәм кырпу бүрекләрдән, яшьрәкләр исә түбәтәйләрен кырын салганнар, аксакаллар сүзен тыңларга җыенганнар. Кичке табынны зур һәм иркен итеп, идәнгә әзерләгәннәр иде, чөнки картларга шулай җайлы, алар гомер буе шуңа өйрәнгән. Көне буе эштә, сәүдәдә булган ир-атлар кайнар шулпасын да, табагы белән елкы итен дә ялындырмыйча гына ашап куйды, өчпочмагы, гөбәдиясе белән чәй эчтеләр, соңыннан кулларын күтәреп дога кылдылар, Гомәр абыз Коръән укыды. Болардан соң барысы бергә ястү намазы укыдылар, ул арада асрау кызлар табынны җыеп алды, инде иркенләп сөйләшергә дә була иде.

Гомәр абыз Байбәк – инде туксан яшьләрдәге мишәр карты, Чистай шәһәренә беренче булып күчеп килгән татарлардан. Ул да морза нәселеннән, Татар Талкышы, Яңа Усман авылларында зур җир биләмәләре бар, тегермән тота, Чистайда исә ашлык сәүдәсе белән шөгыльләнде. Улы Яһүдә Мөслим авылы мәчетендә имам, шул ук вакытта өязнең ахуны да булып тора. Чистай мәчете имамы Әхмәт Халит, аның ярдәмчеләре Габделгафур һәм Габделхәким хәзрәтләр дә бүген биредә. Соңыннан халык арасында Закир ишан Чиставый дип дан алачак Мөхәммәтзакир Габделвәһһаб улы Камали да монда, ул зур сәүдәгәр дә, дин әһеле дә... Шулай ук биредә зур сәүдәгәрләр – Тумашевлар, Канзафаровлар, Атнагуловлар, Таишевлар, Курамшиннар, Урманчеевлар, Уразгилдеевлар да бар... Алар барысы да морзалар, авыллары, җир биләмәләре дә шушы тирәләрдә, кайберләре әле һаман авылда яшәвен дәвам итә, әмма Чистай кешесе булып хисаплана. Бу йомышлы татарларның, дәүләт крестьяны булудан туктап, шәһәр сәүдәгәре-купец һәм мещан катламына күчүләре хөкүмәт өчен дә, морзаларның үзләре өчен дә файдалы иде. Бер яктан, шәһәргә акчалы татарлар килеп, аны биредә әйләнешкә кертеп җибәрсә, икенче яктан, әлеге йомышлы татарлар, шәһәр кешесе булганнан соң, үзәкләренә үткән лашманлыктан котылалар иде.

Әмма бу мөселман-татарларны берләштерә торган тагы бер яшерен нәрсә

бар иде, ул – суфыйчылык, ягъни, аларның барысының да диярлек Нәкышбәнди тарикатендә булулары. Бу хәрәкәт бигрәк тә көчләп чукындыру елларында, башка чарасы булмаган татарның явызлыкка каршы җавабы иде. Татарның үз күңел төрбәсенә качып булса да, яшәүгә өметен саклап калырга тырышуы иде... Шул ук вакытта җыелышып, бу авыр заманнар үтәр әле, Аллаһ безнең догаларыбызны ишетер, ярдәмгә ислам гаскәрен җибәрер, татарны коткарырга төрекләр килер, фарсылар-гарәпләр килер, дип, зекер әйтеп, үз-үзләрен дә, берберләрен дә юатырга омтылулары иде... Аларның остазлары, шәех-ишаннары халыкны Болгар-Биләр дәүләтләрен яңадан торгызырга дәртләндерде, әлеге суфыйлар кяфер илендә ислам дәүләте төзибез, дип хыялландылар, хәтта ки моңа омтылышлар да ясап карадылар. Бу хәлләр Әби патша заманында булды, һәм бу эшләрнең башында Морадбакый исемле мишәр абызы торды... Ул үзе нәсел чыгышы белән шушы яклардан – Чулман аръягындагы Балык Бистәсе төбәге Күгәрчен авылыннан иде, хәзер Самар якларында яши икән.

Әйе, Гомәр карт та яхшы хәтерли аны, ул чагында ябь-яшь егет иде әле Гомәр... Рәсәйдә патша алмашынып, мөселманнарга бераз ирек килгән вакытлар иде бу. Шул чакта Әби патшаның дин иреге турында әмере чыкты, бу татар дөньясы өчен күптән тилмереп көткән азатлык кояшы кебек тоелды. Җимертелгән, татарсыз калган Болгар-Биләрләр искә төште, басып алынган һәм урыс кереп тулган милли мәркәз – Казан үзәкләрне өзде, муеннарына көчләп тәре асылган мөселманнар ярдәм сорап тилмерде. «Менә безнең дә заман килде, менә болгар-татарга да азатлык кояшы чыкты, менә без дә курыкмыйча үз динебезне тота алабыз!» дип куанды мөселманнар. Алар шунда ук оеша, аралаша башладылар, хөҗрәләреннән чыгып, татарның данлы вә шанлы чакларын хәтерләткән урыннарга агылдылар, ул җирләрне тезләнеп үптеләр, монда яңадан мөселман дәүләте торгызырга ант иттеләр...

Әйе, Гомәр морза хәтерли – ул елны Корбан бәйрәме май ахырына – июнь башларына туры килде, 1769 еллар иде бу... Алдан ук киңәшеп, бәйрәмне Шәһре Биләрдә – Хуҗалар тавында уздырырга булдылар, Морадбакый абыз үзе килә икән, диделәр. Моңа бигрәк тә мәчетсез калган татар авылларында сөенделәр, керәшен мәкруһлары да курыкмыйча мөселман кардәшләренә килеп кушылды. Кичтән үк тирә-як авыллардан атлар җигеп, бала-чагаларны төяп, ризык алып, юлга кузгалдылар, чаласы корбанлыклар да аерым арбаларга бәйләп салынган иде... Һай, үзенә күрә дәртләндергеч тә, моңсу да, шатлыклы да, хәвефле дә күренеш иде бу! Элек тә шулай язгы кыр эшләреннән соң халык болын-кырларга чыгып, җыеннар уздыра, атлар чаптыра, батырлар мәйдан тота иде... Теге патшалар вакытында алар барысы да тыелды, татарларга хәтта бәйрәмнәре вакытында да бергә җыелырга рөхсәт булмады, хәтта Сабан туйлары да туктатылды. Һәм менә соңгы йөз елдагы тарихта беренче тапкыр, татарлар тагы кубарылып, дөньяга чыктылар, ата-бабалары дәүләт тоткан урыннарга баралар...

Төнне учаклар ягып, намазлар укып, зекер әйтеп, Хуҗалар тавында уздырдылар, борынгы заманнардагы кебек, чатырлар корып, шунда йокладылар. Иртән Хуҗалар тавы башында азан тавышы яңгырады, ул чатырлар белән тулган үзәннәргә, аларны чорнап алган имән урманнарына, Чирмешән буйларына таралды... Иртәнге азан тавышы моннан ерак булмаган урыс авылына да барып иреште, зыңгылдап, чиркәү тәреләренә килеп бәрелде, аларны урап үтеп, Шәһре Биләргә – Җәмигъ мәчете хәрабәләренә килеп тезләнде... И, Биләр, халык телендә – Бүләр, котып тарафында дөньяның үзәге

саналган Бөек Шәһәр! Мең ел элек рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгән, аңа кадәр дә мәчетләре булган, мәйданы дистә чакрымнарга сузылган, көмеш акчалар сугылган, Кол Галиләр яшәгән, «Кыйссаи Йосыф»лар язылган затлы таш кала! Дошман тарафыннан таланган, ак мәрмәр ташларың аяк астына салынган, мәчетләрең – чиркәүгә, кәрвансарайларың үләт базына әйләнгән ятим шәһәр! Син кичер безне һәм көт безне! Синең кебек үк таланган, мәсхәрәләнгән, әмма иманын җуймаган халкың бүген Биләренә кайту юлында! Йөзләрчә еллар коллыктан соң, ул сиңа изге дога белән кайта, инде китмәскә дип кайта...

Азан тавышы артыннан меңләгән татар да моннан мең ел элек ислам дине кабул ителгән изге туфракка тезләнде, очы-кырые күренмәгән рәтләргә тезелеп, иртәнге намазга басты. Гомәр морза да шушы халык арасында иде, ул шәех Морадбакыйдан ерак түгел, аның артында ук намаз укыды. Иртәнге намаздан соң Корбан гаетенә кадәр, кояш чыкканчы, шактый вакыт бар иде, Морадбакый абыз халыкка вәгазь белән мөрәҗәгать итте:

– Газиз милләттәшләрем, дин кардәшләрем! Аллаһ рәхмәте белән, менә без йөз елларга беренче тапкыр ата-бабаларыбыз дәүләт тоткан, ислам динен кабул иткән, беренче тапкыр тезләнеп намаз укыган җиргә җыелдык. Без дә биредә тезләнеп намаз укырга, Раббыбыз Аллаһны зекер белән искә алырга, халкыбыз өчен дога кылырга дип җыелдык, изге Корбан гаетенә килдек. Кайчандыр ата-бабаларыбызның Биләр-Болгар дәүләтләре тирә-яктагы бөтен кыйтгаларны һәм халыкларны берләштергән кебек, бүген дә бирегә Җаек һәм Себерләрдән, Идел һәм Сакмарлардан, Чулман һәм Сура буйларыннан милләтебез җыелды, монда болгар-мишәре вә татары да, башкорт-типтәрләр дә, нугай-кыргызлар да, хәтта ки ислам динендәге чуваш-чирмешләр дә бар, әлхәмдүлиллаһ, без бер өммәт – Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәте! Биредә залим патшалар һәм әрхәриләр тарафыннан керәшенлеккә чыгарылып, көчләп чукындырылган, әмма иманнан язмаган, яшерен вә ачыктан-ачык ислам дине тоткан, шул сәбәпле күп газаплар күргән мәкруһ татарлар да бар. Бу хәтле күп халаек, дистә меңләгән татар вә башкорт, мөселманнар вә керәшеннәр, мәкруһлар Биләргә алдагы язмышлары турында бер ачык фәтва ишетербез, бергәләп бер дөрес юл табарбыз, дип тә өметләнеп килделәр. Һәм дөрес эшләделәр, ул сүз әйтеләчәк, ул юл күрсәтеләчәк, инша Аллаһ!

Үзегезгә мәгълүм – безнең ул фәтваны әйтерлек дин башлыкларыбыз, халкыбызны азатлыкка алып чыгарлык дәүләт ирләребез-падишаһларыбыз юк, Аллаһ безне, сынау өчен, вакытлыча алардан мәхрүм иткән иде. Әмма заманнар үзгәрә, халык уяна, үз дине, иманы өчен көрәшә, милләт хәрәкәттә, акыл ияләре бу аянычлы хәлләрдән чыгу юлларын эзли. Миңа, Ишали углы Морадбакыйга да, Аллаһы Тәгалә хикмәтле төшләр аша хәбәрләр бирә, халкыбызны иманга, азатлыкка өндәргә куша. Кара диңгездән – Ак диңгезгә шае, Татар дәрьясыннан – Боз дәрьясына кадәр төрки-ислам туфракларында яңадан үз дәүләтебезне торгызырга әмер бирә Раббыбыз! Кяфер коллыгыннан котылырга чакыра, үзебезнең хәрәкәт итүне көтә! Аллаһ ярдәме белән, мин бу турыда китаплар да яздым, болгар-татар биләмәләренең харитасын да ясадым. Кулымда – «Ахырзаман китабы», ул милләтнең азатлык байрагы булырга тиеш! Бүгенге көндә халкыбыз күңел төшенкелегендә, бу хәлләрдән чыгу юлын күрми, әмма чыгу юлы бер генә – Аллаһка кайту һәм шушы җирләрдә үз дәүләтебезне торгызу! Милләтебезгә башкача исән калу юлы юк!

Хуҗалар тавына җыелган халык җир тетрәтеп тәкъбир әйтә башлады,

бу – гасырлар буе күрелмәгән хәл, ишетелмәгән сүзләр иде. Милләт башын күтәрде, як-ягына карады – бу аның туган туфрагы, бу аның ата-бабалары дәүләт тоткан урын, бу аның Ана-Ватаны иде! Һәм монда шушы халык хуҗа булырга тиеш иде! Гомәр морзаның да шул вакытта күңел күзләре ачылды, иманы куәтләнде, бәдәне ныгыды, ул үзен беркем дә җиңә алмас әкияти Алып батыр итеп хис итте. Кояш чыгып, бераз күтәрелгәч, Гает намазын укыдылар, аннан халык корбан чалырга таралды. Урыс авылларында керәшен булып яшәп, урманнарга барып, кача-поса корбан чалган, тотылган очракта, канга батырып кыйналган, җәзаланган татарлар бүген беркемнән курыкмыйча, бөтен шартын китереп, бер Аллаһ ризалыгы өчен корбан чалалар иде... Мәчетләре җимертелгәч, кырларга чыгып, зиратларга кереп намаз укырга мәҗбүр булган татарлар бүген үзләре дәүләт тоткан шанлы җирләрдә беркемнән курыкмыйча гыйбадәт кылалар иде...

Ирләр үз эшләрен бетергәч, үзәнлектә әзерләнгән табыннарда чәйләп алдылар, хатын-кызлар исә зур казаннарда корбан итеннән шулпа пешерергә тотындылар. Чирмешән буйларына, куе имән урманнарына, хәтта урыслар яшәп яткан Биләр бистәсенә кадәр казаннардан тәмле ит исе таралды, татарлар хәбәре таралды... Һай, күңелле чаклар, мәңге онытылмаслык хатирәләр булган икән ул! Ит шулпасы пешкән арада, ирләр мәйдан ясап, бил көрәше башлап җибәрде, атлар урман юлы буйлап чаптырып китте, бала-чагалар колга урынына биек агач башларына үрмәләде – бәйрәм башланды! Кемдер кайдандыр кубыз-курай тартып чыгарды, кайсыдыр тирмә-чатырдан думбра-сорнай тавышлары яңгырады, картлар җыелып, зекер, карчыклар мөнәҗәт әйтте, яшь егетләр, каннары кызышканга түзә алмыйча, типтереп бии башладылар. Милләт бәйрәм итә иде! Чатыр тирәләрендә чулпылар чыңлады, җиңгәчәйләр яшь кызларга булачак кияү егетләрен күзләде, балалар яшел чирәм өстендә колыннар белән бергә ятып аунады – милләт бәйрәм итә иде...

Гомәр морза күбрәк Морадбакый абыз янында булырга тырышты, аның һәр сүзен, һәр хәрәкәтен хәтеренә сеңдереп барды. Морадбакый абыз да бу зур гәүдәле, лачын канатларыдай киң җилкәле, янып торган кара күзле мишәр егетен башкалардан тиз аерып алды, үзенә якынайтты, чөнки аңа уен-көлке түгел, хикмәтле сүз кирәк иде. Гомәр морзаның бик тә теге хикмәтле китапны укыйсы, һич югы тотып карыйсы килгән иде, әмма ул бер генә нөсхәдә булып чыкты. Морадбакый абыз ул китапны, күбәйтеп күчереп язу өчен, Казанга һәм Әстерханга җибәрәсен әйтте, әмма соңрак аның үзен дә, ярдәмчеләрен дә тотып алып, кул-аякларын богаулап, Петербургка озатулары билгеле булды, китапны да шунда юк иткәннәр икән. Әйе, Морадбакый Ишали улының, Болгар-Биләрләрдә корылтайлар җыеп, халыкны дингә, азатлыкка өндәп йөрүе карагруһ түрәләргә ошамаган, алай гына да түгел, котларын алган. Әле Батырша явы сүрелеп тә бетмәгән, менә тагы икенче мишәр мулласы мәйданга чыккан! Ырынбурдагы Сәгыйть бистәсе имамнарыннан тиз генә Морадбакый абызның китапларына бәяләмә яздырып алганнар, алар исә аны ислам динен бозучы итеп күрсәткәннәр. Бу бәя белән хәтта Екатерина патшабикә дә танышкан, Морадбакыйны тилелеккә чыгарган, акыллы кеше мондый әйберләр язмас, дигән, аны һәм юлдашларын, мәҗнүннәр, дип, кире туган якларына кайтарып җибәргәннәр. Хәер, «татарга үз дәүләте кирәк!» дигән кешене кем акыллыга санасын, аны йә тотып атканнар, йә тиләләр йортына япканнар... Бәлки Морадбакый абыз, төрмәгә утырмас өчен, башын шулай җүләрлеккә салгандыр, бәлки чыннан да чарасызлыктан, милләт хәсрәтеннән җиңеләя

башлагандыр – бу турыда беркем дә дөресен әйтә алмый. Аннан соң – бөтен илне актарып ташлаган Пугач яулары, Морадбакый абызның ярдәмчеләрен, шушы фетнәдә катнашкан өчен, тотып алып җәзалап үтерүләр, барысының да яңадан иске эзенә төшүе...

Хәер, соңрак Морадбакый абызны эзләп тапты Гомәр морза, ул Богырысланнан ерак түгел Гали авылында яши булып чыкты, инде урын өстендә ята иде. Үлем көтеп ятса да, ул Гомәрне тиз таныды, «Биләр бөркете!» дип башыннан сыйпады, фатихасын бирде, бәйгатен тапшырды... Әйе, ул аңа: «Дин-милләт өчен көрәшне син дәвам итәсең, улым, – диде. – Мин синең киләсеңне белдем, төшемдә хәбәр иттеләр, шуңа күрә Аллаһтан бакыйлыкка күчүне бераз кичектереп торуны сорадым... Менә хәзер тыныч күңел белән китәм инде... Бу дөньяда төрлесен күрдем, әмма иманымны сатмадым, дошманнан да, үзебезнекеләрдән дә таландым, җүләргә чыгарылдым... Бу дөньяда, бу заманда дөрес сүзне әйткән кеше атакка тотылды, тилегә чыгарылды... Әмма дөрес сүзне әйтүчеләр, милләткә юл күрсәтүчеләр дә кирәк... Бәйгатемне сиңа тапшырам, улым, кулымны бирәм – миннән соң милләтне син иманга һәм азатлыкка өндә! Милләтне керәшенлектә калдырма – васыятем шул! Һәр татар, һәр мәкруһ өчен көрәш, кяфер чоңгылыннан чыгар! Болгар-Биләрне яңадан күтәрегез, аны ислам үзәгенә әйләндерегез, бу җирләрдә мөселман-татар дәүләте төзегез! Әмма моның өчен әле сезгә бик күп авырлыклар күрергә, бик күп югалтулар кичерергә туры киләчәк, Аллаһ бәхетсез милләтемә сабырлыклар бирсен һәм җиңү насыйп итсен иде...»

Әйе, Морадбакый абыз, чыннан да, Гомәрнең килүен генә көтеп яткан икән, шушы сүзләрне әйткәч, ул аның кулында тынычлап җан бирде, бу дөньядан шәһадәт кәлимәсен әйтеп, елмаеп китте... Дивана, мәҗнүн, дип даны чыккан ил карты милләтенә иң кирәкле сүзләрне әйтеп китте... Ул кисәткән авырлыклар һәм югалтулар да тиз килеп җитте, илдә тәхет алышу белән, тагы татарларга һөҗүм көчәйде, Болгар-Биләрләр күген тагы тәре шәүләсе каплады... Морадбакый абыз әйткән көннәр җитте...

– Әйе, оланнар, Морадбакый абыз әйткән көннәр җитте, – диде Гомәр морза, үз-үзенә сөйләнгәндәй. – Әби патшабикә биргән хөррият тә ярым-йорты гына булып чыкты, татарлар баш күтәрмәсен өчен генә безгә калҗа ыргыттылар. Бер караганда, дин иреге килде, икенче яктан, үз динеңә кайтырга ирек килмәде һәм, көрәшмәсәк, килмәячәк тә! Микулай патша дигәннәре башта әйбәт кенә башлаган иде, без иллеләп керәшенгә яңадан исламга кайтырга рәсми рөхсәт тә ала алдык, әмма бу эш тиз тукталды, хәзер андый рөхсәт юк һәм булмаячак та... Хөкүмәт безгә каршы эшли, моны яшереп тә тормыйлар, соңгы татарны чукындырып бетермичә туктамаячаклар. Ә мәкруһлар бик күп, милләтнең кимендә чиреге көчләп чукындырылган, яңадан үз диненә кайта алмый тилмерә, шул сәбәпле күп авырлыклар күрә, иленнән-жиреннән куыла, кыйнала, хәтта үтерелә... Инде нишлик, җәмәгать? Бүгенге мәхкәмә татарларны куркыту өчен эшләнгән эш бит ул, барыбызга да хәбәр бирәләр – йә чукынасың, йә урының төрмәдә булачак! Халыкның үз иманы өчен ахыргача көрәшергә көче, сабырлыгы, түземлеге җитәрме, яки, әнә Актау керәшеннәре кебек, чын-чынлап чукынып яши башларлармы?

– Халык хәзергә нык тора, Гомәр әзи! – дип җавап бирде йорт хуҗасы Исмәгыйль морза. – Моннан ун еллар элек Акъяр һәм Кади керәшеннәренә яңадан исламга кайтырга рөхсәт булгач, халык дәррәү кузгалды, мондый авылларның саны – йөзләгән, патшага үтенеч хатлары – меңләгән! Менә

шушы хәл чиркәү әһелләрен куркытты да инде, чөнки керәшен татарлары, алар белән бергә чуваш-чирмешләр китсә, аларның приходларында кеше саны калмаячак! Һәм алар бу китүне «чиркәүгә каршы фетнә» итеп хөкүмәткә күрсәтә башладылар, шулай итеп, патша хәтле патшаны безгә каршы бора алдылар. Хәзер яңадан исламга кайтырга теләгән мәкруһларга закон бик каты – аларны, бөтен мал-мөлкәтен тартып алып, җинаятьче ясап, урыс авылларына сөрәләр, анда кыйнап эштән чыгаралар... Шунда христиан динен тотмасалар, татар хатын-кызларын, ирләреннән аерып, урысларга кияүгә бирәләр, ирләрен исә Себер сөрәләр, монастырьларга ябалар, гомерлек солдатка җибәрәләр... Милләтнең хәле бик авыр, Гомәр әзи, күпмегә түзәр!

– Алай да бүгенге мәхкәмә күңелдә бераз өмет уятты әле, – дип, Ишмөхәммәт тә сүзгә кушылды. – Алар мәсьәләне бүген үк хәл итеп, Гөләйзаның үзен бер якка, балаларын икенче якка каерып илтеп ташлый алалар иде бит... Биләр побы ярсый-ярсый шуны таләп итте дә, балаларны чукындырырга инде суларына кадәр әзер булган, Якуб атакай әйтте. Алланың рәхмәте, эшне бер айга чигерделәр, аларга да, безгә дә уйланырга, әзерләнергә вакыт бар.

– Әйе, бүгенгесе кадерле, ә бүген балаң һәм оныкларың иректә, – диде Гомәр морза. – Исмәгыйль энем, мин карт инде, күзләрем дә күрми, әмма өстемдә Морадбакый абызның әманәте тора – бер генә керәшенне дә аларга калдырмаска, дигән васыять ул! Чиркәү азды, ул да һәр татарны керәшен ясау өчен көрәшә, монда хөкүмәт кешеләре белән эш йөртеп карарга кирәк, дип уйлыйм, урысның да төрлесе бар, иске диндәгеләре безгә охшаган, диләр...

– Әйе, Гомәр әзи, алар да безнең кебек хакимияттән һәм рәсми чиркәүдән күп зыян күргән, газап татыган кешеләр... Алар белән сөйләшүләр алып барабыз, бер шәһәрдә яшибез бит! Бүгенге мәхкәмә алдыннан да судьяга эшне аңлаткан идек... Әмма аның өстеннән өяз судьясы бар бит, һәр адымын күзәтеп һәм әләкләп торучы Биләр атакае бар, шуңа күрә ачыктан-ачык эшләп тә булмый. Әмма кул кушырып ятарга да ярамый. Бер ай – шактый вакыт ул, аның бер генә көнен дә әрәм итмичә әзерләнергә, сөйләшүләр алып барырга кирәк. Хәзер безгә иң мөһиме – вакытны сузу, төрле сәбәпләр табып, мәхкәмәне чигерү, үзебезнең файдага өстәмә дәлилләр җыю. Әмма Биләр побы һәм Казан әрхәрие дә йоклап ятмаслар, алар Гөләйзаның Пелагея икәнен исбатлау өчен бөтен көчләрен куячаклар, хәтта чиркәү кенәгәләрен дә яңадан тутырырга мөмкиннәр.

– Әйе, Кызылъярның элеккеге побы без әйткәнчәрәк тутыра иде ул кенәгәләрне, аларына акча гына кирәк иде... Монысы яшь кеше, эчәргә ярата, бүген без әйткәнчә эшләсә, иртәгә көмешкә хакына аларча да сөйләргә мөмкин... Эчкән кешегә ышаныч юк. Бу хәлләр буласын баштарак белгән булсак, балаларын алып, качырган булыр идек Гөләйзаны, соң белдек шул, капка төбенә приставлар килеп туктагач кына белдек...

– Хәзер ул качып йөрүчеләрне дә бик нык эзәрлеклиләр шул, теләсә кайда тотып алып, аяк-кулларына богау салып, ристан кебек кайтарып ташлыйлар һәм хөкем итәләр... Инде эш судка барып җиткән икән, монда көрәшеп карарга кирәк.

Гомәр морза аларны зур игътибар белән тыңлады, башкалар да сүзгә катнашмыйча, тыңлап кына утырдылар. Әйе, татар авыллары кан елый, гаиләләр таркала, халык мал-мөлкәтсез кала, иң кызганычы, иң авыры – милләтне кычкыртып иманыннан аералар... Һәм бу – хөкүмәт сәясәте, патша белән чиркәү әһелләренең татарларга каршы берләшеп эшләгән явызлыклары

иде... Нишләргә? Кая язарга? Кая барып карарга? Кемнән ярдәм көтәргә? Урыс һәм татар диннәре арасында бәргәләнгән бәхетсез милләтне ничек саклап калырга? Бугаздан алган бу сорауларга берсенең дә җавабы юк иде. Барысы да шуны аңлады: бүген керәшен татарларын шулай җиргә салып таптасалар, алардан соң иртәгә чират мөселман-татарларга да җитәргә мөмкин иде.

– Исмәгыйль энем, син халык арасында йөрисең – нигә рәсми динчеләр бу мәкруһларны якламый соң? Безнең бит Әби патша төзеп биргән мөселманнар идарәсе бар иде Ырынбур-Уфаларда, мөфтиләр бар, нигә аларның тавышы чыкмый?

– Алар теркәлгән мәхәлләләр белән генә эшли, Гомәр әзи! Бары тик рәсми мөселманнар белән генә эш йөртә. Керәшен татарлары христианнар исемлегендә, аларны ачыктан-ачык яклау – ислам диненә тарту, аздыру дип атала, моның өчен закон бар, җәза бар, моның ахыры – төрмә. Шуңа күрә рәсми динчеләр, мөфтиләр милләтнең бу фаҗигасеннән читтә торалар. Аларны бит хакимият үзе куя, үзе ала, үзе өчен җайлы булган, хакимият сәясәтенә каршы булмаган кешеләрне генә куялар анда...

– Үзем дә шулайрак уйлаган идем аны, ышанып бетәсем генә килмәгән иде... Кемгә таянырга да белгән юк, оланнар! Морадбакый абыз мең тапкыр хаклы булган – үз дәүләтеңне торгызмыйча, кяфер коллыгыннан котылып булмаячак икән! Ул әйткәнчә, Болгар-Биләрләр өстендә яңадан ислам байрагы җилфердәгәндә генә милләтебез исән калачак, башка юл юк!

Моның шулай икәнен барысы да белә, шул ук вакытта моны тормышка ашырып булмаячагын да барысы да белә иде. Әмма картка каршы сүз әйтмәделәр, чөнки үзләренең дә хыялларында үз дәүләтләре иде, бу хакта аның кебек кычкырып әйтмиләр генә иде. Шул чакта моңа кадәр сүзгә катнашмыйча читтәрәк утырган Мөхәммәтзакир сөбхәткә кушылды.

– Агайлар, сез мине кичерегез, яшьләр сүзен дә тыңлагыз әле, – диде ул. – Бөтен вөҗүдебез белән Болгар-Биләр дәүләтен торгызу ягында булсак та, бүгенге хәлдә ул мөмкин хәл түгел. Әмма ул булачак, Болгар-Биләр дә торгызылачак, алар өстендә ислам байрагы да җилфердәячәк, инша Аллаһ! Әмма моның өчен әле йөзләгән ел үтәчәк... Безнең өчен хәзер иң мөһиме – милләтне саклап калу, аның иманын, әхлагын, динебезне саклап калу. Моның өчен дәүләтебез юк, рәсми динчеләр хакимият күзәтүендә, халкыбыз таркатылган һәм куркытылган, кяфер казыган чоңгылга төшеп бара... Тагы бер-ике буын керәшенлек – һәм аларны исламга кайтарып булмаячак, упкын бу татарларны йотачак. Димәк, иң мөкатдәс, иң изге эшебез – көне-төне халкыбызга ислам динен аңлату, мәгърифәт нуры тарату, өметне өзмәү, кулдан килгән бөтен чаралар белән бу мәкруһларны яклау. Инде бу эшләрне ачыктан-ачык эшләп булмый икән, яшерен юлларын табарга кирәк булачак. Без бер генә керәшен татарын да, бер генә авылны да алар ягында калдырырга тиеш түгел! Исмәгыйль әзи, өйрәтә дип уйлый күрмәгез – зур дөньяга да чыгарга кирәк, хәзер башка заман бит! Үз хәлебезне аңлатып, Истанбулга хатларга язарга, илчеләр юлларга кирәк, хәлифәт тә якламаса, безне кем яклар?! Казан-Питерларны шикаятьләр белән күмәргә, адвокатлар ялларга, үзебезне урыс судларында якларга өйрәнергә кирәк! Югыйсә, елап, зарланып утырсак, болар безнең өстән туфан кебек сытып үтеп китәчәкләр, эзебез дә калмас, Аллам сакласын!

Барысы да бу яшь егеткә карадылар, чөнки ул яңа сүз әйтте, башка төрлерәк юллар күрсәтте, бирегә җыелган халыкта өмет уятты.

– Син әйткәннәрнең кайберләрен эшлибез инде, энем, – диде Исмәгыйль морза. – Әмма син дә хаклы – боларны бер тәртипкә салып, даими эшләргә кирәк, анда-санда, килеп терәлгәч кенә түгел. Алыныгыз яшьләр бу эшкә, матди ягы бездән булыр, нәтиҗәсе генә булсын!

– Бу бала дөресен сөйли, – дип, Гомәр морза сүзгә йомгак ясады. – Заман башка, кешеләр башка, хаклык өчен көрәш алымнары да, бәлки, башкарак булырга тиештер... Без инде олылар, шуннан артыгын эшли алмыйбыз, улым! Сез алыныгыз бу изге эшкә, без киңәшләребез белән ярдәм итәрбез, догада булырбыз...

Мәҗлес «Амин!» дип дога кылды, аннан кичәнең икенче өлеше – Аллаһка зекер әйтү башланды. Алар түгәрәкләнеп утырдылар һәм бер җайга селкенеп, көй уңаена оеп, Аллаһка мәдхияләрен укыдылар, изге теләкләрен әйттеләр... Гасырлар буе телдән-телгә күчеп йөргән, Азия чүлләреннән кыпчак далаларына таралган, Каф тауларыннан Идел-Җаек буйларына хәтле килеп җиткән зекер-мәдхия иде бу... Чарасыз калган милләтнең яклаучысы булып, күңелләрен юаткан, өмет чаткысы кабызган, түземлеккә, сабырлыкка өйрәткән дога-теләкләр иде...

Башың күтәр гафләтдин, гафил торма,
һу тигел.
Күзең ачкыл уйкудин, гафил торма,
һу тигел.
Һу-һу тийү һу кошы, акар күзендин йәше,
Көйеп эче һәм тышы, гафил торма,
һу тигел.
Башың күтәр ваемсызлыктан, белми торма,
«Аллаһу», диген.
Күзең ач син йокыдан, белми торма,
«Аллаһу», диген.
Һу-һу, дияр һу кошы, агар күзеннән яше,
Көеп эче һәм тышы, белми торма,
«Аллаһу», диген...

Гөләйза ирләрнең сөйләгәннәрен дә, бергәләп моңлы тавыш белән зекер әйтүләрен дә йотлыгып тыңлады, биредә яңгыраган һәр сүз аның өчен яңалык иде. Ул үзенең ялгыз түгеллеген аңлады, әнә бит нинди кешеләр җыелып, кич буе аның язмышы турында сөйләштеләр-киңәштеләр, ярдәм итү юлларын эзләделәр! Ул, патша хөкүмәте һәм чиркәү тегермән ташлары арасында калган нәни бөртек, аның исән калуы өчен шул тегермәнне туктатырга кирәк икән! Һәм милләттә аны туктатырлык ир-егетләр бар икән! Гөләйза кебек меңнәрчә мәкруһка ярдәм итәргә әзер торган кешеләр бар икән! Алар Гөләйзаны да, аның балаларын да күрәләтә кяфер коллыгына бирмәсләр, инша Аллаһ! Әнә алар нинди зур ышаныч белән Аллаһка ялваралар бит, бу догаларгамы күк капуслары ачылмас?!

...Гөләйза иртән азан тавышына уянып китте, башта үзенең кайдалыгын аңламыйча ятты. Тирә-ягында кеше биеклеге гөлләр, алардан әллә нинди хуш исләр тарала... «Әллә җәннәттәме икән мин? – дип уйлады Гөләйза йокы аралаш. – Җирдә мондый тормыш була алмый... Әллә аның җаны, бу хәтле авырлыкларга түзә алмыйча, җиде кат күкләргә аштымы икән? Ә балалары? Алар кайда соң?!»

Гөләйзаның борчулы уйларына җавап итеп, янәшәдә сабые аваз салды,

аның имәр вакыты җиткән иде. Гөләйза күкрәкләренә шаулап сөт төшкәнен сизде, алар кызышып тулды, бала караңгыда сөт исеннән әнисенең күкрәкләрен эзләп тапты һәм йотлыгып имәргә тотынды. Шул чагында гына Гөләйза үзенең кайда икәнлеген аңлады – ул Чистайда, Хәлимәбану абыстайларда кунакта иде. Әнә әнисе дә торып килә, ул да кичәге хәлләрдән санын җыя алмыйча арып йоклаган, Габделвахит әле һаман мыш-мыш килеп йоклый. Ул арада ишектә Хәлимәбану абыстай үзе күренде. «Ирләр мәчеткә намазга китте, безгә дә укып алырга вакыт», диде ул, балаларны уятмыйча, пышылдап кына. Хатыннар юынып, тәһарәтләнеп, иртәнге намазга бастылар, хуҗабикә үзе, кызлары да алар янәшәсендә иде. Намаз бүлмәсенә әйтерсең лә күктән фәрештәләр төшеп кунаклаган – бу кызлар шундый матурлар, йөзләреннән нур түгелеп тора, ә өсләрендәге киемнәре җәннәттәге хур кызларын хәтерләтә иде...

Иртәнге намаздан соң ятып тормадылар, ирләр мәчеттән кайтышка, чәй әзерләп, капкалап алдылар.

– Юл кешесенең юлда булуы хәерле, без инде кузгалырбыз, – диде Ишмөхәммәт, чәйләп алганнан соң. – Кайтышлый Актауга да сугылырбыз, дигән идек... Сезгә Аллаһның рәхмәтләре яусын – үз туганнарыгыз кебек каршы алдыгыз, кунак иттегез, бу изгелекләрегез үзегезгә меңе белән кире кайтсын!

– Безнең ишекләребез сезнең өчен һәрвакыт ачык, – диде Исмәгыйль морза. – Сез – Аллаһ кунаклары, Аллаһ мосафирлары, дин-ислам юлында күп газаплар күргән изге җаннар... Безгә дә савап эшләргә мөмкинлек бирдегез, үзегезгә рәхмәт! Чистайга килсәгез, туп-туры үзебезгә керегез! Ә суд эшләрен сөйләшенгәнчә алып барырбыз, инша Аллаһ!

Хәлимәбану абыстай кочак тутырып күчтәнәчләр бирде, балаларга әллә нинди матур киемнәр бүләк итте, Гөләйзаны да баштанаяк шәһәр киемнәренә киендерде. Кичә кара кайгыга батып, үлемгә, мәңгелек аерылуга әзерләнеп юлга чыккан Гөләйза, бүген хан кызлары кебек затлы киемнәргә төренеп, мәхкәмәдә вакытлыча булса да җиңеп, ата-анасы, сабыйлары белән өенә кайтып бара... Ул бүген бәхетле, ул бүген шат, ул үзенең ялгыз түгеллеген аңлады, аның янәшәсендә җаннарын ярып бирергә әзер кешеләр барлыгын күрде. Иң мөһиме – Аллаһы Тәгалә бу мөслимә хатын белән иде, шуңа күрә Гөләйза инде бернәрсәдән дә курыкмый иде...

Яңа мәхкәмәгә хәтле аның әле ире, балалары янәшәсендә бәхетле тагын бер ае бар иде...

*(Беренче китап тәмам. Дәвамы алдагы саннарда.)*



Сирень
Якупова

# КАРАШЫМДА ХӨРЛЕК ЧАГЫЛА...

## Тау ташы

Тау ташы мин үзем.
Тик… күптәннән
Үз иткән таш яшәү үзәнен...
Ваклануын вакланмадым,
Ләкин… шомардыммы бераз, –
Үзгәрдем.

Тау ташы мин үзем.
Ерак өндә
Күкрәгеннән бөркет очырган.
Горур җанны күккә чөеп калдым,
Убылганда кыя очыннан.

Тау ташы мин үзем.
Яу ташы да.
Абыналар, башлар ярыла!
Йөрәк мүген юып хәтер ургый,
Карашымда хөрлек чагыла.

Тау ташы мин үзем.
Зар ташы да.
Моң ташы да әле, белсәгез!
Бөркет-бөркет җырым каршы алыр,
Кыяларга, берчак, менсәгез...

---

Сирень ЯКУПОВА (1961) – *шагыйрә, прозаик; «Йолдызлы уйлар», «Яшәү сере», «Кар юлы» исемле китаплар авторы. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

## Чатта

Мин гомернең шундый бер чатында…
Ирексездән,
гел кызыл төс телим  светофорга.
Йөгерә-йөгерә барган җирдән туктап,
торыр идем бүгенгемдә озак-озак…

Исем китми юлның аръягында
кемдер көткәненә.
Язмышымның иртәгәсе
алтын таулар вәгъдә иткәненә...
Тирә-юньдәгенең
эткәненә, төрткәненә,
чыш-пыш килеп гайбәт сипкәненә
исем китми…

Торыр идем
бүгенгемнең һәр мизгелен
тәмләп,
киләчәкне (хет хыялда!) ямьләп.
Битлегемне салып, үз-үземне табып,
Хак таләбен танып,
җан таләбен язып…

Әйе,
Гомернең мин шундый бер чатында... –
Гел кызыл төс телим  светофорга.
Тик...
Дертләп куя йөрәк «сары»сыннан,
аннан «яшел» яна…
                                    Һәм түз генә
бөтереп алган вакыт агышына...
Ялгышына, сагышына…

## Күзләремә авыл карый

И шәһәрнең
Уйдык-уйдык кыргый гөлле ишегалды,
Син бар ярый!
Шул уйдыктан
Һәр иртәне мөлдерәпләр күзләремә
Авыл карый.
Тукранбашлар, зәңгәр чәчәк,
Ак чәчәге...
Бәллүрләнеп җемелдәшә
Чык-яшьләре...
Гөлләр елый, мин чак түзәм –
Ирексездән
Иеләм дә әрем өзәм,
Телгә салам – баллы, чындыр!
Мин чак түзәм, йөрәк түзми,
Әрнеп-әрнеп

Әчеттерә күкрәгемне –
Җирсү шулдыр...

И шәһәрнең
Уйдык-уйдык үлән-гөлле ишегалды,
Син бар ярый!
Һәр иртәне
Таш сукмаклар арасыннан
Мин – адашкан баласына
Авыл карый...

***

Гомеремнең
Әниле еллары белән
Әнисез еллары тигезлеге
Җитте...

Әниле елларның яктысы
Әнисез юлларым яктыртты.
Әниле елларның җылысы
Җылытты гомерем яртысын...

Рәнҗетсә әнисез елларым,
Әниле балачак юатты.
Әнисез елларым елатса,
Әниле яшьлегем
Яшемне сөртергә мең кайтты...

Әнисез җуелган нигезне
Әниле хәтерем саклады.
Әниле, әнисез еллар бар...
Юк җанның әнисез чаклары!

## Җан авазы

«Ник тудырдың мине шушы илдә?
Җинаять бу, әни!»
Әллә уйлап, әллә уйнап әйткән
Кызымамы рәнҗим?!

Телсез, өнсез калып һәм... җавапсыз
Торам менә басып...
Шапылдатып аңым ишек япты –
Йөрәк шәрран ачык.

«Ник тудырдың мине шушы илдә?»
Сулык-сулык ярам.
«Шушы иле», белмим, кемнекедер,
Җире газиз, балам!

Ата-анам, әби-бабам җире,
Һәр карышы үздер.
Китәрмен бер ташлап Ак дөньяны,
Кара җирне түгел!

«Шушы иле», әйе, кемнекедер,
Без – үксезләр аңа.
Ил какканда, хәтта... мин какканда,
Җиргә сыен, бала.

Туган телгә, иман-дингә сыен,
Җан авазым ишет!

Ник тудырдың, никләр тудым, диеп,
Яшәү, ай-һай, читен...

...Кабатлана бар да... Шул сорауны
Биргән көнем истә,
Һәм... сискәнгән мизгел,
Телсез, өнсез калган әниемнең
Җан авазын ишетеп...

***

Төшләремә яланаяк керәм...
Имеш,
Йә мәктәпкә, йә кибеткә шулай
барганмын...
Матур күлмәк өстә,
Ефәк яулык,
Ә чүәкләр кая калгандыр...

Ялантәпи бер мин генә, имеш,
Оят, читен, тагын әллә ничек...
Балачагым төштә үч аламы
Бүгенгемнең ун туфлие өчен.

Затлы күннән, лаклы, лаксызлары,
Төсләре дә, фасоны да төрле...
Яланаяк җиргә баскан да юк,
Авылымнан киткән җәйдән бирле.

Яланаяк җиргә, их, баскан юк!
Чыклы үлән назы онытылган.
Ширпы кадалмый ла табаннарга,
Йөз чытыла йөрәк авыртудан.

Төшләремә яланаяк керәм,
Үткәнемне күрәм, киләчәкне:
Ак дөньяга ялантәпи килеп,
Яланаяк кына китәчәкне...

## Шәһәр күгәрчене

Аклары читлектә утыра баш иеп...
Күкләре чүплектән җим эзли мәш килеп,
Баш иеп, баш иеп...
Текәләм күкләргә,
Ешая сулышым,
Күгәрчен булсаммы?!
Читлекне онытып,
Их, очар идем лә
Иңендә болытның!
Ешая адымым,
Булсаммы канатлы,

Онытып ашауны,
Их, очар!..
Абындым, егылдым,
Теземне канаттым...
Атлыймын баш иеп...
...кебек...

## Кичке кала

Күз камаша неон балкышыннан,
Мең тәрәзә яна бер йортта.
Рәт-рәт фонарь, фара ташкыннары –
Кичке кала тоташ гел утта.

Ә бит минем
Үтерепләр йолдыз «күрге кели»,
Һич югында айның китеген.
Текәләм дә күккә, кызгылт бушлык
Тери җанга авыр итеген.

Баса, баса... Тын кысыла, йөрәк
Туктар чиккә җитә...
Аһ, каһәр!
Йолдызларны онытттырыр өчен
Төзелгән лә икән бу шәһәр.

Айга карап уй уйлатмас өчен,
(Һәм улатмас өчен сагыштан?!)
Күңелләргә – читлек, аңга – капкын,
Тәнгә – зиндан... Бар да ак таштан...

Язмышныңмы «кара» көлүе – шул
Ак зинданга ябып тилмертү.
Татлы сулар алда, тәмле ашлар...
Гомер итү генә – гел көтү
Яши башлаганны кайчан да бер
Җаның теләгәнчә... иректә,
Үз-үзеңнән качар җай эзләми,
Газапланмый, җитеп соң чиккә.

Үтерепләр йолдыз «күрге кели»,
Һәр төн саен айга багасы...
Дога итеп шигырь көйли-көйли,
Чынга ашмас хыялларын җирли,
Неон балкышыннан
Сукырайган авыл баласы...

***

Бүген, хәзер, шул мизгелдә яшә!
И тыңлаусыз булды бу йөрәк:
Яшьлектә гел киләчәк дип типте,
Үткәннәр дип инде тилерә...

Күңелгә ни... Йөрәк сүзе – канун!
Икегә – бер!
Ярый... акыл файдасына түгел…
Кара йөзле, нурсыз күзле булып,
Узар иде көнем, аты-юлы белән
дөнья сүгеп.

Ә болай рәхәт. Акыл дәшми.
Үткәннәр белән яшим...
Ни дисәң дә, матур кебек алар:
Алсу булып кына истә калган
таңнар...
Төннәр, билгеле, айлы-йолдызлы,
Йөрәк – сөюле, җан – моңлы.
Иң мөһиме – хыял бар! Ак!
Киләчәктә, ягъни мәсәлән, бүгенгемдә
Чынга ашмаячак...

– Менә хәзер, шул мизгелдә яшә!
Ялгыш ишетәмме: йөрәк дәшә!
Күңел кушыла, акыл кабатлый...
Тыңламый да чарам юк,
Яшәп тә булмый –
Үз-үземдә... гүя, адаштым...



Хисаметдин
Исмәгыйлев

# ӘФГАН ТАУЛАРЫН КИЧЕП...

ПОВЕСТЬ

Таң белән, юынып та тормастан, урамга чыктым. Моны әнинең кушуы буенча эшләдем, кичтән үк өйрәтеп куйган иде. Имеш, урамда кем беренче булып очрар… Безнең әни шундый юк-барга ышанучан кеше инде.

Йә Ходай, тыкрыктан Юрис абзый чыгып килә, әзрәк салмыш та ахры. Хәер, аның салмыйча йөргән чагы да юк. Ул – авылның бригадиры, үзе болай начар кеше түгел. Әмма шайтан аяклы кеше. Юлга чыкканда ул очрадымы, иң яхшысы – кире борылу, юлың барыбер уңмаячак... Белгән догаларымны укыдым да кулдагы икмәк кисәген күрше Габдулла бабай этенә ихата аша гына очырдым. Эт мине белә, койрыгын болгап, рәхмәт әйткән сыман карап алды да икмәк кисәген ике генә капты.

Түземсезлек белән көтеп алган әни:

– Кем очрады, улым? – дип сорады.

– Урам буш, беркем дә очрамады, әни. Икмәк кисәген Габдулла бабайлар этенә бирдем, – дидем, күз дә йоммыйча.

– Бик әйбәт, улым, болай булгач, юньле кешеләр белән ару урынга хезмәткә эләгерсең, – дип куана-куана, плитә тирәсендә чаж да чож пешеренә башлады. Дөресен әйтеп, әнинең күңелен шомландырасым килмәде инде. Чөнки әнинең Юрис абзый турында: «Таш аяклы да кеше инде, ул очраса, бер дә хәерле юл булмый», дип сөйләгәнен әллә ничә тапкыр ишеткәнем бар. Үзем болай андый-мондый юрауларга бик ышанып та бетмим. Әйдә, әни миңа беренче булып эт очраган дип уйласын. Эт очраса, юл уңуына ышана инде ул. Ерак юлга чыкканда, гарип-горабага, ятимнәргә, йә булмаса, эткә хәер бирергә кушалар. Мин дә шулай эшләдем, чөнки бүген хәрби хезмәткә китәм.

Иртәнге чәйдән кузгалуга, күрше-күлән, туган-тумача җыелышып, мине армиягә озатырга килеп тә җиттеләр.

Искерә төшкән киемнәремне киеп, пешкән тавык, каклаган ярты каз, кыстыбый, тагы әни пешергән бүтән камыр ашлары, кружка, калак, пәке

---

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ (1953) – *язучы, Эстәрлебаш татар җәмәгатьчелеге рәисе; «Зимагурлар» исемле китап авторы. Башкортстанның Эстәрлебаш районы Тормай авылында яши.*

салынган рюкзакны кулбашыма асып, капка төбенә чыгып бастым. Әни лышык-лышык балавыз сыга. Үземә дә җәл булып китте, әни шул мизгелдә бәләкәйләнеп, картаеп калган кебек күренде. Әти генә, үзенең тамагына төелгән яшен сиздермәскә тырыша-тырыша, кыхым-кыхым килгән булып:

– Син, улым, бик бирешеп барма, анда авыл түгел. Командирларыңны тыңла. Бик алга йөгермә, артта да калма. Ишетсен колагың, безнең йөзгә кызыллык китерерлек булмасын, – дип, үзенең нотыкларын укый. Әти шулай безне адым саен тәрбияләргә ярата. Үзе әйтмешли, безне чын кеше итеп күрәсе килә.

Кызып алган ут күрше Хәмит абзый да:

– Син, парень, тегеләй-болай геройлык күрсәтергә яратасың, сматри, тегендә эләксәң, сак бул, – ди. «Тегендә» дигәне Әфган инде аның. Ул үзе Әфганда хезмәт итеп кайтты, кайтканына дүрт ел булды, һаман өйләнми. Көн саен исерек. Әле дә бит әнә иртә таңнан эчеп алган. «Бу сугыш бетмичә өйләнмим, эчүне дә ташламыйм. Тегендә калганнар өчен эчәм, – ди. – Синең геройлыгың безгә кирәкми, исән-сау йөреп кайт», – дип, әллә ничәнче тапкыр колакка килеп, шым гына пышылдый. Янәсе, туганнар, әти-әниләр ишетмәсен. Үзеңне ничек тотарга кирәклеген өйрәтә-өйрәтә туйдырып бетерде инде. Мин дәшмим, сирәк-саяк күңеле булсынга: «Әйе, ярый», – дип баш каккалыйм. Үзем, Ләйлә күренмәсме дип, югары очны күзәтәм. Ниһаять, ул да килеп җитте. Мин аны безнең авыл кызлары кебек ерактан гына озатыр дип уйлаган идем дә, ул яныма ук килеп басты. Әтиләр алдында уңайсыз булып китте. Ләйлә – шәһәр кызы, безнең авылга картәтиләренә кайткалап йөри. Кичә төнлә саубуллашкан идек тә, түзмәгән, иртән тагын килеп җиткән. Әти-әниләр алдында оялыбрак калсам да, әллә ничек күңелгә рәхәт булып китте. Китапларда язылганча, бер-беребезне үлеп яратышмасак та, озаткалап куя идем үзен.

Ул арада колхоз автобусы да килеп җитте. Быел армиягә китүче егетләр авылдан өчәү, ә колхоздан барлыгы җидәүбез. Автобуска утырганда, көтмәгәндә Ләйлә мине кочаклап үбеп алды да, урысчалап: «Буду ждать сине», – диде.

Бөтен халык «аһ» итте. Җир ярылса, шунда керә идем. Ярый әле ярылмады. Авылда бит безнең болай түгел, шәһәр кызы – шәһәр кызы шул инде. Үзем дә сизмәстән, Ләйләне этеп үк җибәрдем. Автобустагы егетләр шаулашып көлешәләр, Ләйлә белән Мәҗнүн, дип, мине ирештерәләр. Автобус кузгалды. Авыл күздән югалды. Мин тәрәзәдән карап барам. Егетләр һаман Ләйләнең мине үбеп озатканына, әллә көнләшеп, әллә аптырап, үчекләп, шаярткалап алалар.

Районда хәрби комиссариат ишегалдында безне шау-гөр килеп тагы утыз-кырыклап егет каршы алды. Бер ярты сәгатьтән, безне рәтләргә тезеп, фамилияләрне барладылар да, эшне тиз-тиз тотып, тагын да зуррак автобуска утыртып, Уфага озаттылар. Анда янә комиссия үткәрделәр һәм, аерым вагоннарга төяп, төнлә алып та киттеләр.

Тәрәзәдән тирә-юньне карап барам. Кайсы якка барганыбызны шәйләргә чамалыйм, юк, белеп булмый. Озатып баручы офицерлар берни дә әйтми. Янәсе, барып җиткәч белерсез. Вагон умарта күче кебек гөж килә. Егетләр төркем-төркем булып утырганнар: ашыйлар, аракы эчәләр, төрле-төрле анекдотлар сөйләшеп, шаулашып көлешәләр. Якташлар белән бер тирәгәрәк урнаштык. Бүтәннәр дә шулай үзенең якташлары тирәсенә елыша. Җырлашалар, кемдер болай ару гына гитарада уйный. Кем-кемне ничек озаткан, кемнең кеме калган – барысын да төрләндерәләр. Ә мин, берсенә дә кысылмыйча гына, икенче «кат»та тәрәзәдән карап барам. Дөресен әйткәндә, минем бит әле поездга беренче тапкыр утыруым, күзәтеп баруы кызык тоела. Төрле станцияләр,

төрле авыллар күренә. Поезд, үзенең бер ритмлы җырын көйләп, һаман алга, билгесезлеккә чаба. Вагонда төрле хәбәрләр йөри. Имеш, туры Әфганга алып китәләр икән, йә булмаса, Каспий диңгезенә, дип тә сөйләп куялар. Бара торгач, мин дә чамаладым: безне көньякка алып китеп баралар. Юлдагы агачлар шау чәчкәдә. Ә бездә әле агачлар юньләп яфрак та ярмаган иде. Ике тәүлек поездда дыңгырдап барганнан соң, Әстерхан шәһәре кырына китереп төшерделәр. Хезмәт итә торган частька төнлә генә барып җиттек. Туп-туры мунчага алып киттеләр. Мунчадан чыкканда, без инде солдатлар идек. Солдат киемнәре кидереп, казармага урнаштырдылар. Башкортстаннан якташлар хәтсез генә булса да, авылдашларны Уфа үзәк военкоматында ук төрле якларга озаттылар.

Туган илгә хезмәт итүебез менә шулай башланды. Иртән подъём, кич отбой, шуның арасында йөгерү дә йөгерү, ә инде туктап торган арада сәяси әзерлек. Иртәнге сәгать алтыда уяталар, бер шырпы янып беткәнче киенеп өлгерергә, ә кичке сәгать унда бер бөртек шырпы янып беткән арада чишенеп йокларга ятарга тиешсең. Башыңны мендәргә терәргә дә өлгермисең, торырга вакыт җитә. Хезмәттә булмаган кеше йокы кадерен белми. Миңа, авыл малаена, физик әзерлек, йөгерү һәм башка күнегүләр җиңел бирелә анысы. Алты ел күрше авылга көн дә иртән җиде чакрым, дәрес беткәч, өйгә җиде чакрым йөреп өйрәнгән кешегә бу чүп кенә. Бәләкәй арбага бер-ике капчык салып тоттырсалар да, шәһәр малайларыннан калышмас идем. Шәһәрнекеләргә бик кыенга туры килә, йә итекләре аякларын кыра, йә тегесе, йә монысы. Дөресен генә әйткәндә, бәрәңге кәлҗемәләре инде. Йомшак буынлы кешегә бездә шулай диләр. Ә менә сәяси әзерлек белән махсус әзерлекләр миңа кыен бирелә. Урысча чамалы белгәнгә, бик аңлап бетереп булмый. Кайчак аңлаганыңны сөйли башласаң, йә сүзләр дөрес әйтелми, йә җөмлә төзелеше чатлы-ботлы килеп чыга. Шуннан егетләр кычкырып көлеп тә алалар. Нишлисең бит, шул урыс телен гомер бакый яратмадым. Филзә апа белеп «ике» һәм «бер» тезгән икән. Миннән ачыктан-ачык көлүче булмады болай. Шаярышып кына көлү исәптә түгел бит инде. Монда без барыбыз да тигез хокукта. Ә теге «старик», «дед» дигәннәре күрше казармаларда. Без әле карантин дигән нәрсәне үтәбез.

Әнә шулай солдат тормышына өйрәнә-өйрәнә, карантинны да үткәрдек. Солдат анты кабул иткәч, безне, самолётларга утыртып, Ташкент каласына китереп төшерделәр. Каһәр суккыры Юриснең аягы: юраган юш килә түгелме соң? Безне көннән-көн шушы куркыныч «интернациональ ярдәм» дип аталган Әфган сугышына якынайталар бит. Күңел ышанмый, мине монда калдырырлар кебек. Солдатлар арасында да төрле шомлы хәбәрләр йөри. Имеш, тегеләй булган, имеш, болай булган. Тагы да әллә нәрсәләр булачак, диләр. Тагын безне, якташлардан аерып, төрле частьларга бүлгәләделәр. Мине икенче миномёт взводына тәгаенләделәр. Егетләр болай ару гына күренә. Әмма взвод командиры гына бик шәп егет түгел ахры. Минем ватып-сындырып урысча сөйләшкәнне белгәч тә: «Вот ещё один чурка», – диде. Бу сүз инде мөселманнарга тагыла торган кушамат. Шуңа да взвод командирын тәүдә үк яратмадым. Ул моны сизде бугай.

– Ничего, салага, ты ещё меня полюбишь, как мать родную. Если не будешь, то заставлю, – ди бу.

Шулай итеп, армия сафларында хезмәтебез дәвам итә.

Отделение командиры армиядә бик зур кеше инде ул безнең кебек «салагаларга». Бөтенесе аңа бәйле. Ашханәдә ул кайсы өстәл артына утырта, шунда утырасың. Җитмәсә, өстәлнең дә төрле почмагы була бит. Ярый ла шикәр, май, икмәк куелган

башына эләксәң. Аннары, ризыкны кем бүлә бит. Мине өстәлнең иң аргы буш башына утыртты командир. Ярый әле аш бүлүче гадел «черпак» (бер ел хезмәт иткәннәрне шулай атыйлар) туры килде. Ул гел тигез бүлергә тырыша.

Командир белән ике арадагы яшерен киеренкелек аркасында миңа башкаларга караганда авырракка туры килә. Әмма бирешмәскә тырышам. Төрле кыенлыклары, ыгы-зыгысы белән дүрт ай сизелми дә үтеп китте. Бер төнне безне «КамАЗ» машиналарына төяп, каядыр алып киттеләр. Әйтмиләр, шулай да сизенәбез. Шул Әфганга инде. «Солдат телефоны» да тик тормый, шуны сөйли. Моны инде акылы камил булган һәркем аңлый. Безне бит юкка гына көне-төне сугыш алымнарына, тау шартларында сугышырга өйрәтмәделәр. Бер-береңә тауда ничек ярдәм күрсәтергә дә, пуштун телендә ун-унбиш җөмлә дә өйрәндек. Юкка түгел инде бу, юкка түгел.

Эх, дөньяларда бу яшь башлар нәрсә күрер дә, нәрсә булыр, әллә исән калып була, әллә юк. Күңелдә шом. Таң алдыннан таулар арасындагы бер кышлакка килеп урнаштык. Көне буе шунда яттык. Төнлә тагын бөркәүле «КамАЗ»ларга төяп, каядыр алып киттеләр. Шулай дүрт көн тирәсе барып, бер елганы чыккач, чыбыксыз «солдат телефоны» Әфган чиген кисеп чыгуыбыз турында җиткерде. Географиядән үткәннәрне искә төшерергә тырышып, кай тирәдәрәк икәнбез дип уйланып барам. Әмәлгә калгандай, Әфганга бәйле һичбер нәрсә искә төшми.

Тагы берничә көн, берничә төн баргач, безне бер тарлавыкка китереп урнаштырдылар. Иң тәүдә хәйран калдырган нәрсә – өскә ишелеп төшәргә торган тау-ташлар булды. Өскә карасаң, тәннәр чымырдап китә. Безнең авылдагы иң зурдан исәпләнгән Мөгәзәй тавы бу таулар белән чагыштырсаң, бер көрәк җир кебек кенә булып кала. Таулар менә ничек була икән. Таудан берәр таш тәгәрәп төшәр дә сине үтерер кебек. Гел тау башына карап йөреп, муеннар тартыша башлый. Җирдә яткан ташларга абынып, бер-ике рәт егылып та алсаң, аннары өйрәнәсең, тауның биеклеген сизмисең. Шулай да таулар кырында адәм баласы үзен бу дөньяда бик кечкенә җан иясе икәнен чынлап торып тоя башлый. Менә шушында, таулар арасында, без юл сакларга тиешбез икән. Безне, бер взвод солдатны, шушында калдырдылар. Машиналар янә алга китте. Тау-таш арасында уникe кеше калдык. Тирә-якта таулар да таулар. Карап торуга гаҗәеп матур да, сискәндерерлек шомлы да. Машиналар киткәч, тауга күтәрелдек һәм икегә бүлендек. Аста – бормалы-бормалы юл. Таулар арасыннан килеп чыга да таулар арасына кереп югала. Юлның ике ягында ватык, янган БТРлар, «КамАЗ»лар аунап ята. Күбесен аска – елгага очырганнар. Юл елга яры буйлап үтә. Икенче ягында – текә тау, йә кеше башы әйләнерлек кыялар. Юлдан бераз гына читтәрәк егермеләп йорты булган бәләкәй генә әфган авылы урнашкан. Ул яшеллеккә күмелеп утыра. Безнең карамакта рация һәм унбиш-егерме көнлек азык, ике примус, егерме литрлы берничә канистра белән бензин. Ашарга үзебез пешерергә тиеш. Бөтен ризыгыбыз ун буханка икмәк, консервалар һәм коры паёктан гыйбарәт. Консерваларны җылытып кына ашарга инде. Эчәргә суыбыз бар тагын. Бөтен корал аркада. Шуларны күтәреп чак килеп урнаштык. Взвод командиры карт солдат – «дед» икән. Миңа карата бик төксе кыланса да, болай башлы гына күренә. Безне өч төркемгә бүлеп, кайда ничек яшеренергә, кай җирләрне ныгытырга, кайсы төшкә ныграк игътибар итәргә кирәклеге турында күрсәтмәләр бирде. Шул ук көнне, бик күренеп бармаска тырышып, үзебез кереп сыенырлык урын әзерләдек. Командир Кравченко әйтүенчә, шулай эшләгәндә генә монда исән калырга мөмкин икән.

Төркемебездә ике «черпак», бер «дед». Бүтән төркемнәрдә дә шулайрак. «Дед»лар һәр төркемдә дә берәр. Алар безне сугыш тәҗрибәсенә өйрәтергә тиешләр, имеш.

Безгә тәүлегенә егерме дүрт сәгать алмаш-тилмәш тирә-якны, бигрәк тә юлны күзәтергә кушылган. Безнең машиналарның кайчан үткәнен журналга терки барырга һәм командир билгеле код белән бу турыда рация аша үзәккә хәбәр итеп торырга тиеш. Тирә-як тауларда нинди үзгәрешләр була, кем килә, кем китә, «духлар» күренмиме, һәммәсен игътибарга алып тикшерергә икән. Һәр төркемдә дә берәр бинокль.

«Дед» килгәч: «Копайте, если жить хотите», – диде дә йокларга ятты. Без үзебезгә кереп ятарлык бер нәрсә әмәлли башладык. Җир дисәң, хәтере калыр. Монда җир юк, таш та таш. Ташларны тирә-якка өеп, окоп сыман нәрсә әмәлләдек. Көн кыздыра, түзәр хәл юк, су эчәргә ярамый, вакыт җитмәгән. Ярый әле таудан әзрәк җил искәләп китә. Шулай этләнә торгач, кичне дә җиткердек. Консервалар җылытып, кичке аш ашадык. Кемнең чираты – шул дозорда тора. Без йоклыйбыз.

Шулай бер атна үтеп тә китте, тирә-якка өйрәнә төштек. Чиратлап юлны, тауларны күзәтәбез. Ял иткән арада окопларны киңәйтәбез. Төнлә тауларда суык, күзгә төртсәң дә, берни күренми, караңгы, шуңа күрә тыңлыйбыз гына. Тыңлау да бик кызык нәрсә икән ул. Әле тегендә, әле монда шыбыр-шыбыр тычканнар йә кәлтә-еланнар шуыша, йөгерешә, йә таудан таш тәгәрәп төшә. Сирәк-мирәк нindидер кошлар кычкырып куя. Кайбер көнне тау йә ыңгыраша, йә ухылдап көрсенеп куя. Монысы бигрәк тә шомлы. Аны сөйләп тә, аңлатып та булмый, аны үзеңә ишетергә кирәк. Шул вакытта бөтен нәрсә, бөтен дөнья кинәт кенә тынып кала. Тик күктә йолдызлар гына, синең куркуыңны күреп, чекерәешеп көлә сыман.

Чит ил тынлыгы бигрәк шомлы, һәр таш артында дошман утырган кебек. Менә-менә сине атып егарлар сыман. Суыктан, бигрәк тә шушы шомлы тынлыктан үзеннән-үзе калтырата. Окопта палатка астында егетләр йоклый, аларга рәхәт, ә син туңа-туңа сакта торасың. Командир йокламаска куша, килеп тикшереп китә. Кайда инде ул йоклау. Кайсы чакларда бигрәк куркыныч була, әйтерсең лә син бар галәмдә берүзең. Шулхәтле ялгыз хис итәсең, хет бүре кебек улап җибәр. Безнең төркемнән ике йөз-өч йөз метр ераклыктагы икенче төркемдәгеләргә дә шулай, күрәсең. Көткәндә вакыт һич үтми. Офык яктыра башлаганын көчкә көтеп аласың.

Монда караңгы ничек тиз төшсә, таң да шулай ук тиз ата. Тауларда кемнең таң аттырганы бар? Дөньяда иң гүзәл күренешләрнең берсе ул. Бигрәк тә син тау башында булсаң һәм түземсезлек белән төне буе таң атканын көтеп утырсаң. Дөньяга яңадан туган кебек буласың. Аста елга ага, тау елгасы. Аның шау-гөр килгәне югарыга кадәр ишетелми. Елгадан томан күтәрелә. Теге якта, каршы тау итәгендә, озын-озын чинар, тагы без белмәгән агачлар арасына яшеренеп, бәләкәй генә әфган кышлагы урнашкан. Тәүге көннәрдә кышлак ташландык, серле бер урын булып күренсә дә, бүген, ничектер, ул күңелгә якын. Җил бу яккарак искәндә, анда-санда эт өргәне, әтәч кычкырганы ишетелеп китә. Иң кырыйдагы өйдән сыек кына төтен күтәрелә. Монда өйләр барысы да бер-берсенә охшаган, яссы түбәле, балчыктан. Кышлак уртасында ихатасы матур ямь-яшел бакча белән уратып алынган зур, биек бер өй. Мөгаен, берәр байның өедер инде. Кайвакыт тауларны яңгыратып азан тавышы ишетелеп куя. Күңелгә рәхәт булып китә. Моны тик мөселман гына аңлый. Кяфер кешегә моны аңлау насыйбы тимәгән.

Ә без күзәтәбез. Кулларда бинокль. Алмаш-тилмәш күзәтәбез. Кушылганча, үтә дә дикъкать белән. Һәрбер ташны җентекләп. Кышлак кырыннан без күзәткән юл уза. Юлдан юньләп үткән кеше дә юк. Атнасына барлыгы ун-унбиш машиналы ике колонна үтте. Әнә, авылдан ишәкме, әллә лошакмы җиккән бер әфганлы чыкты. Ике тәгәрмәчле арбасына бер-ике капчык салган һәм бер бала утырткан. Шәп-шәп атлап, Кандагар ягына китте. Базаргадыр, мөгаен. Авылдан көн дә берничә сыерны, бер көтү кәҗә-сарыкны тауга куалар. Көтүне ике малай көтә. Авылны күзәтү кызыграк та, күңеллерәк тә. Анда үзенчә бер тормыш бара.

Ниһаять, кояш кыздыра башлый. Тәүдә тән җылыга туя алмый, тора-бара үзең дә җылынасың, аннан кыздыра башлаган кояш җылысына тир бәреп чыга. Бераздан мине алыштыралар. Ашап алганнан соң, өсте палатка белән ябылган куыш-окопка ял итәргә кереп ятам. Арыткан. Изрәп йокыга талам.

Безнең тау-таш арасында ятканга унике көн булды. Ә хезмәт итә башлавыма озакламый алты ай була. Һәр кешенең кесәсендә календаре бар, үткән көннәрне шунда билгели бара. Берсе энә белән тишек тишә, берсе аркылы-торкылы сызып тәре куя, берсе түгәрәк сыза. Мин үзем һәр үткән көнне түгәрәк эченә алам.

Хезмәт шулай җай гына бара. Көн дә шул ук күренеш. Үзебез белән алып килгән су да, азык та чамалы гына калды. Бик шәп итеп мунча кереп, рәхәтләнеп бер каен себеркесе белән чабынасы иде. Эсседә тирләтә. Итекләрне салып, аякларны җилләтәсе, рәхәтләнеп җиргә, үләнгә басып яланаяк йөрисе килә. Егетләрнең аяклары бозыла башлады. Мин, элекке бабайлар кебек, көн дә кич аякларны ком-балчык белән ышкыйм. Рәхәт булып китә. Моны безгә тарих укытучысы Хәлимә апа сөйләгән иде. Аңа – мәрхүмәгә мең рәхмәт инде. Бер шулай дин турында сүз чыгып китте. Без әле алтынчы класста укый идек. Безне бит атеистлар итеп тәрбияләделәр. Дәрес вакытында: «Ә менә мөселманнар чүлдә ничек тәһарәт алганнар, әнә бит, юынырга түгел, эчәргә дә су табып булмый?» дигәч, «Бәдәвиләр ком белән юынганнар. Ком белән аякларын, кулларын ышкыганнар. Шул тәһарәт алуга бәрабәр. Ком да чистарта, тазарта», дигән иде. Укытучыбызның шул җавабы ярап куйды менә.

Никадәр саклап тотсак та, су бетте. Ризыкны тагын бер-ике көнгә сузарга була әле. Әмма сусыз түзүләре ай-һай яман. Командир дүрт солдатны суга җибәрде. Бер өч сәгать чамасы вакыт үткәч, су алып килделәр.

Рәхәтләнеп эчтек. Битләрне юып, кырынып алдык. Кырынучылар күбесе «дед»лар инде. Безнең кебек «салага»ларның мыеклары яңа гына сызылып килә. «Дед»лар әйтмешли, без сөлге белән генә кырынабыз.

Буш вакытта окоп тирәнәйтәбез. Без дигәнебез – салагалар һәм черпаклар. Шуңа да окоплар сукыр тычкан оясын хәтерләтә башлады. Таш актарабыз да таш өябез. Шулай тау арасында ятабыз. Сугыш дигәненең «с» хәрефе дә ишетелми. Әйтерсең, дөньяның барышы бер урында туктап калган да, көн дә шул күренеш кенә кабатлана.

Ниһаять, берничә көннән безгә алмаш килде. Безне төп частька алып кайттылар. Мунча кереп, киемнәрне тәртипкә китереп, өч көн ял иткәч, тагын тауларга җибәрделәр. Хәзер инде без теге бәләкәй кышлакның арт ягында идек. Яңа урынга урнашсак та, һаман авылны, юлны, тауларны күзәтәбез. Һаман шул ук палатка белән өсте ябылган окоп һәм бинокльләр. Карый-карый күзләр арып, тонып бетә. Көн дә һәм атналар буе бер нәрсәне алтышар сәгать күзәтә башласаң, бик кызык түгел ул. Астагы кышлакта кемнәр яши, ничек яши – барысын да беләбез дияргә була. Теге лошак җиккән бабай, чынлап та, базарга бара ахры, утын алып бара.

Аннан төрле кием-салым йә ашарга алып кайта. Аннары күрше-тирәгә сата. Йортында берсеннән-берсе бәләкәй бала-чага. Әнә авыл уртасындагы ак йортта улы һәм килене белән бер әби яши. Әбине иртән күтәреп алып чыгалар һәм кәнәфигә утырталар, көн кыздыра башласа, чинар күләгәсенә күчерәләр. Елгада зур тәгәрмәч әйләнә. Гади һәм бик акыллы итеп эшләнгән су күтәрү җайланмасы ул. Көне-төне әйләнә, авылга су күтәрә. Безнең авылда да элек су тегермәне бар иде. Бездә тегермән кулачасына су өстән төшә һәм кулачаны әйләндерә. Ә кулача тагын нindидер тәгәрмәчләрне хәрәкәткә китерә. Алар исә үз чиратында тегермән ташын әйләндерә. Таш кырындагы улакка он коела иде. Без, малайлар, Тегермән буасында су кереп, гел шул зур тәгәрмәчнең әйләнгәнен күзәтәбез.

...Кичә теге авыл уртасындагы зур ак йортка бер бик шәп машина килеп китте. «Джип» икән, азактан «дед»лар әйтте. Бер кыз бала, бер үсмер егет һәм бик бай киенгән кара күзлекле ханым килде. Күренеп тора, хәлле кешеләр, матур итеп киенгәннәр. Без ак йорт дип атаган йортка килгән теге кыз баланың монда беренче генә килүе түгелдер, күрәсең. Килүенә күп вакыт үтмәде, үзенә тиңдәш кызлар белән су буена төшеп киттеләр. Су буендагы агачлар ышыкклады аларны. Бу атнада бүтән үзгәрешләр булмады.

Буш вакытларда командирыбыз Виктор Кравченко бездән, салагалардан, ут позициясен ныгыттыра. Янәсе, безне кулга өйрәтә. Үзен һәм солдат хезмәтен шулай хөрмәт иттерә. Ә көннәр сузыла да сузыла. Консервалар һәм галетлар туйдырды. Авызга көчләп тыксаң да, йотасы килми.

Шулай тәмам ялкып, тизрәк безне алыштырганнарын көтеп ятканда, сержант калган ике-өч литр суны түкте дә:

– Йәле, салагалар, тамак чылатырга чишмә суы алып килегез, тапсагыз, капкаларга бүтән нәрсә дә ярый, – диде. Һәм, әфганнардан алыштырып алырга дип, бер плащ бирде.

Тауга менүе генә рәхәт кебек, ә төшүе үзе бер бәла. Безнең кебек дала кешеләренә аеруча. Кәҗә сукмаклары белән авылдан бер-ике чакрым читкәрәк төштек. Унбиш көнләп чиста салкын су күрмәгән кешеләргә нәрсә кирәк? Ташлар арасында тиз-тиз генә юынырга, йотлыга-йотлыга эчәргә кереште к. Куйбышев егете Саша, без канистраларга су тутырган арада, ярда безне саклап торырга тиеш иде. Тау елгасына килеп тоташкан чишмәне күргәч, түзмәде, биленә кадәр чишенеп, автоматын яр читенә ташлап, юынырга кереп китте. Аңа карап, без дә кызыгып, коралларны яр читенә куеп, юынып алдык. Биш минут вакыт үтмәгәндер, канистраларны тутырып, ярга чыксак, безнең автоматларны безгә төзәп, ике әфганлы тора. Ишарәләп безгә киенергә куштылар. Без салкын судан бигрәк куркудан дер калтырап, киенә башладык. Менә сиңа мә! Безнең бит әле үз гомеребездә беренче тапкыр «духларны» күрүебез. Зиһеннәребез буталды. Ничә киеп, ничә салган чалбарны чак кидем. Духларның йөзендә иман әсәре күренми. Йөз дигәнен дә йон баскан, битләрендә ике күзләре генә ялтырый тегеләрнең. Без киенүгә, ишарәләп, кышлакка табан атларга куштылар. Беләләр, иблисләр, чалбар каешларын алдылар, берсе чалбар төймәләрен кисеп чыкты. Ә икенчесе безгә уттай янган күзләрен ялтыратып карап тора. Бер кул белән чалбарларны тоттык, икенче кулда – канистра. Эчтән генә әнкәй, картинәй өйрәткән догаларны укырга чамалап карыйм, һич кенә дә искә төшми, каһәрең. Барыбыз да күшеккән тавыкка охшап калдык. Тик Пермь егете Ваня гына бер ел хезмәт иткән, калганнарыбызга чак-чак алты ай тула. Безне, өч солдатны, тезделәр, дүртенчебез Ваняны су кырында үскән агачка бәйләп тә куйдылар. Бер дух урысча сукалый, ахры, гел «так, так» дигән була.

Затворларын алып, автоматларны кире үзебезгә тоттырдылар, янәсе, үзегез күтәрегез. Духларның яшьрәге безнең артка басты. Эх, малай, үзебезнекеләр тау башында бинокльдән күрмәсеннәр дип, без, юньсезләр, таллырак урынны – елга борылышын сайлаган булдык бит. Тау башындагылар, чынлап та, безне күрмиләр шул. Димәк, безгә ярдәмгә дә килә алмыйлар.

Дух безгә кычкырмый, әмма усал итеп:

– Вперёд! Бежать не надо, будем пух-пух, – дип, автоматка күрсәтә. Болай да аңлашыла. Болардан мәрхәмәт көтү түгел, ул турыда уйларга да ярамый. Шулай итеп, өчебезне кышлак ягына алып та киттеләр. Читтән караганда, тыныч кына авылга таба барабыз. Янәсе, сержант биргән плащны авылда йә алмага, йә виноградка алыштырабыз. Духларның икенчесе елга буенда үскән куаклар арасыннан безне мушкага тотып бара. Коры автомат белән ни эшлисең, җитмәсә, арттагысының кулында пистолет та бар. Бер кул тагын буш түгел, чалбар күтәреп барабыз, шул ук кул белән автомат каешын да тотканбыз, икенче кулда канистра. Менә шулай без дүрт солдат тыныч кына авылга керәбез. Чөнки арттагы дух Пермь егете киемен кигән. Читтән карасаң, һичбер аерма юк, буйлары да туры килеп тора.

Авыл уртасындагы теге ак йорт күршесендәге бер өйгә алып керделәр. Өй хуҗасы йөгереп чыкты, безнең арттан пистолет тоткан духка кызып-кызып нәрсәдер аңлата башлады. Тау башына төртеп-төртеп күрсәтә. Әмма теге дух йорт хуҗасын төртеп җибәрде дә тамак төбе белән каты итеп аңа җикерде. Өй хуҗасы йортына кереп китте. Дух безгә, кулы белән ымлап, өйнең нигез буена утырырга кушты. Нишлисең? Барып утырдык. Таудан безне күрә алмаячаклар. Авылда өйләр тыгыз утырган. Балчыктан, таштан өйгән биек-биек коймалар. Таудан караганда, авылның һәр өе яхшы күренә сыман иде, алай түгел. Чинар, хөрмә һәм башка агачлар арасыннан авыл юньләп күренмәгән дә икән. Үзем шулай уйлыйм, үзем астан гына күзәтәм. Ничек котылырга моннан? Капка бикле. Койма биек. Озакламый кайдандыр тагын алты-җиде дух килде. Өйгә кереп киттеләр. Ә берсе безне саклый, бездән күзен алмый. Тегеләр үзләре белән Пермь егете Ваняны алып килделәр. Духлар Ваняны кыйнаганнар, күрәсең. Аның борыны канаган, ирене ярылган, бер күзе күгәреп, бөтенләй капланган. Ваняны минем кырга китереп утырттылар, мин сораштыра башлаган идем, шулвакыт безне саклап торган яшь кенә дух арттан кабыргага китереп типте, үләм икән дип торам. Тын бетте, йөрәк чүт туктамый калды, чак-чак адәм рәтле тын ала башладым. Кабырга сынды ахры, тын алган саен чәнчә башлады. Сөйләшергә теләү кайгысы бетте. Бераз утырганнан соң, безне берәм-берәм өйгә алып керә башладылар. Өченче булып мин кердем. Духларның мөселманнарга карата бик үк каты булмаганнарын ишеткән бар иде. Шуңа да ишектән кергәндә: «Бисмилләһир-рахманир-рахим», дип, картинәй өйрәткән доганы укып кергән булам. Теге урысча сукалаган дух:

– Ә, Аллаһны исеңә төшерденме, кяфер колы, – ди. Һәм минем чалбарны төшереп карадылар, янәсе сөннәтлеме мин? Ничә яшь булгандыр, анысын белмим, әмма миңа «яңа чалбар тегәбез», дип алдап, сәкедә сөннәтләгәннәрен бик яхшы хәтерлим. Картәни белән картәти бик диндар кешеләр иде. Менә хәзер духларга шуның нәтиҗәсен күрсәтеп торам.

Урысчаны вата-җимерә, милләтемне сорыйлар, кайсы частьтан, нинди күрсәтмә белән монда килеп эләгүем турында төпченәләр. Мин, солдат антына тугры калырга тырышып, дәшмим. Духлар үзара нәрсәдер сөйләшеп алдылар да тыштагыларны алып керделәр. Аларның да чалбарларын төшереп карадылар.

Тегеләр сөннәтсез иде, чөнки алар барысы да – христианнар. Моны күреп, бер дух төкеренә үк башлады. Теге урысча сукалаган дух үзенең биленнән зур гына гаҗәеп матур һәм бизәкле пычагын алып, кулында зыр әйләндереп, миңа сузды.

– Үзең мөселман, ә үзең кяферлар белән мөселманга каршы сугышып йөрисең. Мә, исән каласың килсә, сөннәтлә шуларны, тыңламасаң, үзем башыңны кисеп, үз кулларым белән казык башына эләм, – ди бу. Вакытны сузып, аңламаган булып кыланам. Автомат прикладына белән берне сыртка салып, ишарә белән күрсәттеләр. Ниһаять, үзебезнең егетләр дә аңлап алды: миңа карап дер калтырап торалар. Духларның йодрыгын беренче татыган Ваня белә: болардан котылу – тик үлем аша гына. Шуңадыр да елап ук җибәрде. Минем кот очты, чәчләр үрә торды. Тегенең пычагын һаман кулга алмый тора идем, духларның берсе күкрәк авызына типтеме, суктымы, аңышмый калдым, аңымны югалтып егылганмын. Биткә су бөркеп һушка китерделәр, кулга тагы пычак тоттырдылар. Пычакны алдым. Үзем: «Әллә бер-икесен чәнчергә дә тәрәзәдән сикереп чыгып качаргамы икән?» – дип уйлыйм. Башта төрле уйлар. Бер адым да ясый алмыйсың, әнә, теге тәрәзә кырындагы дух кулында пистолетын уйнатып кына тора. Беренче пуляны шунда ук җибәрәчәк. Үзем: «Үтерсәләр, тизрәк үтерсеннәр иде», – дип уйлыйм. Юк, үләсе килми. Әти-әниләр әллә кайдан искә төште. Мин шулай икеләнеп торганда, нәрсә беләндер арттан җилкә тамырына суктылар. Кул белән болай сугып булмый. Мин шундук упкынга очтым.

Шулай күпме ятканмындыр, тышта автомат тырылдавына аңыма килдем. Үтереп баш чатный, тамак кипкән, телне әйләндереп алырлык түгел, кайда ятканымны аңламыйм. Начар төш күреп саташам, һаман уяна алмый җәфаланам кебек. Караңгы баз дисәң, баз түгел, ниндидер бер бүлмә. Ишек такталары арасыннан якты төшә. Яктылык өстән дә, бер дүрткел тишектән дә төшә. Ә-ә, чак башыма барып җитте – бу якларда кышкы көннәрдә икмәк пешерә торган урыннары бар икән. Идән уртасында тандыр дип аталган чокыр бар, чак шунда төшмәдем. Ишек ярыгыннан карарга дип шуышам. Мөгаен, безнең егетләр коткарырга килгәннәрдер, тышта кызу гына атышалар, кул гранаталары шартлый. Ишекне этәреп карыйм. Юк, бирешми, тыштан бикләгәннәр. Көчкә торып бастым. Баш әйләнә, күңел болгана. Ишекне бөтен гәүдә белән этәргә чамалыйм. Шунда кемдер түшәмдәге тишектән бер бәйләм граната очырды. Калганын уйлап өлгерә алмадым. Ишек белән бергә кайдадыр очып баруым гына хәтердә. Мин кабат караңгылыкка – упкынга төшеп югалдым.

Һушыма килгәндә, кемнәрдер мине аяктан сөйрәп каядыр алып бара иде. Мине ике мәет арасына илтеп салдылар. Шул вакытта ыңгырашканмындыр, күрәсең.

– Тере инде әллә, эт җан, – дип кычкырды кемдер. Шунда гына шәйләдем – үзебезнекеләр! Урысча сөйләшәләр. Күз юньләп күрми, туфрак тулган ахры, баш зыңлый. Аның зыңлавы шулкадәр көчле ки, туктаусыз укшыта. Юньләп ишетеп булмый. Торып басарга итәм, юк, булмый. Шулай мүкәйләп йөрим. Берәрсе килеп ярдәм итсә – егылам да китәм, егылам да китәм. Шунда кайсыдыр теге каһәр суккан канистрадагы суны башка коя башлады. Чәчи-чәчи булса да, әзрәк су да эчеп алдым. Су – су инде, шундук ару булып китте. Күз дә әзрәк күрә башлады. Ишегалдындагы бер баганага тотынып, торып бастым. Җир көчкә үз урынына ятты, йә бер якка, йә икенче якка авыша. Егылмаска тырышып, теге багананы кочаклыйм...

Пермь егете Ваняның аягы яраланган, аны бот төбенә кадәр бәйләп күләгәгә салып куйганнар. Ике солдат үлеп ята, битләренә ак тастымал япканнар.

Командир белән калган егетләр миңа карап торалар. Берсе дә сүз дәшми. Мин аңламыйм. Әйтерсең лә теге яман саташу һаман дәвам итә. Уй-фикер башка керә башлады. Без ничек исән калганбыздыр, белмим. Теге, түбәдән очырылган граната, безне ябып куйган алачыкның идән уртасындагы тирән тандыр эченә төшкән, күрәсең. Шул коткарган. Ә мин, ишек янында басып торганга, иң көчле шартлау дулкынына эләккәнмен. Алачыкның түшәме, ишеге һәм ярты стенасы юк. Теге тандыр урынында зур гына чокыр. Миңа бераз спирт эчерделәр. Безнең взводта медбрат булып йөргән ефрейтор Николай ниндидер укол ясагач, бөтенләй хәл керде. Шуннан минем өчен газаплар башланды да инде.

Взвод командиры Виктор кемнең гаепле булуы турында бүтәннәрдән сорашкан ахры, су алырга барган барыбызның да күпмедер дәрәҗәдә гаебе булганга, мине күрсәткәннәр. Мин селкенмичә дә, тын да алмыйча ятканга, мине үлгән дип исәпләгәннәр. Шуңа да бөтен гаепне миңа аударганнар. Моны азактан санитар Николай аңлатты. Сугышта ничек? Кем гаепле? Иң башта – үлгәннәр. Аннан соң гына тереләр. Сугышның язылмаган законы шулай. Безнең белән булган күңелсез хәлләрнең барысына да мин гаепле булып торып калдым.

Әллә юньле-рәтле сөннәт булмаганга, әллә күп кан югалтканга, минем белән суга барган солдатлар селкенергә дә куркып, ботларын аерып, чак-чак басып торалар. Акланып карыйм, миңа ышанмыйлар. Пермь егете Ваня гына яткан җиреннән: «Гаеп аңарда гына түгел», – дип сөйли башлаган иде, аны әллә саташа дип, әллә бүтән уй беләнме, укол кадап йоклаттылар. Сүзен дә сөйләп бетерә алмыйча, йоклап китте Ваня.

Командир котыра, йөзе кара көйгән.

– Синең гаеп белән икәү үлде, өчәү печтерелгән. Шуларның берсе – Ваня. Ул да аяксыз калырга может. Кем гаепле? Кем җавап бирер? Мин түгел. Син җавап бирергә тиеш. Хәзер сине атабыз. Юк, кыйнап кул пычратып тормыйбыз. Гади генә «чек» һәм син юк! Син сугышта үлдең, кем пулясыннан – анысы мөһим түгел. Духлар белән бәрелешкәндә үлдең. Мөгаен, әниеңә картлык көнендә синең пенсияңне түләрләр. Бер файда синнән. Бу үлгәннәрнең әтиләренә кем ни дип җавап бирер? – дип, үлгәннәргә төртеп күрсәтә һәм, тагын да котырына биреп:

– Барысына да син гаепле, – ди.

Мин башта ышанмадым, куркытадыр дип уйладым. Бу вакытта әллә әле генә эчкән спирттан, әллә уколдан минем өчен барыбер иде. Мине ниндидер ваемсыз бушлык биләп алды. Теге җимерек стеналы алачык алдына бастырып та куйдылар. Командир:

– Хәзер сине атабыз, – дигәч кенә айнып киткәндәй булдым. Әнкәй, әткәй күз алдына килде, елыйсыларым килеп китте. «Яратам, сине көтәм», – дип биттән үпкән, хат язып торган Ләйлә искә төште. Шул минутта Виктор:

– Соңгы теләгең? – ди. Шушы искә төшерүләрдән тамакка утырган төенне йотарга тырышып:

– Өйләнергә иде, – дим.

Бу ничектер шулай килеп чыкты инде. Виктор: «Соңгы теләгең?» – дип сораганда, минем күңелдә «Ләйләгә өйләнеп булмас микәнни» дигән уй иде.

– Өйләнергә иде, – дип тагын кабатладым да миңа төбәлгән автомат көбәкләренә карап тора башладым.

Виктор шунда, тамак төбе белән:

– Булмаганны сорыйсың. Бу мөмкин түгел. Бүтән теләгеңне әйт, – ди.

Мин тагын, үҗәтләнеп:

– Өйләнергә иде, – дим, үзем дә сизмәстән. Белеп торам: хәзер мине атулары ихтимал, нигә бер тапкыр булса да үҗәтләнеп, карышып тормаска? Мин әле тын алам, йөрәк тибә, шулай булгач, минем әзме-күпме гомер дәвам итә.

Командир тынып калды. Мин ваемсыз гына басып торам. Баш тагын әйләнә башлады. Егылмас өчен стенага сөялдем. Стена суык, әмма аркага рәхәт булып китте. Әнә, каршы як тауга ашыга-ашыга өч дух менеп бара. Төзәбрәк атсаң, йә миномёттан бер-ике кучтәнәч «мина» җибәрсәң, алырга була. Яшәсеннәр әйдә, алар да кеше бит. Шунда командир:

– Срочно бабу ему, невесту найти, – дип акырды.

Мин һаман теге өч духны күзәтәм. Йорттагы безнең солдатлар аларны күрмиләр, ә миңа күренә. Алар без калдырган позиция ягына кача-поса менеп баралар. Баш тагын чатный башлады. Басып торган саен баш үтереп авырта, йөрәк, әйтерсең лә күкрәктә түгел, ә баш эчендә. Атсалар, тизрәк атсыннар иде дип уйлый башладым. Җир тагын чайкала башлады, һәм мин тагын упкынга очтым...

Яңадан һушыма килгәндә, башыма кемнеңдер су сибүен тойдым. Гүя, өстән кемдер минем биткә пес итә. Азактан гына шәйләдем: бу кеше безнең командир иде. Ул, минем авызга, борынга туры китерергә тырыша-тырыша, кече хаҗәтен башкара иде. Тәүдә һични аңламый хәлем бетте. Мин кайда ятам, ни өчен мин монда? Җайлап искә төште. Мине атарга бастырганнар иде бугай, тик ни өчен соң әле? Ә-ә, егетләрне духлар сөннәтләгән өчен. Ике иптәш үлгән. Шуларның барысы өчен дә мин гаепле булып калдым. Викторның минем биткә бушанганына ачу кабарды. Бөтен көчемне җыеп, җан ачуыма тегенең бот арасына тибәргә дип, аякларны селтәндем. Барып чыкмады, аяклар һавада буталды. Мин үземнең көчсезлегемнән, үземне яклап бер сүз дә әйтә һәм үземнең гаепсез икәнемне исбат итә алмавымнан гарьләнеп елый идем.

Виктор тагын:

– Невесту ему, последнее желание смертника исполняется, – дип, ниндидер явыз көлү белән көлә.

– Берәр убырлы карчыкны китерегез монда тизрәк, – дип кычкыра Виктор.

Мин чит-ят туфракта буталып ятам. Гаепсез икәнемне бүтәннәр белсәләр дә, мине яклап дәшмичә, Виктордан куркып торганнары өчен ярсып, яшь аралаш яралы җанвар кебек ыңгырашам. Көч-хәл белән торып утырдым. Бераздан бер әфган карчыгын алып керделәр. Мин аны таныдым. Ул теге мин «ак йорт» дип атаган күркәм бай йорттан иде. Кресло-каталкасы белән күтәреп алып керделәр. Карчыкка ияреп, чар-чор елап, урта яшьтәге хатын белән ун-унике яшьлек кыз бала килеп керде. Теге хатын әбине безнең солдатларга бирмәскә тырыша, тарткалаша, кычкыра. Карчыкны күтәргән солдатлар хатынны этеп-этеп җибәрәләр. Хатын аның саен кычкырып елый. Ярты битен яулык почмагы белән каплаган, шәригать кушканча, йөзен чит кешегә күрсәтмәскә тырыша.

Мин Викторның нәрсә эшләргә җыенганын һаман аңлый алмыйм. Үксеп, гарьлектән нәрсә эшләргә белмичә, җирдә елап утырам. Карчыкны креслосы белән минем каршыга китереп утырттылар.

Карчык та берни аңламый: йә миңа, йә солдатларга, йә аңа ияреп тарткалашкан хатынга карый.

– Тор, жених, выбирай невесту, кайсысын телисең – сайла! – дип, Виктор минем билгә китереп типте. Тагын һушны югалтканмын.

Аңыма килгәндә, мине ике солдат күтәреп тора, ә өченчесе битемә солдат кружкасы белән су сибә. Болары миңа таныш түгел, күрше позициядән килгәннәр бугай.

– Сездә ничек өйләнәләр? Мулла никах укыймы әле? Хәзер мулланы да табабыз. Кичекмәстән мулла табарга! – дип кычкыра Виктор. Бөтенләй җенләнде.

– Син үзеңә кәләш сайла, – дип, минем каршымда торган теге әфган хатыннарына күрсәтә. – Сиңа, мөгаен, шушысы ошыйдыр, – дип, теге карт карчыкка ымлый. Чит позициядән килгәннәр шаркылдап көләләр. Мин карчыкка карап торам, үзем уйлыйм – карчыклар кайда да бертөрле инде. Бу карчык күрше авылдагы Хәнифә дигән әбигә тартым. Ә болар көлә. Бу усал бер саташу да түгел, бу – чынбарлык. Минем баштан төрле уйлар үтә. Ничек тә вакытны сузарга кирәк. Базага хәбәр иткәннәрдер, мөгаен, озакламый йә старшина, йә командир Иванов килеп җитәр. Аңлатырлар, мине акларлар, коткарырлар, дип уйлыйм. Йә Ходай, шулай гына итә күр, ярдәм ит миңа, дип, Ходайга ялварам.

Викторның нәрсә сөйләгәне колакка чалынып кына кала.

– Әллә син чын мөселман туганнарың кебек өчесенә дә өйләнергә телисеңме? Йә, сайла! – дип, миңа дәшә Виктор. Теге өч әфган хатыны да миннән күзләрен алмый, алар да аңлады ахры, үзләренең язмышлары ничектер миңа бәйле икәнен.

– Нигә дәшмисең, чурка? Әллә күңелең кайттымы, теләк юкмы әллә? – ди бу. Шул вакытта, эткәләп-төрткәләп, бер бабайны алып килделәр. Күрше позициядән килгән үзбәкме, таҗикмы, пуштун телендә бабайга никах укырга кирәклеген аңлата. Бабай тарткалаша, әллә аңламый. Миңа да теге солдатның «никах, никах» дигән сүзе генә аңлашыла. Виктор, автоматын алып, бабайның баш очыннан бер очередь бирде. Бабай куркып китте, шулай да башын селкеп тора. Ни әйтергә теләптер, йөрәгенә төртеп күрсәтә. Янәсе, «атыгыз». Виктор автомат затворын тартты да бабайның йөрәгенә төзи башлады. Болай олы кешедән көлү теге таҗик солдатына да ошап бетмәде, күрәсең:

– Ярар, үзем укыйм, мин дә беләм, – дип, Виктор каршына килеп басты. Виктор:

– Чурка чурбанны яклый, әйдә, укы! – ди һәм, миңа карап: – Сайла! – дип акырды.

Мине һаман ике солдат тотып тора, ә мин йә карчыкка, йә теге хатын белән кызга карап торам. Теге бала минем күзгә бер тутырып карады да бер адым алга чыкты. Бу кызны да таныдым. Аны өченче көн ак йортка бер «джип» калдырып киткән иде бит. Күрәсең, бу карчыкның берәр оныгыдыр инде.

Мин дә ымлап теге кыз балага күрсәттем. Үзебезнең солдатлар да, күрше позициядән килгәннәр дә дәшмиләр. Викторның явыз икәнен беләләр шул. Аның кулы каты, озак сөйләшеп тормый. Теге баланы минем кырга китереп бастырдылар. Хәзер карчык белән теге хатын чарбайлап елый башладылар. Хәтта теге карчык креслосыннан егылып ук төште, аяклары йөрми, күрәсең. Кире креслога мендереп утырттылар. Виктор таҗикка:

– Укы, – дип җикерде. Теге, бахыр, тотлыга-тотлыга укый башлады. Сүз арасында пышылдап кына мине битәрли. – Нигә баланы бозасың, сиңа хатын ярамыймыни? – ди бу. Мин дәшмим. Теге тагы кычкырып укуын дәвам итә. Нәрсә укыгандыр, миңа билгесез. Әмма минем исемне урысча сорады, мин әйттем. Теге баланың исемен үзләренчә сорады ахры, ул үзенең бала тавышы белән Фотыйма дип җавап бирде. Бу мизгелдә миңа тирә-як тынып калган кебек тоелды. Һәм теге баланың яңгыравык тавышы таулардан яңгырап ишетелгәндәй булды. Ризалыкны таҗик миннән урысча сорады. Мин «риза» дип, урысча җаваплады. Ә теге кыз бала башын гына иде. Мөселманнарда

бит хатын-кызның «әйе» дип әйтүе мөһим түгел. Ул дәшми дә калырга мөмкин. Дәшмәү – ризалык билгесе.

Безнең яклардагы кебегрәк мөселман туена охшатып, бөтен шартын китереп, мине теге кыз бала белән бер бүлмәгә кертеп ябып та куйдылар. Виктор:

– Өйләнсәң, мөгаен, исән калырсың, – дип, арттан кычкырып калды. Алар безнең егетләрне ничек кискәннәр, без дә аларның хатын-кызларын шулай итәбез, – дип, пычрак сүгенде. Бу вакытта безнең солдатлар бары тик үч алу теләге белән генә яналар иде. Алар акны карадан, караны актан аермаслык хәлгә килгәннәр. Чөнки печтерелгән өч егетнең берсе каты яраланган һәм... ике мәет. Бу мәетләр һәм печтерелгәннәр арасында безнең һәркайсыбызның булуы ихтимал иде бит. Менә шуңа да инде егетләр кан исенә исергәннәр, аек итеп уйлый алмыйлар.

Миңа батырлык өчен бер кружка спиртка әзрәк әфьюн тамызып бирделәр. Монда һәр кышлакта әфьюнне бер канистра солярка йә бензинга күпме кирәк, шулай алып була. Безне бикләгән урын бәләкәй генә бер бүлмә булып, әллә җәй ял итә торган бүлмә, әллә йокы бүлмәсе иде. Ярымкараңгы бу бүлмә идәнендә иске келәмнәр, почмактагы сәке өстендә мендәр, ястык, паласлар өелеп тора. Шуннан бер юрган сыман нәрсәне тартып идәнгә төшердем дә, барып утырдым. Теге баланы карап торам. Матур киенгән, кышлактагы балалардан аерылып тора. Чебек кенә, әле күкрәге дә калыкмаган бу балага бармак белән кагылырга да исәп юк. Хәтта текәлеп карарга да уңайсызланам. Шулай да:

– Исемең ничек? – дип татарча сорыйм. Дәшми. Үземә төртеп:

– Исламов Халик, – дидем дә сораулы карашым белән аңа багам. Мөселман исемен ишеткәч, бераз җанланып китеп, үзенең исемен кабатлады.

– Фотыйма, – ди.

Онытканмын, теге таҗик никах укыганда әйткән иде ләбаса. Шуның белән сүз бетте. Тыштагы тавышларны тыңлап карыйм. Дөнья шау килә. Теге бер кружка әфьюнле спирт тәэсир итә ахры. Бу дөньясы миңа барыбер дигәнрәк хис урап алды күңелемне һәм... калганын белмим.

Күпме йоклаганмындыр, күпме вакыт үткәндер, тыштагы шартлау тавышына айнып киттем. Күзгә һичнәрсә күренми. Тышта йөгерешәләр. Шәйләп алдым: безнекеләр кычкырыша. Виктор кычкырып, сүгенеп команда бирә. Мин ишекне этеп карыйм. Ачарлык түгел, тыштан элгәннәр. Хәл дә юк, бөтен тән авырта. Кичә каты эләккән, күрәсең. Ишекне этәрә-этәрә:

– Чыгарыгыз мине! Чыгарыгыз! – дип кычкырам, әмма ишеткән кеше юк. Тагы ныграк этәрә башлаган идем, борыннан һәм колактан ниндидер җылы сыекча агып төште. Тотып карыйм, үзе җылы, үзе ябешкәк. Сизеп торам, кан инде бу. Борыннан акканы авызга керде. Кан шул, тәме шулай. Минем баш тагын әйләнә башлады. Егылмас өчен ирексездән чүгәләп утыруым булды, автомат пулялары ишекне ике тапкыр аркылы кисеп, йомычка ясады. Басып торган булсам, һичшиксез, мине кисеп үтә иде. Алла саклады. Эшнең болай юнәлеш алуын шәйләгәч, шым гына стена буена барып аудым. Бу миңа дип исәпләнгән иде, тик кемнеке. Духныкымы, әллә, чынлап та, үзебезнекеме? Әзрәк торгач, ишекнең астынарак тагын бер атып җибәрделәр. Монысы инде чынлап торып миңа әҗәл итеп җибәрелгәне иде. Уку үзәгендә биргән белемнәре өчен рәхмәт, карантиннан соң безне шунда әзерләгәннәр иде бит. Ишек һәм тәрәзә уемнарында озак тормаска дип, кабат-кабат өйрәттеләр. Менә шул турыда уйлап, стена буенда ятам. Башта бүтән уй да юк. Кем атты? Белеп булмый. Чөнки духларда да совет автоматы – «Калашка» бит. Бездә дә шул.

Тышта шау-шу басыла төште. Әмма монысы бигрәк тә куркыныч иде. Чөнки урыс сүгенүе – Викторның тавышы урынына әллә нинди чит тавышлар килә башлады. Ничек кенә каты, кабахәт булса да, Викторның сүгенүе йөрәккә якын иде. Ә бу тавышлар әллә ничек, шомлы. Шулай уйлап та бетермәдем, кинәт ишек бөтен тупсасы-келәсе белән кырылып та төште. Ишектә озын буйлы, сакаллы, кулына «Калашка» тоткан бер дух басып тора. Тамак төбе белән нәрсәдер әйтеп җикерде бу. Мин дәшмичә ята бирәм. Мине аяклардан өстерәп тышка алып чыктылар. Бернинди каршылык та күрсәтмим. Хәл дә, теләк тә юк. Әйтерсең лә мине түгел, үлгән сарык түшкәсе өстериләр. Баш кына даңгыр-доңгыр бәрелеп китә. Нык бәрелмәсен өчен, кул белән башны йомарлап тоттым.

...Якты кояш нурыннан күз камаша. Иртәнге сәгать ун-унберләр тирәсе булыр, нindидер бер бүлмәдә тәүлек буе йоклаганмын. Башка юньле-рәтле уй керә башлады. Менә сиңа мә, икенче тапкыр духларга эләктем ләбаса. Болары инде баштанаяк кораллы, безнең кебек бала-чага түгел, сазаган ир урталары. Мине бер дух дер селкетеп аякка бастырырга чамалый, ә минем аяклар берни дә тоймый. Әйтерсең, аяклар бөтенләй юк. Мин гөрселдәп җиргә авам. Духлар тәмәке тартырга утырдылар, ә мин, бераз аңыма килеп, тирә-якны күзәтәм. Капка төбендә безнең берничә солдат үлеп ята. Викторны асып куйганнар. Ул болай гына бирелмәс иде, яралангандыр, күрәсең. Терсәктән уң кулы юк, бәйләп куелган. Сөннәтләгән егетләр баштүбән асылганнар, алары әле тере. Берсе кулы белән авызына, борынына кунган чебеннәрне кугалый. Минем алда шундый күренеш, ә артта ниндирәк хәлләрдер – анысын белмим. Селкенергә дә куркып ятам. Духларның берсе минем шулай күзәтеп ятканны күрде. Викторның чалбар каешын салдырып, мине артымда үсеп утырган чикләвек агачына баштүбән асып куярга чамалый, тик көче җитми. Шулай да аяктан күтәреп баштүбән асып куйды. Күрәселәр бар икән. Йөрәк дөп-дөп тибә, баш чатный. Битләр шешенә башлады ахры, шулай тоела. Иптәшләргә карыйм. Духлар бер чинар агачы төбенә чәй эчәргә утырдылар. Әйтерсең лә дөньяда без юк. Әйләнә-тирә бөтенләй тынычланды. Кошлар чыркылдаша. Йорт алдына тавыклар чыкты, әтәч алар тирәсендә кукраеп эре генә кыяфәттә йөри. Аларның үз эшләре: тибенә-тибенә җим эзлиләр. Мин агач күләгәсендә асулы, егетләр кояшта, алар миннән элегрәк асылгангамы, тирә-якларында чебеннәр гөж килә. Әтәч шуңа игътибар итеп, егетләр янына килде һәм, битләренә кунган чебеннәрне тотарга чамалап, сикереп-сикереп егетләрнең битен чукып алды. Аягы ялалы Пермь егете Ваня кулы белән селтәнеп әтәчне куып җибәрде. Хәле мөшкел егетнең. Шуннан әтәч икенче егет янына күчте. Килгән җайга аның битен чукый һәм кыткылдап тавыкларны чакыра башлады. Теге селкенми дә. Йөзе миңа күренми, чөнки җилкәсе белән борылган. Тавыклар күмәкләп чукый башлагач, минем якка борылды. Үлгән икән. Тавыклар күзләрен чокый башлаган. Йә Ходай, миңа да шундый үлем әзерләнде микәнни? Нинди гаепләрем өчен? Безнең нәсел-нәсәбәдә, туган-тумача арасында кеше үтерү түгел, кешенең энәсенә дә тигән кеше юк. Ни гөнаһлар өчен болай газаплыйсың? Бармы Син бер галәмдә, әллә юкмы?! Булсаң, зинһар, туктат мондый эшне, дип ыңгырашам. Бар көчкә тешне кысам, яңаклар шытырдый, тешләр кителә.

Шулвакыт капкадан берәү керде, хатын-кыз ахры, үзе чар-чор кычкыра. Ниндидер Абдулланы чакыра. Мин, гәүдәм белән борылып булмасмы, дип, селкенеп-селкенеп карыйм. Юк, килеп чыкмый. Башны борып карагач, күрдем: теге кичәге хатын икән. Башында кара яулык, битен каплаган. Кичә

безне япкан бүлмәгә төртеп-төртеп күрсәтеп нидер сөйли, шуннан безнең үлгән солдатларга күрсәтә. Духлар дәррәү килеп урыннарыннан тордылар, теге хатын янына килеп бастылар. Бераздан минем янга килделәр. Теге таза дух мине тотып алды да кулында күтәреп тора башлады. Аяк өскә бәйләүле. Кичәге урысча сукалаган дух:

– Кыз кайда? – ди.

– Белмим, – дип, татарча җавап бирәм.

– Ә-ә, белмисеңмени әле, – ди бу. Үзбәк ахры, безнең телләр охшаш бит.

– Тидеңме? – ди.

– Юк, – дим.

Теге үзбәк үзләренең кешеләренә нәрсәдер әйтте. Шуннан әзмәвердәй дух мине, кирәге беткән әйбер сыман, кисәк кенә ташлады. Әллә каеш өзелде, әллә чикләвек ботагы сынды. Мин гөрселдәп җиргә барып төштем. Тагын аңымны югалтканмын. Кичкә табан мине тагын баштүбән асып куйдылар. Шунда гына һушыма килдем. Ни өчен болай иткәннәрдер, әле дә аңламыйм. Үтерсәләр, тизрәк үтерсеннәр иде. Шуның белән вәссәлам булыр. Ярый кулны бәйләмәгәннәр, төнлә ычкынырга тырышып карарга кирәк булыр дип уйлап та бетмәдем, бер дух, өйдән чыгып, минем кулларны аерым бәйләп, өй почмагына кагылган тимер чөйгә тарттырып куйды. Хәзер мин гамакта яткан кеше кебегрәк булып калдым. Аяк-кул өскә тарттырылып, ике якка бәйләп куелган. Болай җиңелрәк, баш бик чатнамый, әмма куллар авырта. Һәм мин инде ничәнче тапкыр һушымны югалтам...

Саташулы-уяулы килеш ятам. Нәрсә булганын белмим. Күпме вакыт үткәндер, билгесез. Әнә, кемдер мине баудан ычкындырып маташа бугай. Ниндидер малайлар каешны киселәр ахры. Тагын кайдадыр өстериләр, һич аңламассың. Тын алып булмый. Мин саташам. Әллә нинди, берчә куркыныч, берчә бик тә матур төшләр күрәм. Әни мине биләүдән алып су кертә икән. И, мин шатланам, и, әни шатлана. Әти кырыбызда тора, барысы да шатлана. Дөнья йә бик матур, йә бик куркыныч. Мин бертуктаусыз упкынга очам. Очам, очам, һич төбенә төшеп җитеп булмый. Төшеп җитеп чәлпәрәмә киләм бит инде. Уянып та булмый.

...Елга буенда комда ятам. Суык, өшим. Ниндидер эт минем битне ялый. Эт түгел икән – бер кыз бала. Кыз бала да түгел, бер малай. Мин саташам. Бу минем хатын да инде. Мин боз булып туңганмын. Ап-ак кием кигән хатын тыны белән мине эретә. Үлгәнмен икән, миңа кәфенлек кидерәләр. Кәфен җылы. Бәй, бу кәфен түгел, әллә нинди чүпрәк-чапрак, чит кеше киеме дә инде. Мин үзем дух икәнмен, башымда да духлар чалмасы. Ниндидер арбада барам. Бәй, теге кышлактагы карт үзенең арбасына салган лабаса, каядыр алып бара. Безгә бер яшь кенә малай ияргән. Ул минем баш очындагы чүпрәкне әйбәтли. Монысы саташу түгел ахры. Тик менә нишләп миндә духлар киеме икән? Туктап, чәй кайнатып, чәй эчтеләр. Миңа да чәй кайнатып эчерәләр, ашарга кушалар. Ашап булмый, чәй эчәм. Чәй әллә нинди, үлән чәе. Эчәргә була. Чәй эчкәч, тагы изрәп йоклап китәм. Тагы саташам, тагын куркыныч катыш татлы төшләр күрәм. Мине кул арбасында да тартып алып бардылар. Ат сыртына аркылы да салдылар. Нигә алай итүләрен һич аңлый алмыйм. Туктап чәй эчәбез дә тагын юлга кузгалабыз. Мин йә йоклап китәм, йә исемне югалтам. Ниндидер машина белән дә алып бардылар. Иң мөһиме – уянган саен чәй эчерәләр, баллы чәй.

Җанны ниндидер битарафлык, ниндидер тынычлану чолгап алды. Кайда алып баралар, кемнәр, нигә, минем өчен барыбер... Шулай ничә көн үткәндер, белмим.

Әмма теге малай гел минем янда, минем белән сөйләшергә дә әйтеп карый, тик аның телен аңламыйм. Минем өчен ул ниндидер бик якын кешегә әйләнеп китте. Шулай мине Кабулда, безнең хәрби госпитальнең капка төбендә калдырып, солдат киемнәрен баш очына куеп киткәннәр икән. Моны медсестралар әйтте. Госпитальдә бер унбиш көнләп яткач кына, үзем белән ни булганын әзрәк аңлый башладым. Шәфкать туташлары сөйләве буенча, минем өч кабырга сынган, баш мие селкенгән, дөресе – авыр гына контузия булган икән.

Әмма иң гаҗәпләндергәне шул: мине коткарган малай госпиталь ихатасы алдында һаман күренгәли икән. Беркөнне шәфкать туташлары ул малайны миңа тәрәзәдән дә күрсәттеләр.

Госпиталь ихатасына чыгып йөри башлагач, ихата аша гына теге малай белән исәнләштем, үзбәкләргә охшатып кулымны күкрәккә куеп, бил бөгеп рәхмәт әйттем. Аңлады ахры, миңа ручка белән конверт суза. Янәсе, хат яз. Мин аңламыйм. Тимер рәшәткәнең ул бер ягында, мин бер ягында. Шуннан конверт тышына язып күрсәтте. Чак аңладым, адрес сорый икән. Хезмәт иткән частьның адресын язып булмый бит инде. Тоттым да үземнең туган авылның адресын яздым. Хәтта районны да язмадым. Үземне иртәгә Ташкентка җибәрүләрен аңлатырга тырыштым. Аңламады ахры. Хәл юк бит инде. Әле култык таягы белән чак селкенеп йөрим. Мин кереп киттем, ул миңа карап торып калды. Икенче көнне мине самолёт белән Ташкент шәһәренә хәрби госпитальгә күчерделәр. Мине ныклап тикшерәләр. Бер профессор хатын миңа: «Куркыныч юк, бу – нерв стрессы, – дип аңлатты чирем турында. – Җайлап барысы да үз урынына кайтачак», – ди. Авылга кайткач та, тәмәке тартмаска, аракы эчмәскә кушты. Ташкентта ике айлап госпитальдә яттым. Беркөнне шулай бакчага йөрергә чыккач, теге малайны тагын күреп хәйран калдым. Күземә күренәме дип торам. Янына бардым. Элеккечә ихата аша гына тагы рәхмәтемне белдердем. Русча да, татарча да кабатлап:

– Бар кайтып кит, зур рәхмәт сиңа, – дим.

Ул нәрсәдер сөйли, мин аңламыйм. Шул минутта палатада бергә дәваланып яткан Магнитогорскидан Фәрит исемле татар егете килеп:

– Тиз бул, сине анда эзлиләр. Хезмәт иткән җиреңнән алырга килгәннәр, – диде. Мин әфган малаена карап саубуллаштым да китә башладым. Теге малай өзгәләнеп нәрсәдер сөйли, хәтта елый ук башлады. Үзе күкрәкләренә күрсәтә, хатын-кыз күкрәге, янәсе, нәрсә уйларга да белмим. Фәрит: «Йә, тиз бул, бетмәс монда таҗик балалары», – дип, мине өстери үк башлады. Бераз киткәч, теге малай минем арттан:

– Талак! Талак! Талак! – дип кычкырып калды. Ни аңлатырга телидер, һич аңламассың.

Мине көтеп торалар иде. Документ-кәгазьләр әзер.

Тиз генә палатага кереп, хәрби кием киендем дә, вак-төяк әйберләрне алып, машинага чыгып утырдым. Биш-алты сәгатьтән мин үзебезнең частьта идем инде. Таныш егетләр калмаган, гел яңалар.

Частька кайтканның икенче көнендә үк мине особый отделга чакырттылар. Шуннан башланды инде: көн дә чакыралар, кайбер көнне икешәр тапкыр. Безнең взводның ничек һәлак булганын белешәләр. Ничек булганын бер егерме тапкыр гына аңлатып кәгазьгә яздым. Егерме көннән минем нерв стрессы, контузия яңадан көчәйде. Аяклар яңадан йөрми башлады. Кабаттан госпитальгә эләктем. Тагы ике айлап яткач, мине частька да кайтарып тормадылар, комиссовать иттеләр. Калганы нәрсә булып беткәндер, һич кызыксынмадым.

...Менә шулай итеп, Әфган сугышында булып, бер тапкыр да мылтыктан атмыйча, хезмәт итә башлавыма бер ел тулганда, мин авылга кайтып та җиттем. Исән-сау кайтуга өйдәгеләр шатландылар. Хезмәтне вакытын тутырмыйча кайтканга үзем генә әзрәк кыенсынып йөрдем. Хәзер өйрәндем инде. Тик кайбер вакыт баш кына авырта, үтерә инде. Аяклар да хәзер әзрәк җайга кереп бара. Ләйләләрнең туе булды. Мин армиягә китүгә, түбән оч Вәкил белән йөри башлаган икән. Ярый, нишлисең бит, аңа да бик көенмәдем. Була торган хәл.

Кеше кебек юньле эштә эшләп булмый, баш авырта башлый. Шуңа күрә колхозда төрле җиңел эштә йөргән булам. Дөресе – эленке-салынкы йөреп ятам шунда. Шулай вакытның да үткәнен сизми калганмын. Әти дә кинәт кенә үлеп китте. «Яман шеш», диделәр. Хәзер әнкәй белән икәү генә яшәп ятабыз. Дөнья миңа калды. Әнкәй дә көннән-көн яшәрми, олыгая бара.

Шулай уйланып йөри торгач, бер уй төште башка. Гомер үтә, иптәшләр, яшьтәшләр барысы да гаиләле булып бетте. Балалар үстереп яталар. Теттереп дөнья көтәләр. Ә мин һаман буйдак. Көн дә бәйрәм, көн дә туй, дигәндәй, хәмер белән дә шаяргалый башладым. Җитмәсә, монавы үзгәреш, перестройкалары башланып китте.

Икенче көнне үк конторага төштем. Эчеп авария ясаган Фәниснең «КамАЗ»ын сорадым председательдән. Безгә туган тиешле кеше ул, бераз тарткалашса да, риза булды.

– Эчеп, бәйрәм итеп йөрер булсаң, үзем тотып арт сабагыңны укытам, парень, – дип кисәтеп куйды. Ул бик кырыс, гадел кеше, әйткәнен эшли. Мин бүтән эчмәскә ант итеп, шул ук көнне машинаны кабул иттем.

Хуҗаның бирми хәле юк. Авылда шофёрлар җитешми. Бүген-иртәгә уборка да башланырга тора. Менә икенче ел инде мин «КамАЗ» йөртәм, эчүне ташладым. Әни шатланып бетә алмый. Эчмәгәч, ерак рейсларга да мине җибәрәләр. Иртәгә дә колхозга төрле кирәк-ярак һәм буяу алырга Самара шәһәренә барам. Ерак рейсларның акчасы да төшемле. Бераз җыйган акча да бар. Самара базарында машиналар да очсыз, диләр, аны да караштырып кайтырга кирәк. Аллаһы боерса, иртәгә таң белән рейска.

Иртән иртүк машинаны кабызып чыктым. Йә Хода, элеге шул шайтан алгыры Юрис тагы килеп очрады. Ул хәзер бригадир түгел. Авыруы сәбәпле, сыер фермасында каравылда тора. Ну торганы бер зәхмәт инде. Машинаны туктатып, үтеп киткәнен көтеп тордым. Әни юлга куйган ризыктан бер телем күмәчне, бисмилланы укып, тегенең этенә бирдем. Бер генә капты. Мин кузгалып киттем.

«Армиягә алганда очрап, мең бәлаләрдән чак котылып кайтып егылган идем. Ярый, начарга юрамыйм әле. Барысы да әйбәт булыр, Алла боерса», дип уйларга тырыштым. Колхозның завхозы Инсафны утырттым, ул бөтен документ, кәгазьләр белән эш итә, йөк ташучы да.

– Нишләп озак, җитмәсә, төсең качкан, нәрсә булды? – ди бу. «Юрис очрады», дип булмый бит инде.

– Юньләп йоклап булмады, әллә ниләр белән саташып чыктым, – дим.

– Шыттырма, төне буе кызлар артыннан чапкансыңдыр әле, – ди бу. Кабинага кереп утыргач, бер-ике сүз кыстырды да, гадәте буенча, йоклап та китте. Ул үзе миннән бер-ике яшькә генә олы, ну салырга ярата. Шунысы бар: колхозга берәр әйбер кирәксә – җир читеннән таба. Кеше белән тиз уртак тел таба, эзләгән запчастьне тапмый кайтканы юк. Шуңа күрә эчсә дә эшләп йөри.

Менә әле Самарада ары чабып, бире чабып, колхозга әллә никадәр запчасть, кыйммәтле буяулар алдык. Акча да артып калды. Инсафның сөйләшә белүе

инде. Колхоздан алган бер фляга бал да бетмәде. Кайтырга чыктык. Инсаф, гадәте буенча, бер яртыны түңкәрде дә гырлап йоклап та китте. Юл әйбәт, машина матур гына эшли. Эсселек сүрелә төште. Көн кичкә авышты. «Юлдан читкәрәк кереп, берәр авыл кырында машинада гына ашап, ял итеп алырга кирәк», дип уйлыйм. Тик анавы арттан килгән «джип» күңелгә тынгылык бирми. Артка төшеп алды да, ни узмый, ни артта калмый. Мин бөтенләй акрынлап бара башладым. Бара торгач, узып китте. Шулай да шүрләтә бераз. Машина тулы дефицит запчасть, төрле буяулар. Җитмәсә, кесәдә ару гына акча да бар. Теге «джип» тау артына ышыклангач, борылып, бер бәләкәй генә урман читенә кереп киттем. Якында гына авыл, елгасы да шәп, матур күренә. Шушында туктап, тамак туйдырып, ял итеп алырга кирәк. Көне буе Самарада ары чабып, бире чабып, арыткан. Күз дә йомыла башлады. Ял иткән баш белән тиз арада кайтып та җитәрбез, Аллаһы боерса.

Әни әзерләгән юл ашларын паяльный лампа астында җылыттым да, тамак ялгап, йокларга яттым. Инсафны ашарга уятып караган идем, ул торып тагын бер стакан җибәрде дә тагын йоклап китте. Караңгы тиз төште. Мин төрле уйларга бирелеп ятам. Инсаф колак төбендә хырылдый, туптан атсаң да, уянмый хәзер. Кешенең рәхәт, бер кайгы юк. Шулай уйлана-уйлана, «КамАЗ»ның өске киштәсендә йокыга талдым.

Төнлә, нишләптер, дертләп уянып китсәм, ни галәмәттер, тәгәрмәчтән пышылдап тын чыга. Әллә тишелде микән? Йөк тә болай бик авыр түгел иде бит. Нәрсә булды икән, дип, Инсафның өстенә басмаска тырышып, кабинадан төштем. Ә тәгәрмәч һаман чыгара. Шырпы сызып карамакчы булган идем, кемдер арттан башка китереп сукты. Эх, шушы башны, теге контузия галәмәте инде, баш бәрелдеме – аяклар киреләнеп, атламас хәлгә килә дә куя. Әле дә аңны югалтмадым, тик аяклар тотмагач, гөрселдәп җиргә аудым. Шунда берсе:

– Монысы әзер, – диде.

Инсафны да өстерәп төшерделәр. Мине читкәрәк илтеп бер агач төбенә ташладылар. Ә Инсаф мыгырдап кычкырына, берни дә аңламыйча, тузына башлаган иде, тәгәрмәч кырына бәйләп тә салдылар үзен. Авызына да берне бирделәр ахры. Шундук тынып калды. Нәрсә булыр? Берни дә эшләр хәл юк. Әзрәк баш җибәрмичә, мин атлый алмаячакмын. Моңарчы да бу хәлнең кабатланганы бар иде. Шулай күрше Әкълимә әбинең тәпәш ишеге кәсәгенә башны бәргәч, бер сәгатьтән артыграк аяксыз булып яттым. Әле дә шулай. Ятам, тизрәк баш җибәрсен иде, дип. Үзем күзәтәм: ничәү болар? Әһә, дүртәү икән. Берсе телефон аша кемнедер чакыра. Шуннан выжлап теге «джип» килеп туктады. Утларын ярым сүндергән. Руль артында бер хатын-кыз утыра. Бу дүртәүгә команда бирә.

– Йөкнең документларын монда китерегез тизрәк! – ди.

Минем түш кесәсен актарып, бар булган документларны алып киттеләр. Һушны җуйган кеше кебек тик кенә ятам, чөнки тагын берне башка тондырсалар, минем аяклар бөтенләй йөрмәячәк һәм озакка. Тиздән безнең кырга тагын бер «КамАЗ» килеп туктады һәм безнең йөкне теге дүрт әзмәвер үзләренең «КамАЗ»ына төйи дә башлады.

Тегеләрнең мәш килүеннән һәм караңгылыктан файдаланып, мин җайлап кына шуыша-шуыша, моннан таю ягын карыйм. Тизрәк юлга чыгып, милиция йә ГАИ чакырырга кирәк. Тик ятсаң, үтереп китәргә дә күп сорап тормаслар. Иман юк боларда. Җай гына шуышып, «джип» машинасы кырыннан үтеп барам. Эчкә күз салам, эче ярым караңгы. Теге хатын безнең паспортларны,

документларны актарып утыра. Машинада бүтән кеше күренми. Әзрәк шуышкач, әллә җиргә төшкән чыкка суланып, әллә бүтән сәбәбе булды, башымның авыртуы бетеп киткән кебек тоелды. Торып бастым, аяклар да тыңлый башлады. Шунда башка бер уй килде. Теге «КамАЗ»дагыларга, әлбәттә, көч җитмәячәк. Әмма бу чебек кенә кызны машинадан чыгарып очыру миңа берни тормый. Шулай итәргә дә «джип»ны алып качарга. Тегеләр «КамАЗ»дан төшеп, йөгереп килеп җиткәнче, машинаны кыздырып, тизлек җыеп өлгерәчәкмен, ара шактый гына.

Кулга тотарга ипле генә берәр нәрсә эзли башладым. Урман кыры бит, җилле генә бер агач кулга эләкте. Ныклы күренә болай. Кеше үтерерлек булмаса да, исәңгерәтергә була. Агач кулга эләккәч, күңелне бер үҗәтлек биләп алды. Агачны әзер тотып, үләннәрне кыштырдатмаска тырышып, «джип» кырына килдем. Теге хатын дигәнем бик чибәр генә икән үзе. Шофёр утыра торган ягына утырган да, иелеп, бәләкәй кул фонаре яктысында минем паспортны актара. Килгәнемне сизмәде. Шунда ярымачык ишекне каерып ачып, агач кисәге белән берне тегенең җилкә тамырына «яндырдым». Ул пассажир урындыгына авып төште. «Эх» тә итмәде, аякларыннан сөйрәп пассажир утыра торган якка аудардым. Ачкыч урынында иде. Дулкынланудан калтыранам. «Джип» «ә» дигәнче кабынды, тизлеккә салган көе кузгалып та китте. Утны яндырып, «КамАЗ»лар кырыннан чажлап үтеп тә киттем. Теге бандитлар һушларына килгәнче, урман юлыннан асфальтка барып та чыктым. Кайсы якка китәргә? Иң яхшысы – кирегә, Самара ягына, анда 40-50 чакрым арада бер ГАИ посты калган иде. Мөгаен, анда дежур ГАИ хезмәткәре торадыр, тизрәк шунда барып хәлне сөйләп бирергә һәм бу бандитларны тотарга кирәк.

Шулай уйлана-уйлана, биш-алты чакрым да китеп өлгермәдем, теге хатын ыңгыраша башлады. Вәт зәхмәт, хатын-кыз башы белән кеше талап йөрсен инде. Милициягә илтеп тапшырыйм әле. Кемне бит әле? Элекке әфганчыны таларга уйлаганнар. Сездән куркынычрак духлар алдында да бирешмәдем мин. Бераз баргач, бу хатын:

– Прости, Хаким, гафу ит мине, – ди. Колакка ишетеләме дип торам. Вот, мәлгунь, хәтер үзендә. Паспортны укып, исемне дә исендә калдырган. Машинаны туктаттым, үрелеп чәченнән тартып торгыздым да маңгаена тагын берне ямадым. Хатын-кызга һичбер сукканым юк иде. Бөтенләй бөгелеп төште. Арткы утыргычлар арасына алып очырдым, югыйсә аяклары газга басарга комачаулый иде. Хатын-кызны һич болай тоткан юк иде. Бигрәк тә шушындый чибәр иблисләрне. Аякларын идәнгә сузып салдым. Итәге ачылып китте. Аяклары соң, аяклары! Бандит булса да, хатын-кыз бит! Нинди чибәр! Ә үзе юлбасар, тьфу, зәхмәт. Кулыннан паспортны ычкындырмаган, йомарлап ук тоткан, күкрәгенә кыскан хәтта, иблисиха, тәмуг кисәве. Кулыннан паспортны каерып алдым да кесәгә салдым. Башка вакытта хатын-кызга якын килергә дә курка идем. Әле үзем монавы чибәрне утыргычлар арасыннан ничегрәк бөкләп очыруыма үзем дә аптырап киттем. Кузгалдым. Тизрәк барып җитәргә кирәк. Шәп барырга куркыта, булмый, чит машина бит, тизлекләрен белеп бетереп булмый. Төнге юл тыныч. Бөтен белгәнемне искә төшереп, шәбрәк барырга тырышам. Юк бит, җитмеш-сиксәннән арттырып булмый. Төрле кнопкалардагы язуларны укып карыйм, юк – барысы да чит телдә язылган. Шулай җәфаланып, ярты юлны үттем ахры. Хәзер, әнә теге түбәдән соң, ГАИ посты да күренергә тиеш.

Шунда теге хатын сикереп тә торды һәм минем чигәгә пистолетының

салкын көбәгеn китереп тә терәде. Юкка бәйләп салмаганмын. Хатын-кызга күп кирәкмени, болай да һушын җыялмас, дип уйлаган идем. Юк икән, торганы бер аждаһа.

– Үләсең килмәсә, тукта, – ди бу. Шыр җибәрдем, шулай да:

– Үлсәк, бергә үләбез инде, – дигән булам.

Әйе, егетләр, бу инде хәзер әфган духы гына түгел. Үзем һаман тизлекне югалтмый бара бирәм. Мине атса, үзе дә чукыначак. Юлда каршыга бер машина килә. «Әллә каршы якка чыгып, аны туктатыргамы? Туктамаса... Килеп бәрелсә?» Баштан «зыр» итеп төрле уйлар үтә. Йөк машинасы булса ярый да бит. Җиңел машинадагылар, һичшиксез, үләчәкләр, юкка һәлак булачаклар. Аларның ни гаебе бар? Кинәт кенә әни искә төште. Минем үлгән хәбәр ишетелсә, ул да кайгысыннан үләчәк. Шунда теге аждаһа:

– Шурави, тукта, – дип, пистолет белән чигәгә нык итеп төртте. «Шурави» дип безне гади әфганлылар атый иде бит. Шул сүз, ничектер, айнытып җибәрде. Үзем дә сизмәстән, тормозга бастым. «Джип» шып туктады.

– Хәзер кире борыл, курыкма, барысы да әйбәт булыр. Сиңа тимибез, – ди. Мин, әллә пистолеттан куркып, әллә теге «шурави» дигәненә буйсынып, кире борылам һәм бандит хатын әйткәнне эшлим – килгән юлдан барам.

– Шәбрәк, – ди бу.

– Кайда ашыгырга, үлемгәме? – дим.

– Курыкма, мин сез уйлаганча ук начар түгелмен, – ди бу иблис.

Кирәкмәгәндә тегеләй-болай чапкан, һәр сикәлтә саен очраган ГАИшниклар да туры килми бит, ичмасам. Очрасалар, йә юл кагыйдәсен бозар идем, йә күзләренә яктыртыр идем. Юк бит, юк.

– Әфганда булдың инде, ә, шурави? – ди бу.

– Туры килде, – дим, иблиснең кешечә сөйләшә белүенә шатланып.

– Сагындырмыймы?

– Юк, – дим. Үзем: «Ничек котылырга бу аждаһадан?» – дип уйлыйм. Һаман сораша:

– Өйләнгәнме? – ди. Вәт бер яман чир, минем йөрәккә керергә чамалый.

– Сиңа нигә кирәк минем өйләнү-өйләнмәү? – дим. – Файдасы тияр дип уйлыйсыңмы әллә?

– Мөгаен, – дип, һаман тел чарлый бу.

– Буйдак. 1967 елгымын, буем йөз дә җитмеш сигез сантиметр, авырлыгым җитмеш биш килограмм. Сәяси яктан ышанычлы, белемем – техникум, милләт – ни башкорт, ни татар. Ике арада, бер турыда, – дип тезеп киттем. – Чит илдә булганым юк, чит илдә туганнарым да, бәйләнешем дә юк, – дим.

– Алдама, – дип, тынып калды бу.

Моннан ничек котылырга? Пистолеты белән чигәне төртеп тишәрдәй булып бораулап килә. Хәтта мылтык мае һәм дары исе борынга килеп бәрелде. Таныш ис, бу исне мин бернинди ис белән дә бутамыйм. Әфган искә килеп төште.

Әллә үзендә булган, әллә «джип»та, минем уң кулга шап итеп боздай салкын богавын да кидереп куйды бандит кыз. Ә бер очын үзенең сул кулына эләктергән. «Бетте, хәзер качып котылып булмаячак». Шайтан кыз алга – пассажир урындыгына ук күчеп утырды. Җиңел сулап куйды. Йөзе дә канәгать елмаеп тора.

– Ә син болай ару егет күренәсең, – дигән була.

– Ну, күренсәм соң...

– Син миңа ошый башладың, һәм... син бөтенләй үзгәрмәгәнсең, – дип,

көзгегә карап, чәчләрен төзәткән була, итәкләрен сыпыра. Аның шулай кинәт кенә тынычланып, гади кеше кебек сөйләшүе мине дә тынычландыра төште. Пистолетын да алып уң як кырына салды, әмма кулыннан ычкындырмый. Мин дә аны дикъкать белән күзәтәм. Ну үзе чибәр, малай! Урамда күрсәң, һичшиксез, гашыйк булуың бар. Песи баласы кебек артыннан ияреп китүеңне сизми дә калуың ихтимал. Ул керфекләр! Ярым караңгы машина эчендә дә чибәрлеге бөтен ир-атны арбарлык. Бәйләгән кофтадан күкрәкләре тишеп чыгардай булып төртеп тора. Торганы бер сихри сын. Ә үзе – юлбасар. Минем үзен күзәткәнемне сизде ахры. Бите кызарып киткән кебек булды, һәрхәлдә миңа шулай тоелды.

– Йә, хәзер сөйлә инде, – ди бу.

– Нәрсә сөйлим? – дим. Әллә нык дулкынланганга, әллә башка сукканга, баш тагын чатный башлады. Башкача сөйләшеп булмады. Теге урман юлын юри үтеп китим дигән идем, булмады. Юлны игътибар белән карап килгән икән.

– Хәзер сулга, шурави, – ди.

Нишлисең, пистолетын кулына алды, баш та чатный, борылмаска иткән идем, башка сугарга чамалый. Ирексездән борылдым. Теге урынга килеп җиттек. Тып-тын, бер кеше юк. Фара яктысында чалкан яткан Инсафның гәүдәсе күренә. Аны үтереп ташлаганнар ахры. Мин тагын калтырана башладым. Миңа бит нык дулкынланырга ярамый. Баш тагын ярыла башлады. Хет бүре булып ула. Күздән утлар күренеп китә. Ике «КамАЗ» да туктаган урынында тора, йөкне генә күчереп төягәннәр.

– Сүндер! – диде дә бу албасты, мин сүндергәнне дә көтмичә, ачкычны тартып алды. Караңгылыкка карап нидер кычкырды. Калган бандитлар да килеп чыктылар. Бу тегеләргә команда бирә башлады.

– Барысы да үзгәрде, йөкне кичекмәстән кире төяргә кирәк булыр. – Бандитларның кайсыдыр сорау бирергә дип авыз ача башлаган иде:

– Мин сезгә нәрсә әйттем, әллә аңлашылмыймы? – дип кенә җикерде. Берәр сәгатьтән йөкне кире төяп тә куйдылар. Шуннан бу иблис Инсафка тагын аракы эчәргә кушты. Мин аны үлгән дип кайгырып утырам. Авызына аракы тидергәч, рәхмәтләр әйтә-әйтә йотып җибәрде. Әллә бер, әллә ике стаканны чөмерде, алкаш. Минем баш чатнаганнан-чатный, авыртканнан-авырта. Бернәрсә дә аңламаслык хәлгә киләм. Колакка:

– Югалыгыз, таралыгыз! Безнең куллар канга буялмаган. Кирәк булса, үзем табармын, – дигәне генә ишетелә иблиснең. Мин баш авыртудан һушымны югалттым.

...Машина тигез генә үкереп бара һәм мине рәхәт итеп тирбәтә. Мин богаулы килеш өске киштәдә ятам. «КамАЗ» руле артында теге иблис хатын утыра. Оста йөртә, чукынган хатын. Мин ята бирәм. Миңа рәхәт, баш та җиңеләйгән. Авырту басыла барган саен, рәхәтлек арта, дөнья матурая, яшәгән саен тагын озаграк яшисе килә...

***

...Дәү әниләренең хәлен белергә барырга алар күптән әзерләнгән булсалар да, бу сәяхәт, ничектер, көтмәгәндәрәк килеп чыкты. Кичтән абыйсы белән әтисе сөйләшеп алгач, әтиләре: «Иртәгә картәниегезне барып алып килегез әле», – дип хәбәр салды. Моңа совет гаскәрләренең көтмәгәндә ясаган яңа һөҗүме сәбәп булды. Фатыйманы өйдә калдырырга уйладылар. Әмма барып чыкмады. Китәр вакытта гына Фатыйма «джип»ның утыргычлар артына, әйберләр төялгән урынга кереп яшеренгән иде. Ярты юлны үтеп, ниндидер бер тау чишмәсе

кырына чәй эчәргә туктагач кына, Фатыйманы күреп алдылар. Әнисе нык ачуланса да, абыйсы бер сүз дә әйтмәде. Фатыйма гаиләдә бердәнбер кыз иде, чәй эчеп алуга ук, әнисе аның гөнаһын кичерде. Фатыйманы юлга алмауларының сәбәбе – юл тыныч-имин булмауда иде. Совет гаскәрләре юлны ябарга тиеш икән.

Фатыйма биш малай арасында берүзе булганга, аны гаиләдә барысы да яратып иркәлиләр, шуңа Фатыйманың бу шуклыгы да җиңел генә кичерелде.

Фатыйма бәләкәйдән үк бик шук, чая, үткер бер «малайша» булып үсте. Абыйлары нәрсә эшләсә, шуны кабатлады. Алар белән малайлар уены уйнады. Укырга кызлар гимназиясенә бирделәр. Анда да ул гел беренчеләрдән булып төрле уеннарга кызларны үз артыннан ияртә иде. Кайчакта шуклыгы, чаялыгы белән укытучыларның теңкәсенә тиде. Шулай булуга карамастан, укуда да гел алдынгылар исәбендә булды. Бөтен фәннәрдән дә өлгәшеп, беренчеләр исәбендә йөрде.

Бүген ул үзен ни өчен юлга алырга теләмәгәннәрен дә белде. Совет гаскәрләре баш күтәрүчеләр белән Кандагар шәһәренә керергә тиеш икән. Бу инде картәнисе яшәгән кышлактан җәяүлегә бер көнлек юл дигән сүз. Юл бик үк яхшы булмаса да, әнисе туган-үскән һәм картәнисе торган кышлакка өйлә намазына барып та җиттеләр.

Бәләкәй генә, таулар кочагына сыенып, кырыннан матур гына тау елгасы аккан һәм бөтенләй яшеллеккә чумган кышлакка Фатыйма ел да каникул вакытында килә торган иде. Шуңа да кышлакта дус кызлары җитәрлек. Кызлар да Фатыйманың кайтуын көтеп алалар, чөнки ул кала күчтәнәчләре алып килә, төрле уеннар өйрәтә. Хәтта берничәсен укырга-язарга да өйрәтте әле. Кышлакта мәдрәсә юк иде шул. Бай гаиләдән булуына карамастан, үзен башкалардан һич өстен тотмаганга, кышлак кызлары да аны үз иттеләр. Ул кызлар белән чишмәгә суга йөрде, тауда кәҗәләр көтте.

Бу юлы кышлак Фатыймаларны ничектер сәер һәм шомлы каршылады. Картәнисе нык шатланса да, әнисенең йөзе дә, күңеле дә шомлана иде. Шуңа да Фатыйманы кышлактагы дус кызларын күрергә чыгармадылар. Тик абыйсы белән генә чишмәгә барып, чәйгә су алып килергә рөхсәт бирделәр. Барсын да белмәсә, барысына да өлгермәсә, Фатыйма Фатыйма булмас иде.

Әнисе белән картәнисе чәй эчкән арада, Фатыйма дус кызларына йөгерде. Юлда әнисенең икетуган агаларына да кереп чыкты һәм шуны белде: урыс солдатлары бу тирәдә дә күренә башлаганнар. Төрле имеш-мимешләр һәм шомлы хәбәрләр йөри икән. Күрше кышлакта талибаннар өч дехканны үтергән һәм рус солдатлары белән дә атыш булган икән, дип тә сөйләделәр, җитмәсә. Әллә Фатыйманы куркытырга уйладылар, әллә чынлап та, шулай иде, белмәссең. Имеш, яшь кызларны да урлыйлар икән. Кем урлаганын да белмиләр ди.

Фатыймага унике яшь кенә булуына карамастан, ул барысын да аңлый иде. Юкка гына әтисенең китапханәсендәге китапларны укып чыкмады ич ул. Дус кызларыннан да кызларны урлаулары турында яңадан ишеткәч, Фатыйма, ниндидер хискә бирелеп:

– Минеме? Мине беркайчан да үзем теләмәгән кеше белән яткыра алмаячаклар. Үлсәм үләм, әмма никахсыз ир-егет куенына кермәячәкмен. Әгәр дә көчләп үз хатыны ясый икән, ул егетне башта үтерәм, аннан үзем үләм. Мин никах белән генә һәм үзем теләгән кешегә генә кияүгә чыгачакмын, – дип тезеп алып китте.

Бу якларда кызларның ризалыгын сорап та тормыйча кияүгә бирү очраклары еш булганга, Фатыйма ахирәтләренең елмая биреп: «Сөйлә әйдә, сөйлә», диебрәк карап торуларын күргәч:

– Ышанмасагыз, менә Аллаһи-билләһи, шушы Коръәнне тотып ант итәм, – дип, өй түрендәге шүрлектә торган Коръән китабын алып, иң башта маңгаена тидерде, аннан күкрәгенә кысып, үбеп алды. Дус кызлары аңа күзләрен шардай итеп, аптырап карап тордылар. Аларның Коръән тотып ант иткән кешеләр турында ишеткәннәре булса да, андый кешене күргәннәре юк иде әле. Шуңа да алар бераз куркышып тынып калды. Алар моның иң зур ант икәнен белә. Антны бозган кеше йә үлә, йә гариплэнә. Бер дә булмаса, балаларына, әти-әниләренә һәм ыру-туганнарына зур бәла-каза киләчәк. Шуңа да кызлар тын калдылар. Ә Фатыйма тагын да дәртләнебрәк үзенең туган илен – Пакыстанын, кирәк булса, ирләр белән бергә саклаячагын әйтеп бирде. Дус кызларына караганда, Фатыйма күп белә һәм күп нәрсәне алардан ныграк аңлый. Ул элекке ил батырлары турында, горурланып:

– Бездә, Пакыстанда, хәтта хатын-кызлар хезмәт иткән хәрби частьлар бар, – дип сөйләп, кызларны тагын да ныграк аптыратты.

Үзенең туган иле дип Фатыйма Пакыстанны саный иде. Чөнки әтисе Пакыстанда үскән, ул үзе дә анда туып, анда үсте. Ә әнисе – Әфганстаннан. Пакыстандагы кызлар гына укый торган югары уку йортына укырга килгәч, булачак ире белән таныша. Һәм әти-әниләренең ризалыгы белән кияүгә чыга. Әтиләренең ыруы, электән үк хәллеләрдән булып, әтисе яклап картәтиләре шул ыруда зур вазифа били иде. Әниләре дә шушы кышлактагы хәлле гаиләдән булып, абруйлы кешеләр исәбендә йөри.

Иртәгесен кышлакта: «Урыс солдатлары кышлакның ике ягындагы тауда урнашкан икән», – дигән хәбәр таралды. «Юлны япканнар икән», – дип тә сөйләделәр. Әмма калага баручылар һәм авылга кайтучылар моны инкяр итте. Хатыннар шомланып калды, ирләр җыелышып киңәш тотты. Алар халыкка һәм кышлакка зыян килмәсен өчен, болай эшләргә булдылар. Әгәр дә шуравиларның халыкка зыяны тимәсә, аларга каршы чыкмаска, талибаннарга да ярдәм итмәскә. Кыскасы, кысылмаска. Шулай да коралларны барлап, майлап, әзер тотарга.

Әмма хәлләр бөтенләй башкачарак килеп чыкты. Фатыймалар иртәгә кайтыр юлга чыгабыз дигән көнне, кышлактан күптән киткән Абдулла кайтып төште. Ул берүзе генә түгел иде. Башта дүрт әсир шуравины алып килделәр. Аннан баштанаяк кораллы биш-алты кеше килде. Шуннан башланды да инде.

Кышлакта сугыш булып алды. Бер-ике йорт җимерелде. Яралanучылар да, үлүчеләр дә булды.

Фатыймалар чәй эчеп утыралар иде. Атыш тавышлары ишетелгәч, барысы да базга төшеп качты. Базда төрле догалар укып утырдылар. Әнисе, картәнисен шелтәләп:

– Әгәр син болай кышлактан китмим дип киреләнмәсәң, без мондый хәлгә тарымый идек. Түрдә генә тәсбих тартып утырасы урынга хәзер базда ятасың менә, – дип әйтеп куйды.

Базда күпме утырганнардыр, чыгып карарга дип, базны ачулары булды – өйгә чит кешеләр килеп керде. Киемнәренә караганда, болар шуравилар иде. Шуннан китте мәхшәр. Абыйсын сугып ектылар. Картәниләре атлый алмаганга, шуравилар аны креслосы белән күтәреп күрше йортка алып кереп китте. Фатыйма да, әнисе белән картәниләрен калдыруларын үтенеп, елап, шуравиларга иярде. Аларны, җирдә авыз-борыны канга баткан, тузанда аунап яткан шурави каршына китереп бастырдылар. Аннан ул кешене ике шурави тартып торгызды. Берсе кычкыра-кычкыра нәрсәдер сөйләде. Бу бик усал

шурави иде. Канга баткан шуравины Фатыйма бик тә жәлләде. Ул кай җире беләндер аның уртанчы абыйсына охшап тора иде.

Кышлак мулласын алып килделәр. Нәрсәгәдер ризалашмаганы өчен, аны бәргәләп ташладылар. Мулланы әллә аттылар, әллә кире җибәрделәр, анысын Фатыйма хәтерләми. Кыз, картәнисен якларга була, алга атлады. Аннан аны теге адәм кырына бастырдылар. Фатыйма куркуыннан нәрсә булганын да аңлап өлгермәде. Бер шурави мөселманча ниндидер дога укыды, амин тоттылар. Фатыйма, кайчан атарлар инде дип, дер калтырап торды. Әнисе белән картәнисен капканың теге ягына ук чыгардылар. Кызны теге шурави белән бер алачыкка кертеп яптылар, тыштан бикләп куйдылар. Бу канга батып беткән шуравидан нәрсәдер таләп итәләр, ә шурави карыша. Фатыйма берни аңламаса да, курку аралаш егетнең начарлык эшләмәячәгенә ышана иде.

Әсир шурави үксеп-үксеп елап ятты да бераздан тынды. Әллә йоклап китте, әллә үлде. Юк, үлмәгән икән, төне буе саташып чыкты. Фатыйма, тышта бераз шау-шу тынгач, ишекне этеп-этеп караган иде дә, ишек бирешмәде. Шулай йокысыз төн үткәреп, ул таң алдыннан гына изрәп йоклап китте.

Кемдер кыштырдаганга һәм ату тавышына уянды ул. Почмактагы юрганнар арасына кереп качты. Ишекне каерып ачтылар. Теге әсирне өстерәп алып чыгып киттеләр. Бераздан Фатыйманы да кием-салым арасыннан сөйрәп чыгардылар. Әнисе йөгереп килеп кочаклап алды. Читләр карап торуга карамастан, Фатыйманы баштанаяк диярлек капшап чыкты. Кичәге шуравилар асылып куелганнар, кайсылары үлгән, кайсылары бәйле килеш җирдә ята. Бу сакаллылар башка кешеләр иде. Теге әсирнең Фатыймага тимәгәнен белгәч, әнисе бик тә шатланды. Өйгә кергәч кенә, ул Фатыймага шул әсир белән никахландырулары турында әйтеп салды. Фатыймага әллә ничек булып китте. Никахның нәрсә икәнен ул белә иде. Үзенең никахы шушындый шартларда булыр дип һич тә уйламаган иде, менә ничек килеп чыкты. Һәм ул теге әсир шуравины тагын күз алдыннан кичерде. Шурави дигәне болай матур гына: кара чәчле, кара кашлы бер кеше. Әфганлыга, уртанчы абыйсына охшап тора. Тик нигә аны шуравилар кыйнаган да, нигә Фатыйма белән никахлап, ябып куйганнар соң? Инде менә икенчеләре килеп, тагын теге шуравины өстерәп алып чыгып киттеләр?

Кыз күңелендә ниндидер бер әрсез кызыксыну уянды. Нинди кеше ул? Куркуын җиңеп, күрше йортның капка ярыгыннан күз салды. Кичке як, урамда мәхшәр беткән. Өч шурави баштүбән асылынып тора. Йорт кырындагы чинар ботагына теге шуравины аякларыннан һәм кулларыннан асып куйганнар. Куркып, кире йортларына кереп качты кыз. Караңгы төшкәч, Фатыйма, абыйсын үгетләп теге шуравины асылынып торган җиреннән алырга күндерде. Абыйсы, каршы килеп:

– Әйдә, Алла ни кушса, шуны күрә, үзе гаепле, – дисә дә, Фатыйма:

– Ул хәзер минем ирем бит. Без никахлы, мин аңа ярдәм итәргә тиеш, миңа аңардан «талак» алырга да кирәк, – дигәч, ризалашты тагын. Алар кияүгә никах белән чыгып, талак белән аерылышуны гына белә иделәр.

Асып куелган җирдән төшергәндә, шурави аңын югалткан иде, ул акрын гына ыңгырашып куйды. Өйләренә алып кереп юындырдылар, абыйсының кием-салымын киендереп, авызына чәй тамыздылар. Фатыйманың картәнисе чәйгә ниндидер үзе әзерләгән үлән тамырларын салды. Төрле догалар укып, Аллаһы Тәгаләдән шуравига исәнлек сорап, намаз укыды да амин тотты.

Картәнисенең өендә яшәгән Лотфуллага шуравины Кабулдагы совет гаскәрләре госпиталенә илтеп тапшырырга куштылар. Лотфулла шул ук төнне шуравины алып юлга чыкты, аңа ярдәмгә улы да иярде.

Лотфулла әйләнеп кайткач, шуравины ничек, нинди юллар белән Кабулдагы Совет гаскәрләре госпиталенең капка төбендә калдыруы турында өйдәгеләргә бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Лотфулла сөйләгәннәрне Фатыйма, колакларын торгызып, барысын да хәтерендә калдырырга тырышып тыңлады. Кеше сөйләгәндә бүлдерү тәрбиясезлек булып исәпләнсә дә, госпитальнең кай тирәдә урнашканлыгы турында сорамыйча түзәлмәде:

– Госпитальне ничек таптыгыз, ул кай тирәдәрәк?

– Андый госпиталь берәү генә булганга, аны барысы да белә. Бүтән госпитальләр – кыр госпитале, хәрби частьлар тирәсендә палаткалардан гына корылган, – дип аңлатты Лотфулла.

Икенче көнне Фатыйма юкка чыкты. «Бер-ике көннән кайтып җитәрмен, мине югалтмагыз», дип язу калдырган. Кайда киткәнен әйтмәгән. Тирә-як күршеләрдән сорашып карадылар, берсе дә кызны күрмәгән иде. Лотфулланың улы гына:

– Ул минем иске киемнәрне киде, – дип әйтеп куйды. Шуннан башканы белүче булмады.

Фатыймага бу шуравидан ничек тә «талак» алырга кирәк иде. Әгәр шулай эшләмәсә, Фатыйма бит кияүгә чыгу хокукын югалта. Шурави үлсә генә, кыз никахтан азат була ала. Ә Фатыйманың гаиләсе бер гаепсезгә шуравиның җанын кыя алмый, моңа Коръән дә каршы. Шулай итеп, кыз Кабулга юл тотты. Исәбе – теге шуравидан «талак» алырга да кире кайтырга. Малайлар киеме кигәч, бөтенләй яшүсмергә охшап калды. Ул белә: малайларга юлда йөрү җиңелрәк һәм хәвефсезрәк.

Кабулда совет гаскәрләре госпитален тиз тапты кыз. Тик менә шуравины күрү генә ул уйлаганча җиңел булмады. Ничек кенә тырышса да, ике атнадан соң гына очраша алды. Анда да танымас иде, госпитальдә эшләгән әфган бабае ярдәм итте.

Шурави Фатыйма кырына үзе килде. Рәхмәтен белдерде. Фатыйма үзе төрлечә сөйләп, әйтеп караса да, егет аны аңламады. Шуннан Фатыйма конверт һәм ручка сузды. Әзрәк икеләнеп торгач, ят хәрефләр белән конверт тышына нәрсәдер язды. Бу адрес иде ахры. Ташкент шәһәренә кайтып китәчәген әйтте. Фатыйма монысын аңлады.

Икенче көнне шурави күренмәде.

Теге әфган бабаеннан сорап белде – шуравины Ташкент шәһәренә күчергәннәр икән. Шул ук көнне Фатыйма юлга чыкты. Ташкент шәһәренә мең бәла һәм авырлык белән килеп җитте, юлда гына ун-унбиш көн үтте. Ташкенттагы госпитальне табу үзе бер газапка әйләнде. Ярый әле шуравиның исем-шәрифләрен исендә калдырган иде кыз. Ахыр чиктә барыбер эзләп тапты. Бер-ике көн госпиталь ихатасыннан китмәде. Шунда шурави үзе Фатыйманы күреп, янына килде. Бик нык аптырады, әлбәттә. Тагын рәхмәтләр әйтте.

Фатыйма үзенең кыз кеше икәнлеген аңлатырга тырышса да, егет аны аңламады. Фатыйма:

– Талак, талак, талак, – дип кычкырды. Шурави артына карый-карый китте. Иң соңгы чиктә Фатыйма үзенең чәчләрен туздырып күрсәтте, тик шурави бу юлы да аңламады. Фатыйма үксеп-үксеп елады. Икенче көнне дә килде ул госпиталь ихатасына, тик шурави башкача күренмәде...

Автобуска билетсыз утырган өчен, контролёрлар Фатыйманы тотып милициягә озаттылар. Әфганстаннан икәнен әйткәч, пуштун телен белгән тылмач аша сораштылар да кире Әфганстанга озатмакчы булдылар. Җаен китереп, качты кыз. Шуннан соң Фатыйма үзенең Әфганстаннан икәнен беркемгә дә әйтмәде. Тагы тоттылар, тагы качты...

***

...Мин әллә төш күрәм, әллә саташам? Нигә миңа бу кадәр рәхәт? Әйтерсең лә машинам белән болытлар өстеннән йөзәм. Бәй, руль артында кем? Бу нипди кыз? Үзе уйга чумып бара... Мин кайда? Миңа тагын рәхәт... Күзләрне ачасы да килми. Машина гүләве ниндидер сихри көй булып ишетелә. Теге руль артында утырган чибәр кыз күз алдыма килә. Күзне ачсам, әлбәттә, югалачак. Уянсам, бу матур төш бетәчәк, тик нигә мин богаулы? Инсаф нишләп аста, ә мин өске киштәдә ятам? Күзне ачам. Ә нишләп бу кыз минем машинада бара? Нәрсә булды? Нигә һаман уяна алмый газапланам? Нишләп болай? Баш чатнап куйды. Мин барысын да искә төшердем. Тәрәзәдән үрелеп карыйм. Кая барабыз? Кайсы тирә икәнен төшенә алмыйм. Юл таныш сыман.

Бәй, бу теге иблис түгелме соң? Хатын-кыз сурәтенә кергән кичәге юлбасар ич! Минем паспортны алдына ачып салган, шуңа карап елмаеп-елмаеп алган була. Ә Инсаф, селәгәйләрен агызып, берни булмагандай йоклап ята. Иблис – чибәр кыз, уяныи, үзен күзәткәнне көзгедән күреп калды да:

– Хәерле көн, шурави, ничек йокладың? – ди. Итагатьле, йомшак итеп сөйләшә дә белә икән әле. Елмаеп күз кыскан була. Чибәрлегеннән күзләр камаша. Күренеп тора, авыл кызы түгел, шәһәрнеке. Нинди шәп киенеп алган, берәр түрә баласыдыр инде. Мин йоклаганда кигән, күрәсең. Контузиядән соң минем шулай үлек кебек йоклый торган гадәт бар. Шуңардан файдаланган инде бу. Ә кичә төнлә күрсәң соң үзен! Күзләре ут чәчә, торганы бер аждаһа. Бүген юха еланга әверелгән. Моның кичәге дүрт башкисәре кайда икән? Арттан киләләрдер, мөгаен. Шулай ята бирәм. Мин богаулы, үзем уйлыйм, үзем дәшмим. Болай булгач, мин исән, Инсаф та исән. «КамАЗ»ның үкереп баруына караганда, йөк тә урынында. Алда күпер, зур гына елга. Бәй, бу бит безнең Дим елгасы түгелме соң? Шул бит. Димәк, кайтып җиткәнбез, нибары утыз чакрымлап юл үтәсе калган. Мин бөтенләй аптырадым.

Машина күперне чыккан көе уңга борылып, тугай юлы белән тал-өянке, шомырт агачлары арасына кереп, бер-ике чакрым үтте дә туктады.

– Тор, шурави, килеп җиттек, безнең алда – киләчәк, – ди теге хатын-кыз кыяфәтенә кергән иблис. Тукайның: «Тор, шәкерт, җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан...» дигән юллары кебегрәк яңгырады инде бу.

Ә Дим буйлары шундый матур! Кошлар сайрый. Кояшка караганда, иртәнге ун-унберләр тирәсе. Шушы юллардан күпме йөреп, Дим тугайларының бу кадәр ямьлелеген ничек күрмәгәнмен, ничек тоймаганмын? Теге иблис богауны машинадан ычкындырды һәм үзенең кулына эләктерде.

– Шулай яхшырак булыр, шурави, – ди. Бу нәрсә, гел шурави да шурави дип кабатлый, каян белгән Әфганда хезмәт иткәнемне? Паспортта язылмаган. Әллә кичә Инсаф тыкылдаганмы? Алай дисәң, ничә көн инде айныганы юк. Кыз мине елга кырына алып килде, мин, әйтерсең лә бәйдәге эт, аңа ияләм.

– Ә хәзер юыныгыз, – ди бу иблис.

Башымда төрле уйлар. Минем кул аның кулы белән бергә богауланган. Мин бит ир кеше, бу чебек кенә кызны «һә» дигәнче бөгеп сала алам... Юк, тыелырга туры килә, чөнки буш кулын куеныннан алмый. Анда, мөгаен, пистолеттыр инде. Уйлана-уйлана, бер кул белән генә юынам. Димнең суы чиста, салкын, тәнгә көч-куәт өсти. Теге: «Ике куллап юын», – ди һәм үзенең богаулы кулын минем кул уңаена йөртә. Нишләптер, мин аңа берсүзсез буйсынам. Юынып алгач, башның авыртуы бөтенләй беткәндәй булды. Шулай да уйлардан һич арынып булмый.

– Хатының бармы? – ди бу. – Әфганда өйләндеңме? – ди.

Мин:

– Юк, – дим.

– Алдашасың. Синең анда никахлы кәләшең калды бит, – ди бу. Мин ирексездән Әфганны искә төшерәм. Бу албасты минем турыда барысын да каян белә икән?

– Беренчедән, көчләп өйләндерделәр, икенчедән, мин ул кәләшкә – кәләш, дисәм, җир ярылыр, ул бер бала иде, һәм мин аңа кагылу түгел, юньләп карамадым да.

– Тагын ялганлыйсың. Син үзең мине сайладың. Ә без бит синең каршыңда өчәү идек, – ди бу.

Бу бөтен нәрсәне энәсеннән җебенә кадәр белә. Чын иблис. Бу турыда бер кешегә дә сөйләгән юк, югыйсә. Белгән-күргәннәр дә үлеләр. Берсе дә исән калмады. Мине ярты ел буе юкка гына особый отделда сорау артыннан сорау алып җәфаламадылар. Ә әфганлылар тегендә калды. Кем соң бу кыз? Әллә КГБдан җибәрелгәнме? Әллә чит ил разведкасы агентымы? Баш тагын чатнарга әйтә. Калтырый ук башладым ахры.

– Калтырама, – ди. – Кызлар алдында килешми.

– Сез кем? – дип, чак-чак тел әйләндереп әйтә алдым.

– Мин – Фатыйма, синең Әфгандагы никахың.

Аякларым тагын тыңламый башлады. Чүгәләргә итәм. Тик чибәр иблис шундый итеп тутырып караган, күзләрне күзеннән алып булмый хәтта. Нишләптер, аның да күзеннән яшь ага башлады. Куенына тыккан кулын чыгарып, минем кулдагы богауны ачкыч белән ачты, аннан үзенең кулын бушатты. Богауны Димгә очырды. Минем куллар азат, тик йөрү түгел, басып та торып булмый, аяклар тотмый. Мин җиргә чүгәләдем. Ышанырлык түгел, ышанасы килми. Ничә еллар үткән. Тугыз ел!

– Миңа хәзер егерме бер яшь. Теге вакытта, синең алда басып торганда, унике иде. Шуңа да мине танымадың. Ә син үзгәрмәгәнсең. Мин сине шундук таныдым. Паспорттагы фотоң ярдәм итте. Кичәге төн өчен гафу үтенәм. Егетләр кызу кыланганнар.

– Нинди егетләр, чын юлбасарлар, кеше үтерүчеләр, – дим, төнге хәлләрне тагы искә төшереп.

– Ярар, анысын кайтышлый сөйләрмен. Ә хәзер, әйдә, өеңә алып кайт, кияү егете, – ди.

Үзе елмая. Шушы елмаю белән арбый да куя. Тик мин утырган җирдән тора алмыйм. Торырга итәм – торып булмый. Баш чатный. Җир ярылса, хет шунда кереп кит. Нык дулкынланганга шулай. Аяклар тыңламый. Мине бит шуңа да авылда үземнең артта «контуженный», дип йөртәләр.

– Контузия зәхмәте. Әфганнан шулай булып калдым, хәзер үтә ул, – дим. Фатыйма минем кулдан тартып торгызмакчы булды. Юк, булмый. Шуннан кабинадагы чиләкне алып, Дим суы белән баштанаяк коендырды. Сикереп торганны сизми дә калдым, үзем аптырап торам.

– Ә хәзер җай гына бир кулыңны, – ди бу. Кулны сузам, буй җитми. Егылырмын дип, атларга куркам.

– Йә, бир кулыңны, кияү егете, – дип көлеп җибәргән иде, дәртләнеп бер адым атлап, кулын тотып алдым. Әйтерсең, упкын өстендәге бүрәнәдән атлыйм. Кулларны җәеп, селкенеп киттем, әмма егылмадым. Вәт могҗиза, элек булса, гөрселдәп авар идем. Берне атлагач, кызның кулына тотынып,

тагын берне атладым. Гүя, мин яшь бала, яңа тәпи киткәнмен. Бу чибәрнең кулы йомшак, җылы. Аңардан миңа бер сихри көч килә кебек. Кызның кулын тоткан килеш, «КамАЗ» кырына ук килеп җиттем. Кабинага үзем көч-хәл белән менеп утырдым.

Әйе, егетләр. Башка сыймаслык хәлләр кинода гына түгел, тормышта да була икән ул. Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмаслык хәлләр. Моңа үзем дә ышанып бетәлмим әле...

– Милиционерлар кулына бер эләгеп, бер ычкынып йөри торгач, сукбай балалар интернатына эләктем. Усал идем, шуның өчен Самара тирәсендәге интернат-колониягә җибәрделәр. Анда күргәннәрне бер иркенләп сөйләрмен әле. Укуын әйбәт укыдым. Совет мәктәбе аттестаты һәм кызыл тышлы совет паспортын кулга алгач, ил буйлап иркенләп йөрергә, никахлы иремне эзләргә җайлырак булды. Каңгырап йөри торгач, юлдагы бандит, шпана, рэкетирлар белән дә дуслашып алдым. Башта алар мине кармак урынына файдаланалар иде, тора-бара үзем авторитетка әвереледем. – Фатыйманың үзалдына елмаеп сөйләгәннәренә дә тиз генә ышанасым килмәде.

Төш вакытларына авылга кайтып җиттек. Инсаф та мыгырданып торып утырды. Аны үзенең капка төбендә төшердем. Ул:

– Кара әле, парень, син нинди чибәрне утыртып алдың ул? Нинди кыз, кемгә кайткан? – дип төпченә башлаган иде, мин:

– Бар, бар, атлавыңны бел, әнә, өеңдә Нәсимәң белән малаең көтә, – дип, сүзне кыска тоттым.

Кайтып җиттек. Капка төбенә килеп туктадык. Шушы мизгелдә шулкадәр кыен булып китте, үземне эчтән генә сүгеп ташладым. Авылда халык зур-зур матур йортларда яши. Ә безнеке? Бер як почмагы җиргә кереп беткән, үзе бәләкәй генә, җитмәсә, сылап агартылган. Юньле кешенең тавык абзары да моңардан арурак. Капка да бик шәптән түгел. Ярый әле былтыр ихатаны яңарткан идем. Авылда безнең өй кебек өйләр хәтсез, кәнишне. Аңардан начарраклары да бар барлыкка, әмма бу минутта безнең өй иң бәләкәеде, иң җиргә чүккәнедер кебек тоелды миңа. Шушы өйгә кунак алып кайтырлыкмы соң? Әле дә әнкәй маладис. Бар дөнья чиста, пөхтә итеп җыештырылган, идәннәр ялт итеп тора. Йортта да тәртип, һәрнәрсә урынында, бернәрсә дә тузып ятмый. Борынга әнинең тәмле итеп пешергән пәрәмәч исе килеп бәрелде. Әнкәй шулай минем рейстан кайтканны гел тәмле ашлар пешереп көтеп ала. Фатыйманы «КамАЗ»дан күтәреп диярлек төшердем. Болай карышмады үзе. Җитәкләп өйгә алып кереп киләм. Ишек төбеннән үк әнкәй чыгып каршы алды. Әнине күргәч, Фатыйма:

– Здравствуйте, исәнме, әни, – диде, урысчалы-татарчалы итеп. Юлда өйрәнеп кайткан булса да каушады ахры. Кызарынып китте, үзе әни алдында баш ия.

– Исән әле, кызым, Аллага шөкер, үзегез ничек кайтып җиттегез, балалар? Кунак та бар икән, таныштыр, улым, – ди әни.

Мин тотлыгыбрак:

– Бу ни... әни, күрше авылга кайтып килүче марҗа инде, – дим. Әфгандагы кәләш дип әйтеп булмый ич, кем ышансын? Алай әйтергә тел дә бармый. Әле үзем ышанып бетә алмыйм, Фатыйма бик чибәр кыз булса да, кем шулай кинәт кенә өйләнә. Мин Фатыйманың җиңеннән тартам, янәсе, озак иелеп-сыгылып торма әле.

– Йәгез, балалар, әйдәгез, өйгә керик. Чәем дә кайнаган, – дип, әни Фатыйманың аркасыннан җиңелчә сөеп-сөеп алгач кына, Фатыйма кыяр-кыймас өйгә атлады.

Әни миңа карый. Күзе белән генә, «кем була бу кыз, улым», дип сорый инде. Мин, кулбашымны гына сикертәм. Өчәүләп чәй эчәбез. Фатыйма, татарча ничек була, монысы ничек, дип, һәр сүзне сораша. Мин өйрәтәм. Әни, Фатыйманың урысча гына аңлаганын белеп:

– Улым, үзе мөселман кызына охшаган, үзе бер авыз сүз дә белми бугай безнеңчә. Мин аны бит үзебезнең як башкорт кызы дип белдем, – ди. Минем әни үзе башкорт булгач, үзенә охшаган кешене һәрвакыт «бу безнең башкорт кешесе», ди. Мин:

– Ничауа, әни, өйрәнер, аның эти-әнисе мөселман, – дим. – Чәй эчә дә китә ул хәзер. Юлчы гына ул, – дип, әнине тынычландырырга тырышам.

Әни элек тә динне һәм дини кешеләрне бик ихтирам итә иде, хәзер бигрәк тә динигә әйләнеп китте. Фатыйманың сорауларына җавап бирә-бирә, чәй эчеп туйгач, әни амин тотып, битен сыпырып торып баскан иде, Фатыйма да: «Бир-рәхмәтикә-әр-рахман-рахим», дип, яртылаш ишетерлек итеп, ике кулы белән битен сыпырды. Моны күргән әнинең кулыннан чәй калаклары төшеп үк китте. Әни урындыкка утырды да, аминны яңадан тулысынча укып, «әппәр» итте. Һәм кызарынып, бер миңа, бер Фатыймага карады:

– Улым, сора әле, сора, нинди дин тота соң ул? Әллә мине генә үртиме? Алайга бер дә охшамаган. Безнеңчә аңламаган-белмәгән мөселман була димени?

– Мөселман кызы дип әйттем бит инде, әни. Урыс арасында гына үскән ул.

Фатыйма әни белән үзенчә чөкердәшеп чәй урыны җыештырып калды. Мин машинадагы йөкне тапшырырга төшеп киттем.

Үзем Фатыйма турында уйлыйм. Нинди тырышлык, үзсүзлелек, үҗәтлек кирәк! Нинди хәтер булырга тиеш кешедә! Советлар Союзында адресы билгесез бер солдатны эзләп тап инде. Әллә язмыш шулай кушканмы? Кешенең язмышы туганда ук маңгаена язылып туа, диләр бит. Моңа мин ышанып бетмим, ышанырга теләмим дә. Тугыз ел элек үзем белән булган хәлләрне искә төшерәм. Әйтерсең лә күптән караган киноны тагын бер тапкыр карарга, хәтердә әйләндерергә тырышам. Вак-төяге онытыла башлаган. Әмма Әфганда күргәннәрнең барысы да хәтердә. Әйтерсең лә кичә генә булган. Басып торган бала белән ананы да, коляскада утырган әби кешене дә хәтерлим. Таҗик солдатының никах укыганы да хәтердә. Миңа хатын буласы теге кыз яшь бала гына иде бит ул чакта. Күзләрен әле дә хәтерлим. Әле дә булса миңа аптырап карап торган төсле. Госпитальгә дә ул килеп йөргән бит. Ә мин аны малай дип уйладым. Соңгы күрүдә чәчләрен туздырып күрсәткәнен дә аңламадым бит... Юләр баш... Машинаны бушатып бетергәннәрен сизми калганмын. Склад мөдиренең:

– Йә, нәрсә эшләп утырасың? Йокладыңмы әллә? – дип кычкыруына сискәнеп киттем.

– Юл авыр булды, төнлә дә юньләп йоклый алмадым, – дип акланган булдым. Эшләрне бетереп, машинаны караштырып өйгә кайтканда, көтү кайткан иде инде. Әни сыер савып йөри, ә Фатыйма әни тирәсендә бөтерелә. Тегесен китергән була, монысын эшләргә тырыша, тик белеп бетерми шул.

Кичке ашны ашагач, әни миңа урын-җир сала башлады. Ерак юл алҗытса да, ятарга исәбем юк иде әле. Әни кабаттан:

– Улым, сиңа кайда салыйм урынны? – дип сорап куйды.

Мин:

– Чоланга, әлбәттә, – дим. Җәй көне чоланда йокларга яратам, бала чактан ук шулай.

Әни Фатыймага урынны түр якка сала. Мин Фатыймадан күзләремне ала алмыйм. Ул әнинең өр-яңа халатын киеп алган, килешеп тора үзенә. Миңа бер-ике тапкыр өттереп карап алды, янәсе, күзең белән чамалап кара. Мин эш юктан эш булсын дип, йә гәзитләр алырга, йә башка нәрсә дип, түр якка кереп, Фатыймага күз салам. Эх, малай, нинди чибәр! Ул буй-сын, ул күзләр! Чәчләрен безнеңчә итеп үреп төшергән. Мода журналындагы кызлардан да чибәррәк. Түр як стенасындагы фоторәсемнәрне карый. Ә бит үзе кичә генә мине үтерергә әзер иде. Юлбасар, нинди боерыклар бирә иде кичә үзенең башкисәрләренә. Бүген мич эргәсендә басып торган Фатыйма белән кичәге Фатыйманы һич чагыштырырлык түгел. Кичәгесе – аждаһа, иблис, хатын-кыз кыяфәтенә кергән бер гыйфрит. Ә бүгенгесе – фәрештә, хур кызы. Әни Фатыймага йокларга урын күрсәтте. Ал якка чыккач, әнигә:

– Шулай да, әни, күз-колак бул. Нинди кыз бит әле, – дим. Әни үзе мине шелтәли башлады.

– Белмәгән, күрмәгән кызлар утыртып йөрмә бүтән. Чынлап та, әллә кем бит әле, әллә чегән кызы, әллә юлбасар баласы, – ди. Шуннан, үзен-үзе тынычландырып:

– Син машинаңны куярга киткәч, «Әлхәм» белән «Колһуалла»ны да укып күрсәтте әле, улым. Бик ипле балага охшаган. Бик итагатьле күренә. Әти-әниләре кем икән? – ди.

– Ул ятим үскән, – дигән булам. Ә эчтән: «Кичә төнлә күрсәң иде, әни, ул зәхмәтне!» – дип уйлыйм. Анысын әйтмим, әнине куркытасым килми. Шулай да әни бүлмә ишеген ябып, утыргыч терәде дә аның кырына подносны сөяде. Чыга-нитә калса, поднос төшеп шалтырый һәм безне уята, имеш. Төне буе боргаланып яттым, йокы керми күзгә, йә тегесен, йә монысын уйлыйм. Бөтен уйлар Фатыймага килеп терәлә.

Нигә миңа утырып килде ул? Ә ни өчен бандасын калдырып китте? Бөтенләй бозылып, хатын-кыз сыйфатын югалткан бер бандиттыр әле. Тугыз ел буе ни эшләп йөрмәк кирәк? Йоклаганда үтереп китүе дә ихтимал. Таларга дисәң, безнең өйдә таларлык бер әйбер дә юк. Әллә Әфганда әниләрен безнекеләр үтереп, шуның үчен алырга йөриме? Алай дисәң, мин беркемне дә үтермәдем. Сугышта булып, автоматны хәтта духларга да төзәргә туры килмәде. Фатыйманың ул кадәр начар булуына ышанасы килми иде. Шулай, уйларыма үзем каршы килә-килә, таң алдыннан гына изрәп йоклап киткәнмен.

Иртән табак-савыт шалтыраганга, тәмле исләр борынны кытыклаганга уянып киттем. Әни белән Фатыйма газ плитәсе тирәсендә мәш киләләр. Нәрсәдер пешерәләр ахры, исе тәмле булып өйгә таралган. Утыргычтагы поднос төшкәндерме, юкмы, анысын белмим, әмма әни татарча-башкортчалап сөйли. Ә Фатыйма – урысча. Әни урысча бик аңлап бетермәсә дә, болар барыбер бер-берсен яхшы аңлыйлар. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды. Казан янында йөреп, Фатыйманың йөзләре алсуланып киткән, житмәсә, әнинең кичәге халатын кигән. Халат аңа кыскарак, иелгәндә, тез башыннан өстәрәк ботлары күз кызыктырып күренеп китkәли. Яулыкны да үзебезнең кызларча, чөеп бәйләп куйган.

Тиз-тиз генә чәй эчеп, эшкә йөгердем. Авыл авыл инде. Хәбәр тиз тарала. Әле берсе туктата, әле икенчесе.

– Син нәрсә, парень, кәләш алып кайткансың, диләр. Чынмы бу?

Кайберләре:

– Молодец, күптән кирәк иде. Бик яхшы булган, – ди.

Бүген рейсны Стәрлетамакка язганнар. Тагын Инсаф белән. Аны алырга кергәч, ул сагыз кебек ябышты.

– Туй кайчан? Кайчан килениең тәпиен юабыз? Вот сиңа «контужен»! – ди, мөртәт. Аңардан, бер ярты вәгъдә итеп, чак котылдым. Безнең авылда һәркемнең исеме бар. Кайберләренең хәтта икешәр. Бу «Кантужен» ләкабын Әптер Гыйльми кызы кушты. Армиядән кайткан ел. Нык дулкынлансам, йә баш бәрелсә, аяклар тотмаганын белми идем әле. Шулай егетләр белән бәхәсләшеп китеп, Әптер Әкълимәсен кочаклап үбәргә булдым. Миңа бу күз атып та йөри. Үземнең тәгаен генә йөргән кызым булмагач, бер кичне тәвәккәлләдем. Туры китереп, тегене кысып кочакладым да үбәргә чамалыйм. Теге дә миңа елышып килә. Дулкынланудан баш чатный ук башлады. Тез башлары калтырый.

– Кит, кит, юньсез, – дип, бер-ике тапкыр башка суккан булды. Алай нык та сукмады инде, болай, исем-йола өчен генә. Үзенең дә мине кочакларга чамасы бар кебек. Әмма шул ике сугуы җитте инде. Аяк ычкынды да куйды. Тыңламый, и бетте. Егылмаска тырышып, мин тегене тагын да кысыбрак кочакладым. Бөтен гәүдәм белән аңа асылындым.

Сизеп торам, курка калды. Ярый әле клуб коймасына бер кул белән тотынып өлгердем. Тегене ычкындырып, штакетникка ике куллап ябыштым. Беренче һәм соңгы тапкыр кызлар кочаклавым шулай тәмамланды. Теге Әптер Әкълимәсе:

– Кит, женле нәрсә. Эчеп килгәнсең, аягыңда да басып торалмыйсың, юньсез, – дип, мине әрли башлады. – Җитмәсә, кызлар кочаклаган була, егет калдыгы, – дип, мине мыскыллап сөйләнә-сөйләнә китте. Шул минутта җир ярылса, бәхәссез, мәңгелеккә шунда керергә риза идем. Шулхәтле гарьләндем ки, тешләремне кысудан яңакларым шытырдады, күздән яшьләр чыкты. Ярый әле якын-тирәдә бүтән яшьләр юк иде. Үләселәрем килде шул минутта.

Читтән килгән кызлар янына да баргалап карадым. Анда да шулай. Баш чатный башлый. Бу миңа «кит моннан» дигән сигнал, шартлы кисәтү була иде.

Тагы шундый бер-ике хәлдән соң мин кызлар янына йөрмәс булдым. Һәм мине «бума чирле», «кантужен», дип йөртә башладылар. Үземнең артта гына инде. Ачулары килгән юньсезрәкләренең битемә дә бәреп әйткән чаклары булды.

Шулай итеп, мин тора-бара «кантужен»га әйләндем. Яшьләр мине жәлли. Алар минем шул контузия аркасында бер генә ел хезмәт итеп кире кайтканны белә бит инде.

Шул ук Әптер Әкълимәсе: «Үзем шуңа барыр идем. Болай ару егет», – дип, әнигә дә ишеттергән. Әни дә үзенчә үгетләп карады. Әмма күңелем, йөрәгем таш булып каткан шул.

Яшьтәшләр «юмарт» Зиләне дә алып килеп карадылар. Зилә үзе дә кыю икән, алдыма ук менеп утырды. Әмма миңа андыйлар кирәкми. Түбән оч Мәдинә дә, ире аракы эчеп трактор астында вафат булгач, берничә тапкыр кичләтеп кенә өенә чакырган иде дә, аңардан да шүрләдем. Бигрәк ирдәүкә, бер эләксәң – котылырмын димә. Үрмәкүч авына эләккән чебеннән болайрак булырсың.

Шулай итеп, мин кызлар кочакламаган килеш, буйдак егет булып йөри бирәм. Авылдагылар моның Әфган сугышы зәхмәте икәнен беләләр, бик теңкәгә тимиләр иде.

Эштән соң кич өйгә кайтсам, әни караватта еламсырап утыра. Яулык почмагы белән күзләрен сөрткәли. Фатыйма күренми. Йөрәк «жу» итеп китте. Баш та чатнарга итә башлады.

– Нәрсә булды, әнкәй? – дим.

– Булуын бер нәрсә дә булмады, тик менә Фатыйма гына иртәгә синең белән сөйләшкәч, кайтып китәрмен ахры, ди.

– Соң, шуның өчен елыйлармы? – дим.

– Еламый ни, килен күрмичә үлеп китәрмендер инде. Күрше-күләннән оят. Барысы да оныклар үстерә, ә мин? Әкълимә булды – Әкълимәне ошатмадың, Мәдинә булды – аңардан качып йөрисең. Сиңа кем кирәк? Бик ипле бала күренә, әллә, дим, Сәхи бабаңны чакыртып, никах укытабызмы? Печән өстенә дип симерткән теге ала сарык та бар. Кешене мин бик тиз сыныйм, улым. Бу бала күңелемә май булып ятты, – ди.

– Соң, әни, ике көндә кешене белеп бетереп буламыни? – дим.

– Була, улым, була. Кешене бер күрүдә үк белеп була, – дип, әни үзенекен тезеп алып китте.

– Әнә, тәрәзәдән кара әле, әйтерсең лә бу йортка күптән килен булып төшкән, – ди әни. Мин тәрәзәгә күз салам. Фатыйма мунча идәнен юып йөри. Чынлап та, шушы йортта туып-үскәнмени.

– Ярар, ярар, әнкәй, тынычлан, берәр нәрсә уйларбыз, – дип, әнине тынычландырам. Ул:

– Уйлыйсы юк инде, улым, күптән вакыт. Бар, чакыр, чәй әзер, ашым да пеште. Кичке ашны ашыйк, көтү кайта башлар, – ди. Мин чыгып Фатыйманы чакырам. Көне буе баштан да чыкмады, чукынган. Әллә ярату шушы була микән? Әле аны күргәч, яз кояшы күренгәндәй, бөтен дөнья балкып китте.

Кичке ашны ашагач, көтү кайтты. Тәүдә әни белән Фатыйма, аннары мин мунча кереп алдык. Мин Фатыймадан күзне ала алмыйм. Мине чынлап торып сихерләде. Ул да моны сизеп алды:

– Әйдә, йөреп кайтыйк, авылыңны күрсәт, – ди. Бәрәңге бакчасы аша икәүләп бакча артындагы тауга менеп киттек. Артка борылып карасам, безне ярты авыл күзәтеп, карап тора лабаса, күрше тирә-яклар барысы да өй артларына, өй алларына чыгып басканнар, шым гына карап торалар. Бала-чагасына кадәр, уеннарын ташлап, безне күзәтә. Әйтерсең лә без бер могҗиза.

Тегеләргә үч итеп, Фатыйманы җитәкләп алдым. Кулы бигрәк эссе. Минем кул да тирләп чыкты. Аның кулын тартып алмавы миңа ничектер дәрт өстәп җибәрде. Үзеннән ниндидер затлы, тәмле, хуш ис бөркелә. Дулкынланмаска тырышам, юк, буламы соң? Ярый әле баш чатнамый.

Тау башына менеп утырдык. Авыл һәм каршы як уч төбендәге кебек. Тирә-як матур. Мин дәшмим, Фатыйма да сүзсез генә утыра. Икебез дә, сүз берләшкән кебек, җиргә утырдык. Җәйге җылы кич. Җайлап кына караңгы төшә. Тугайда кошлар моңлана. Сүзсез тормас өчен, мин:

– Менә, шушы инде минем туган авылым, – дигән булам.

– Әйе, матур яклар. – Тагын сүзсез калдык. Сүз табып булмый. Мин аның гүзәллегенә карап, сокланып утырам. Бик иркәлисем, чәчләреннән үбеп аласым килә, куркам, кыюлык җитми.

– Шурави, – ди бу һәм әзрәк тынып торгач дәвам итә. – Мин никах белән генә кияүгә чыгачакмын, һичкем белән йокламаячакмын, дип, кызлар алдында Коръән тотып ант иткән идем. Теге вакытта безнең икебезгә сезнең бер шуравиегыз никах укыды. Моны әнием белән картәнием азактан әйттеләр, аңлаттылар. Ул вакытта мин безгә никах укыганнарын белмәдем.

Фатыйма тагын тынып калды. Шактый вакыт сүзсез торгач:

– Мөмкин булса, син миңа өйләнеп, өч көн тор. Аннан «талак» әйтерсең, – ди бу. Мин һаман, миңгерәү сарык кебек, кызга карап шаккатып утырам.

– Ничек? – дим.

– Менә болайрак, – дип, үзе, караңгы төшсә дә, сизеп торам, кызара-кызара, минем кулны иплəп кенә алып, үзенең тыгыз күкрәкләре өстенә куйды да һәм, ишетелер-ишетелмәс итеп:

– Әйдә, кыюрак бул, курыкма, ашамам, – ди. Минем һаман кыюсыз гына карап торуыма:

– Син нәрсә, әллә хатын-кыз белән бер дә кунганың юкмы? – ди.

– Бер кундым... Тугыз ел элек Әфганда синең белән бер төн. Һаман күз алдымда, – дим. Һәм кызның кайнар битенә кыюсыз гына иреннәремне тидерәм. Утырып торгач, нык дулкынлансам да, егылу куркынычы юк, шөкер. Тез башы да калтырамый. Күкрәктә, әйтерсең лә бер зур буа язгы ташкында ярылып китте. Мин шашып-шашып Фатыйманы үбә, кочаклый, иркәләп-назлый башладым. Фатыйма карышмады. Ул да мине иркәли. Нинди сүзләр булгандыр, «мәхәббәтем» дигән сүзен генә аңладым. Күрәсең, әфганча, пуштунча иркәли. Аның саен дәртем таша, инде бөтен тәненнән үбәм. Гомер буе шулай кыланганмын диярсең. Каян килгәндер миңа мондый кыюлык... Фатыйманың йомшак, хуш исле чәчләрен үбә-үбә иркәлим. Әни назыннан башка мәңге хатын-кыз назы күрмәгән кеше бит, бу кадәр чибәр Фатыйманың иркәләвеннән исердем дә куйдым. Аның, серле пышылдап, кысып-кысып кочаклап иркәләүләре мине бөтенләй шәбәйтеп җибәрде. Һәм без... ир белән хатын булдык. Фатыйманың шатлыклы кайнар күз яшьләре минем биткә тамды. Мин дә хатын-кызны, Фатыйманы ярата алу сәләтен югалтмаганыма шатланып елап җибәрдем. Үземнең чын ир-егет булып яши алуымны аңлагач, Фатыймадан никтер оялмадым. Аңа мең-мең рәхмәтләр укыдым. Ул миңа яшәргә көч-куәт, дәрт бирде. Бу минутларда ул минем өчен кояшка тиң иде. Аңардан:

– Син нигә елыйсың, Фатыйма? – дим.

– Үзеңне минем урынга куеп, тугыз ел эзләп кара, шуннан, мөгаен, аңларсың, – ди. Күпме яткандыбыздыр, белмим, әмма офык кызара башлады. Караңгыда шунысы әйбәт: бер-береңнең күзләрен күрмисең. Шуңа да бик оялдырмый. Кинәт Фатыйма сикереп торды да:

– Әйдә, ирем, тор, өйгә кайтабыз. Әни дә көтеп арыгандыр, – дип, куаныч-шатлык белән миңа кулларын сузды. Кулларыннан тотып, сикереп тордым. Күктә – йолдызлар, аста – йокыга талган авыл. Офыктагы алсулыкта Фатыйма тагын да гүзәлрәк, тагын да сихрирәк күренә иде. Әйтерсең, айдагы Зөһрә кыз бөтен матурлыгы белән алдымда басып тора һәм мине алга – киләчәккә әйди. Фатыйманы күтәреп алдым, һәм килгән сукмактан авылга төшеп киттек.

Йә Ходай, мин атлап барам түгелме соң? Фатыймамны күтәреп барам. Шатлыгымнан хәтта тезләр калтырап китте. Фатыймамны куркытмас өчен, җай гына җиргә бастырдым. Аякларга карыйм – урынында, тезләр бераз калтыраса да, шөкер, аяклар киреләнмәделәр. Фатыйма, нәрсәдер сизенепме, кулдан тотып:

– Әйдә, мәхәббәтем минем, – диде, әйдәде, һәм мин, ничәнче тапкыр инде, аңа берсүзсез буйсынып, артыннан иярдем.

Үзем шатланам. Кара инде, аякларда да калтырау бетте һәм без, әкрен генә җитәкләшеп, караңгы төннән авылга, шәрык ягында алсуланган офыкка – үзебезнең киләчәккә, якты таңыбызга карап, җай гына атлап киттек...



Ирек Сабиров

# БЕЗ – МИЛЛӘТНЕҢ ЕРАК ИЛЧЕЛӘРЕ...

## Мөһаҗир сүзе

Татар тарихында сукмакларның
Булмагандыр һич тә такыры.
...Яздай истә калган узган йөздә
Сиксәненче еллар ахыры.

Яңа кодрәт алдык, дигән идек,
Җиңәр, диеп, безнең бу барыш:
Әмма бигрәк кыска булып чыкты
Зур өметләр биргән Яңарыш.

Зыялылар бераз шаулап алды,
Һәм – тончыкты, бетте инкыйлаб:
Тәкъдиребез биргән язмышыбыз –
Яшәү микән мәңге зар елап?

Без – милләтнең ерак илчеләре –
Туган илдән читтә яшибез;
Казаныбыз – изге кәгъбә безгә,
Шуннан килә милли көчебез.

Читен заман. Ләкин белми Казан –
Мөһаҗиргә бүген мең читен:
Хәер сорап кына чыгарабыз
Уралга бер татар гәзитен.

Башкаланы кызыксындырдымы
Ерак милләттәшләр адымы?
Без Ватанга дога кылып тордык,
Ватан безгә бер күз салдымы?

Ирек САБИРОВ (1950) – *шагыйрь; «Манзара», «Аваз», «Апрель» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чиләбе өлкәсенең Зауральский шәһәрендә яши.*

Башкорт туганнарга, әнә, рәхәт.
Без алардан күпкә ярлырак:
Уфалылар көн дә Чиләбедә,
Казанлылар – елга бер кунак.

Берлек барда тереклек бар, диләр:
Җиңәр өчен шиңү газабын,
Без дә сиңа кирәк, Ватаныбыз,
Мин дә сиңа кирәк, Казаным!

...Бөтенләйгә кайтып булмас инде,
Ишетелерме, дим, бу зарым?
Казан! Назлап бер карарсың, диеп
Өметләнә нәүмиз улларың...

## Нәни Тукай

Тәүге кайгысы сабыйның
Киң дөньясын тар ясый:
«Әнкәемне кайтарыгыз!..» –
Чәбәләнә нарасый.
Ятим язмыш, фәкыйрь тормыш
Алдан тора күренеп:
Сабый бәхете китеп бара
Ак кәфенгә төренеп.
Сөю, назлау, иркәләүдән
Алда тагын бар ниең?
Көтә сине ким дигәндә
Ике үги әниең.
Тәңре сиңа биргән очкын
Гасырларда йоклаган;
Милләтеңнең бар хыялын
Ходай синдә туплаган.
Кем бар тагын шулай үсеп,
Әдип булып өлгергән?
Бөеклеккә ятимлектән
Җирдә тагын кем менгән?
Кем әле халыктан шытып,
Шул халыкка моң биргән?
Зар күленнән дан күгенә
Җирдә тагын кем менгән?
Тоярсыңмы бу җиһанның
Рәхмәтен һәм хөрмәтен?
...Иң сәләтле бер баласын
Үги иткән милләтем...

## Без киткәч...

Әле дә моңлы һәр көнебез һаман –
Без әлегә исән, карагыз!
Узып бара безнең җырлы заман,
Үзебез дә китеп барабыз.
Без – шигърият сөйгән соңгы буын.
Әйтче, айфон тоткан яшь иптәш:
Кырлай болыннарын, Ашыт суын
Кемнәр җырга салыр, без киткәч?
Мәгъруур Тукай! Узса да шул гомрең
Ятимлектә, ачлык-салкында,
Аз булса да, яшәп өлгергәнсең
Милләтемнең таза чагында.
Сине ятлап яшәсәк тә әле,
Ерагая инде арабыз:
Безнең дә бит узып бара заман,
Үзебез дә китеп барабыз...

## Китмим

Ага язлар, яна җәйләр,
Әнә китә көз...
Китәселәр килмәсә дә,
Без дә китәрбез.

Яшь чагымда курка идем
Соңгы мизгелдән:
Кемгә калыр без киткәчтен
Күлләр, диңгезләр.

Назлы ярлар, гөлбакчалар,
Чия, карлыган...
Хәзер тыныч күңелкәем:
Чөнки арылган.

...Тәрәз янында утырам
Берүзем ялгыз.
Күрәм: уза урам буйлап
Бер төркем яшь кыз.

Чыркылдашалар, дәртләре
Ярлардан ашкан:
Гүя Җиргә мәңгегә дип
Килеп урнашкан.

Дәштем: «Гөлләрем! Кайчандыр
Мин дә яшь идем;
Бүген исә... Тик барыбер
Әле яшимен!

Без бит әле бу дөньяда,
Бергә барыбыз, –
Берүк мине исән чакта
Сөеп калыгыз!

Зар белмичә типсен йөрәк,
Җуймый кыйбласын;
Соңардык, дип үкенергә
Сәбәп булмасын!»

Узды кызлар. Артка чикте
Давыллы көзләр:
Китмим, китмим, гөлбакчалар,
Күлләр, диңгезләр!

Китәселәр – мине куып
Узсалар узар;
Минем исә – әнә, тагын
Тәрәздә кызлар...

## Сине күрсәм

Күзләреңдә Мәмдәл урманнары,
Юртыш болыннары чагыла;
Сине күрсәм, бер әйләнеп кайткан
Кебек булам үсмер чагыма.

Кайткан кебек була май айларым,
Кайткан кебек була мартларым,
Һәр чибәрне кочып назлап үбеп
Сөярлек дәрт булган чакларым.

Сеңлем, дисәм, сиңа, кызым, дисәм,
Тумас микән шуңа үпкәләш?
Шулай дими нишлим соң – мөгаен,
Әниең дә миннән күпкә яшь.

Оныккаем булсаң... Нигә шулай
Чәчләреңнән килә яз исе?
Нигә шулай күкрәгемә кысып,
Үбә-үбә килә назлыйсы?

Очрашканда карашыңны тойсам,
Яшәү көчем арта бергә-бер;
Куанамын: бу җиһанда мин дә
Кирәк икән әле кемгәдер!

Мин дә икән әле җәлеп итәм,
Мин дә икән әле файдалы...
...Кайда минем тиле хыялларым,
Язгы теләкләрем кайдале?!

Кайда теләкләрем, хыял-хисләр...
Бар, йөрәктә әле, бар алар!
...Әмма теләкләрдән ниятләргә,
Ниятләрдән гамәлләргә кадәр –
Мин узалмас ерак аралар.

## Елмай

Таңда чыгып урамнарга,
Карап алсу офыкка, –
Күккә, Җиргә, үләннәргә,
Чыр-чу күрше-күләннәргә
Елмаерга онытма!
Елмай җәйге шәфәкъләргә,
Елмай кышкы таңнарга,
Шөкрана кылып тормышта
Туган-дусларың барга.
Шул мизгелдә белсәң иде:
Мин дә яшим дөньяда;
Елмаюың, бәлки, бераз
Эләгер, дим, миңа да.
Минем елмаюым да шул
Таң нурына кушылып,
Очсын иде синең якка,
Якты куаныч булып.
Барып җитсен иде сиңа,
Карамый буран-җилгә!
...Сине куандырып яшәү –
Төп максатым бу Җирдә.

## Сәхнә чибәренә

Мин ишеткән иң беренче җырың
«Җомга» булды. Җырлап, баш идең.
Мин карт түгел идем ул заманда,
Ә син исә – бигрәк яшь идең.

Айлар, еллар узды. Җырларыңда –
Син кабызган утта – мин яндым;
Бер җырыңнан ярсып еласам да,
Икенчесен тыңлап куандым.

Һәрбер җырың, йөрәгемә сеңеп,
Җанга ялкын өстәп яшәде.
Бер аяныч – мин картаеп беттем,
Ә син исә – һаман яшь әле.



Галимҗан Гыйльманов

# АЛТЫН БАСУЫ

ХИКӘЯ

**1**

«Мәмәт басуында алтын бар икән!» – дигән хәбәр авылга яшен тизлегендә таралды. Ул бик тиз генә урам-тыкрыклар аша үтеп, һәр өйгә азга гына туктала-туктала, төшлеккә якынлашканда, Җәмиләләр йортына җитте. Күршедәге Мәрьям карчык алып килде аларга бу хәбәрне. Керә-керешкә үк:

– Ишеттегезме әле, Күркә Фатыйхасының улы алтын эзли ди Мәмәт тавында. Бөтен халык шуны сөйли. Әнә, берничә кеше, көрәк тотып, шул басуга йөгергән дә инде. Ә сез берни белми өйдә утырасыз... – диде.

Ничек кергән булса, күрше карчыгы шулай ук җилләнеп чыгып та китте. Аның артыннан ишек ябылуга, түр яктан Җәмиләнең кечә соң гына шәһәрдән кайтып төшкән улы Зөлфәт килеп чыкты.

– Әнкәй, нишләп йөри бу җен карчыгы ачы таң белән, кеше уятып?

Җәмилә, гүя, аның соравын җавапсыз калдырды. Үз сүзе сүз иде:

– И-и, балам, нинди таң булсын инде? Төш җитеп ята бит. Колхоз булганда, без бу вакытта әбәткә кайта торган идек. Әйдә, юын, үзеңне рәткә китер. Бу юлы бик талчыгып кайткансың, кичкә таба мунча ягып җибәрермен, рәхәтләнеп чабынырсың... Эшкә барасы юк бит, бакчасына да, мунчасына да вакыт иркен хәзер...

– Әнкәй, син мине ишетмисеңме әллә? Бу карчык нигә кергән, дим, нинди алтын турында сөйли ул?

– Юк белән башыңны катырма, улым, ниндидер алтын тапканнар, диме... Буш сүздер әле, бездә бит хыялый халык яши, эшләмичә генә баерга теләүчеләр күбәйде хәзер... – Җәмилә боларын үзалдына сөйләнгән кебек кенә әйтте. Аннары җитди сөйләшүгә күчте: – Күпкәме син, улым? Нигә Әлфия кайтмады? Эшләрең барамы? Әйтми-нитми генә кайтып төштең, шуңа сорашуым...

Зөлфәт үзен бик сәер тотты. Гүя, әнисен бөтенләй дә ишетми иде. Ул һаман алтын турында сорашты:

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ (1957) – *прозаик, шагыйрь, әдәбият белгече; «Тозлы яңгыр», «Албастылар», «Оча торган кешеләр», «Тәкъдиргә юл» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш һәм Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

– Нинди алтын ул, әнкәй? Бу җәһәннәм тишегендә нинди алтын булсын?!

Бу юлы аны Җәмилә ишетмәде. Нидер сизенеп, ул һаман үз туксанын тукыды:

– Барысы да әйбәттер бит? Нигә әйтмисең, улым?

– Әйбәт, әнкәй, әйбәт... Борчылма...

Әнисеннән бер сүз дә ала алмаячагын аңлагач, Зөлфәт, җил-җил атлап, урамга чыгып китте. Аның зиһененә «алтын» сүзе ныклап кереп урнашкан иде. «Алтын тапканнар» дигән хәбәр исә шәһәрдә таркалып, җимерелеп калган бизнесын кабат торгызуга бер илаһи ишарә, өмет чаткысы булып тоелды.

Урамда беркем дә юк. Авылда юкка-барга пычрак таптап йөрмиләр. Яз быел иртә килде, әмма соңарып китәргә охшый. Апрель урталары җитсә дә, кояш калын болытлар аркылы ныклап яктырта алмый, яңгырлары да көздәгечә салкын, ә көтелгән җылы ләйсән бу якларны урабрак уза ахры.

Зөлфәт үзе дә бу пычрак вакытта авылына өстерәлеп кайтып йөрмәс иде. Эшендә бик зур кыенлыклар килеп чыкты. Чит ил валютасы «төшеп-менеп» йөргән бер чорда, аның фирмасы бөлде, кешеләре таралды, кредит акчалары баш очында балта булып эленеп калды. Әлеге авырлыктан чыгуның бер генә юлы бар иде: фирманы бөтен биналары, товарлары белән сатып, кредитны түләп бетереп, калган акчаны кесәгә салып, читкә китеп торырга... Бераз вакыттан соң яңадан берәр эш башларга... Башы яшь, җаен белә, кабат башлау элекке кебек авыр булмаячак. Зөлфәт шулай ниятләде дә – бераз вакытка авылга кайтып, әнисе янында торып килергә булды.

Мәктәпне тәмамлап, Казанга киткәннән бирле, аның юньләп кайтканы да юк икән. Башта укуга бирелде, икътисадчы, юрист дипломнары алды, аннары, әле башлап, әле ташлап дигәндәй, үз эшен булдырырга тырышып, ун еллап гомерен үткәрде. Ниһаять, торак йортларны, кибетләрне җылләтү җиһазлары сату, урнаштыру буенча фирма ачып, эшен җайга сала алды. Фатир булдырды, затлы машина алды, туйсыз-нисез генә Әлфия исемле сабакташ кызы белән яши башлады. Зур мәхәббәт булмаса да, дуслык бар, аңлашу-килешү бар...

Туктале, алтын турында иде бит уйның башы. Зөлфәт уйлаган уйлары белән бүген Мәрьям карчык алып килгән шаккатмалы хәбәргә әйләнеп кайтты: «Алтын тапканнар!..» Нигә аптырарга, бала чактан ук белә Зөлфәт – аларның авылында алтын турында имеш-мимешләр гел йөреп торды. Картлардан кемдер, Казанны алгач, шушы якларга чигенгән морзалар күмгән алтын турында сөйләде, икенче берәүләр инкыйлаб чорындааклар штабы белән барган алтынның чәчелеп төшеп калуы хакында гәп сатты...

Бу сүзләр дөрес булып чыкса?.. Әнә бит – тапканнар, ди! Бар монда алтын, бар!

– Нәрсә, син дә алтын турында җенләнәсеңме, Зөлфәт улым?

Зөлфәт каяндыр җир төпкеленнән килгән кебек ишетелгән карлыккан тавышка сискәнеп китте. Әллә, «алтын-алтын» дип, акылдан яза башладымы? Алтынны шаукымлы, диләр бит...

– Син кем? Син кайда?

– Мин монда, Шакир бабаңны танымыйсыңмы әллә?

– Ак бабай? Синмени бу? Ә мин, колагыма ишетеләме, дип торам...

Койма буена өеп куелган агачлар артында тәмәке көйрәтеп утыручы Шакир картның шәүләсен чамалап алгач кына тынычланды Зөлфәт.

Алар шулай, бүрәнә аша бүре куган кебек, койма аркылы гына сөйләшә башладылар.

– Каян белдең минем алтын турында уйлап утырганны? Ә, Ак бабай?

– Белдем. Бу минутта бөтен авыл алтын турында уйлый.

– Син дә уйлыйсыңмы?

– Юк, мин алтын турында уйлаучылар турында уйлыйм.

– Ничек инде? Сиңа алтын кирәкмимени?

– Инде кирәкми. Миңа Ходаебыз тагын берничә сәламәт ел бирсә, шул җитә.

– Синеңчә, гомер алтыннан да кадерле инде алайса?

– Гомер түгел, берничә сәламәт ел.

– Аннары?..

– Аннары... юлга. Җәннәттә алтын кирәкми, – дип елмайды Шакир карт.

Көн караңгылана башлаган булса да, Зөлфәт чамалап алды: күрше картының йөз-бит чалымнары, гәүдә тотышлары, берничә еллык кына түгел әле. Гомере озын булыр кебек, иншалла! Булсын гына! Ак бабай бит ул, элек-электән малайларның хөрмәт иткән кешесе, өлкәннәрнең киңәшчесе... Ансыз авылда бик күңелсез булачак...

– Әйт әле, Ак бабай, бу хакта син ничек уйлыйсың? Әллә тәвәккәлләп карарга микән?

– Нишләмәкче буласың?

– Кеше нәрсә эшли – шуны эшлим. Иртәгә үк, көрәк тотып, шул тауга менәм, мин дә бәхетемне сынап карарга тиештер бит?

– Бик кирәкмени соң сиңа алтын?

– Кирәк шул, бөтен эшне ябып кайттым, яңасын башларга кирәк.

– Табылдык алтын белән уңышлы эш башлап булыр дисеңме?

– Була, Ак бабай, андый мая табылса – була.

– Алайса, карарың нык?

– Кем белгән инде аны, кеше көлсә көләр, чыгып карыйм.

Карт бераз уйланып торды. Тәмәкесен соңгы мәртәбә суырды да аяк астына салып таптады. Күктә кабына башлаган йолдызларга күтәрелеп карады. Аннары, тавышын баса төшеп, ниндидер мөһим нәрсә хәбәр иткәндәй, сөйләп китте:

– Тагын бер юлы бар алтынны кулга төшерүнең. Көрәк күтәреп, үз-үзеңне кимсетеп йөрүгә караганда, күпкә отышлырак. Яшем бераз яшьрәк булса, мин нәкъ шулай эшләр идем...

– Нинди юл ул, Ак бабай? Миңа әйтергә ярыйдыр бит?

– Әйтәм. Миннән юк инде, шуңа да сиңа әйтәм. Алтын тавын бөтенләе белән бергә үз милкең итәргә кирәк. Тавы синеке булгач, җир куенында яткан алтыны да синеке дигән сүз.

– Колхозны килештереп булырмы соң? Алтын да табылса...

– Колхоз таралды, аның фермасы гына тырпаеп утырып калды, утыз сыер белән ике доярка, бер скотник кына хәзер колхозда. Ә җирләр сатылып бетте, «алтын басуын» казнадагы иң зур банкта эшләүче берәү үзенә алган. Безнең як кешесе түгел. Менә ничә ел инде берни чәчми, кая чәчү, ялгышып та килеп чыкмый. Кабат сатар өчен, җирнең бәясе артканын көтә, имеш.

– Алай да буламыни?

– Әйе икән шул. Мин дә, булмыйдыр, дип уйлый идем дә...

– Ничек табарга соң ул кешене?

– Анысы иң җиңеле. Авыл советында адресы, телефоны бар ла. Бер елны кереп, телефоннан үзем сөйләшеп карадым: нигә чәчмисең, мин әйтәм, җир чүпкә батып, интегеп ята бит, дим... Әлегә мин чит илдә, кайткач килермен, сөйләшербез, дигән иде. Кайтмады да, сөйләшмәде дә...

Икесе дә тирән уйга чумдылар. Шакир карт кабат көйрәтеп җибәрде. Зөлфәт, баш очыннан чаган яфрагын өзеп алып, чәйнәргә кереште... Бу минутта

зиһене яшен тизлегендә эшли иде аның. «Ә нәрсә, шәп идея бит бу! Бөтен басуны кулга ала да рәхәтләнеп алтын эзли. Алтын бар анда, бар, әллә кай җире белән тоя ул, бары тик иренмәскә, эзләргә, эзләргә һәм эзләргә! Иртәгә үк авыл советына бара, теге җирбиләүче бәндәне таба, сатып ала... Туктале, җир кыйммәт микән монда? Акчасы җитәрме? Җитмәсә, кредит алыр. Юк, кредитка башка кермәячәк ул... Ант итте...»

Бу юлы да Шакир карт аның уйларын белеп, укып торган икән:

– Әлләни кыйммәт түгел. Синең генә көч җитәрлек.

– Ә? Каян беләсең миндә күпме акча барын?

– Беләм. Йөзеңә карап беләм. Сөйләшүеңә карап, киемеңә карап беләм.

– Ай-һай серле дә кеше син, Ак бабай... Бала чакта да аптырап бетә идек. Хәзер дә аптыратасың...

– Син минем кадәр яшәп кара әле, үзең дә кешеләрне аптыратып йөдәтерсең. Мин бит бер аягым белән ике дөнья чигенә баскан инде. Аллаһы Тәгалә карамагына күчкән вакытта күңел барысын да алдан тоя башлый ул, Зөлфәт улым...

**2**

Әнисе улының ниятен хупламады. Ачы таң белән торып, чәй өстәле янына утырган Зөлфәтне битәрләп тә алды әле.

– Шулкадәр укып, кеше булгач, шушы балчыкка кайтырсыңмы инде, юк алтынны эзләп, тау башында чокчынып йөрерсеңме? Әтиең исән булса, тыяр иде дә, мине тыңламыйсың шул син...

Күз яшьләрен чак-чак тыеп торучы әнисенә карап, Зөлфәт ниятләгән эшеннән баш тартырга да уйлаган иде, аннары тагын күңеле үз урынына утырды – авыл советына җыена башлады. Әнисенең әтисен телгә алуы гына бәгырен тырнап алды... Әтисе вакытсыз китте шул – колхоз дип инде, уңыш дип, икмәк дип... Механизатор иде, гомере буе трактордан төшмәде. Әлеге дә баягы Мәмәт кырында кар тотып кайткач, үпкәсе шешеп вафат булды. Зөлфәткә җиде генә яшь иде. Ул вакытта малай әтисенең үлемен тоеп та бетермәгән, күрәсең. Елый алмады ул, елый алмый изаланды. Мәрхүмнең җидесендә генә беренче мәртәбә күз яшен чыгарды. Еламаса, акылдан яза иде малаең, дип, әнисенә әллә ничә кеше әйтеп китте.

Авыл советында сыйныфташы Гөләндәм эшли икән. Укытучылыкка укып, бераз шәһәрдә яшәп кайткач, мәктәптә озак эшләргә туры килмәгән, кыюлыгы-чаялыгы бар, сүзе үтә, дип, авыл җитәкчелегенә чакырганнар. Соңгы сыйныфларда укыганда, Зөлфәт аны берничә тапкыр озатып та куйган иде. Чыгарылыш кичәсендә дә биюгә аны чакырды. Бөтен кеше: «Болар бергә булыр ахры», – дип тел шартлатып торган иде... Аннары юллары аерылды. Һәркем үз юлыннан китте. Күрәсең, алар арасында көчле мәхәббәт хисләре кабынып өлгермәгәндер. Бүген авыл советының тар гына бүлмәсендә очрашкач, шул вакытларны искә төшереп, икесе дә уңайсызланып тордылар. Әмма үсмер чакта кабына язып калган җылы хисләр сүнеп, сүрелеп бетмәгән кебек тоелды Зөлфәткә. Юк, ул төгәл сизде: йөрәге сискәнеп, калкынып куйды, ешрак тибә башлады. Гөләндәмнең күз карашларында да ниндидер нурлы очкын чагылып алды...

– Син авылда калырга уйладыңмы, Гөләндәм?

– Шулай уйладым. Мин дә калмагач, кем кала?.. Барыгыз да китеп югалдыгыз, авыл ятим хәзер. Әнә, кырлар, яланнар, күлләр, чишмәләр – барысы да ятимлеккә дучар. Без үскәндәге Кендек авылы юк инде ул, Зөлфәт...

– Алайса... нигә шәһәрдә генә төпләнмәдең соң?

– Ә син нигә кире кайттың соң?

– Минем тарих башкача, Гөләндәм.

– Юк, шул бер үк тарих бу, Зөлфәт. Кыен чакта барыбыз да авылга кайтып сыенабыз. Ул барысын да күтәрә, киң күңелле, мәрхәмәтле, миһербанлы безнең җир, ничек кенә кайтсак та, үзенең җылысына төреп, куенына ала белә. Сине дә, мине дә сыендыра...

– Үзең нихәлләрдә яшисең соң син, Гөләндәм?

– Мин шәһәрдә эшләдем, кияүгә чыктым. Әмма ялгыштым. Җиде айдан аерылып, шушында кайттым. Әле ярый балабыз юк иде... Балабыз булса, калыр идем дә, түбәнчелектә гомер кичерер идем. Ә үзеңнең гаиләң бармы соң?

– Бар да, юк та.

– Ничек инде?

– Ялгыз ук түгел – якын кешем бар, әмма хатыным юк, балаларым юк...

– Алтын тапсаң, шәһәргә кабат китәсеңме?

– Аны табарга кирәк әле!

– Тапсаң, дим бит...

– Тапсам, бәлки калырмын да, тапмасам – китәм. Мин бу сүземне синең алда – күңелемә иң якын, иң кадерле кеше алдында әйтәм!..

– Димәк, китәсең...

– Нигә алай дисең, Гөләндәм?

– Юк бездә алтын. Алтын куллы кешеләр бар, алтын йөрәкле абзыйлар, апайлар бар... Очраклы гына табылган бер бөртек алтыннан әллә нинди нәтиҗәләр ясап, бөтен авыл шашынып җир чокый... Колхоз да онытылды, язгы мәшәкатьләр дә юкка чыкты, күпләр үз гаиләләрен дә онытты... Мин шуны тоям: дөрес гамәл түгел бу: хакыйкать тирәндәрәк булырга тиеш, ә кеше бик җиңел генә байлыкка ия булмакчы...

– Ярый, Гөләндәм, мин кузгалыйм инде теге җир хуҗасын барып табасым бар. Рәхмәт сиңа барысы өчен дә. Менә... документлар өчен, авылга карашың өчен, миңа матур мөнәсәбәтең өчен рәхмәт. Аннары...

– Нәрсә – аннары?

– Кичерүең өчен...

– Кемне? Нәрсә өчен?

– Мине... Теге вакытта үҗәтрәк булмавым өчен. Ул вакытта кыюрак булсам, безнең тормышлар бөтенләй башка юлдан китәсе иде...

– Рәхмәт, Зөлфәт, боларның барысын да аңлавың өчен рәхмәт...

– Ну, мин киттем!

– Зөлфәт!

– Әү!

– Теге, бая әйткән сүзеңне тагын бер мәртәбә кабатла әле.

– Нинди сүз ул?

– «Күңелемә иң якын, иң кадерле кеше» дигән сүз.

Зөлфәт кызарып киткәндәй булды. Чынлап та әйтте микәнни ул бу сүзләрне? Әйтте шул... Нигә әйтмәскә – чынында шулай: бүген аның өчен иң якын, иң кадерле кеше Гөләндәм исемле шушы мөлаем, акыллы, тугры зат булып чыга...

– Әйтәм, игътибар белән тыңла: минем өчен иң-иң якын, иң-иң кадерле кеше...

– Рәхмәт, Зөлфәт... Йә, бар инде кит, үз юлыңда бул. Кайткач тагын керерсең, авыл советы каршында хисап тотарга кирәк булачак... – Соңгы сүзләрен Гөләндәм күзен кысыбрак, хәйләкәр елмаеп әйтте.

### 3

Районадагы Җир идарәсендә бераз токарланып, кирәкле белешмәләрне алгач, Зөлфәт Мәмәт басуының хуҗасын Казаннан – кәттә генә бер банктан барып тапты.

Николай Петрович дигәннәре чып-чын татар икән. Керәшен татары. Кызыл битле, зәңгәр күзле бу кеше бик ачык адәм булып чыкты. Сөйләшкәндә «җ» авазына басым ясап, «һ»не «х»лаштырып, үзенең керәшен икәнен сиздеребрәк сөйләшә.

– Син, җегеткәй, дөрес җулда. Җирнең җылысын хич суытырга җарамый... Үземә дә бик кыен иде ул җир өчен, кызулык белән алып калган идем... Кул җитмәде... Хаман-хаман барып җөреп булмый шул, әле банк, әле кибет эшләре ике кулны җөгәнләп бәйләп куйган... Үз бәясенә бирә алмыйм, кыйммәтрәккә сатмасам, җоклый алмаячакмын. Худай алдында җөзем ак, аның тәртибе шундый. Аңла, җегет: сине хөрмәт иткәнгә генә бирәм. Җир ул – капитал. Аны теләсә ничек, теләсә кайчан сатып җөрмиләр...

Зөлфәткә: «Рәхмәт! Рәхмәт!» – дип, баш чайкап торырга гына калды. Аның өчен барысын да Иван Петрович сөйләп, эшләп бетерде. Бу яклап аның юристлары бик өлгер булып чыкты. Бөтен дөньясын үз кулында тотып яшәгән, әмма шушы болгавыр заманда да күңел матурлыгын, аек акылын югалтмаган бу мөлаем кешенең тагын сүзе калган икән әле:

– Җарый, ал, рәхәтен күр, тик җелеген суырма! Җайлы итеп кенә җөртергә кирәк җир эшен. Ишетсен колагың, җегеткәй: белешеп, тикшереп торачакмын, хилаф эш күрсәм, кире алам, килешүгә дә шулай дип яздым... Аннары...

– Нәрсә – аннары?.. – Зөлфәтнең йөрәге аяк табанына төшеп ятты. Әллә алтын турында сорыймы бу банкир? Каян белгән?

– Аннары шул: тормыш бик китереп кысса, минем җанга кил, мин сиңа җүн генә процентка акча биреп торырмын.

– Юк, кредит кирәк түгел. Бүтән булашмыйм ул нәрсә белән.

– Кредитка түгел. Үз җөрәгем белән тапкан акча турында әйтәм.

– Рәхмәт, Николай Петрович! Бу изгелекләреңне мәңге онытмам...

Әлбәттә инде, Зөлфәт Мәмәт басуындагы алтын турында бер сүз дә әйтмәде. Акчасын кирәкле урынга күчерде дә, районнан тиешле кәгазьләрне алгач, ике көн дигәндә тагын Кендеккә кайтып төште. Кайтышлый ук авыл советына кереп, кирәкле кәгазьләрне күрсәтте, аннары, өенә дә тиеп тормыйча, үзенең хосусый җиренә – Мәмәт басуына менеп китте...

Авылга кайтканнан бирле беренче күрүе иде әле аның «алтын җирен». Ләкин Зөлфәтне Мәмәт тавында «шайтан җире» каршы алды. Балчыктан өелгән дамбага менеп басуга ук, чак кына егылып китмәде. Бу җирне алуына үкенеп куйды.

Басу өслеге чын-чынлап сугыш кырын хәтерләтә: гүя, бомба, миналар шартлаудан әле анда, әле монда «окоп чокырлары» хасил булган, «траншеялар» ерылган, хәтта кунып-төнеп ята торган «блиндаж куышлары»на кадәр бар...

Ул арада, җир астыннан чыккан кебек кенә, Зөлфәтнең каршында кулына көрәк тоткан Трактор Фәниле пәйда булды. Гомере буе трактор тирәсендә кайнашканга күрә, аны шулай дип йөртәләр иде. Кайчандыр алдынгы механизатор булып йөргән, җор телле, алтын куллы, җитез хәрәкәтле бу кешене хәзер танырлык та түгел. Авылга сирәк кенә кайткан мәлләрдә аны бик каты эчә дип әйтәләр иде, дөрес ахры: әнә бит, йөз-бите җимерелгән, маңгай тирәләре, күз читләре җыерчыкка баткан, чал төшә башлаган сакалы кырылмаган, пумала кебек тарау чәчләрендә басу тузаны...

– Нишләп йөрисең син монда, Фәнил абый? Тракторың кайда?

Зөлфәт телен тешли язды. Каян булсын инде аның тракторы, колхоз таралган, тракторлар «очкан», диделәр бит... Ләкин сүз әйтелгән, сорау бирелгән иде инде.

– Ә-ә, Зөлфәт икән әле... Касыйм малае... Трактормы? Трактор – тү-тү... Колхоз да – тү-тү... Менә шуннан соң... Трактор Фәнил дә – тү-тү... Аракы шешәсенә утырып очты Фәнил абыең... Их, Касыйм белән ярыша-ярыша сөргән басулар, сөенә-сөенә иккән игеннәр! Кайда хәзер ул вакытлар? Касыйм китте дә котылды... Ул күрмәде бу мәхшәрне!.. Кайчандыр тау кебек тракторларны биетеп кенә йөрткән Фәнил хәзер, ярык көрәк тотып, алтын эзләп йөри, тьфү, шайтан типкесе! Их, Касыйм!.. Их, Зөлфәт!..

Аракы сөреме башын миңгерәйткән Трактор Фәниле озак тукталып тормады, иңке-миңке килеп, авылга төшеп китте. Зөлфәт шунда гына кайсы заманга, нинди хәвефле җиргә килеп эләккәнен ныклап аңлап-төшенеп алды. Бу афәткә ул әзер түгел иде, әмма ният кылынган, эш башланган инде. Җир аныкы. Андагы алтын да аныкы. Юк, көрәк тотып, берәм-берәм басудан чыгып, кача-поса өйләренә кайтып баручы авыл кешеләренең зомбига әверелү тарихы аның йөрәгенә тияргә, күңелен авырттырырга тиеш түгел. Ул алар кебек түгел, түгел!

Зөлфәт «сугыш яланына» кереп тормады, карашын алтын басуыннан каерып алып, йөгерә-атлый авылга төшеп китте. Үзе һаман шул бер сүзне тәкрарлый иде: «Түгел! Түгел! Түгел!..»

Бераздан зиһен күгендәге томан тарала төште. Иң тәүге аек уй ныклы карар рәвешендә туды: «Ничек тә бу кыямәтне туктатырга, бу афәтне бетерергә кирәк!» Тик ничек? Мылтык тотып, басу читенә басаргамы? Бу эш түгел. «Җир минеке» дигән документ белән, өй борынча йөреп чыгаргамы? Бу хакта кем белән киңәшергә? Кем бар, кем генә калган соң бу авылда алтын шаукымына бирелмичә? Кем булсын – Ак бабай!

**4**

Ак бабай, һәйкәл кебек, һаман шул үз урынында – койма буена өелеп куелган агачлар ышыгында утыра иде.

– Ни хәлләр, Ак бабай? Исәнме-саумы!

– Исән-сау әлегә, үзеңнең генә хәлләр мөшкел ахры.

– Каян беләсең, Ак бабай?

– Минем белән сөйләшергә телисең бит, шулаймы?

– Шулай. Син әүлия кебек, билләһи газыйм!

– Җирне ала алдыңмы?

– Җир – минеке, тик...

– Тәк-тәк?..

– Мин аны нишләтергә белмим, анда бөтен авыл казынып ята... Мин дә алар янына көрәк тотып басыйммы, әллә, мылтык тотып, каравылларга чыгыйммы?

– Син кешеләргә ачуланма, Зөлфәт улым. Алар, көрәк тотып, чарасызлыктан барып кергәннәр ул басуга. Колхоз таралганга ун ел инде, бу вакыт эчендә авыл үзалдына тормыш итте, кем нәрсә булдыра – шуны эшләде. Тик күпчелек бөлде, авыр хәлдән чыга алмады. Кемдер, соңгы сыерын сатып, читкә китеп барды, монда калганнарның кайберләре эчүгә сабышты, күпчелеге шабашка белән көн күрде, калганнар берәдәклектә гомер кичерде. Кеше күзенә ак кара булып күренә башлады. Шуннан аңла инде авылдашларыңны... Һәм кичер аларны.

– Эш бит кичерү-кичермәүдә түгел, Ак бабай. Миңа нишләргә хәзер, дим. Бөтен басуны казып чыкканнар. Көрәк тыгарлык җире дә юк...

– Сөреп чыгарга кирәк.

– Нәрсә-ә-ә?

– Ни ишеттең – шул: сөрдерергә кирәк Мәмәт басуын.

– Син нәрсә, Ак бабай, көләсеңме әллә? Нинди сөрдерү ул тагын? Каян алыйм мин ул тракторларны?

– Мәмәт басуы алтынны ныклап яшергән. Югыйсә ул сиздерер иде инде. Борынын яисә койрыгын булса да чыгарып күрсәтер иде. Үртәргә ярата бит ул алтын дигәннәре...

– Шуннан? Причём монда сөрү?

– Их шул гадәтегезне! Тыңларга яратмыйсыз сез, яшьләр. Менә шул: бары сөрдереп кенә табып булачак ул алтынны. Сөреп кенә бөтен басуны иңләп казып чыгып булачак... Төрәнне тирәнгәрәк кертеп җибәрәсең дә...

– Ярый, шулай да булсын, ди. Тик каян алырга соң ул трактор дигәннәрен? Авылда трактор тавышы ишетелми кебек...

– Бар бер трактор. Фәнилнең капка төбендә. Кайбер зәпчәсләр таба алсаң, хәзер йөреп китәчәк ул.

– Күрдем мин аны – Трактор Фәнилен. Дөресрәге, аның өрәген. Әле дә күз алдында тора – күргәннән күрмәгәнең артык...

– Ашыкма карар чыгарырга... Бер күрүдә кешеләрдән ваз кичәргә ашыкма... Кешенең асылы йөзендә түгел, җанында...

– Барыбер үзгәргән ул.

– Үзгәрмәгән, үз эченә йомылган. Аның күңелен кабат ачарга, кабат дөньяга кайтарырга кирәк. Шул гына.

– Тик ничек итеп? Ничек...

– Өенә бар син аның. Тәмле сүзеңне кызганма. Эш бир. Яшәрлек акча бир, шартлар тудыр... Ышан син аңа, ул әле синең төп таянычыңа әвереләчәк.

Күңеленнән ышанып бетмәсә дә, Зөлфәт бу юлы да Шакир картны тыңларга булды. Әнисе янына кереп күренеп чыкты да, кичке офык читенә караңгылык тарала башлауга да карамастан, пычрак ера-ера, Трактор Фәнилен эзләп китте.

Капка төбенә үк чыгып каршы алган Фәнил бу юлы Зөлфәткә ул чаклы ямьсез булып күренмәде.

– Килерсең дип уйлаган идем аны...

«Әүлияләр авылы бу, чынлап та, синең ниятеңне әллә кайдан белеп торалар...» – дип уйлап өлгерде Зөлфәт, күрешергә кулын биргәндә.

– Менә килдем әле, Фәнил абый, бик зур йомыш белән килдем... Исәнме-саумы...

Трактор Фәнилен таныйрлык та түгел.

– Исән-сау, Аллага шөкер әле, Касыймыч, – дип, үтә дә ачык йөз белән күреште ул, аннары, гафу үтенгән кебек, өстәп куйды: – Басу читендә очрашканны «очрашмадык» дип уйла, яме?..

Чынлап та, басу читендә ул булмаган ахры. Әнә бит – бу юлы пөхтә итеп киенгән, кырынган, чистарынган... Күзләре дә башкача карый, сүзләре дә ипле, мәгънәле...

– Трактор кирәк, Фәнил абый... – Зөлфәт як-ягына каранып алды. Ерак та түгел, шактый караңгылана башлаган урам буенда, коймалар читендә тау кебек трактор тора иде...

Зөлфәтнең эзләнгәнен сизенеп, Фәнил кул гына селтәде:

– Юкка мәшәкатьләнеп йөрисең, Касыймыч. Юк дип сана бу тракторны. Үзе тере кебек күренсә дә, җаны юк аның, колхоз беткәнгә ун ел, шул ун ел буе чыкты аның җаны... Мин әбәткә кайткан сәгатьтә бетте безнең колхоз. Ватылыбрак кайткан идем, шул килеш койма буенда торып калды.

– Кабызырга тырышып карамадыңмы?

– Карадым, карамаган кая?

– Ну, ничек?

– Миңа үпкәләгән кебек, һич кабынмый, шайтан алгыры! Тегеләй дә, болай да итеп карадым, зәпчәсләр дә юнәттем. Юк, тынын да чыгармый!..

– Шулай да, тагын бер карап кара әле, Фәнил абый, тракторыңны. Мин сине үземә эшкә алам, Мәмәт басуын сөреп чыгарга кирәк...

– Минем башка да килгән иде андый уй. Тик... кем рөхсәт бирсен сиңа аны сөрдерергә?

– Рөхсәт бар инде, менә, кәгазьләр кулда... – Зөлфәт куеныннан үтә күренмәле папка чыгарды. – Бу яклап барысы да тәртиптә: җир минеке, хет аркылыга, хет буйга сөреп чык...

– Алай икән... Дөньялар үзгәрә, болай булгач... Нәрсә чәчәргә уйлыйсың соң?

– Нинди чәчү ул? Алтын эзлибез синең белән... Алтын, белдеңме?!

Трактор Фәниленең йөзе тагын моңсуланып калды.

– Син дә шул турыда икән... Укып кайткан кешегә дә йогар икән бу чир, вәт, малай, ә?.. – дип сөйләнде ул үзалдына.

– Фәнил абый, син ризамы?

– Риза булмаган кая, миңа да нindидер эш кирәк бит инде...

– Бик яхшы, алайса болай итәбез: син иртәгә тракторыңны тагын бер мәртәбә карап чык. Нәрсә җитми, нинди запас частьлар кирәк – барысын да бөртекләп яз, шәһәрдән җыеп алып кайтырмын, ягулык мәсьәләсен дә үзем хәл итәрмен...

– Ярый соң... Шулай эшләрмен. Тырышып карармын...

– Тырыш, Фәнил абый, тырыш, ничек тә җанлы ит бу нәмәрсәкәйне, бөтен Мәмәт тавы гөрелдәп торсын!

Шулай килештеләр, аерылыштылар. Трактор Фәниле: «Алтын, алтын, алтын түгел – ялкын», – дип сөйләнә-сөйләнә, капкасыннан кереп китте, Зөлфәт исә, Ак бабай «ставка»сына юл тотты. Ләкин бу юлы Шакир карт үз урынында юк иде. Өендә дә ут алынмаган... Берәр кая киткәнме әллә картлач? Бер-бер хәл була күрмәсен үзе белән. Бик кирәк ул хәзер Зөлфәткә, ай-һай кирәк!

**5**

Трактор Фәниле сүзендә торды. Көне буе тракторы белән булашып ятканнан соң, кулында шактый озын кәгазь кисәге пәйда булды. Зөлфәт аның янына килеп-китеп йөрде, туктаусыз сораштырды, хәтта йөдәтеп бетерде.

Ниһаять, ул, теге озын кәгазьне тотып, эре-эре адымнар белән авыл советына юл алды. Анда аның затлы машинасы тора. Авылга кергән ташлы юл шул урынга кадәр генә килә. Янәшәдә генә искереп карая башлаган клуб бинасы тора, аннан арырак элеккеге колхоз идарәсе, ябык фельдшер-акушер пункты... Шунда ук кибет. Анысы эшли икән әле, кемнеңдер оныгы – шәһәрдән кайткан эшлекле генә бер ханым – үз эшен ачып, җәһәт кенә биләп алган.

Зөлфәт машинасын кабызды да авыл советы бинасына төбәлеп уйга калды. Гөләндәм... Ул ничек икән анда? Классташын онытып бетермәгәнме? Нинди сәбәп табарга соң? Ә! Кереп, хисап биреп торырга кушты лабаса...

– Сәлам, Гөләндәм!

Кинәт ишектә пәйда булган Зөлфәтне күргәч, кыенсынып, тәмам каушап төште Гөләндәм. Күлмәкләрен рәтләде, чәчләрен төзәтте...

– Сәлам... Исәнме, Зөлфәт... Ни эш бетереп йөрисең?

– Менә, хисап белән кердем. Үзең әйттең бит – хакимияткә күренеп йөр,

дидең. Разрешите докладывать: Мәмәт басуын сөрдерергә булдым, Трактор Фәниле белән сөйләштем, хәзер ягулык юнәтергә, запчастьләр алырга шәһәргә китеп барышым... Доклад окончен!..

– Йә, кыланма инде, Зөлфәт. Шәһәрне сагындым, сезнең пычрак авылыгыздан туйдым, димәкче буласыңдыр әле. Хатының да югалткандыр...

– Анысы да бардыр. Әмма минем ният нык: азрак җир генә кибенсен – Мәмәт басуын иңләп-буйлап сөреп чыгабыз.

– Алла боерса, диген.

– Алла боерса!..

– Алтын турындагы ниятең дә ныкмы?

– Нык. Алтын бар. Һәм мин аны табачакмын! Мин моны йөрәгем белән тоям һәм беләм!

– Ул йөрәгең тагын нәрсәләр тоя?

– Күп нәрсә тоя ул. Менә сине, синең күңелеңне тоя... Дөресен генә әйткәндә, мин хисап бирергә түгел, сине күрергә кердем, Гөләндәм...

– Рәхмәт матур сүзеңә, чын булса инде... Мин тәмле сүзләргә бик ышанып бетмим шул хәзер, Зөлфәт...

Зөлфәт ни дип әйтергә дә белмәде, бераз таптанып торды да: «Пока, Гөләндәм!» – дип чыгып китте.

Казанга җиткәнче шушы соңгы очрашу турында уйлап барды.

Гөләндәм. Гө-лән-дәм... Кем ул хәзер Зөлфәт өчен? Классташы гынамы? Дусты-фикердәшеме, ярдәмчесеме? Якын сердәшеме? Кайчандыр күңеленә кереп, күп еллардан соң кабат балкып яна башлаган йолдызмы, хисме, язмышмы? Ә Әлфия кем? Гомеренең иң кыен минутларында янәшә булган, аның бөтен борчуын, мәшәкатьләрен бүлешкән ихлас җанмы? Шулай гынамы? Зөлфәт әлегә бу сорауларга җавап тапмаган. Бу ике якын кешенең аның язмышында нинди урын билгәләнен ул әлегә әйтә алмый. Күңелен бик ашыктырасы да килми, әлегә уйларын башка гамь, башка мәшәкатьләр биләп алган. Эшен җайга салу, Мәмәт басуын сөрдереп чыгу, алтын табу, иң мөһиме, кеше алдында хур булмау...

Зөлфәт көне буе махсус кибетләргә, базарларга кереп, Фәнилнең тракторына яңа детальләр эзләде, анда булмаганнарын Интернет аша сорашып тапты, шулай көн үткәнен сизми дә калды.

Фатирына кереп, киемен алыштырды, башка кирәк- яракларын төйнәде дә, чыгып китәргә ниятләгән генә иде, шулвакыт ванна ишегендә ак халатына төренгән Әлфия пәйда булды. Аптыраулы карашында Зөлфәтне җибәрәсе килмәгәнлеге күренеп тора.

– Зөлфәт, китәсең дәмени?

– Юк, булмый, калып булмый, Әлфия... Эшем тыгыз, авылда җир алдым, трактор юнәтеп йөрим, гафу, мин киттем, яме...

Әлфия матур нәзек иреннәреннән бер генә җөмлә кысып чыгара алды:

– Син бу юлы нык үзгәргәнсең, Зөлфәт...

– Кеше үзгәрми тормый инде ул, Әлфия... – Зөлфәт өйдәшенә якын килеп, бит очыннан үпте дә кызның сарыга буялган чәчләреннән сыйпап алды. – Борчылма, барысы да о-кей!

**6**

Фәнил, тракторын кабызып, бөтен урамны күк-зәңгәр төтенгә тутырганчы, ике атна вакыт узды.

Ул арада Зөлфәт вак-төяк эшләр белән мәшгуль булды. Иң элек, махсус

язулар язып, аларны таякларга кагылган рамнар эченә беркетеп, Мәмәт басуының чик буйларына урнаштырып чыкты. Авыл кешеләре «Зөлфәт Касыйм улының шәхси җире» дигән язуны, ышаныргамы-юкмы дигән кебек, кат-кат килеп карадылар.

Икенче эш итеп, Зөлфәт, ун кеше аша белешеп, җир астыннан металл эзләү җайланмасы табып кайтты, үз ишегалларында аның белән «сынау да үткәрде». Янында торган Шакир карт белән Җәмиләне шаккатырып, ул үз биләмәләреннән бер уч кадак, бер уч шөреп, бер уч бакыр акча, ике җиз төймә, чулпы тәңкәсе һәм теткәләнеп беткән иске гильза табып алды.

Тагын бер ниятен гамәлгә ашырмакчы булды Зөлфәт. Мәмәт басуыннан алтын тапкан малайны эзләп китте. Аның табылган алтынны бик тә күрәсе килә иде. Ләкин теләгенә ирешә алмыйча кайтты. Алтын тапкан малай, юеш борынын мышкылдатып торды да: «Югалттым мин аны, белмим, кесәдән төшеп калган...» – дип, йөгереп өйләренә кереп китте...

Иң мөһиме, акча юнәтәсе бар иде аның. Теге вакытта Казаннан кайтып төшкәч, Зөлфәтнең саклау кенәгәләрендә, акча карточкаларында бер тиен калмаганлыгы мәгълүм булды. Казанда Николай Петрович бар-барын... Акча акча сорый, дип, ул тагын процент куячак инде. Кредитлардан, процентлардан гарык булып авылга кайткан Зөлфәт бу юлы банкирлар янына бармаска уйлады. Авыл, район эчендә генә хәл итеп булмасмы? Бу хакта киңәшләшү өчен, ул Гөләндәм янына керде. Бүлмәдә Зөлфәттән ике ел алдан тәмамлап чыгып киткән, әнисенең сөйләве буенча, авылга кайтып берничә сыер, үгез асрап, шуларның итен сатып көн күрүче Замир утыра иде. Зөлфәтнең үз ниятләре хакында аның алдында сөйләшәсе килмәде, авылдашы белән салкын гына кул биреп күреште дә:

– Замир, зинһар, беразга гына чыгып тор әле, Гөләндәмгә бер-ике сүзем бар иде, – диде.

Замир урыныннан кузгалмды. Хәтта кузгалырга уйламады да. Бүлмәдә ниндидер киеренкелек барлыкка килде. Зөлфәт белән Замир бер-берсенә укталып сүзсез калдылар. Киеренкелекне Гөләндәм бозды:

– Замир, бар, чыгып тор.

Замир бер Гөләндәмгә, бер Зөлфәткә карап куйды да, авыр гына кузгалып, ишеккә юнәлде, Зөлфәт яныннан узганда, аны янбашы белән этеп җибәрде, тегесе стена янәшәсенә тезеп куелган урындыклар өстенә авып төште.

– Нәрсә булган аңа? – дип сорады Зөлфәт, Замир чыгып киткәч.

– Нәрсә булсын, көнләшә.

– Миннәнме?

– Кемнән булсын?! Авылда бүтән көнләшерлек ир заты юк. Ул да син хәзер. Бөтен кеше телендә сез бүген...

– Ә син? Синең аңа карашың ничек?

– Туктале, Зөлфәт! Синең соравың шушы идеме? Әллә тагын берәр сүзең бармы? Булса, әйт тә чыгып кит, миңа эшләргә комачаулама!

– Гөләндәм, гафу! Ну, аңла, ул көнләшкәндә, миңа да көнләшергә ярыйдыр бит?.. Ә беләсеңме, мин сине беркемгә дә бирмәячәкмен!

– Сүзең?

– Нәрсә?

– Сүзең ни иде, дим...

– Фу, чистый баш буталды әле монда... Эш болай тора: җир бар, трактор белән тракторчы бар, запас частьлар алынды, трактор ремонтлана.

Ләкин... акча бетте. Ягулыкларга, эш хакы түләргә, басудагыларны

ашатырга-эчертергә, башка чыгымнарга акча кирәк! Берәр юлын күрсәтә алмыйсыңмы? Мин монда яңа кеше, берәр каян ссуда юнәтү мөмкинлеге юкмы? Алтын табу белән, мин аны шундук кайтарып түлим, әлбәттә!

– Зөлфәт, әйтмә шул сүзне, ә! Нинди алтын булсын бездә?! Картлар әкияте бит ул! Ялтыравык тимер тапкан малай сүзенә карап... Бөтен авыл шул әкияткә ышанып, акылдан язды бит инде!.. Син соң, ике дипломлы, аек акыллы кеше, алтын эзлим, дип, кеше ышандырып йөрисең... Үзеңә көлке түгелме? Мин сине, җитдигә санап, ташландык җирне сатып алып, сөреп рәткә китерәм, дигәнгә күрә генә үз итеп йөрим. Белдеңме инде, җүләр баш!

Зөлфәттә дә горурлык җитәрлек. Ул:

– Аңладым, пока! – дип чыгарга кузгалды.

– Тукта, Зөлфәт!

– Туктадым, шуннан?

– Бер юл бар. Фермерлык яки игенчелек юлына баскан авыл кешеләренә ярдәм йөзеннән хөкүмәтебез дәүләт программасы эшләгән. Анда авыл җирендә үз эшен башлаган һәр эшмәкәргә миллион сум субсидия бирелә.

– Кредит түгел, димәк?

– Юк, ярдәм йөзеннән, дидем бит инде. Ләкин сиңа кагылмый бугай бу программа.

– Ни өчен?

– Син бит иген игәргә җыенмыйсың, син, алтын табып, байлык тупларга җыенасың... Андыйларга ябык хөкүмәт ярдәме...

– Туктале, син ашыкма, Гөләндәм. – Зөлфәт үзе уйлады, үзе килеп туган авыр хәлдән чыгу юлларын эзләде. – Әйтик, мин җирне сөрдем, ди, бу гына җитмиме? Җитми, димәк. Сөрелгән җиргә бөртек чәчеп, нинди дә булса уңыш үстерергә кирәкме?.. Минемчә, монда проблема юк. Аңарчы инде мин басудагы алтыннарны тапкан булам... Басу кысыр ятканчы, үссен шунда арыш йә бодай... Шулай дип кәгазь язып бирә аласыңмы? Үзем очына чыгар идем ул программаның, мин бит юристлыкка укыган кеше әле.

– Ярый, иртәгә кил, документлар әзер булыр.

Зөлфәт, үз теләгенә ирешкән сабый бала кебек сөенеп, баскан урынында әйләнгәләп куйды да: «Ну, пока!» – дип чыгып китте. Әмма шундук артыннан ишекне ачып, Гөләндәмгә дәште:

– Мин сине беркемгә дә бирмәячәкмен!

Ләкин, урамга чыккач, күтәренке күңеле тиз басылды. Дөресрәге, аны бик тиз бастылар. Болдырдан төшеп, җиргә аяк басуына ук, Замирның көрәктәй куллары аның бугазыннан бөтереп алды.

– Син нәрсә, миңа аяк чалырга уйладыңмы? Гөләндәмгә каныктыңмы? Тапмаган алтының белән күзен томаламакчы буласыңмы? Ул минеке, белдеңме? Ми-не-ке! Бу тирәдә тагын бер мәртәбә күрсәм, башыңны борып, кулыңа тоттырып җибәрәчәкмен. Мин ике сөйләшмим. Аңладыңмы? Ә, аңладыңмы, дим?..

– Аңла...дым, аңла...дым. Аңламаган кая ул?! – Зөлфәт, нәрсә әйтергә белми торгач, теленә ни килсә, шуны мыгырданды: – Исемең «за мир» дигән бит, ә үзең... сугыш чукмары!..

Абзар исләре килеп торган куллардан чак ычкына алды Зөлфәт. Тыны бетеп, сулышы киселеп, гырылдый башлаган иде инде. Менә ул йөткергәләп куйды да кызу адымнар белән машинасына таба китте. Анда да Замирдан котыла алмады. Әлеге усал бәндәдән килеп ирешкән хәбәр аны тагын сискәнергә мәҗбүр итте. Бу хәбәр-ишарә – Зөлфәт машинасының ишегенә тырнап язылган «ОЛАК» дигән сүз иде...

## 7

Субсидия акчасын алу кыен булмады. Закон тулысынча Зөлфәт ягында иде. Акча кулга килеп керүгә, Ак бабай аша чәчү орлыклары юнәтергә кереште. Аның район үзәгендә яшәүче бер малае күрше өлкәдәге орлык амбарына җиһазлар ташый икән. Шуннан сөйләшеп алып кайтырга булдылар. Бер уңайдан, Зөлфәт Шакир картны үзе җитәкчелек иткән «агрофирма»га агроном итеп билгеләде.

Инде тракторны сафка бастырасы да, кабызып, басуга алып менеп китәсе генә калды.

Бу тарихи мизгелне карарга бөтен урам җыелды. Әлбәттә инде, Мәмәт басуында алтын эзләүчеләрдән кала...

Арада иң дулкынланганы – Трактор Фәниле. Йөзе-бите, кием-салымы майга, корымга буялып беткән бу кеше соңгы көннәрдә тәмам үзгәрде. Җитдиләнде. Шул ук вакытта йөзенә серле елмаю кунды. Ул елмаюны үз эшеннән канәгать булуга, үз-үзенә ышануга юрадылар. Күп сөйләшми, үз эшен белеп эшли торган гади авыл эшчесе Зөлфәт күзенә пәйгамбәри бер зат булып күренде.

Менә бервакыт «авыл пәйгамбәре», кулындагы чүпрәк кисәге белән тракторының фараларын сөрткәләп алды да: «Булды бу!» – дигән кебек, җыелып торган халыкка күтәрелеп карады. Ак бабай, алгарак чыгып: «Әйдә, улым, әйдә, тизрәк кабызып җибәр. Сагындырды безне трактор тавышы, бик сагындырды. Хәерле сәгатьтә булсын!» – диде дә, авыз эченнән генә дога укып, битен сыпырып куйды.

Берничә мизгелдән авыл урамын күкле-зәңгәрле төтен тутырды. Ләкин, ничек кенә төтен болыты эчендә калсалар да, Кендек авылы кешеләре таралырга уйламады, шушы үтә дә таныш исне иснәп, баскан урыннарында тора бирделәр.

Үзара киңәшләшеп алгач, басуга төштән соң, җир өсте бераз кибенгәч керергә булдылар. Ак бабай башкаларга сүз әйтергә дә ирек бирмәде.

– Агроном итеп сайлагансыз икән – тыңлагыз! Бүген төштән соң сөрүгә төшәбез. Ләкин сөрү вакыты көненә ике-өч сәгатьтән артмасын. Җирнең җылынган чагын сайлап кына сөрергә кирәк. Йомшап, күпереп калырлык булсын, аның әле куенына орлык аласы бар...

Төштән соң трактор Мәмәт басуы читендә басып тора иде инде. Шунда ук ягулык салынган берничә тимер мичкә аунап ята... Тыныч кына гөрелдәп утырган тракторга артына алты төрәнле сабан беркетелгән, сабан артына берничә тырма да тагылган. Бу җиһазларны элеккеге колхозның МТС җиреннән барып таптылар, рәткә китерделәр. Моның өчен элеккеге тимерчелекне дә торгызырга, эшләтеп җибәрергә туры килде. Бу эштә Трактор Фәниленә кайчандыр колхозда механик булып эшләгән Югары оч Мәхмүте булышты.

Ак бабай да шунда, Җәмилә белән Гөләндәм дә янәшә басканнар, бер-берсенең колакларына пышылдашып, ни турындадыр сөйләшәләр. Көлешеп тә алалар. Аларга карап, Зөлфәт: «Колак исе чыкты», – дип уйлап, елмаеп куя. Ул үзе тагын да көлкелерәк хәлдә: кулына металл эзләү җайланмасы тоткан, колагына колакчыннар киеп алган. Күбрәк очучыны хәтерләткән Зөлфәт янында берничә малай бөтерелә...

Читтәрәк көрәк-кәтмән тоткан бер төркем хатын-кыз җанлы гына әңгәмә корган. Аларны Зөлфәт исеменнән Ак бабай яллаган. Акча түләү бәрабәренә, авыл хатыннары менә берничә көн инде басудагы чокыр-чакырларны тигезләү

белән мәшгуль булдылар. Аларга да алтын очрамаган ахры, андый-мондый хәбәр ишетелмәде.

Ниһаять, Шакир карт басу эченә кереп китте. Апрель ахыры гына булуга карамастан, кибеп-җилләп өлгергән басу туфрагын учларына алып, бер уып, бер таратып карады. Аннары, трактор ягына борылып: «Әйдә!» – дип, кул болгады. Тыныч кына гөрелдәп утырган трактор, ухылдап, бер көлтә төтен чыгарды да, бөтен көченә ыргылып, басу эченә кереп китте. Трактор артына Мәхмүт иярде, ул, бераз баргач, сабан өстенә беркетелгән тимер утыргычка менеп кунаклады. Кулындагы тимер төрән белән, сабанга ябышкан үзле балчыкны кырып барырга тиеш иде. Ниһаять, Мәхмүтне үзенең килбәтсез кораллары белән Зөлфәт куып җитте.

Басуга җан керде. Трактор тавышы бөтен Мәмәт буйларын яңгыратты. Күз күреме генә җирдә үскән талларда, тупылларда оя корган каргалар берәмләп тә, көтү-көтү дә яңа сөрелгән җиргә төшеп куна башладылар... Бу күңелле күренеш басу читендәге кешеләргә дә җан өрде ахры, әнә, хатын-кызлар арасыннан кемдер җырлап ук җибәрде, аңа башкалар кушылды:

Сөйгән ярым укып кайтты,
Тракторга өйрәнгән.
Минем якка карамый да,
Тракторга өйләнгән...
Ай-ли, ай-ли-ли,
Тракторга өйләнгән...

Зөлфәтнең дә күңеле күтәренке. Ул, сабан артыннан күпереп калган кара җир өстеннән атлый-атлый, кулындагы җайланманы җиргә тияр-тимәс тотып, әле бер якка, әле икенче якка йөртеп алып бара. Колак элмәсендә сызгырулы тавыш чыгуга, ул, билендәге кечкенә көрәк белән, аяк астындагы җирне чокып карый. Берәр нәрсә килеп чыкса, янбашына elenгән киндер букчасына салып куя...

Басу буйлап өч буй үттеләр инде, әлегә алтын күренми. Тракторлардан, комбайннардан төшеп калган тимер-томыр чыга, төймә, кадак, калак, пычак кисәкләре табыла, кайчандыр, гражданнар сугышы елларында, шушы кырларда узган канкоешлар шаһиты булып, тутыгып беткән гильзалар очрый, әнә, иске револьвер сыныгы килеп чыкты... Бер Николай патша акчасы, берничә совет чоры тәңкәсе күзгә чалынды... Акча табылган саен, Зөлфәтнең күңеле җылынып китә, – акча булган җирдә алтын булмас, дип кем әйтә ала?..

**8**

Өч көн эчендә илле гектарлык басу сөрелеп бетте. Мәмәт кыры караеп, матураеп калды. Бу көннәрдә табигать тә миһербанлы булды – яңгырын яудырмыйча, кояшын елмайтып торды.

Тик алтын гына табылмады. Инде сөрелеп бетте дигәндә, бер җыйнак кына калай тартмага юлыктылар. Зөлфәтнең бөтен өмете шунда иде. Ләкин аның эченнән ак чүпрәккә кат-кат төрелгән китап чыкты. Янындагы дисбе төймәләренә караганда, табылдык китап – дини басма иде. Шундук Шакир картны чакырттылар. Ул дин телендәге китапларны укый белә икән. Шунда ук: «Бу – изге Коръәнебез», – диде ул. Шул ук чүпрәк эченнән шактый саргайган, бер чите караеп челтәрләнә башлаган язу кисәге төште. Анысын Шакир карт кычкырып укыды: «Җәмәгать! Бүген мәчетебезнең манарасын кисеп төшерделәр. Догалы китапларыбызны яндырдылар, муллаларыбызны

мәсхәрә иттеләр. Шушы Коръән китабын гына саклап кала алдык. Сез – киләсе буыннар, оныкларыбызның оныклары табып куаныр, дип өметләнәбез. Тапкан кешеләр аны кадерләп тотсыннар. Мөхәммәд пәйгамбәребездән килүче динебезне сакласыннар. Туганнар! Изге догадан аерылмагыз! Безне искә алып, рухларыбызга дога кылыгыз... Иман иманны чакыра – онытмагыз!.. Аллаһы Тәгалә ихтыярына тапшырдык, амин... Кендек авылы мөселманнары».

Җыелган халык тынсыз-өнсез калды. Барысы да бер үк уйны уйлый иде ахры: хәзергә кадәр Кендек авылында мәчет юк лабаса! Зөлфәткә дә тынгылык бирмәде бу уй, шунда ул ниятләп тә куйды: алтын тапса да, тапмаса да, барыбер бер мәчет салдырачак Кендектә!

Ул тимер тартманы Шакир картка сузды:

– Ак бабай, бу изге китап синдә торсын. Мәчет салдыргач, шунда куярбыз...

Басу читендәге тимер-томыр өеме янында аякларын бөкләп утырган Зөлфәтнең тавышы бик басынкы чыкты. Аның бу хәлен алтын табылмауга юрап, Шакир карт яланда борын гына төртә башлаган чирәмгә тезләнде:

– Борчылма, улым, алтын дигәннәре бер сөрүдә табылмаса, икенче, өченче сөрүдә чыга ул... Бер үз куенына алгач, туфрак тиз генә бирми шул андый затлы әйберләрне.

– Юк ла, мин аның өчен борчылмыйм. Чыкса – чыгар, чыкмаса... Баш бәласе түгел. Ак бабай, менә мин шулай уйлыйм: әллә, мин әйтәм, шушы изге Коръәнебезне табар өчен мәшәкатьләндекме без?

– Аның өчен дәдер. Әмма безнең бу эшебез иң элек бүгенге авылыбызга кирәк иде. Авыл бит ул басулардан, иген кырларыннан башлана. Басу бар икән – икмәк бар, икмәк бар икән – авылның тамагы тук, тормыш бөтен, кешеләр шат. Шулай түгелмени?!

– Шулай, нәкъ шулай. Аннары... Бу басулар – безнең өчен изге җир дә бит. Менә минем өчен... Мәрхүм әтием шушы басудан авырып кайтып җан биргән... Димәк, шушы басу өчен һәлак булган. Бүген күңелем шат минем, Ак бабай, менә шушы изге урынга җан өрдек ләса без. Әтинең рухы да шаттыр, дип уйлыйм.

Алар янына Җәмилә белән Гөләндәм килеп җитте. Зөлфәт торып басты. Кыенсыныбрак торган Гөләндәмгә карап, елмаеп куйды:

– Авыл хакимияте разыймы безнең эштән? Алтынын табып булмады, аның каравы, җир чәчүгә әзер!

– И шушы Зөлфәтне! Һаман төрттереп сөйләшә, әйт әле шуңа, Җәмилә апа, минем белән балаларча сөйләшмәсен...

Җәмилә Гөләндәмнең аркасыннан кагып куйды:

– И балалар, сез бит әле бик яшь, беренче тормыш сынауларын гына үтәсез. Көлегез... Көлешеп, шаярышып калыгыз, тормыш ул гел көлдереп тормаячак. Ә син, Зөлфәт, чынлап та, ипле генә сөйләш кызлар белән!.. – Аннары Шакир картка таба борылып өстәде: – Әйдәгез безгә, Шакир абзый, мин бүген күп итеп кыстыбый пешердем, чәй өстәле әзерләдем. Фәнилне, Мәхмүтне алыгыз да... әйдәгез. Гөләндәм, әйдә син дә, миңа булышырсың...

Беркем дә «бармыйм», дип тормады, шундук риза булдылар.

Өйдәге чәй өстәле озакка сузылды. Берничә сәгатьтән ул, аш өстәленә күчеп, Зөлфәт төзегән яңа агрофирманың тәүге киңәшмәсенә әверелде. Бу утырышта кайчан чәчүгә төшү, нинди орлык чәчү, чәчкечләр юнәтү, шул ук Мәмәт басуы читендә амбар төзү, янәшәсенә лапас кору, шунда ук кое казу, юл салу кебек мәсьәләләр хәл ителде.

Яннарында «авыл советы»ның булуы да ярап куйды. Аның белән уртакка хәл итәсе тагын бер мәсьәлә бар иде. Аны Зөлфәт үзе кузгатты:

– Гөләндәм, ничек уйлыйсың, тагын бер йөз илле гектар җир алсак, эшкәртә алырбыз микән?

Моңа кадәр бер сүз дәшми утырган Трактор Фәниленең «теле ачылды»:

– Зөлфәт туган, бу уңайдан мин ныклап әйтә алам. Элекке колхоз кырларында калган ватык тракторлардан тагын бер «ДТ-75», бер «Т-90» җыярга була. Механик үзебездә бар, – дип, ул Мәхмүт ягына ымлады. – Ә инде ике яки өч трактор булса, берничә басуга да өлгерергә мөмкин.

Ак бабайның да әйтер сүзе бар икән:

– Берәр ат та кирәк булыр, анысын үзем карармын. Печән җитәрлек бездә. Киләчәктә бераз солы да, клевер да чәчәрбез.

Гөләндәм дә акыллы фикер әйтте:

– Элекке колхоз таралгач, фермаларны күрше авылдан бер эшмәкәр үзенә алды. Артык үсеп, көчәеп китә алмаса да, безнең авыл кешеләренә эш биреп тора ул. Аның белән дә килешү төзергә кирәктер. Аңарда берничә «Беларусь» тракторы бар, диләр. Аңа – салам, орлык, ә ул безгә тракторлары белән булышыр... Ә җиргә килгәндә, анысын район белән киңәшләшербез, хуҗаларын ачыкларбыз... – Гөләндәмнең тагын бер сүзе калган икән әле: – Ак бабай, Зөлфәт, минем сезгә тагын бер үтенечем бар. Авыл советы бинасында бер буш бүлмә тора. Әйдәгез, шунда Кендек авылының музеен оештырабыз. Әнә бит – бер басудан гына да тау кадәр тарихи ядкарь җыелды. Юып, чистартып, матур итеп киштәләргә тезеп чыксак, шулар янына авылыбызның шәҗәрәсен, тарихын да язып куйсак, безнең яктан бер изге гамәл булыр иде...

Киңәшмәгә җыелган халык, бердәм баш кагып, Гөләндәмнең тәкъдимен хуплап куйды.

## 9

Чәчү уңышлы узды.

Чәчкечләрне элеккеге МТС чүплекләреннән табып юнәттеләр. Чәчүлек орлыкларын Шакир карт малае кайтарып бирде. Чәчүгә керер алдыннан Ак бабай ызанга «күкәй тәгәрәтте». Бу йола Кендек авылында бик борынгыдан килә. Уңыш мул булсын өчен шулай эшләнә ул. Кыр ияләренә корбан бирелә, аларны бәхилләп, яңа уңыш сезонын ачып җибәрәләр. Әлбәттә инде, Шакир картның догаларыннан башка бер зур эш тә башланмый авылда. Бу юлы да догалар укылды, салават әйтелде, мөнәҗәт җырланды...

Чәчеп кенә бетергәннәр иде, яңгырлар башланды... Шушы юеш чордан файдаланып, Зөлфәт Казанга чыгып китте.

Өендә булмаганга да бер айлап бар икән инде. Ләкин аны буш, салкын фатир каршы алды. Кием элгечләренең бушап калганын күрүгә, Зөлфәтнең йөрәгенә салкын йөгерде: Әлфия киткән. Шундук телефонга ябышты:

– Алло, Әлфия, синме бу? Син кая киттең? Әлфия!..

– Ачуланма, Зөлфәт, мин әниләргә күчтем. Шулай дөресрәк булыр. Бер-беребезгә кирәк чакта бергә идек, ә хәзер... Һәрберебезнең үз юлы яңадан башлана, шул гына.

– Нигә алай дисең? Мин бит сине...

– Яратам, дисеңме? Юк, яратмыйсың син мине. Мин дә сине язмышым итә алмыйм. Без яхшы дуслар, әмма сөйгән ярлар түгел...

– Сиңа нәрсә булды, Әлфия, мин сине танымыйм... Мин авылда...

– Авылда калам, дисеңме? Ләкин мин авылга кайта алмыйм. Авыл минем

өчен түгел. Ачуланма миңа бу сүзләрем өчен, фәннәр кандидаты булуым да, инглиз теле өйрәнеп, чит ил делегацияләре белән эш итүем дә авыл пычрагына батып яшәү өчен түгел иде... Мин сиңа яңа тормышыңда бәхет телим! Хуш, пока!

Зөлфәт телсез калды. Йөрәге чын-чынлап кысылып куйды, хәтта вакыт-вакыт туктап алгандай булды... Әлфия белән яшәгән бөтен тормышы күз алдыннан үтте. Начар, мәгънәсез түгел иде бу тормыш, анда рәхәте дә, михнәте дә җитәрлек иде, ләкин рәхәте, ләззәте барыбер күбрәктер.

Зөлфәт тоеп белә: Әлфия белән яшәлгән гомер – тормышының бер матур чоры, тик ул язмышның үзе түгел. Язмыш тойгысы ул башкачадыр, бәгырьләргә үтеп, бер мизгел дә тынгылык бирми торган тойгыдыр... Әйе, ул, бәхеттән бигрәк, авырлык, җаваплылык, үкенеч, тугрылык, кичерү... Язмышта табуга караганда югалтулар күбрәк. Югалтулар аша, сынаулар узып килгән бәхет кенә язмышка юрала... Менә Гөләндәм белән шундыйрак тарих килеп чыга... Тик бу язмышмы?

Зөлфәт авылына җиткәнче шул турыда уйлап кайтты. Шунда ук ниятләп куйды: шәһәрдәге фатирны сатарга да авылдагы нигезне ныгытырга. Бу чит ил машинасын да авыл өчен җайлырак машинага алыштырырга... Мәмәт басуында эшли башлаган агрофирманы күтәрергә, алдагы ике-өч елга акыллы планнар корырга, авыл кешеләренә эш бирергә, мәчет салырга, клубны торгызырга, мәктәп белән элемтәне яңартырга...

Өйгә кайтып керүгә, Җәмилә аны кире борып чыгарып җибәрде:

– Бар, анда бер малай көтә сине. Күркә Фатыйхасының уртанчы улына охшаган. Теге вакытта Мәрьям карчык әйтеп киткән малай түгел микән?

Зөлфәт җилкә сикертеп кенә куйды да урамга чыкты. Шакир карт ягындагы бүрәнәләр өстендә бер малай утыра. Зөлфәт малайны мышык-мышык борын тартуыннан ук танып алды.

– Мине эзләдеңме?

– Зөлфәт абый синме?

– Мин.

– Алайса сине эзләдем.

– Нигә кирәк булдым инде мин сиңа?

– Мин теге алтынны күрсәтергә килдем.

– Нинди алтынны?

– Басудан тапкан алтынны.

– Күрсәт соң.

– Юк ул, мин тапкан әйбер алтын түгел...

– Син каян беләсең аның алтын түгеллеген?

– Әти тикшертеп кайтты.

– Алтын да булмагач, нигә килдең инде?

– Әйтергә килдем. Юкка эзләмә, дип...

– Ну, әйттең, бар, кайт инде...

– Күрәсең килмимени?

– Алтын түгел, дидең бит.

– Тапкан әйберне күрәсең килмимени, дим. Менә ул...

Зөлфәт малай янына якынрак килде. Аның учында яткан җиз калай кисәген үрелеп карады. Кызыксынудан түгел, күбрәк малайның күңеле булсын өченгә.

– Килүеӊ, кисәтүеӊ өчен рәхмәт, кем дип әйтим?..

– Мөнир булам мин.

– Рәхмәт, Мөнир. Инде моннан соң, алтын таптым, дип, кеше башын бутап йөрмә, яме?

– Ярар, абый...

Малай китте. Зөлфәт үзенең язмыш гаме белән торып калды. Бүген аны алтын белән бәйләп торган соңгы өмет җебе өзелде. Ул җеп болай да нечкә генә калган иде, өзелер-өзелмәс кенә тора иде...

– Кыен булып калдымы? – Шакир карт капка төбенә чыгып утырган икән. – Алтыннан колак кагу кыенмы?

– Кыен булса да, баш бәласе түгел. Үз күңелемне үзем үсендердем, үзем үк аны, үгетләп, кешелегенә кайтардым...

– Бу яклап чын егет булып чыктың, Зөлфәт улым. Авыл гаменә бик тиз кердең син. Димәк, рухың авылны сагынган...

– Рәхмәт, Ак бабай, син булмасаң, авылдашлардан башка, мин үзем генә нишләр идем?!

– Юк, улым, иң элек без – Кендек авылы кешеләре – сиңа олы рәхмәтләребезне белдерергә тиешбез. Безне асылыбызга, хәтта, әйтер идем, иманыбызга кайтардың син. Җан тәслим кылам дип торган җиребезгә, басуларыбызга кабат рух өрдең, гомер бирдең... Синең үҗәтлек белән эшләнде бу эшләр. Ә алтын... Алтын боларның барысы өчен бер сәбәп кенә булган. Ым-ишарә генә, Ходайның бер хикмәтле сынавы гына...

Бу көнне алар бик озак сөйләштеләр. Караңгы төште, авыл ут алды. Зөлфәтләр урамыннан күренеп торган авыл советы йортында да ут сүнде. Димәк, Гөләндәм өенә кайтырга чыкты. Зөлфәт, күрше карты белән тиз-тиз генә саубуллашты да шул якка китеп барды. Бер аягы белән ахирәт чигенә баскан Шакир карт үзалдына әйтеп куйды: «Бәхетләре генә булсын, бәхетләре генә... Бәхетнең авыры да ярый, авыр нәрсә «өф» иткәнгә генә очып китми ул...»

**10**

Менә кайда ул алтын! Менә кайда ул күз явын алырлык байлык!

Алтынга манчылып, күпереп уңган бодай басуы буйлап икәү атлый. Кемнәр икәнен укучы аңлап алгандыр. Әлбәттә инде, Зөлфәт белән Гөләндәм. Икесенең дә шатлыклары эчләренә сыймый. Алтынга чумып утырган иген басуларын күреп шатланалар дип уйлыйсызмы? Алай гына микән? Бу мәл – аларның бер-берсенә йөрәкләрен ачкан мәл. Аларның күңеле саф бүген, саф мәхәббәт кебек, чын хакыйкать кебек, илаһи иман яисә ихлас тугрылык кебек...

Мәмәт тавы буйлап икәү атлый. Кайдадыр кемдер чалгы кайрый, кемдер, чыбыркы шартлата-шартлата, көтү көтә, кемдер, бишек җыры җырлый-җырлый, бала имезә, мәчет ягыннан – азан авазы, мәктәп ягыннан балалар тавышы яңгырап тора, кайдадыр трактор гөрелтесе ишетелеп кала, аны ат кешнәве күмеп китә... Бер читтә, сабын күбеге белән ышкый-ышкый, ах-ух килеп, итче Замир Зөлфәттән очсызга гына сатып алган затлы машинасын юа... Авыл яши, тормыш көтә...

Бу минутта инде Мәмәт тавыннан «табылган» алтын хакында кешеләр онытткан, онытмаганнарның искә дә аласылары килми... Яңа мәчеткә җомга намазына барганда гына, кайберәүләр Мәмәт тавына күтәрелеп карыйлар. Әмма шундук, «алтын тарихы» исләренә төшеп, башларын түбән ияләр.



Фәнил
Гыйләҗев

# ЕФӘК ЮЛЫ ЧАТЫНДА

***(Төркестан дәфтәреннән)***

*2014 ел җәендә Көньяк Казакъстанның Казыгурт тавында Бөтендөнья төрки халыклары Ассамблеясенең корылтае узды. 2017 елны ТЮРКСОЙ тарафыннан Төркестан шәһәре Төрки мәдәниятнең башкаласы буларак билгеләнде. Төркестан элек Урта Азия җирләренең гомуми атамасы булган.*

**I**

Казакъ даласы. Тирмәдә ятам төш күреп:
Ат көтүе йөри утлап, кешнәп-пошкырып.

Ефәк юлының чатында Төркестан күге.
Бу туфраклар әйтерсең лә җәннәтнең үзе.

Алда җәйрәп ята дала, бәрхет – чирәме.
Казан аса шомырт күзле дала чибәре.

Башактай тигез үрелгән чем-кара толым
Иген кырыдай тирбәлә алганда тынын.

Игез тауга тиң түшенә береккән күзем,
«Жаксыкүрәм!» дияр идем, оялам үзем.

Думбра итеп чиртә, каһәр, күңел кылларын,
Касәсенә кымыз салып суза кулларын.

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ (1987) – *шагыйрь; «Ризасызлык» исемле китап авторы. Казанда яши.*

(Кымыз, кортны ризык иткән карын тук була.
Егет дигән атың барда, җаның ут була.)

Дала җиле. Кымыз тәме. Карагат күзләр...
...Сәгадәтле бу мизгелдә кирәкми сүзләр.

***

Казакъ даласы. Юлчылар уянган төшкә
Казанда өр-яңа суйган куй ите пешә.

Чатыр-чотыр яна учак. Оча кузлары.
Аш хәстәрли көләч йөзле дала кызлары.

Карашлары очкан уктай җанга кадала,
Куй итедәй кайный хисләр төрки далада.

***

Ә кайчандыр бу җирләрдә базар кайнаган.
Шунда ханнар кәнизәк вә хатын сайлаган.

Алган, саткан, тәкъдим иткән, алмашкан малын,
«Гәпләшергә шәп урын!» – дип, көйләгән ялын.

Кырык чакрым саен булган кәрвансарае –
Тукталган да хәл өстәгән ярлысы, бае...

Фәлсәфәче әл-Фараби трактатын язган,
Монда көмеш тәңкә суккан Карахан каһан...

***

...Чыңгызхан атлары утлап йөргән бу җирдә.
Ә гарәпләр шул сукмактан юл салган дингә.

Шәех Әхмәт Ясәвинең, Арслан бабаның
Төрбәсен зиярәт итә бар төрки кавем!

«Дивани-хикмәт»ләр язган суфый әүлия
Йөз җитмешләп силсиләи иҗазга ия.

Ул – рисалә иҗат иткән шагыйрь затыннан,
«Хуҗа» дигән исем алган коеп алтыннан.

***

...Нух пәйгамбәр үзе, имеш, Шимкент янында,
Бер куышка имза куйган, Казгурт тавында.

Нух көймәсе, имеш, монда комга терәлгән,
Һәм җир буйлап төркиләрнең нәселе таралган.

...Тамырларыбыз тарихы ансыз да атлы.
Риваяти бу фикер дә яшәргә хаклы.

***

Бу туфракта күпме төрки кардәш кавемнәр,
Чатыр корып, казан аскан – шаһит каберләр.

Ватаннарыннан сөрелмеш мөһаҗирләрне,
Качакларны сыендырган яшьле җирләр бу.

Төрбә, мазарлар алдашмас. Байтак татарлар
Бу тарафта насыйп ризык, бәхет тапканнар.

Шул туфракны сугарганнар, мәгърифәт чәчеп,
Йә булмаса сәүдә белән иткәннәр кәсеп.

Яңа тормыш башлап, бире нигез корганнар,
Шул туфракны ашлаганнар – шаһит курганнар...

**II**

Тарих атамалар тагып бүлсә дә йөзгә,
Бабамнар юл салган чатта күрештек без дә.

Бавырыбыз Ерментай бәк кунакка дәште,
«Ядкарьханә ачыгыз!» – дип, туфрак өләште.

Барча төрки кавемнәргә бүлде тигезләп,
«ТУРАН шәһәрчеге бу!» – дип, сүзен нигезләп.

Үз әләмен кагу өчен барлык ир-ат та
Шобага тартты, тезелеп басты чиратка.

Аннан һәркем сөйләп бирде милли моң-зарын,
Яңгырады төрле бурыч-тәкъдимнәр тагын...

***

Өстәгеләр җир ызанын уртак биләмнән
Безнең төрки кавемнәргә тигез бүлмәгән.

Чит-ятларның өлешенә тигән бихисап,
Безләрне санламаган шул никтер җанисәп...

Берәүләрне ил дошманы – сөрген иткәннәр,
Икенчеләр – нигез ташлап, качып киткәннәр...

Дәүләтен җуйган адәмнең юк хокук-хакы! –
Терсәкне булмый ла тешләп, булса да якын.

Бик күпләрне катнаш никах йоткан упкынга,
Һәм бик күпләр чит дәүләттә гүя тоткыннар...

Илбасар хөкем ителми, җиңүче – хаклы!
Ирекне тик яулап була, ирек – кан хакы!

Куй хәлендә бүген күпме бүре нәселе.
Бу фаҗига кем гаебе? Кемнәр мәкере?..

***

...Төрки халыклар җыены узмый моң-зарсыз.
Дәшти-Кыпчак далалары сыкрый ТУРАНсыз.

Бар җиһанны тезләндереп, дөнья тетрәткән
Бүрелек качкан, җуелган төрки йөрәктән.

Изге урын буш тормавы – мәгълүм хакыйкать.
Кулга ияләнгән бүре – бүре түгел, эт!

Эт нәселе – хуҗасының иң тугры колы,
Ул тугрылык, хакыйкатьтә, маңкортлык юлы!

...Казгурт тавында, җыенда беркетмә төзеп,
Бурыч-тәкъдимнәрне барлап, куйдылар тезеп.

**III**

Киез тирмәләр эченнән таңга чыктык без,
Дала туфрагын тетрәтеп бәйрәм иттек без.

Әфсенле җыр-моңнан җанда учак кабынды,
Тылмачсыз да аңлашырдай сүзләр табылды.

Бер казаннан авыз иттек уртак тәгамне,
Бер йодрыкка төйнәдек без төрки галәмне.

Кан берлеген, җан берлеген тойдык, таныдык:
– Тамырыбыз – Ашинадан, безнең тамыр нык!

***

Чатыр-чотыр яна учак, оча кузлары.
Камнар дөңгер кага, бии дала кызлары.

Канны кайната бу халәт, камчылый җанны.
Дөңгер моңы, кубыз тыны томалый аңны.

Ат көтүе җилдергәндәй, киң дала буйлап,
Тарих көлендә казына мәҗүси уйлар.

...Ефәк юлының чатында Төркестан күге!
Бу туфраклар әйтерсең лә җәннәтнең үзе.

# ФӘНИЛ ГЫЙЛӘҖЕВ. ШИГЪРИЯТ

Фәнил Гыйләҗевның «Төркестан дәфтәреннән» дип аңлатма куелган «Ефәк юл чатында» әсәре, исемен укыгач ук, Һ.Такташның «Төркестан сахраларында»сы, Х.Туфанның бу якларга багышланган шигырьләрен искә төшерә. Әлеге матур, мәҗүси хәтерне уята торган, серле-шигъриятле яклар күпме шигъри илһамнарга канат биргән. Исемдәге бер-берсен кабатлап һәм тулыландырып килгән «Ефәк юлы» һәм «Төркестан», аннан соң ук шигырь тууның фактик җирлеген ачыклаган эпиграф (бу эпиграфта бүгенге вакыйгалар һәм Төркестанның тарихи үткәне тоташа) текстны кабул итү юнәлешен билгели. Шушы тәэсирне аның 13/13 вәзенендәге һәр тезмәсе рифмалаша торган бәет итеп язылуы тагын да көчәйтә.

Текст өч бүлеккә бүленгән. Беренчесендә – дала, Төркестан тарихы турында сөйләү, икенчесендә – шушы җирдә төрки халыкларның очрашуы турында бәян итү, өченчесе кардәш халыкларның бердәмлек нигезен барлау белән тәгәлләнә. Әсәр поэма яки шигъри цикл таләпләренә җавап бирми – ул татар шигърияте өчен жанр яссылыгында эзләнүләрнең бер чагылышы: күп кенә төрки халыкларда бүгенге көнгә кадәр сакланып килгән, әмма татарларда китап культурасы, китаби дастаннар бик иртә кысрыклап чыгарган чичәнлек традицияләрендә язылган. Төгәлләштереп, «чичән текстларга охшатып стильләштерелгән озын шигырь», дияргә була, шул мәгънәне күздә тотып, «көйләү шигыре», дип атарга да мөмкин. Әлеге традиция текстка шәркый борынгылык тәмен бирә.

Текстның укучы өчен гадәти булмаган яклары да шушы сыйфат – үзгә традициягә йөз тоту белән бәйләнгән. Чичән шагыйрь күзенә күренгән, кичергән һәрнәрсә турында ашыкмыйча һәм башкалар да күзалларлык образлы итеп көйли. Биредә дә шулай. Поэмадагы яки циклдагы һәр аерылып торган өлештән үзгә фикер белергә күнеккән татар укучысына әлеге зур-зур шигъри кисәкләрдә, тирә-юньдәге күңелгә хуш картинаны сурәтләүдән тыш, фикер (без, бигрәк тә, фәлсәфи яки иҗтимагый фикер яратабыз) әйтелмәү сәер тоела башлый. Әмма чичәнлек традициясе өчен бу табигый.

Шул ук вакытта чичәнлек көйнең бик төгәл булу таләбен куя. 13/13 үлчәменең көен текст буенча цезураларның 8+5 булып урнашуы тәэмин итә. Бу – чичән шагыйрьләр өчен традицион вәзен. Әмма текстның иң беренче юлындагы 5+8-не үзгәртәсе, бу матур әсәрнең музыкасын торгызасы килә. Образларга бик сизгер, яңалык шулар хисабына туа торган чичәнлекне саклаганда, уңышсыз «өр-яңа суйган», «куй итедәй кайный хисләр» кебек сурәтләрне, һәр бәетендә диярлек җырлап торган рифмалар тапкан авторның «терәлгән-таралган» рифмасын да алыштырырга кирәк булгандыр.

Эчтәлек ягына килсәк, шигъри әсәр дә, хәтта чичән шигырь дә фикернең, мөнәсәбәтнең аныклыгын таләп итә. Аерым бер өлешләрдә шушы аныклык җитми. Мәсәлән, татарларның бу тарафларга күчүе, ризык табу турындагы беренче бүлекне йомгаклаган бүлекчәдә соңгы, иң мөһим строфадагы «Шул туфракны ашлаганнар – шаһит курганнар» дигән тезмә нинди мөнәсәбәтне белдерә – үкенечме, сызлanумы, горурланумы, әллә шатлык укмы? Моңа төгәл җавап биреп булмый.

Гомумән, стильләштерү кулланылганда да, автор-шагыйрьнең фикерләре үткәзеп җиткерелү мөһим. Икенче бүлектә бу күренә дә. Әйтик, төркиләрнең үз җирләрен югалтуы сәбәпләрен барлау: сөрелү, дәүләтчелекне җую, катнаш никахлар һ.б. турындагы өлешләр дә, төркиләр тарихының иң борынгы легендасы бүре турындагы тарихны уйнату да матур тәэсир калдыра. Әмма көчле позициягә – исемгә чыгарылган Ефәк юлын да, башка образларны да уйнату мөмкинлеге игътибарга алынмаган.

Өченче бүлектә дә шундый гомумиләштерелгән фикер әйтү омтылышы ясала: Без – бер тамырдан, моны үткәнебезнең, җыр-моңыбызның, уй-фикерләребезнең бер булуы раслый, дию матур яңгырый. Әмма шактый күләмле заман әсәре өчен бу гына аз: аның мәгънәви ягын тагын да тирәнәйтәсе, шушы фикри энҗеләрне дә эзләп укырлык әсәр буларак күрәсе килә.

Шулай итеп, журналның әлеге санында Ф.Гыйләҗевның шигъри аһәңе төзек-камил, тәэсирле, укыла торган, күчмәннәрнең чичәнлек традицияләрендә иҗат ителгән көйләү шигыре тәкъдим ителә. Ул татар әдәбиятының эзләнүләр юлында булуы, тәҗрибәләрне чит күрмәве хакында сөйли. Без дә яшь шагыйрьгә үсү-камилләшү мөмкинлекләрен күрсәтергә тырыштык.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Фатыйма Гыйльметдинова

# ХИКӘЯЛӘР

## Сабыным кала, сатыгыз…

Килә дә җитә икән ул… Сорап та, кисәтеп тә тормый, килә дә җитә икән. Көч-куәтең ташып торганда, болай булырмын дип уеңа да керми. Картлык ул әнә тегеңә генә килә торган хәл, сиңа килмәс, бу чәчләрең бер дә агармас та, бу күзләреңнең нуры бер дә кимемәс, кулыңнан эш төшмәс кебек. Башта ул, җәй уртасында шау яшел агачка ялгыш килеп эләккән бер бөртек сары яфрак кебек, үзен җайлап кына сиздерә. Монсы әле көз түгел, җәй алда әле дип үзеңне юатырга, күңелеңне төшермәскә әллә күпме сәбәп табып була. Ә агачың шау сарыга сабышса, яфракларын коеп, бөтенләй шыр ялангач калса…

Мәһинур да бирешә. Бирешмәскә тырышса да бирешә. Эшләгән эшләреңне синең арттан төзәтеп яңадан эшләсәләр, син ябып бетермәгән ишекне шапылдатып ябып куйсалар, читтә яшәгән балаларыңда кунак булу элекке кебек санаулы ике-өч көн генә түгел, айлар буена сузылса, картайдың дигән сүз инде. Мәһинур да кызында айлар буе тора башлады. Килененең чиләкләре ишек яңагына ешрак бәрелә, табак-савыты ныграк шалтырый башласа, көт тә тор, кияве белән кызы Гадилә аны кунакка алып китәчәк. Ялындырып тормый, алырга килгәннәренә сөенеп, төенчекләрен төйни дә, утыра да китә кортка.

– Бер тыңламый, үзенчә тик йөри. Кичә әнә пешер-пешмәс карагатларымны вич җыйган да кергән. Болай да барлы-юклы гына иде быел. Аннан, чүп утыйм дип, бөтен бөтнегемне йолкып бетергән, чаклар гына тамыр алдырып үсә башлаганые! Кушсаң эшләмәс иде әле! Ничә кереп ничә чыга торгандыр, киләпне сарыпмы-сара инде, ишекләр генә чыдасын. Ул чебен тула! Инде өстенә кунып кына керәләр. Кергән саен бер эскерт чебен! Аларны үтерә-үтерә стена-түшәмнең карарлыгы да калмады. Юдың ни дә юмадың ни – адин чурт!

Киленнең болай тузынуына каршы кайтарып бер сүз әйтә алмый Гадилә. Ут белән ялкын арасында тора да кала. Башка кызлар кебек, әнкәсе белән серләрен бүлешеп, аннан киңәшләр сорап, сөйләшеп-чөкердәшеп үсә алмады Гадилә. Таң сарысы белән эшкә китеп, күз бәйләнгәч кенә кайтканга, аны өйдә бик сирәк күрә иде ул. Йорттагы бар эшне энекәше белән башкаралар. Әткәләре,

---

Фатыйма ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА (1961) – *язучы; «Мәктәбем, укытучым», «Сипкелле малай» китаплары авторы. Башкортстанның Борай районы Искебикмәт авылында яши.*

мәрхүм, сугышта башын тиштереп, аягын өздереп кенә калмыйча, бик нык эчәргә дә өйрәнеп кайткан, дөньясын онытып, атналар буе йөзеп эчә торган гадәте дә бар иде. Андый чакларда өйләре шыксызлана, тәмәке катыш аракы исе күңелне болгата, исерек әткәсенең сүгенүе үзәкләренә үтә. Өйгә керергә куркып, әнкәләренең эштән кайтканын көтеп гарык булалар. Ул кайткач, дөньяны җилләтеп, өйне тәртипкә китерәләр, әткәләрен уятмаска тырышып, аяк очында гына йөреп ашарга әзерлиләр, пыш-пыш кына сөйләшеп, кичке ашны ашыйлар. Дөнья ямьләнеп, күңелләре көрәеп китә.

Урынны ишек төбенә җәяләр. Әткәләре төнлә уянып тавышлана башласа, чыгып йөгерергә җайлы булсын дип, киемнәрен салмый йоклыйлар иде. Шулай да кышкы суык төннәрдә пимасыз чыгып йөгергән чаклары да булды (пима киеп ятып булмый бит!). Абзар артында суыктан куырылып, саламга оекчан басып, тешләрен шыкылдатып торсалар торалар, әнкәсе кешегә алып керми иде. Гаиләдәге мондый чакларны башкаларга сиздерәсе килмәде күрәсең. Үсә төшкәч, инде үзләрен якларлык була башлагач та, каршы дәштермәде:

– Әтәңә, нинди булса да, сүз әйтмәң, соңнан кыен булыр үзегезгә. Начар кеше түгел ул. Әтәй-инәй хакы бар, – дип туктата торган иде. – Бигрәк яшьли, буыннары ныгып та бетмәс борын, сугышка илтеп ташладылар… Аның күргәннәрен без белмибез бит…

И, гомерләр! Әткәләренең гүр иясе булганына да утыз еллап вакыт үткән икән инде. И-и еладылар әткәләре кинәт кенә үлеп киткәч. Ярый әле исән чагында авыз ачып каршы сүз әйтмәгәннәр! И үкенерләр иде! Бактисәң, ул да гел эчеп-тузынып кына ятмаган икән бит. Чирләреннән ыңгыраша-ыңгыраша, аксаклап булса да, өен җиткезгән, абзар, мунчасын салып куйган, ишегалдына кое казыган. Ат асрый иде ул, ат ярата иде. Атлары да хуҗасына тугры була торганнар иде. Бигрәк тә Күгәрчен кушаматлы атлары исендә Гадиләнең. Әткәсе нинди генә хәлдә булмасын, капка төбенә алып кайтып җиткезә мәхлук. Капканы озаграк ачмый торсаң, авылны дер селкетеп кешнәп җибәрә. Алар, кемузардан йөгерешеп, капка ачарга чабалар. Ат тугарырга-җигәргә дә өйрәнделәр. Өйрәнмичә, кая барасың, эткәй исерек дип, атны төн буе тәртә арасында тотып булмый бит инде.

Күрше-күлән печән-утын ташырга алып торсалар, атның гадәтен беләләр: дилбегә кем кулында булса да, ул кая гына каерса да, төялгән йөген гел үзләренең капка төбенә алып кайта Күгәрчен. Кешнәп, мин кайттым, нишлим, дигәндәй тавыш бирә. Әткәсе, ул булмаганда, Гадилә белән энекәше, атны авызлыгыннан җитәкләп, тиешле капка төбенә илтеп куялар.

Ә ат арбасына утырып болынга барулар! Хуш исле печән өсләрендә чәчкәгә күмелеп кайтулар! Юлның таш юлга килеп менгән урынында әткәләре, атны туктатып, Гадиләләрне йөк башыннан күтәреп ала, атны юлга мендереп куйгач, күтәреп кире утырта. Кытыршы яңакларын юри битләренә тидереп, кытыклатып та ала. Әй болар шырык-шырык көлешәләр! И-и, рәхәт чаклар!..

…Бу юлы бик озак кунак булды Маһинур кызында. Элекке кебек, «өйрәнгән яу сугышырга яхшы», дип, кайту ягына каерып тормады.

Көн дә сөйли торган сүзләре азайган, орчык хәтле генә калган гәүдәсе бик салмак хәрәкәтләнә, элеккечә җилкенеп эшкә дә тотынмый, артык күп сорашмый да ул хәзер. Исән булганына сөенеп, көне буе рәхмәт укып, тазалык-саулык теләп кенә йөри. Шулай да Гадиләнең күңеленә ярамаган бер гадәте бар: кырында кем барын да уйлап тормыйча, һич килешмәгәнне, кычкырып җырлап җибәрә. Картайганда тыртайган дигәндәй, олы кешегә авыз күтәреп җырлап

йөрү бөтенләй килешми. Менә кайчан кирәк икән намазга тезләнүләр! Моны, түзми, әнкәсенә әйтә. Тегесе тулысынча кызы белән килешә, аның шулай уйлый белгәненә сөенә, ләкин ике-өч минуттан тагын онытылып такмаклап җибәрә:

Сабыным кала, сатыгыз…
Җәйгән урыннарым кала,
Сагынганда ятыгыз…

Дини китаплар, дисбе, мәчеткә йөрүче корткалар гына бәйли торган матур яулыклар алып кайтты беркөн Гадилә. Укы, өйрән, болай такмаклап йөргәнче, Аллаһ сүзен сөйләп йөре, дип, үзенә күрә бик каты гына битәрләп тә алды.

– Әбигә сүз әйтмә, аның иманы үзендә, кычкырып табынмаса да, Аллаһны ачуландырырлык эш-гамәле юк, – дип, әбисен гел яклап торган иренә дә эләкте. Ә Маһинур карчык, кызының тузынып бетүен сабыр гына көтеп торды да, тагын җырлап җибәрде:

Берсен кисәргә кирәк,
Берсен киссәң ялгыз кала,
Ялгыз нишләргә кирәк…

Колагына элде ди менә, көт… Иренә рәхмәт инде, кортканың нинди чагы булуга карамастан, аны олылап, хөрмәт итеп карый. Булган хәлләрне көлкегә борып, Гадиләнең ачуларын сыеклата, сүзне икенчегә борып җибәрә белә.

Әткәсе исән булса, болай каңгырып йөрмәс иде дә бит… Яшәп ятырлар иде икесе чөкердәшеп – җырлашып… Сүз әйтүче дә булмас иде…

Кияве генә түгел, авылда аралашып кереп-чыгып йөргән күршеләре дә үз итә Маһинурны. Үз авылдашлары кебек, килгән саен аны ашка дәшәләр, янына кич утырырга керәләр, хәер-сәдакасын кертеп кенә торалар. Гадилә генә әнисенең «кич юынып урынга яткач укыйм мин», – дип, хәерне алып калуына бер дә риза булып бетми: әллә укый, әллә юк, кем белсен…

Бу юлы Коръән ашына әнкәсе белән бергә Гадиләне дә дәштеләр. Барырга да, бармаска да белми аптырады. Бердән, әнкәсен тиргәгән була, үзе дә амин тотудан башка бер дога да белми, хәзер Коръәнле табында ни йөз белән утырмак кирәк, икенчедән, әнкәсенә бер ышаныч та юк: табын уртасында такмагын җырлап җибәрсә…

Табын мул әзерләнгән иде. Хәерне дә мулдан өләштеләр. Ләкин авыл мулласы тагын бер табынга чакырулы икән, шулпа эчү белән, шунда ашыкты. Мулла белән абыстай чыгып киткәч, табын үги баладай моңаеп калгандай булды. Хуҗалар да нишләргә белми утыра бирделәр. Шулчак арадан берәү:

– Табынны тәмамларга иде, җәмәгать, тәмамланып бетмәде бу, – дип куйды. Барысы да шул уйда булган күрәсең, җанланып китеп, шыбырдашып сөйләшеп алдылар. Хуҗабикә, сикереп торып, ашны яңартты, өстәлгә әле чыгып өлгермәгән карбыз, кавыннарны тезде.

– …Рөхсәт итсәгез… – Гадилә дерт итеп китте: ни эшләргә җыена икән әнкәсе!

Ә Маһинур карчык тамак кыргалап алды да, башын иеп, күзен тез башында яткан кулларына төбәп, мәкам белән көйләп укый башлады. Табындагылар, яңгырдан соң чыккан кояшка тиенгәндәй, изрәп китеп, тын калдылар. И укыды әнкәсе! Гадилә һушын җыя алмый, ул укып бетергәнче, эссе табада утыргандай утырды: җырып чыгалса гына ярар иде, ялгышмаса гына ярар иде! Ялгышмады. Гадиләне шаккатырып, яңадан сорап укытканда да, бер ялгышмый әллә күпме укыды. Алай гына да түгел, хәер таратканнарның һәрберсенә аерым-аерым, ата-бабаларының, нәсел-нәсәбенең исем шәрифләрен атап, дога кылды.

– Мин укыганда, энә өстендә утырдың инде, – дип кеткелдәде Маһинур кайтканда, – кыз бала шулай шул, инәй өчен кызара, аның гөнаһларын, килешсез гамәлләрен үзенеке итеп карый, аның өчен кыенсына. Шуңа да кортка кеше килене белән яшәргә тиеш. «Киявең куса – ишек бавын тот, малаең куса – бишек бавын тот», дип юри әйтмәгәннәр.

– Аптыраттың әле син мине, әни…

– Бабаң калхузга кермәгән өчен күрмәгәннәр калмады инде, балам. Башта бөтен мал-мөлкәтне пыран-заран китерделәр, муллалык итүен тыйдылар, хәерчегә калдык. Әткәй белән инәй төнлә кайтып керәләр иде, хәер сорашып. Аннан әткәйне кыйнап эштән чыгардылар. Мәчетнең аен кисеп, әткәйгә китереп ташладылар, мә, кабереңә кадарсың, дип. Ике сеңлем, бер энекәш ачтан үлде. Аптырап, үзләре карый алмагач, абзыкай белән мине асрауга биреп тордылар. Гайшә әбидә бер ел тордык. Шул өйрәтте безне. Бик мактый иде, тиз отасыз, дип. Шулар бар да истә… Әткәй, мәрхүм, калхузга кермәс өчен җанын бирде, мин гомер буе шул калхузга бил бөктем. Кая инде анда дин тоту! Ашагач әппәр әйтеп битне сыпырганга да, мыскыл итеп гәзиткә төшерәләр иде. Шуңа да шәригать эшләре качып-посып өйрәнелде инде. Әле дә үстегез инде, балакаем. Сезне күрми дә идем бит. Аллаһы Тәгаләгә ялваруларым бушка китмәгәндер. Аллага шөкерсез бит! Кияүкәем менә дигән, киленем үз кызым кебек, миңа тагын ни кирәк! Сөенеп сезгә киләм, сөенеп кайтып китәм.

Чынлап, сөенеп килде, сөенеп кайтып китте Маһинур бу юлы да кызыннан. Хәтер калмак бер калҗа, хәтер тапмак мең калҗа, дисәләр дә, картлыгына Ходай таман гына китереп биргән онытa торган гадәте аны артык күңел кителүләрдән курчалый, начар уйлап өйрәнмәгән изге күңеле бары тик күңелле хәлләрне генә исендә тота иде. Кайтырга чыккач, кызының җырлап йөргәне өчен ачуланганнарын онытып, тагын җырлап җибәрде:

– Сабыным кала, сатыгыз… Җәйгән урыннарым кала, сагынганда ятыгыз...

Озатып кергәч, әнкәсенең җыелмыйча калган ятагына күзе төшеп сискәнеп китте Гадилә…

Кадерле кешесенең җылысы бөркеп торган мендәренә башын терәп:

– Исәнлектә очрашырга язсын, тагын кунак булып кил, әни… – дип пышылдады.

## Иң кирәге...

– Юлай, кер улым, малларны карарга вакыт!

И шушы әтисе, уенның иң кызган чагында гына чакыра бит. Иң керәсе килми торган чагында! Хәер, кайчан уеннан үз теләгең белән керәсең инде?! Әти эндәшкәнне ишетмәгән булып, бераз уйнасаң да булыр иде дә соң. Әнә Харис, «Ашарга кер!» дип әнисе чакыргач, уйлап та бирми, иркәләнеп кенә «Ю-у-ук», дип куя да уйнавын белә. Юлайга алай ярамый. Дөньяны әтисе белән генә көтәләр бит алар. Харисныкы кебек «инәй әзере» юк. Харис урынында булса-а! Әнисе чыгып эндәшүгә, юк, эндәшмәс борын – капкадан күренү белән, чабып кереп китәр иде өйгә. Әнисе яныннан үткәндә, юри әкренәер иде, әнисе шул арада аның башыннан сыйпар йә аркасыннан сөеп өлгерер иде.

– Улым, тиз бул! Син печән төшерә тор, мин чөгендер алып чыгам. Баскычы шуып китмәсен, әйбәтләп терәп куй. Соңыннан сәндерә ишеген ябарга онытма!

Боларны әтисе көн дә әйтә. Юлайның шулай эшлисен белсә дә, әйтә.

Хәзер менә сыерны саварга кирәк. И-и, ул әтисе сыер сава башласа, үзе бер

мәрәкә. Сөт чажлап йә бидрә читенә сиптерә, йә әтисенең беләге буйлап җиңенә тула. Икенче яктан имәргә маташкан бозауның күзенә, танау тишекләренә чәчри.

Кулы зур әтисенең. Шул мишәйт итә. Ә Юлайныкы бәләкәйрәк әле. Сыерны дөрес итеп, туры бидрәгә төшәрлек итеп савар өчен, уртача кул кирәк. Әнисенең кулы әйбәт булыр иде. Артып та китмәс иде, җитми дә калмас иде.

Юлай әнисенең кулын күз алдына китерергә тырышты. Укытучысы Сәлимә Галимовнаныкы кебегрәктер ул. Кулы да кулы инде! Йоп-йомшак. Кулыңнан тотып яздыра башласа, кулың эри инде менә. Хәрефләр дә матуррак чыга, дөресрәк ята башлый. Валлаһи шулай!

Әнисенең йөзен дә, гәүдәсен дә нәкъ Сәлимә Галимовнаныкы кебек күз алдына китерә Юлай. Беркөн бу хакта әтисенә дә чишелде әле. Әтисе башта югалып калды, бераз эндәшми торгач:

– Әниең сары чәчле, – дип куйды.

И-и, эш чәчнең нинди төстә булуындамыни!

– Мә, улым, сөтне алып кер. Актүшкә салырга онытма.

Актүш тә, Иркәбикә дә яраталар җылы сөтне. Алардан да бигрәк Юлай ярата.

– Әллә нәрсәләр пешереп ашата да алмыйм, улым, сөтне эч син аны, көч кертә ул, тешләрне ныгыта, – ди әтисе.

Әллә нәрсәләр пешереп ашаталмаса ни, аның өчен әтисенә чак кына да ачуланмый. Ач утырмыйлар әле. Кичкелеккә итле аш пешерәләр, көндезгә – бәрәңге. Тагын нәрсә кирәк?

Әнисе булса, ниләр пешерер иде икән? Харис, әнә, көн дә сумкасына бәлеш кисәге, пәрәмәчтер салып килә. Әнисе булса-а, аның ише генә дә пешермәс иде әле.

И-и, онытып та бетергән! Сәлимә Галимовна аларга, кемгә нинди кием бик нык кирәк, эти-әниегез белән киңәшләшеп, белеп килегез, дип әйткән иде бит.

– Әти, миңа нинди кием бик кирәк ул? Сәлимә Галимовна белеп килергә кушты. Исемлеген төзеп куярга кушканнар ди. Соңыннан шул исемлек буенча өләшәләрдер инде, әйеме, әти?

Әтисе кире чыгып та киткән икән, бозауны аерыргадыр. Юлай да, тиз генә киенеп, абзарга йөгереп чыкты. Бозау һаман койрыгын болгый-болгый имеп ята. Борыны белән төрткәли-төрткәли, очлы телен чыгарып сыптырта гына.

Сыер, алдындагы печәнне дә ашамыйча, нидер мөгрәп, бозавын ялый. Буе җиткән бөтен җирен ялый, бер җирен калдырмый. Тегесе, ялыйлармы аны, юкмы, имүен белә. Дүрт имиен дә тыны чыккан шар кебек ләшперәйтеп төшермичә туктамый. Аннан сикереп-сикереп чабарга керешә. Сыерның алдына да, артына да чыга, астыннан да йөгереп үтә. Сыер мескен тагын ашавыннан яза. Бозавын гел күз алдында гына тотарга тырышып, әле бер якка, әле икенче якка әйләнгәли башлый. Бозауның әнә шулай чабулап йөргән чагында, башын борып, юнәлешен үзгәртеп җибәрәсең дә, ул, бураны икегә бүлеп кагылган киртәнең теге ягына чыгып киткәнен сизми дә кала. Арадагы ишекне ялт – ябып та куясың. Бозауның үзенең кайдалыгына исе дә китми, сикергәләп-уйнаклап чабуын белә. Сыер сагаеп, Юлай белән әтисенә карап тора да, бозавына куркыныч янамавына тәмам ышангач кына, алдындагы печәнгә үрелә. Исең китәр. Сыер гына димәссең…

Юлайның әнисе нишләп, аны һәм әтисен ташлап, әллә кая чыгып китте икән? Шул башы әйләнгән чак булуы хактыр. Беркөн үзе ишетеп торды әтисе белән Самат абыйсы сөйләшкәнне.

– Башын әйләндерде бит… башын югалтты бит… эх, ялгышты! – диде әтисе, әнисе турында сүз киткәч.

Ул баш әйләнүне Юлай белә инде! Яз көне бәбкә саклаганда, малайлар белән

уйныйлар алар. Бик озак бер урында әйләнәсең дә әйләнәсең, әйләнәсең дә әйләнәсең. Аннан туктыйсың. Син туктыйсың, ә җир туктамый шул шәплектә әйләнә бирә. Берничек тә аякта басып калып булмый, җиргә тәгәрисең. Аннан җир сине әйләндерә башлый. Бераздан көч-хәл белән торасың. Күпергә таба барам дип уйлыйсың, ә үзең урман ягына китәсең. Мәрәкә!

Әнисенең дә башы шулай әйләнгәндер. Юк, аныкы ныграк та әйләнгәндер әле, әйләндерүчесе булгач. Берзаман кире үз хәленә килер дә кайтып та керер әле.

Сәлимә Галимовнаныкы кебек зәңгәр костюм кигән булыр микән? Беркөн Юлайларга килгәндә, зәп-зәңгәр костюм кигән иде бит ул. Башта ишегалды яктырып, ямьләнеп китте, аннан – өй эче!

– Әти, нәрсә кирәк дип әйтим?

– Үзең кара, улым. Ә болай, кышкылыкка бөтен әйберең дә бар. Аннан соң, – әтисе авыр сулап куйды, – андый бушка килгән әйбергә бик кызыгып та барма. Эшләп алган хәләлеңә җитми инде.

Икенче көнне класста гел шул бушка таратылырга тиешле әйберләр турында сөйләштеләр.

– Америкадан килә икән ди ул.

– Аны поездга дыңгычлап тутырып җибәрәләр икән. Капчык-капчык, ди.

– Әти әйтә, сезгә шул калдык-постыклары гына калыр ул, юл озын, килә-килә юньлерәкләре бетәр, ди.

– Син нәрсә сорыйсың? Мин джинсовка. Астын да, өстен дә.

– Синең джинсовкаң бар ич инде! Әтәң Себердә эшләгән килеш…

– Ну и что, минем джинсовка кара ич, миңа зәңгәре кирәк.

– Ә миңа әни кышкы итек яздырырга кушты, кожа булса, диде.

– Ә миңа «Reebok» дигән спортивка кирәк.

– Ә миңа…

– Ә мин…

Сәлимә Галимовна башта балаларны йомшак тавыш белән тынычландырды. Әйберләрнең бернинди Америкадан да түгел, ә шушы мәктәптә укып чыккан эшкуар авылдашыбызның бүләге икәнен аңлатты.

Бераз тынычлангач, балалар исемлеккә бик кирәк дип санаган әйберләрен яздыра башладылар.

Гөлгенәгә кышкы пәлтә кирәк икән. Анысы хак. Инде кышкы кырлач керсә дә, көзге юка пәлтәдән йөри ул. Әтисе дә, әнисе дә бар инде, югыйсә. Булган акчаларын эчеп бетерә баралар шул. Пәлтә алу түгел, Гөлгенәнең күпвакыт язарга дәфтәре дә булмый әле.

Маратка киез итек булса шәп буласы икән. Алар дүрт бала. Әти-әниләре колхозда эшли. Теттерелгән йоннары бар ди, түлке киез итек бастырырга акчалары юк икән.

…Чират Юлайга җитте.

– Нәрсә дип языйм, Юлай?

Сәлимә Галимовна күтәрелеп Юлайга карады. Күзләре кап-кара. Ничек ягымлы итеп карый Юлайга.

– Минем бөтен нәрсәм дә бар, Сәлимә Галимовна.

Шаулап торган класс тынып калды.

– Минем… әнием генә юк.

# ДӨНЬЯ – ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ СИМФОНИЯ...

## Нью-Джерси штатында

Көн-төн яңгыр коядыр,
Океан якынгадыр.

Күңелем хәле бик сәер,
Кешеләр сәергәдер.
Шар ачылырга әзер, –
Ачыла белмәгәндер!

Бик ягымлы, бик сабыр,
Гаепләре баргадыр...
Хәл сораучылар күптер,
«Ярдәм сорама», – диптер.
Бүреләр дә җанлыдыр –
Сарыкларны жәллидер,
Ит кенә ашап торадыр,
Печәнне калдырадыр...
Бай илләр дә шулайдыр,
Киң күңелле буладыр!

Бай, гомумән, сәердер –
Бар дөньяны жәллидер.
Байлыктан ул көләдер,
Тишек ыштан киядер,
Әллә уйнап киядер,
Әллә чынлап җүләрдер!
Шырык-шырык көләдер,
«Фан»ны гына сөядер,
Әйбере күп буладыр,
Өе шыгрым туладыр.

Тышка тезеп куядыр,
Шулай савап җыядыр.
Кирәклесен, затлысын
Савапка да алышмый –
Бу хакта ул ялгышмый,
Чын кыйммәтне беләдер!

Чын белән чын түгелне
Аеру кыен нигәдер!
Кемдер карап торадыр,
Күп-күп акыл җыядыр.

Америка ача-ача,
Аптырап та куядыр –
Минем кебек буладыр.
Көн-төн яңгыр коядыр,
Чын су микән бу яңгыр...

**Нурия ИЗМАЙЛОВА,**
*Америка Кушма Штатлары*

## Төрек базарында

Мин Төркия базарында йөрим:
Яңа өзелеп төшкән алмалар,
Әфлисуннар яна кояш кебек,
Кишер-кәбестәсе – бар да бар.

Әсәренгән инсан базар күреп:
«Алам, әйдә, – дия, – төшер хак!»
Кискән алма суза сатучылар:
«Кусура бакма, кардәш, тадына бак![*]»

...Туган илне сөю башка монда –
Һәр йорт саен элгән әләмен.
...Үз җирендә кыен ашый халкым,
Чәчә, ура, бит үз галәме!

Басып торам базар уртасында:
Төрек җире, синең җаның ак!
Ишетелә, җанга сыкрау өстәп:
«Кусура бакма, кардәш, тадына бак!..»

**Алсу НУРГАТИНА,**
*Төркия*

## Сыркыды авылында

*Якташым Һади Такташ истәлегенә*

Сыркыды шунда ук...
Әмма
Күченгән икән күптән...
...Юлбашчы рәсемен Шәхми
Өенә алып киткән.

Ташландык өй түбәсеннән
Кояш узды,
Хәерсез...
Ватылган арба көпчәге
Тәгәрәде, әйтерсең.

Мокамайлар курасында
Югалды ул аларып:
Иртән кояшны урлауда
Гаепләрләр малайны.
Мокамай
Эзли шагыйрьне,
Тартып ватык арбаны.
Аерылды да тәгәрмәчләр
Дөнья буйлап таралды.

Атларны да
Алып киткән,
Ат карагы – бу вакыт!

[*] Гафу ит, кардәш, кабып кара

Эзли хәзер үз шагыйрен
Бөтен дөнья буйлатып.

Ай балкый күктә.
Ярымай...
Исә йолдызлар җиле.

Тиздән печән чабарга дип,
Хәйрулла абзый килер.

Тезен чүгә алмаганга
Шагыйрьнең нигезенә,
Мәңге елар бер карт каен,
Яшь кояр үзе генә...

**Камил ТАҢГАЛЫЧЕВ,**
*Мордовия Республикасы,*
*Саранск шәһәре*

## Без

Галәмдә бер нокта –
Җир шары...
Без – бары
Ноктаның тузаны...
Аллаһның рәхмәте төшкере:
Без – Кеше,
Без – җанлы,
Без – тере –
Галәмнең
Ачылмас бер сере!

***

Йөз мәртәбә яшә,
йөз тапкыр үл,
йөз беренче кат
терел, ниһаять.
Дөнья –
иксез-чиксез симфония,
синең гомерең –
кыска хикәят.

**Ибраһим БИЕКТАУЛЫ,**
*Удмуртия Республикасы, Ижевск шәһәре*

## Татармын мин

Татар мин, төптән-тирәннән,
Тамырым, каным татар.
Телем, уем, фикерләвем,
Зиһенем, җаным татар.

Бишек җырыннан иңгәндер
Күңелемә яктылык.
Тукайлы «Әлифба»лардан
Аңга сеңгән яхшылык.

Халкы белән горурланып,
Яшәүче зат та бар – мин!
Түбәтәйле, Сабантуйлы,
Якты уйлы татар мин.

**Шәмси ШАХМАЕВ,**
*Свердловск өлкәсе,*
*Уфа-Шигири авылы*

## Тормыш назга саран...

Үчти-үчти иттең тезләреңдә,
Алдың, әнкәй, кайнар кочакка...
Әле дә булса әйләнәм дә карыйм
Итәгеңдә үскән шул чакка.

«Азындырма!» – диючеләр булды,
Сөеп иркәләгән чагыңда.
«Тормыш назга үтә саран, – дидең, –
Иркәләнеп калсын янымда».

Синме, әнкәй җаным, аңламаган
Дөнья үчти-үчти итмәвен.
Һәр карышын гомер юлларының
Җиңел генә балаң үтмәвен.

«Түз, бәбкәем», – дисең кыен чакта,
Синең киңәш белән тыелам.
«Үчти-үчти» эзләп, күңелемнән
Тезләреңә килеп сыенам...

**Физәлия ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВА,**
*Свердловск өлкәсе,*
*Каменск-Уральски шәһәре*

## Мәхәббәтем

Минсез бу дөньяда син дә
Булмассың кебек иде,
Мин булганга гына син дә
Тугансың кебек иде.

Йөрәгемнән сызылып чыккан
Ләззәтле көемме син?
Әллә күңелемдә яткан
Ләгънәтле төенме син?

Табалмадым чараларын
Хисләр-хыялларыма:
Кара туфракка әйләндем,
Сибелдем юлларыңа...

Шул туфракта мәхәббәтем
Үсеп чыкты гөл булып.
Үзем калдым ялкыныннан
Күмер булып, көл булып.

**Равил НАСЫЙБУЛЛИН,**
*Уфа шәһәре*

## Яшәү

Чынында сөелмәгән дә –
Үкенеч кенә булган.
Кемнедер яулап алырга,
Һәм дә кол итеп калырга
Үтенеч кенә булган.

Чынында яшәлмәгән дә,
Өмет, уй гына булган.
Ашык-пошык аралашкан,
Көн сүрелгәч, таралышкан
Сабантуй гына булган...

**Әдһәм ӘСКӘРОВ,**
*Башкортстан, Учалы шәһәре*

## Гозер

Кисәм кискен дулкыннарны,
Җилне бастырам.
Көймәмне этеп җибәрәм,
Ишкәк батырам.

Күз яшьләремне тамызмыйм,
Дәрья ярына.
Текә ярда йөзем борам,
Кояш ягына.

Артта сизрәп калган гомер,
Алда да гомер.
Йөрәктә – чиксез батырлык,
Җан боек никтер.

Йөрәктә – Ходай чаткысы.
(Әйе, ул кирәк!)
Юлсыз, юньсез бу дөньяда
Кабынсын кинәт.

Эзләмим качарга урын,
(Кемнәрдән качыйм?)
...Упкынга түгел, күкләргә
Очыйм ла... Очыйм!

...Артта – томан сарган гомер,
Алда да гомер.
Йөрәкне, Раббым, суытма!
Бу – минем гозер.

**Равил ШӘФИГУЛЛИН,**
*Ульяновск шәһәре*

## Ике чыпчык

Юлдагы чокырда, күрче,
Ике чыпчык су керә.
Туктадым да карап торам
Шуларга, көлә-көлә.

Су чәчрәтеп коеналар,
Чөкердәшеп-сөйләшеп.
Һич юктан да кызык табып
Яшиләр бергәләшеп.

Күрә белсәң, бу табигать
Безне шулай өйрәтә:
Яшәү серен чокырдагы
Чыпчыклардан сөйләтә...

**Эльвера КӘРИМОВА,**
*Башкортстан, Стәрлебаш районы*
*Яңгырчы авылы*

## Кире кайтмый берни дә

Бу вакытның мизгеле дә кире кайтмый,
Бер яфрак та ике тапкыр җиргә ятмый.

Аккан сулар челтер-челтер ага тора,
Үтә гомер, язмыш юлын бора-бора.

Җылы өстәп шатлык килә, кайгы китә,
Кайчагында бәхет өчен бер сүз җитә.

Беләсеңме-белмисеңме кадерен, үтә
Гомер, көзнең толымнарын сүтә-сүтә.

Китмәс сыман таңнар ата алсуланып,
Алыштыра аны төннәр моңсуланып.

Сүнмәс дигән йолдызлар да бер атыла,
Кояш булып кояш поса тау артына.


Алышына көннәр, һава, давыл, рәшә,
Туктап тормый, тормыш – сынау, алга дәшә.

Мизгелләрнең кайтмаслыгын белсәк тә без –
Калдырырга килгән җиргә бер якты эз.

**Гөлфия ИСХАКОВА,**
*Удмуртия, Воткинск шәһәре*



*Соңгы 10-15 елда Казан читендәге Аккош күле буенда легендар җырчы Илһам Шакировның туган көне уңаеннан иҗат әһелләре җыйнала. Сулдан уңга: Рабит Батулла, Илһам Шакиров, Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев. 2008 ел.*



*Аксакал әдибебез Гомәр ага Бәширов Татарстан Язучылар берлегенә килгәч. Аның янәшәсендә Ринат Мөхәммәдиев (өстә) һәм Рәмис Аймәт 1996 ел.*



*Рөстәм Зәкуан – шагыйрь, күпсанлы популяр җырлар авторы. 2018 елда «Таттелеком» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин белән бергә Рөстәм Зәкуан милли хәзинәбезне һәм тарихи мирасыбызны саклап калуга керткән өлеше өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.*



*Төрки телдәге әдәби журналларның халыкара форумында катнашучылар. Август, 2014 ел.*

Әдәби конкурс Хәзинә



Тәлгат
Галиуллин

# НИК КЕРӘСЕҢ ТӨШЛӘРЕМӘ?

ХАКЫЙКЫЙ БӘЯН

*«Татнефть» берләшмәсенең элекке генераль директоры, СССР нефть промышленносте министрының урынбасары Мөхәмммәтҗанов Әкъләм Касыйм улының якты истәлегенә багышлыйм.*

## Хакым бармы?

Татарстанда кара май чыгарыла башлауның юбилее якынлаша дигән хәбәр колагыма чалынгач, үзем күргән, белгән, якыннан аралашкан ошбу һөнәр кешеләре, аларның якыннары, дуслары, беренче нәүбәттә, бары тик үз көче белән түбәннән күтәрелгән, халкыбыз иркәләп үстергән, ифрат милли җанлы, дастаннарга лаеклы легендар шәхес Әкълим Касыйм улы Мөхәмматҗанов турында хатирәләрем белән уртаклашасым килде. Шул ук вакытта бер шик-шөбһә күңелне кытыклады: яшьлегең Нурлат, Алабуга, Әлмәт кебек нефть чыккан якларда үтеп, әдәбият серләрен, әдәп-әхлак кагыйдәләрен шул төбәкләрдә туып-үскән балалар зиһененә, күңеленә сеңдерү рухы белән яшәсәң дә, бу байлыкны җир бәгыреннән чыгаруда, эшкәртүдә катнашмадың, мазутка чумып, озын балтырлы итекләр киеп пычрак измәдең... Икенче яктан, Алабуга педагогия институтында эшләгәндә, бигрәк тә 1971-1986 елларда ректор вазифаларын үтәгәндә, шул эшләрне башкаручы фидакярләр белән якыннан аралашып, хезмәтләренең авырлыгын, сөенечләрен, шатлыкларын күреп, үз башымнан үткәргәндәй тоеп яшәдем. Бигрәк тә бу өлкәдә гади эшчедән иң югары баскычка күтәрелгән татар кешесе – «ата нефтьче» Әкълим Мөхәмматҗанов белән шактый еллар аралашып яшәвебез, дуслыгыбыз хакында үзе исән чакта ук язарга тиеш идем. Фикеремне әйтми калуым мәгънәсезлек булдымы, «байларга» ялагайлана, диюләреннән шикләндемме, өздереп әйтә алмыйм. Соң булса да, уң булсын, дип, хәзер шул бурычымны үтим.

Әкълим ага, аның хәләл җефете Гөлчәчәк ханым Мөхәммәтҗановлар инде күптәннән бакый дөньяга күчтеләр. Мәгәр аларның якты йөзләре, камил образлары бүгенгедәй күз алдында. Ничек аларны хөрмәт итмисең, сагынып искә алмыйсың. Язмаларыма биргән исем дә кызыл сүз генә түгел, ә ихласи җан авазы. Истәлекләрем аларга дога булып барсын! Амин!

## Беренче очрашу иң игелеклесе булды

Җитмешенче еллар башы. Алабуга педагогия институтына ректор итеп әле генә сайланган вакытым. Ышанычны аклыйсы килә. Хыяллар искитмәле, иксез-чиксез дәрья хәтле, кайсыннан башларга белмичә, уйланып, кәгазь боткасына чумып утырган ямьле яз көннәренең берсе. Төн йокыларын качырып, гелән борчып торган эшләр бихисап. Купец Стахеев хатыны төзеп калдырган, кызыл үгез тиресе төсле кирпечтән салынган бинаның түбәсе урыны белән су үткәрә, котельныйны күмердән газга күчерәсе бар, миңа хәтле бу кәнәфине бизәгән кешеләр барысы башка милләттән булганга, «ул белгечлеккә ихтыяҗ юк», дигән кәкре сылтау белән, татар бүлегенә кабул итүне туктатканнар (мин эшләгән дәвердә татар бүлеге факультет дәрәҗәсенә күтәрелде), хәл итәсе башка мөһим мәсьәләләр дә җитәрлек. Яз, көз, кыш көннәрендә юллар өзелү сәбәпле, Казанга, Мәскәүгә эләгү өчен, иң якын тимер юл станциясенә – Удмуртиянең Можга шәһәренә 100 чакрым юлны «УАЗ»ик, халык телендәгечә – «Бобик» машинасында гына барып була. Ә ул институтта юк. Мәкәрҗә хәерчесе кебек, нефтьчеләрдән яисә горкомнан машина сорап, ялынып йөрүдән туктарга вакыт... Тик менә ул машинаны кемнән сорыйсы, каян аласы?!

Нәкъ шул мәлне ишек ачылды да, мине уй-хыялларымнан арындырып, кабинетка җитез, шул ук вакытта каударланмыйча атлап, өстенә япун миллионерлары бренды булган куе зәңгәр костюм кигән, тулы, килешле гәүдәле, негрларны көнләштерерлек кара бөдрә чәчле бер ир килеп керде. Мин имәнеп киттем, ишек шаку да, башны тыгып рөхсәт сорау да юк.

Миһманым, бу бүлмәдә күп тапкырлар булган кеше кебек, түргә узды, мин инстинкт буенча, торып басарга да өлгермәдем, киң учын миңа сузып:

– Исәнмесез. Мухаметзянов, татарча Мөхәммәтҗанов булам, – диде.

«Сөйләшмичә, киңәшмичә чебенне дә кертми торган Земфира бу мәһабәт гәүдәле иргә ничек ишекне ачкан», дип уйлап та өлгермәдем, чакырылмаган кунагым сүзен дәвам итте.

– Сезгә керергә ханымнан рөхсәт алдым. Мин НГДУ «Прикамнефть»нең яңа начальнигы булам. Минем белән таныштырган җыелышта катнашмадыгыз кебек. Үзем күренеп чыгарга уйладым. Киңәшәсе мәсьәлә дә бар. Икенче атна эшлим инде яңа урында.

– Ул җыелышта була алмадым шул. Казанда идем.

Миңа ачылган авызымны ябарга да вакыт бирмичә, кунагым үзе белән таныштыруны дәвам итте.

– Исемем Әкълим, әтием Касыйм. Мин аны сугышка озатып калдым. Шул чыгып китүдән кайтмады.

Институтка берәр игелек эшләгән кеше турында кайгырткандай сорап куйдым:

– Ә Сапгир иптәш кая китте?

– Ул тю-тю... Алар халкы бер урында озак эшләргә яратмый. Сөтнең каймагын җыеп ала да башка ачыгавызларны имә башлыйлар.

Алабуга – Менделеевск якларында нефть-газ табу, чыгару берләшмәсенең, белүемчә, беренче начальнигы озын буйлы, җирән чәче яртылаш коелган, тәкәббер яһүди Лев Сапгир иде. Ул чорда иң кәттә автомобиль, үзебездә чыгарылган «Волга» машинасы булып, Сапгирны без шуңа утырып узып киткәндә генә күреп кала идек. Пединститутны ул санга да сукмады, безнең мәшәкатьләр белән кызыксынмады да. Кемдер бездән киңәш сораган диярсең: татар йә урыс кешесен тапмадылармы икән шунда, дип борчылыпмы-борчылдык. Кысыр хәсрәт диләрме әле бу халәтне психологлар? Үзебездә әзерлекле, белемле кадрлар җитмәү сәбәпле, аны Мәскәүдән үк җибәргәннәр, дигән имеш-мимеш тә йөрде.

Сапгирның хатыны Нина Петровна – үзе чибәр, өстәвенә, чит илдә тегелгән затлы киемнәргә генә төренеп, япун ислемаен сиптереп, эшенә берничә сәгатькә генә килә, иренең машинасыннан чыгуга, илле биш яшьлек баш табиб Вазыйх Сабиров аны ишек төбендә үк каршы ала, бүлмәсенә чаклы озатып куя... Саескан койрыгында таратылган менә шундый хәбәрләр Алабуга хатыннарының аеруча саруын кайнатты.

Касыйм улының Сапгир турында фикере тәмамланмаган икән әле.

– Мәскәүдә фатир юнәткәнме, сатып алган булганмы, шунда эшкә урнашып йөри, ди бугай. Үзеннән сорашмадым. Бер көн эчендә миңа эшләрен тапшырды да башкача «безнең урамда» күренмәде. Ул милләттән чыккан кешеләрнең сәләтле булуларын да таныйм, үзара, кулның биш бармагы кебек, бердәмлекләрен дә хуплыйм. Әмма авыр вакытларда аларга таянуы шикле. Кстати (күпме сөйләшеп, бер урыс сүзен кулланды), сугыштан соңгы чорда еш сөйләнелә торган анекдотны сез дә беләсездер.

– Кайсы икән, ул төр мәзәкләр күп инде, – дигән булам, тирәнгә кермәскә тырышып.

– Сугыш бара. Командир окоптан сикереп чыга да: «Орлы, вперёд!» – дип, үзе дә дошман ягына ташлана. Атака теләгән нәтиҗәне бирми, күбесе сугыш кырында ятып кала. Кем белә, бәлки минем эти дә шунда булгандыр, исәннәре чигенеп, кире окопларына кайталар. Ни күрсеннәр, берничә кеше урыннарында ышыкланып калган. Командирның ачулануына тыныч кына җавап бирәләр: «Мы же не орлы, а львы, нас не позвали...»

Бу сакаллы мәзәк күптәннән таныш булса да, сиздермәдем, елмайган булдым. Әлеге мизгелдә мин, элекке «Прикамнефть» начальнигының күктән төшкән пәйгамбәр шикелле кылануын искә төшереп, яңасының үзен күптәнге әшнәм шикелле тотуына, саф татар телендә сөйләшүенә гаҗәпләнергә дә өлгермәдем, Әкълим Касыйм улы дәвам итте:

– Мин сезгә бер киңәш белән килгәнием.

– Тыңлыйм!

– Минем икенче улым быел унынчыны тәмамлый. Әлегә, уку елы беткәнче, әнисе белән Лениногорскида калдылар. Малайның белемен дәвам итәргә абыйсы янына Мәскәүгә китәргә исәбе бар. Минем, бигрәк тә әнисенең, аны еракка җибәрәсе килми. Абыйсы Ринат мөстәкыйль бала булып үсте, яхшы укыды. Хәзер архитектор белгечлеген алырга җыена. Икенче улыбыз мулрак тормышта яшәп, иркәрәк үсте. Яшь чакта үзем дә, гармун уйнарга ярата идем, ә Ришатка музыка җене чын-чынлап кагылган, иртәдән кичкә чаклы барабан кагып, гитара чиртеп утырырга мөмкин, ирек бирсәң!

Бүлмәгә өермәдәй килеп кергән абзыйга минем дә кирәгем булуы ихтимал икән, дигән күңелле уй узды башымнан.

– Безнең институтта укытырга ниятегез бармы?

– Төрлесен уйлыйсың инде. Балаларны аякка бастыру – безнең төп бурычларның берсе бит бу дөньяда.

– Күңеле кайсы белгечлеккә тарта? Мәктәптә кайсы фәннәрне яратып өйрәнә? Шунысын да исәпкә алырга кирәк. Без киң профильле инженерлар чыгара торган яңа факультет ачтык.

Абзый, урыныннан торып, аркылыга куелган кечкенә өстәл янында йөреп алды:

– Улым мәктәптә инглиз телен яратып өйрәнә. Биредә калса, сүз шул юнәлешне дәвам итү турында гына булырга мөмкин.

– Улыгыздан нефтяник ясарга теләмисезме? Дәвамчыгыз булыр иде, – дисәм дә, башымда башкарак фикер калыпланып килә иде.

...Аның улы безгә укырга керсә, әле генә чәчне агартып, миемне катырып утырган мәсьәләләрнең күбесен хәл итеп булыр иде. Беренче чиратта, ар Можгасы белән ике арада йөрерлек, аерым алганда, Сибгат абыйны яраннары белән алып килерлек, тотылганрак булса да, төрле юлларда йөри алырлык машина сорар идем...

– Юктыр. Ул теләми, мин көчләмим. Югары белем алып, башлы-күзле булганчы, үзебезнең янда яшәсен, дибез.

Аны юри кирегә үгетләгән шикеллеме, ниятенең ныклыгын тикшереп карау өченме:

– Без бит урта мәктәпләр өчен укытучылар әзерлибез? – дидем.

Аның түгәрәк, киңчә йөзенә өстәмә яктылык иңгәндәй булды. Ул, тигез ак тешләрен ялтыратып, бөтен битен тутырып, елмаеп җибәргән икән.

– Соң бит мин үзем дә төп белгечлегем буенча башлангыч класслар укытучысы. Педучилищены тәмамлап, туган авылым Тимәштә берничә ел балалар укыттым. Хатыным Гөлчәчәк белән шунда табыштык, ул да укытучы, тәрбияче булып эшләде. Мин ул елларны әле дә сагынам. Тормышны алып барырлык түләсәләр, бәлки мәктәптә калган да булыр идем әле... – Күзлеген кулына алып, коңгырт сабының очын авызына капты:

– Юктыр! Кара май табылгач, Әлмәт төбәге тулысынча урыныннан купты, бер-ике ел эчендә җирне нефть вышкалары каплады, дөньяның асты-өскә килде диярсең. Мине дә нефть чыгару романтикасы үзенә тартты. Җегәрне кая куярга белмәгән яшь, дәртле чак. Кыскасы, мин үземне биләгән ашкыну хисенә баш биреп, буровойга гади эшче булып урнаштым.

Кунакны миннән алданрак танып, бәяләп (теге җыелышта ул булган диярсең) өлгергән сәркатибем Земфира ханым киңәшмәләр уздыра торган озын кара өстәлгә чәй ясап кертте, ризыклар куйды. Ярдәмчеләрнең үзеңнән акыллырак, алдан күрүчәнрәк булуы күңелне үсендерә торган фал икән. Гаять төгәл, эшкә бер дәкыйка алдан килми, иртә китми торган, бераз кырысрак Земфира Камил кызының райком, исполком кызыл авызларына да юмартланып, эреп китә торган гадәте юк иде. Ул бары тик Сибгат Хәким һәм аның белән килгән, үзе таныган шәхесләргә генә игътибарлы булды. «Бөдрә чәч»нең якын арада институтка иң файдалы кеше булып китәсен колагына иңендә утыручы фәрештәсе пышылдаган диярсең!

Миңа исә, урынымнан кубып: «Әйдәгез, Әкълим Касыймович, чәйләп алыйк», – дип, кулларны як-якка җәясе генә калды.

Ул, дөньясын онытып, тәмләп чәй эчә торган кеше түгел икән, шул арада минем телефоннан әле урынбасарына, әле складка шалтыратып, күрсәтмәләр

бирде. Ташып торган җегәреме, җаваплылык хисеме аңа җәелеп утырырга ирек бирмәде.

Шул ук вакытта ул китәргә дә ашкынмады, югары уку йортында ул үзен янәдән педагог яисә студент итеп сиздеме, без әле шактый сөйләшеп утырдык, дөресрәге, ул тормыш баскычларын искә төшерде, мин ифрат тәртипле тыңлаучы булдым. Аның эчке сөйләмен (монологын) шул чорда ук көндәлек дәфтәренә язып та куйганмын.

– Мин Лениногорск районына кергән Тимәш авылында туып-үстем. Әтиемне сугышка озатканда, миңа унбер яшь иде, ул миңа һәм шул афәт башланган елны туган энем Өлфәткә бик озак итеп карап торды. Моңлы гына түгел, сагышлы күзләре һаман күз алдымда. Аның җаны безне һәм хатынын соңгы тапкыр күрүен сизенгәндер.

Без әниебезнең җылы кочагында үстек, дип әйтәсе килсә дә, дөреслек башкада иде. Тамагыбыз тук, өс-башыбыз башкаларныкыннан ким-хур булмасын, дип, ул көне-төне колхоз эшендә булды. Әйткәнемчә, безнең тирәдә кара май табылгач, төбәк күтәрелә, гөрли, юллар салына, өйләр төзелә башлады. Шул дулкын мине дә йомычкадай бөтереп алды. Миңа да нефть җене кагылды. Кулга акча керә башлады. Булганына канәгатьләнеп, кичен кулда тальян биетеп, мәҗлесләрдә тел чарлап, кызлар озатып йөреп, ярым романтик, ярым сентименталь тормыш белән дә гомерне уздырып булыр иде. Тынгысыз җанымны җир астында миллион еллар дәвамында туа, җыела килгән кара майның эчтәлеге, структурасы, нинди матдәләрдән торуы кызыксындыра башлады. Аларны күзаллау өчен белем кирәклеген аңладым һәм Уфа нефть институтының Әлмәттәге кечке бүлегенә укырга кердем. Бөгелмә педучилищесы математика, физика, химия, биология кебек фәннәрдән төпле нигез салган икән, мәктәптә дә әзерләнмичә дәрескә кереп булмый иде. Шуңа да институтта укуы авыр булмады. Борынгылар кешене ике нәрсә: хезмәт һәм гыйлем бизи, дигәннәр. Үзеңне үзең мактау тыйнаклык саналмаса да, тиле әйтмешли, үткән юлыма әйләнеп карыйм да гаҗәпләнәм, ничек барысына да түзелгән, әле бит киләчәктә кем, ничек булуың билгесез, барысы Алла хөкемендә. Көне буе буровойда мазутка батып эшлисең дә, тиз генә юынып, ашап, институтка чабасың. Укытучыга бит синең аруың, талуың түгел, ә белемең кирәк. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар, сәгате суккач, гаилә корып, балалар үстерәсе, биргән тәрбиясе, җан җылысы өчен әнигә дә бурычны кайтарасы була.

Акрын гына барысы үз агымнарын тапты, тиешле юлына кереп утырды. Ул чорда әзерлекле, белемле кадрларга кытлык иде. Күп булса ун ел эчендә, барлык мөмкин булган үсеш баскычларын узып, Баулыда НГДУ начальнигы дәрәҗәсенә күтәрелдем, берничә ел туган районым Лениногорскига да ярдәм иттем, хәзер менә, Сапгир «битен югач», сезнең якка җибәрделәр.

Шул рәвешле, тәүге танышуыбыз озакка сузылса да, бәрәкәтле булды һәм киләчәк дуслыгыбызның нигезенә ятты.

## Яшьнәп яшәүгә ни җитә?

Горурлык хисен яшермичә үзе үк әйткәнчә, Әкълим Мөхәммәтҗанов хезмәт юлын бораулау җайланмасында гади эшче буларак башлый. Кара ыштан, шул ук тукымадан тегелгән өске кием белән озын балтырлы резин итек кигән егет нефтьле су сеңгән, үзенә суырып торган кара, кызыл балчыклы җирләрне

шактый изә. Әнисе олыгаеп килә, ул да ярдәмгә мохтаж, энесен аякка бастыру да аның вазифасы. Яшьлек мәхәббәте, чибәр, чая, үткен телле Гөлчәчәкне дә күз уңында тотарга кирәк. Нефть акчасына тамагы туйган әрсезләр читкә борылганыңны көтеп кенә торалар.

Мәктәптә педагог булу, укытучылар даирәсе, ата-аналар белән аралашу холкын чыныктырган һәм кешеләргә мәрхәмәтле, рәхимле булырга да өйрәткән икән. Тормыш тәҗрибәсе, укуын уңышлы дәвам итүе аңа нефть сәнәгатенең бар текә баскычларын уңышлы үтеп, егерме җиде яшендә Баулы нефть-газ идарәсе начальнигының урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелүгә юл ача.

Анасыннан милли тәрбия алган, тумыштан хисле Әкълим яраткан яры Гөлчәчәкне килен итеп төшереп, гөрләтеп туй уздыра, гаилә учагы корып җибәрә. Сөеклесе белән тәннәре генә түгел, рухи омтылышлары тәңгәл килеп, туганнары белән аралашып, ике бала үстереп, һәр гаилә башыннан үтә торган савыт-саба вату кебек вак-төяк «аңлашулар» чорын узып, үлем афәте аерганчы, бербөтен булып гомер сөрәләр.

Югары белем – башта, диплом – өстәл тартмасында, зур тормыш мәктәбе узылган, теленә «шайтан» төкергән, төрле дәрәҗәдәге кешеләр белән аралаша белү сәләте бар, ул тырыш спортчы кебек, теләсә нинди биеклекне алырга әзер.

Аның белән ун ел дәвамында иңгә-иң эшләгән, Баулы нефть-газ берләшмәсенең «хөкемдары», үзе лаеклы ялга киткәндә бушаган кәнәфиенә Әкълим Мөхәммәтҗановны тәкъдим итә. Кандидатура фирка оешмасында да, «Татнефть» җитәкчелегендә дә бәхәс, димим, шик-шөбһә дә уятмый. Әле генә утыз җидесен тутырган Әкълим Мөхәммәтҗанов җаваплы, дәрәҗәле урында гаять тырыш булуы, гади җыештыручыдан алып иң олы дәрәҗәле кешеләр белән уртак тел таба, куйган максатына ирешүдә бар каршылыкларны диярлек җиңә белүе нәтиҗәсендә Баулы нефть-газ берләшмәсен алдынгылар рәтенә чыгара. Кыскасы, ул олы дәрәҗәле кәнәфидә дә тиешле югарылыкта кала.

Шул урында кечтеки генә чигенеш ясап, үткәнебезгә күз салып, аерым алганда, совет чорында кадрларны үстерү, тәрбияләү алымнарын искә төшерәсе килә. Сүз дә юк, кешеләрне байларга, ярлыларга бүлү, хакимиятне бер фиркагә тапшыру (хәзер – бер кешегә) кебек җитешсезлекләре булса да, алмаш әзерләү, сәләтле балаларны пионер, комсомол, фирка оешмаларында тәрбияләп үстерү алымнары үрнәк алырлык иде. Мәктәпләр, югары уку йортлары шул системаның баскычлары булды.

Әшнәлек, кода-кодагыйлык, туган-тумачалык, якташлык галәмәтләре ул чорда булса да, нигездә кешенең белеменә, сәләтенә, профессиональ әзерлегенә игътибар ителә иде. Моңа кире каккысыз мисал: үз өлкәсендә иң югары дәрәҗәгә ирешкән Әкълим Мөхәммәтҗанов. Колхозчы әнисеннән башка ярлыкаучысы, артыннан төртеп баручысы булмаган авыл егете биеклеккә – үз тырышлыгы, ә аның Ходай Тәгалә, табигать, милләте биргән сәләте, хезмәт сөюе нәтиҗәсендә нефть сәнәгате дә безнең йөзек кашы дәрәҗәсенә күтәрелә. Хәзерге хәятебездә әгәр ул фәлән нәселнең дәвамчысы, һич югында ботак очы булмаса, фәлән районда тумаса, хакимият түрендә утыручыларны мактамаса, берәр тәнкыйть сүзе ычкындырса, мондый үсешкә ирешә алмас, әгәренки ул ялгыш кына «үсеп китсә», моңа берәү дә ышанмас, нәсел-нәсәбеннән зур түрәләр белән туганлык җебе эзләрләр иде.

Баулы нефть-газ берләшмәсендә ул үз һөнәрен тирәнтен үзләштергән белгеч, оештыру, алдан күрә белү сәләтенә ия җитәкче, психолог буларак тулы көчкә ачыла. Аерым алганда, җир-анабыз куенындагы байлыкның кадерен белүе,

бурычларны ачыклый алуы аңа нефть чыгаруны берничә мәртәбә арттыру мөмкинлеген тудыра. Әкълим Касыйм улы куйган максатынаирешү юлында киртәләргә юлыкса – үҗәт тә, кискен дә, усал да, хәйләкәр дә була белде, мәгәр дуамаллыктан аны сабырлык, түземлек кебек сыйфатлары коткарды. Урынлы-урынсыз, файдалы-файдасыз мактауларга, тәнкыйть-киңәшләргә дә үз позициясеннән чыгып бәя бирә белде.

Баулы халкы аның җитәкчелегендә төзелеп калган йортлары, ачык йөзү бассейны, «Иволга» санаторий-профилакторий һәм башка игелекле эшләре өчен аны хәзергәчә сагынып искә ала. Рәхмәт хисе буыннан буынга тапшырыла килә һәм яңа гасыр башында Әкълим Мөхәммәтҗановка «Баулының мактаулы гражданы» дигән исем бирелә.

1970 елларга кергәндә, аны үсеш авырлыгы кичергән «Лениногорск» нефть-газ идарәсе хуҗасы итеп күчерәләр. Яңа урында Әкълим Мөхәммәтҗанов, нефть чыгаруны арттыру белән бергә, тирәлекне, табигатьне, чишмәләрне, күлләрне саклау, чистарту буенча зур эш алып бара. Аның әмере һәм ярдәме нәтиҗәсендә авыл хуҗалыгы продуктлары белән эшчеләрне тәэмин итәрлек зур совхоз булдырыла. Яңа урында, туган районында ул нибары берничә ел эшләп кала. Мәгълүм булганча, Сапгир киткәч (яисә азат ителгәч), аны Алабугага күчерәләр. Башка район-шәһәрләрдә урнашкан нефть чыгаручы хуҗалыклардан аермалы буларак, бу төбәктә, әйтик, Әлмәт вилаятендәге шикелле, кара май «күлләре» җәйрәп ятмый, җир катламын бораулаучы һәм кара алтынны чыгаручы корылмалар бер-берсеннән дистәләгән чакрымнар ераклыкта урнашкан. Бусы – бер. Икенчесе, ул үзе кат-кат искә төшергәнчә, «монда нефтьне тонналап суыртып булмый, чиләкләп җыярга туры килә».

Аның яшәү һәм эш темпы гаҗәеп тыгыз: иртән эш бүлмәсенә кагылып, җыелган кәгазьләргә күз сала, беришесен үтәү өчен урынбасарларына юллый, боерыкларын бирә дә, ишек төбендәге «УАЗ»игына «кунаклап», бораулаучы вышкаларга чыгып китә, анда хезмәт итүчеләрнең хәлләрен белә, киңәшләрен бирә, берсен әрли, икенчесен мактый, кая нәрсә җитешмәгәнне телефоннан тиешле кешеләренә иңдерә.

Юлда йөргәндә, төрле кызыклы, гайре табигый хәлләргә юлыкканын мәзәк итеп сөйли иде. Менә шуларның берсе.

– Чираттагы буровой янында булып, икенчесенә барганда, мари авылы аша үтәргә кирәк иде. Бер мөлаем генә хатын кулын күтәреп, күрше авылга алып баруны сорады. Без шофёр белән икәү генә идек, утырттык. Ханымның юл тоткан авылына 100-150 метрлап ара калгач, безгә уңга борылырга кирәк иде. Аны төшерүгә, хатын, шофёр янына килеп: «Рахмат, минем деньга юк, мине ал», – дип, чишенүгә якын хәрәкәтләр ясый башлады. Шофёрым аны әрләп, безгә акчаң да, үзең дә кирәкми, үз юлыңда бул, дигәч, минем якка кулы белән күрсәтеп: «Может грузчигың будет», дип, икебезне дә кызартты...

Алабугада Әкълим Касыйм улы калдырган игелекле эшләрнең шаһиты булдым мин. Ул шулай ук йөзү бассейны, спорт һәм мәдәният йортлары, кунакханә, үзләренең эшчеләре һәм шәһәр халкы өчен менә дигән торак йортлар төзетте. Шактый асфальт юллар салдырды, санаторий-профилакторий белән шатландырды. Институтка да ярдәме аз булмады укытучы-нефтьченең. Һәрхәлдә, без «УАЗ»ик машиналы, «КамАЗ» аша юнәткән кара «Волга»лы да булдык. Ректор кабинетына, машинасына теләсә кайсы шәһәр белән сөйләшә алырлык телефоннар куелды, ничә ел төзүчеләр планына кертә алмыйча интеккән, институт йортында төзелгән ашханәгә яшел ут ачылды. Машиналарга

– бензин белән, такта, металл ише «вак-төяк» белән ярдәм итүләрне санап та тормыйм. Минем үтенеч белән тәэминат бүлегенең җитәкчесе итеп алынган, элекке студентларның профком рәисе Евгений Денисов күп мәсьәләне үзе җиңел хәл итте.

## Исеме җисеменә рас килә...

Адәм баласы тумыштан нинди генә сәләтле, әзерлекле, заманага яраклашып әйткәндә, креатив күренмәсен, өендә аңлар, таяныр яртысы, яисә тәртип булмаса, арып-талып эштән кайткач, аркасыннан, битеннән сыйпап, «әйт, җүнсезем, кайларда йөрдең», дип, кичен каршы алучы, иртән хәерле көн теләп, озатып калучы булмаса, ул хезмәт фронтында тулы көчкә тугарылып, ачылып китә алмый. Үз тормыш тәҗрибәмнән чыгып әйтелгән һәркемгә мәгълүм ошбу фикер Әкълим Касыйм улының гаилә учагы белән якыннан танышкач, янә бер исбатлау, ягъни «апробация» узды.

Без дә Алабуганың калкурак өлешендә урнашкан Разведчиклар урамында, юл салучылардан бушаган йортка күчкәч, Мөхәммәтҗановлар белән ике йорт аша гына күршеләр булып чыктык. Рәткә тезелгән бер катлы өйләр артында элегрәк утыртылган, тоташ каеннардан торган, берничә гектар җир биләгән урманчык бар иде. Иртәнге алтыларда, без шаяртып, «Онегин каенлыгы» дип йөрткән урынга чыгып, алда торган көндәлек эшләр турында киңәшеп йөрү гадәтен керттек.

Янәшәдә яши башлагач, Гөлчәчәк ханым белән дә якыннан танышып, дуслашып киттек. Сәйфетдин абзый кызы түгәрәк ак битле, ачык чырайлы, күгелҗем күзле; гәүдәсе тулылана башласа да, спайлыгын саклаган иде. Җитез хәрәкәтле ханымның үз бәясен белеп яшәгәнлеге, ихтыярлы, нык холыклы булуы сизелеп торды.

Минем җәмәгатем Галия – балалар табибы – ифрат тыныч холыклы, һәр шәйне фәлсәфиioктадан килеп бәяләсә, Гөлчәчәк исә, киресенчә, кайнап торган кызу канлы, артыннан яратып, анда да авызны уч белән каплап, ул чорда киң әйләнешкә кереп киткән «ультра» дигән сүз белән атаган чаклар иде бу.

Без аларга, алар безгә кереп, ял көннәрендә гел аралашып яшәдек. Мөхәммәтҗановлар гаиләсендәге татулыкны, аңлашу үрнәген күреп, сокланып чыга идек. Гөлчәчәкнең өйдә хуҗалык мәсьәләләрендә баш булуы, олы нефть-газ компаниясе белән җитәкчелектән дә гарык булып кайткан иргә (ул горкомга да артык баш бирми иде) буйсыну иллюзиясен тудыруы эчке талгын рәхәтлек биргәндәй тоелды миңа.

Гөлчәчәк тыштан кырыс, таләпчән күренергә тырышса да, балаларын тәрбияләүдә, иренә мөнәсәбәтендә хәлдән килгәнчә, терәк булуы сизелеп тора иде.

Өйләрен тәртиптә тоту, яңа мебель алу кебек хуҗалык мәсьәләләрендә ире, башын «юләргә салып»: «Гөлчәчәк, син ничек әйтәсең, шулай булыр», дип, аның һәр теләге белән елмаеп килешә һәм, әлбәттә инде, үзенчә эшли. Хатыны моны сизеп, «Әкълим, алай ярамый инде», дисә, җавабы әзер.

– Гөлчәчәк, син дөрес әйтәсең! Бу юлы шулай туры килде инде. Киләсендә нәкъ син әйткәнчә эшләрбез.

Шул ук тарих кабатлана торса да, ике як та канәгать.

Ирләр арасындагы дуслык хатыннар аңлашуы белән ныгытылса, нур өстенә нур иңгәндәй, хәтта хәмерне дә хәләлеңнән качып-посып эчү мәшәкатеннән

дә котыласың. Кыскасы, җәмәгатьләребезнең уртак тел табуы безне тагын да ныграк якынлаштырды.

Гөлчәчәк ханым ире янында, кадрларның белемен күтәрү буенча инспектор буларак, төрле семинарлар, очрашулар, хәтта артистларны чакырып концертлар оештыруга күп вакытын бирсә дә, йөгән кияргә өйрәтелмәгән яшь тай яисә шома балык кебек шуып чыгарга гына торган ирен гелән күз уңында тота. Ышанып, авызыңны ачып торсаң, ирсез калуың бик ихтимал икәнен ул тәгаен белә. Әкълиме әле генә Казан йә Әлмәт белән сөйләшә, шул арада кунаклар каршы алырга Чаллы аэропортына чыгып китә, вертолёт белән Әгерҗегә очканын күрми дә каласың. Гөлчәчәк аның эше шундый булуга күнегеп, үзен тыныч тотарга тырышса да, бер вакыйга аны, тәмам чыгырыннан чыгарып, «атакага» ташланырга мәҗбүр итә.

Алабуга урманының рәссам Шишкинны даһи киндерләрен тудыруга рухландырган бер җирендә, Әкълим Касыйм улы санаторий-профилакторий төзетә. Ул гамәлгә кереп, ял итүчеләрне кабул итә башлагач, табиб вазифасына, яшь, чибәр урыс хатынын алалар. Кемдер юриме, әллә чынлапмы, янәсе чибәркәйне хуҗа үзе махсус читтән алып кайткан дип, яңалыкны тиз арада тараталар. Һәм Гөлчәчәк ханымның колагына да ирештерәләр. Әкълимнең үз-үзен тотышыннан бу фараз аклангандай була. Ул бермәлне: «Әкълим Касыймович кая икән?» – дигән соравына сәркатиптән стереотип җавап ала: «Ул профилакторийга китте, ял итүчеләр, бүлмәләр салкын, йөрәк дарулары җитми, дип зарланалар, берсенең ашыннан чебенме, тараканмы чыккан, илләм тавыш купкан», ди. Икенче вакытта инде аның шиген көчәйтеп, каһәр суккан сәркатибе дә хуҗасын «сатмый» башлый: әйтмәде, белмим, күрмәдем, дип кенә котыла. Һәм вәссәлам.

Сәркатипне дә аңлап була, аны бит эшкә чибәр ханым түгел, ә профилакторий «тикшерүчесе» алды, ни өчен ул аны сатарга тиеш, ди. Дураков нема.

Гараждан бер буш машинаны алып, Гөлчәчәк шунда килеп төшсә, Әкълименең, аныңча, «эшен бетереп», профилакторийда тәртип урнаштырып, тараканлы ашны түгеп, машинасына чыгып утырган мәленә тап була.

– Әкълим Касыймович, сезнең профилакторийның медпунктын тикшерүдән, врачка тәлинкә тотудан башка эшегез калмадымыни? – дип, тавыш тембрын иң югары дәрәҗәгә куеп, корбанына сикерергә әзер арысландай, иренең өстенә килә Гөлчәчәк ханым.

Әкълименең сүздә булса да аны тыңлавына, санлавына, «Гөлчәчәк, Гөлчәчәк», дип торуына күнеккән ханым иренең янә бер сыйфатын ача. Ул хатынының беләгеннән каты итеп тота да кара «Волга»ның арткы утыргычына шып итеп кертеп утырта һәм тәрәзәләрне бикли:

– Син нишләп эш сәгатеңдә монда йөрисең? Кем чакырды, кем котыртты? Синең должность штатный расписаниедә юк, аны мин керттем, кыскарта да алам!

Тегесе:

– Әйдә, мине кыскарт та теге марҗаңны ал, – дигән сүз белән каршы тора.

– Минем арттан күзәтеп, көнчеләр сүзенә карап, тилереп йөрсәң, икебезне дә эшсез калдырасың. Сиңа шул кирәкме? Рәхәтеңә чыдый алмый башладыңмы? Каның куерса, салкын су эч!

Ирнең сүзләре кызу канлы ханымны тиз айнытып җибәрә.

– Ярый, киттек, гафу ит, – дияргә генә кала.

Язмышына буйсынган булып кыланса да, ничек кирәк, шулай итә, әмма профилакторий табибын эшеннән җибәрүгә ирешә ханым.

Әкълиме, М.Светловның «Гренада» балладасында югалтуны сизмәгән солдатлар шикелле, табибның кинәт «юкка чыгуын» белми дә кала, янәсе. Минем эшем булмаса да, бар кыюлыгымны телемә «төйнәп», сорарга җөрьәт иттем.

– Теге чибәр ханым профилакторийда күренми, әллә киттеме?

– Ул ышанычлы җирдә, аны Казанның алдынгы хастаханәсенә соратып алдылар.

«Сәяси мәйданнарны», тарлыкны ирләрен яратуга сылтаган хатыннар, аларга да, үзләренә дә өстәмә мәшәкать кенә тудыралар. Профилакторий табибын Гөлчәчәк эшеннән алдырткан, Әкълим аны төплерәк, яхшырак урынга урнаштырган. Дәгъвачыда хис, икенчесендә акыл шәрифләре өстенлек итә, ахыр чиктә, тамашада бар катнашучылар да канәгать. Инглизләр «happi end», диярләр иде. Ире өенә сөйләшенгән вакытта кайтмаса, Гөлчәчәк ханым аны телефоннан эзли, әлбәттә инде, таба алмагач, ничарадан бичара дигәндәй, ярсып безгә кереп җитә.

– Тәлгат Нәбиевич өйдә, минеке кайларда йөри икән тагын, телефоннары да җавап бирми, тәмам гаҗиз булдым инде, – дип чәпченүенә, Галия тыныч кына:

– Гөлчәчәк, нервыларыңны сакла, үзеңне юкка бетермә. Аның эше шундый, кайтыр! Мал да ашаган җиренә кайта... Әйдә әле, чәй эчеп алыйк, минем дә авызым кибеп тора, – дип, «ультра»ны тынычландырып, өенә озатып куя. Берничә минутка иртәрәк кайтып кергән ире юри тавыш күтәрә: «Инде күпме вакыт сине көтеп, ач утырам, кайларда браматта йөрисең?»

Гөлчәчәк ире кая сугылса да, аны җылы ризык көткәнне белә. Бигрәк тә өчәр-дүртәр көн шунда яшәп, эшли торган Менделеевск, Әгерҗе кырларына урнашкан буровикларга термослар белән алып барып ашату тәртибен кертә яңа НГДУ начальнигы. Аның да шуннан кайтуы икән. Кеше турында кайгыртсаң, үзеңә дә файдасы тия, дигәннәре шул була торгандыр инде.

Тулаем алганда, Мөхәммәтҗановлар гаиләсе белән чәй янындамы, телевизор карагандамы, сөйләшеп-аралашып утыру күңелне ял иттерә, вак-төяк хәсрәтләрне оныттыра, саф һавада, иркендә йөреп кергәндәй, кан тамырларын, сулыш юлларын киңәйтеп җибәргәндәй итә иде.

## Укытучы кайда да укытучы!

Советлар идарә иткән заманда коммунистлар фиркасендә, бигрәк тә Фикрәт Табеев беренче секретарь булганда, «партактив» дип аталган җыелышлар даими булып тора иде. Көн тәртибе нинди икәнлегенә нисбәтән, шәһәрләрдән, районнардан җаваплы әгъзаларны чакырып, алдан әзерләнгән докладчыны, кисәтеп куелган нотыкчыларны, куштан хуплаучыларны ифрат бирелеп тыңлаганнан соң, сыйланып алгач, рухланып эшебезгә таралыша торган идек.

1975-1976 еллар тирәсендә булган шундый җыелышка Әкълим Мөхәммәтҗанов белән мин дә чакырылган идем. Кышкы, буранлы вә җилле көннәрнең берсе. Кичке якта табигать, сез кем дә, мин кем дигәндәй, кырыс холкын күрсәтүне кирәк табып, дулавын аеруча көчәйтте. Без «Татнефть»нең тыйнак кунакханәсенә кереп капкаладык та, якты чакта юл алыйк, дип, Алабуга тарафларына чыгып киттек. Мин, әлбәттә, Казанда кунып, иртәнге якта кайтырбыз, дип карасам да, «Волга» машинасының хуҗасы нефтьче булгач, әлләни каршы тора алмадым. Ташлап китсә дә, берни эшләр хәлең юк.

Шул рәвешле, кичке сәгать бишләрдә юлга тәвәккәлләдек. Әле «КамАЗ» юллары, Нократ елгасы аша күпер турында хыялланган да юк. Гадәти авыл юлларының язгы, көзге, кышкы көннәрдәге «сөенечләрен» өлкән буын хәтерли булыр. Юл буйлап күрсәткечләрнең юклыгын искә төшереп тору да кирәкмидер. Әкълим дусның өенә ашкынган дәртле ышанычын миңа да уртаклашырга туры килде. Машина өр-яңа, ажгырып тора, йөртүчесе – Алабуганың иң данлыклы асы. Яктырак чакта шактый юл үттек. Зур тизлек белән автомобилебез көрт өемнәрен ерып кына уза. Мәгәр кәттәләнеп, гел йомшакта утырып кына бара алмадык. Эңгер-меңгер төшкәч, юлны югалткан очраклар да ешайды, төшеп машинаны төртергә, көпчәк асларын казырга, як-якка китеп, төп юлны эзләргә дә туры килгәләде. Тирә-якта ап-ак кар дәрьясы. Юлда машина димим, атлы юлчының да очрамавы турында сүз әрәм итеп әйтеп тә тормыйм. Ачы сызгырып килеп, буран машинаны да, үзебезне дә коендырып китә.

– Абзый, сүземне тыңламадың, кунып кына кайтыйк, дип күпме ялындым. Кай җәһәннәмебезгә шулай ашкынабыз? – «Хатыныңның җылы кочагын сагындыңмы», дип өстәмәкче идем дә, аның кырыс йөзенә багып, тыелып калырга акылым җитте.

– Сезгә нәрсә, арба ватылса – утын, үгез чирләсә – ит. Расписаниегез буенча дәресләр уздырыла тора. Укытучы килмәсә, студентка бәйрәм, дөнья җимерелми. Минем, әнә, өч буровойда буран аркасында ут өзелгән. Күпме зарар!

Шунда ук үзендә шаяртырлык көч табыпмы, ничарадан бичара дигәндәйме:

– Докладны да, чыгышларны да бик бирелеп, дөньяңны онытып тыңлап утырдың, нәрсә диделәр, «эшегезгә кайтып, икеләтә-өчләтә тырышлык белән хезмәт итегез», дип киңәш-нәсихәт бирделәр. Шуның өчен ашыгуым иде.

Бераз үкенгәндәй өстәп куйды:

– Бабайлар, вакыты белән бала-чаганы да тыңларга кирәк, дигәннәр, синең тәкъдим белән, ятып кына йоклыйсылар булган.

Шул арада тирә-якта йөренеп, юл эзләп килгән йөртүчесе:

– Без дөрес барабыз бугай. Әнә тегендә, буран аз гына ял иткән арада, ут күренгәндәй булды. Карагыз әле шул якка.

Егетебезнең күзе үткен икән, ерактa, әллә нәрсәләр вәгъдә итеп, ымсындырып, бүре күзе кебек кенә ут күренә. Без нәкъ шул утка «кайткандай», анда берәр якыныбыз өзелеп көткәндәй, Әкълимебез әмерен төшерде.

Тиз генә утырдык та, киттек шунда. Безне «чакырган» уты да алдавыч булды, тиз генә барып җитә алмадык, без алга үрмәләгән саен, уты да ераклашкандай тоелды. Янәдән ике-өч тапкыр төшеп, машинаны төртә, карны казый торгач, ут янына барып җиттек. Ул колхоз идарәсе булып чыкты. Инкыйлабка чаклы ук берәр кулак төзеткәнлеге, шактыйны күргәнлеге сизелеп торса да, халыкта ташпулат дип йөртелгән бина иде. Димәк, зур татар авылларының берсе икән. Ишек шакып, эчкә уздык.

Урындыкта, күзлеген борын очына төшереп, әллә төнге кизү, әллә җыештыручы – өлкән яшьтәге апа оныгына оекбаш бәйләп утыра. Гаҗәпләнеп, күтәрелеп каравыннан безне көтмәгәнлеген сизү кыен түгел иде. Без авылның кайсы районга кергәнлеген дә, исемен дә белмибез. Бик тәртипле генә исәнләшкәннән соң, буранда адашып калуыбызны аңлаттык.

– Без Алабугага кайтып барабыз. Мин НГДУ начальнигы булам, колхоз рәисе белән тоташтырыгыз әле?

Апабыз ашыкмыйча гына җепләрен, энәләрен күрше урындыкка куеп:

– Персидәтелебез өйдә юк. Казанда, – диде.

– Авыл советы рәисенә шалтыратсагыз иде.

– Ул да өйдә юк, каядыр кунакта.

Шунда мин дә, сүзгә катнашырга булып:

– Мин Алабуга пединституты ректоры булам, мәктәп директоры өйдәдер бит, аңа шалтыратыйк әле, – дим.

– Син дә диликтолмыни? Аны сразы атәсе иде? Хазер, хазер. Безнең диликтолыбыз мишәр генә булса да, бик яхшы, ачык кеше, – дип сөйләнә-сөйләнә, «диликтолның» телефонын җыя башлады.

– Буранда адашкан кешеләр килеп керде. Берсе әллә кем шында, берсе мин дә диликтол, ди. Килеп ал үзләрен!

Мәктәп директоры бик тиз килеп җитте. Урта яшьләрдәге, җыйнак гәүдәле, сүзчән ир-ат булып чыкты. Мине танып, икебез белән дә итагатьле итеп исәнләште. Безне дуамаллыгыбыз өчен, «кем инде шундый буранда төнгә каршы юлга чыга», дип әрләп алганнан соң, «ике йорт аша гына татар теле укытучысы яши, аңа чәй куярга куштым. Хәзер шунда барабыз», диде.

Үзенең ун ел элек, хәзер юкка чыгарылган Казан педагогия институтын тәмамлавы, укытучылар коллективының яртысы диярлек Алабуга пединститутында укып чыгуы, читтән торып белем алучылары да барлыгы, тагын әллә ничә баланың төрле факультетларда белем алуы турында мәгълүмат биргәннән соң, безне кунасы йортка алып китте.

Машинаны колхоз идарәсе янында калдырып, директор артыннан киттек. Тигез сары бүрәнәләрдән корылган якты, зур өйдә хуҗалардан башка тагын берничә кеше бар иде. Алары Алабуга пединститутын тәмамлаган, җирле мәктәптә эшләүче укытучылар булып чыкты. Миңа, өемә кайтып кергәндәй, илләм рәхәт булып китте.

Мәктәп хәлләре, уку еллары, укытучылары турында гәпләшкән арада барысы бергәләшеп төрле ризык белән тулы өстәл әзерләп өлгерделәр. «Чуваш малае» да үз урынын алды. Мин торып тост әйттем.

– Укытучылар, үзара тынгысыз яшәсәләр дә, кыенлык килгәндә берләшә, ярдәмләшә алалар. Чөнки алар иң гуман һөнәр кешеләре. Менә бүген дә безне туңып үлүдән коткардылар, – дип, шактый озын нотык тоттым.

Шул ук вакытта һәркайда игътибар үзәгендә торган Әкълим дусның укытучыларны артык мактаганны хупламавын, үзенә дикъкатьнең җитәрлек булмавыннан кара көюен сизсәм дә, бер рольгә кергәч, фикеремне әйтеп бетермичә туктый алмадым.

Әкълим Касыйм улы, бәлки, чыннан да арыган булгандыр, бәлки, ят-чит коллективта кызык тапмагандыр, гадәттә, бер-ике рюмкадан баш тартмый торган кеше, үпкәләп, авызын турсайткан нарасыйдай, аркама кагылды да:

– Иптәшләр, гафу итегез, мин бик арыдым, мөмкин булса, ятар идем, – диюгә, хуҗа аны такталар белән бүленгән бүлмәгә алып кереп, алдан әзерләп куелган урынга урнаштырып килде.

Без укытучылар белән әле бик озак сөйләшеп утырдык. Тәрбия фәненең без кагылмаган тармагы калмады кебек.

Аның каравы, Әкълим дус бик иртә уятып «үчен алды», гарьлеген чыгарды. Икенче көнне җил тынган, буран басылган булып, безне алырга аның вертолёты килеп җиткән иде. Без, хуҗалар белән җылы гына саубуллашып, Алабугага юл тоттык.

Буранда адашып йөрүләр, күптәнге танышларым, якын туганнарым кебек кабул итүләр мәңгегә җылы истәлек булып күңелдә калды. Тик менә авылның исемен дә, укытучыларның фамилиясен дә – берсен дә хәтерләмим. Язып та куймаганмын. Мәгънәсезлек димә, укытучыларның берәрсе, «диликтол», исән-имин булып, бу язмаларымны укып, Татарстанның Язучылар берлеге аша мине табып шалтыратсалар, яшьлегемә әйләнеп кайткандай булыр идем. Хәтта ул чорда «демагогия» дип кенә бәяләнгән партактивлар да сагындыра шул. Һәр шәйнең, хәтта буранда адашып интегүләрнең дә үз вакыты була икән.

## Бала күңеле далада

Мөхәммәтҗановлар Ринат, Ришат исемле ике ул үстерделәр. Олы улларын бик якыннан белмим. Алар Алабугага килеп урнашканда, егет Мәскәүдә укый иде инде. Шул дәвердә ул «дөньякүләм» тавыш-гауга чыгарып, тарихка кереп калды. Аның тулай торакта яшәгән вакыты. Дәрестән кайткач, бәрәңге турап, чуен табага салып, коридорда торган газ плитәсенә куеп, бүлмәсенә кереп китә. Әзер ризыгын алырга чыкса, ни күрсен, бер студент негр бәрәңгене рәхәтләнеп ашап тора.Тәмләп, кашык белән, авызын тутырып, бәрәңгене кызыл иреннәре аша корсагына озатып бетерә язган. Ач кешенең ачуы яман, дип юкка гына тел шомартмыйлардыр. Шул мизгелдә үк татар дуамаллыгы уяна да, Ринат озак баш катырып тормыйча, табаның сабыннан тота да бәрәңгеле ягы белән ашаучының башына тондыра. Негр егет чак-чак аягында кала, кан китә, ашыгыч ярдәм машинасын чакырталар. Башын бәйләп, дарулар биргән арада, чит ил студентларын карап торучы җаваплы адәм илчелеккә хәбәр бирә. Кеше бәрәңгесен тәмләргә яратучының кайсы мәмләкәттән икәнлеген (Мозамбикмы, Зимбабвемы) тәгаен хәтерләмим, зур тавыш күтәрелгәне әтисе аша миңа да мәгълүм булды. Милләтләр дуслыгы, артта калган илләргә ярдәм итү лазем дигән өрәк советлар иле сәясәтенең асылында ятты. Ректор Ринатның әтисен чакыртып, Мухаметзяновның институттан чыгарылуы турында приказны кулына тоттыра.

Дөрес, ярты елдан соң, тавыш тынгач, ректор егетне үз төркеменә үк кайтара. Приказ чыкканчы ук, декан шыпырт кына аңа лекцияләргә йөрергә, имтиханнарын бирә торырга рөхсәт итә. Егеткә яшәү урынын алыштырырга гына туры килә. Шәхси фатирда яшәп, аның каравы бәрәңгесен берәү белән дә бүлешмичә ашап, дипломын вакытында ала.

Әлеге вакыйгадан хәбәрдар кешеләр Ринатның бу кыюлыгын, «шул кирәк аларга, илебезгә хуҗа булып йөрмәсеннәр әле, чит-ят мәмләкәтләр, кара, соры халыклар алдында тез чүгеп яшәүгә чик куярга вакыт», дип хупладылар, сокландылар гына.

Бәлки, артында куәтле, абруйлы әтисе тормаса, гади авыл мокыты гына булса, Ринат та мондый адымга җөрьәт итмәс, тук негрга кырын караудан узмас, табада калганын күтәреп бүлмәсенә кереп кенә киткән булыр иде.

Әлбәттә, коммунист-җитәкче Әкълим ага сүздә Ринатның бу адымын хупламады, әмма соры яшькелт күзләре горурлык хисен яшерә алмадылар. Әз-мәз «зәмзәм суын» капкалап утырганда, ул мактанып куюны да гарьлеккә санамады.

– Йә, әйтегез, кайсыгызның улы әрсез негр башына чуен таба белән тондырганы бар?.. Дәшмисезме? Шул шул, андый кыюлыкны һәркем булдыра алмый.

Икенче улы Ришат, абыйсы шикелле батырлык майтара алмаса да, шулай ук чегән арбасыннан төшеп калган төссез егет түгел иде. Ул әтисеннән гәүдәгә кайтышрак булып, шундый ук бөдрә чәчле, тиктормас, хәрәкәтчән булуы белән хәтердә калган. Керү имтиханнарын уңышлы тапшырып, тиз арада студент вазифаларын үзләштереп, беренче курсны тәмамлаганда, чит телләр факультетында ул шактый популяр бренд студент иде инде.

Аның төрле музыка коралларында уйный белүе, факультет егетләре-кызлары белән уртак тел табуы үзешчән сәнгатькә җанлану кертте. Факультетның ул чордагы деканы, күренекле тел галиме профессор Фәрит Йосыпов Ришатны аркасыннан сыйпап, үз янында гына йөртте.

Дөрес, Ходай гәүдә җыйнаклыгы өстенә тел осталыгын да биргән, егет безгә дә, бигрәк тә әтисенә шактый мәшәкатьләр тудыра. Чөнки аңа пединститут рамкалары гына тар булып тоела башлый, тиздән ул мәдәни-агарту көллиятендә дә, милиция мәктәбендә дә үз кеше булып китә, өлкәнрәк курсларда шәһәр оркестрын оештыручыларның берсенә әйләнә, күрше Чаллы, Түбән Камада концертлар белән чыгышлар оештыра. Чит телләрне өйрәнүнең энә белән кое казу икәнен белгән әтисе укуыннан артта калыр дип борчыла. Гөлчәчәк ханым улы ишетмәгәндә нәгъръләр ора.

– Меңләгән кеше эшли торган коллектив белән җитәкчелек итүем Ришатны тәртәдә тотуга караганда җиңелрәк. Кич җиттеме, аны эзли башлыйм, кемгә охшагандыр шулхәтле?!

Әкълим ага риторик соравына үзе үк җавап та бирә.

– Мин үзем дә яшь чакта шук, тальянканы кулдан төшерми идем. Тик киләчәк тормышыңа кирәкле төп юнәлешкә – эшеңә, укуыңа зыян китерергә ярамый барыбер.

Шунда ук улына нисбәтән җылы сүзләрен дә таба.

– Ришат үзе бик игелекле, ярдәмчел, иркә малай. Соңарып кайтканда, ишектән керә-керешкә үк: «Әти-әнием, хәлләрегез ничек? Сезне сагынып, йөгереп кайттым. Милиция мәктәбенә музыка коралларын төзәтеп, күрсәтеп бирергә чакырганнар иде, шунда тоткарландым. Үзегез бит ярдәмчел булырга өйрәтәсез», – дип теленә салынуга, без җылыга тарган сары май кебек эрибез дә китәбез, әрләргә әзерләп куйган сүзләребез куактагы өлгергән чикләвек төсле, күңелдән шыбырдап коела да төшә.

Әкълим ага, йөзенә кырыслык касәфәте чыгаргандай булса да, улларын, аннан оныкларын ихластан яратты, булмышлары белән горурланып яшәде.

Үзен Мәскәүгә күчергәч, ике улын да шунда урнаштырып, фатирлы итеп калдырды. Ришат һаман да хәлләрне белешеп тора. Үзгәрмәгән. Шулай ук телгә оста, хәрәкәтчән, теләсә кем белән аралашыр сүзен таба торган үзебезнең Ришат булып калды.

## Яшьнәп яшәүгә ни җитә?

Мин үз гомеремдә бик күп кешеләр белән аралашып яшәдем, әмма Әкълим Мөхәммәтҗанов шикелле баскан җирендә бер дәкыйка да тик тора алмаган, дәртле кешене сирәк очраттым. Әйткәнемчә, ул бер үк вакытта кул куярга кертелгән кәгазьне карый, алдында утырган кешене тыңлый һәм шул ук вакытта телефоннан ниндидер саннарны җыярга мөмкин. Бераздан сәркатибенә кемнедер чакырырга, берсекөнгә баланс комиссиясен җыярга куша, каядыр барырга җыенып, машинасын чакырта. Алабугада эшләү чорында ул Казан,

Әлмәт түрәләре белән уртак тел таба, җылы мөнәсәбәт урнаштыра алды. Аерым алганда, Министрлар Советы рәисе, аннан соң фирканең өлкә, Үзәк комитет сәркатибе Гомәр Усмановның аның эшчәнлеген уңай бәяләве миңа мәгълүм. Ә инде ул чордагы «Татнефть»нең генераль директоры Ришат Булгаков белән дустанә мөнәсәбәтләренә мин күп тапкырлар үзем шаһит булдым. Улына аның исемен бирүе дә тикмәгә түгелдер, шагыйрь әйтмешли, йолдызларны кабызалар икән, бу гамәл кемгәдер кирәктер. «Татнефть»нең ул чордагы генералы (гади халык бу кәнәфине биләгән кешене шулай дип кенә атый) Булгаков ифрат зыялы, тыныч, бервакытта да тавышын күтәрми, ашыкмыйча, һәр сүзен уйлап әйтә, кыскасы, атаклы фамилияне йөртергә лаеклы шәхес иде. Әкълим Касыйм улы белән дуслыгым ярдәмендә, миңа да ул чордагы «Татнефть»нең генераль директоры, җыйнак гәүдәле, җитен чәчле Ришат Булгаковны күреп, аз булса да аралашып калырга насыйп булды. Нәрсәләр сөйләшкәннәре истә калмаган (мин әле өлкәннәр гәпләшкәнне мич башында тыңлап ятучы тыйнак малай гына), әмма Гөлчәчәк ханым биргән сорау һәм аңа җавап һаман хәтердә. Кичә нәрсә ашаганымны оныткаласам да, аларның сөйләшүе бүгенгедәй күз алдымда.

Һәр шәйнең асылына төшенеп ачыкларга яраткан Гөлчәчәк ханымның инде саубуллашыр алдыннан төп бер соравы калган икән.

– Ришат Тимергалиевич, сез чит илләрдә шактый йөреп кайттыгыз, әйтегез әле, кайда яшәве әйбәтрәк, андамы, әллә үзебезнең илдәме?

Булгаков фамилиясен йөрткән кешенең, «Татнефть» берләшмәсе генераль директорының җавапны тирәнгә кереп, череп бетүгә барган капитализмга агуын тамызып, җир, туган ил тартуы, совет чоры кодексы буенча, монда яраткан эшем, хөрмәт иткән коллективым, диюен көтеп утыруым «бушка» китте, ул тамагын кырып алды да, бик гади итеп әйтеп куйды:

– Кайда сине яраталар, шунда яхшы, Гөлчәчәк.

Мин соңрак кына төшендем, бу гадәти күренгән җөмләдә барлык сорауларга җавап җәйрәп ята икән. Череп баеп яткан капиталист сине ярата алмый, син үзең эшләгән җиреңдә, гаиләңдә генә хөрмәт таба аласың! Бетте-китте. Артыгын төпченүнең кирәге юк.

Әкълим дус белән икәү генә калгач, мин ихластан зарланып алдым.

– Булгаков кебек яңгыравык фамилияле кешеләргә рәхәт. Татарча яңгырый, русча да, бозмыйча, авыз тутырып әйтә алалар. Мәскәүдә кунакханәләргә урнашканда яисә үзебезнең Министрлыкта фамилиямне телдән әйткәч, «как, как, повторите», дип интектерәләр, документтан күчереп язганда да, еш кына азактагы «л» ны алга күчереп, «Галлиулин» дип язалар. Ишетүемчә, «Галлы» французча «әтәч» дигәнрәк мәгънәне белдерә. Син дә шул фамилияңне дөрес аңламау белән очрашасыңдыр әле.

– Юк, мин андый мәшәкатьне белмим.

– Ничек инде ул?

– Менә шулай.

– Мин кунакханәләрдә, офисларда утыручы Мәскәү туташ-ханымнары Мухаметзяновны әйтә алмый интегәләр, дип уйлыйм.

– Мин аларга, язу-сызу эшен башлаганчы ук, күчтәнәчне бирәм дә, фамилиям ике рус сүзеннән – «муха» һәм «мед»тан тора, шуларга мәгълүм «зянов» өстәлә, дип аңлатып куям.

– Кызык, – дигән булам, аның шаяртуын кабул итеп. – Ә бу сүзләрне татарча яңгыратсаң нәрсә килеп чыга?

Ул, күзләрен уйнатып:

– Бал өстендә чебен дигән мәгънә туа.

Җәһәт кенә як-ягына каранып алды да кинаяле көлеп өстәп куйды:

– Ә чебеннең кем икәнен үзең чамалыйсың булыр?

– Син фамилияңне аңлатуда җайлы алым тапкансың, ә миңа нишләргә: балым да, хәтта әрсез чебенем дә юк фамилиямдә.

– Филолог, галим исемен күтәреп йөрисең шунда рисвай булып.

– Соң? – дим, үпкәләргә дә өлгерә алмыйча.

– Синең фамилияң ике рус хатын-кызлары исеменнән тора бит.

– Юк, – дим үҗәтләнеп. – Гали – бөек дигәнне аңлата.

– Гарәпчә шулай булсын, ди. Синең фамилияңдә ике рус хатын-кызы елап ята: берсе – Галя, икенчесе – Уля (Ульянадан). Синең очракта беренчесе хатының булса, икенчесе бик яхшы танышың яисә берәр студенткаң булуы ихтимал!

Мин мондый шәрехләүне яраткан фамилиямне мыскыл итү дип кабул итеп, аның исеменә бәйләнергә булдым.

– Әкълимә исемле хатын-кызны күргәнем бар. Ә Әкълим дигән исемне очратканым булмады. Русларда Клим дигән исем, «клин» дигән сүз бар, шулардан алынгандыр инде!

Ул бу төрттерүемә үпкәләү түгел, исе дә китмичә, педагогларча аңлатып бирде.

– «Әкълим» – гарәп сүзе; «климат»тан азган, димәк, һава торышын аңлатучы кеше була инде ул. Тагын сорауларыгыз бармы, иптәш профессор? Булмаса, киттек чәйләргә, ризыгыбыз суынып бетеп, сөйләргә яраткан Гайҗан бабай көненә калуыбыз бар.

## Канатлыга – зәңгәр биеклек

Әлмәттә Ришат Булгаков белән күрешеп, озаклап сөйләшеп утыруыбыз минем өчен соңгысы булып чыкты. Үзен башка эшкә күчергәндә (кая киткәнен тәгаен әйтә алмыйм), ул бу олы вазифаны үтәүгә Мөхәммәтҗановны тәкъдим итә. Обком хуплый. Мин инде Алабугада аның белән киңәшеп, матди ярдәменә таянып яшәргә күнеккән идем. Шул хәбәр миемә килеп җиткәч, йөрәгем жу итеп китте. Шатланырга да, кайгырырга да белмәдем. Дустың, якын кешең үсүгә, әлбәттә, чын күңелдән сөенергә кирәктер. Ә борчылуым күбрәк институт мәшәкатьләре өчен иде. Шул рәвешле, бөтен Алабуга өчен, бераз күпертебрәк әйткәндә, якты йолдыз булып балкыган шәхес 1980 елда аны ташлап китте. Дөньямның бер өлеше убылып төшкәндәй булды. Ректор вазифаларын башкарган чорда (мин Казанга 1986 елда күченеп киттем) Әлмәттә эшендә дә, өйләрендә дә булгаладым.

Ул шундый гаҗәеп олы дәрәҗәгә ирешкәч тә, һәрхәлдә миңа нисбәтән үзгәрмәде, шундый ук гади, киң күңелле һәм ясалмалыкны кабул итмәгән ихласи кеше булып калды. Мин телефоннан хәбәр биреп, вакытны килешүгә, ул мине кабул итү бүлмәсенә чыгып каршы ала. Шул мәлдә, аңа йомыш белән килгән кешеләрдән, нинди гозер белән көтүләрен белешеп, берничәсенең мәсьәләсен шунда ук хәл итүенең дә шаһиты булганым бар.

Эш кабинетында минем белән аралашырга, сөйләшеп утырырга вакыт таба. Ерак юлны якын итеп анда хәтле килгәч, нинди мәсьәләне булса да чишүне сорамыйча кеше борчып йөрмисең. Бер килүемдә яңа төзелгән ашханәгә мебель

белән ярдәм итүгә, икенчесендә, улы укып чыккан факультетның лингофон кабинетларына магнитофоннар туплауга булышты. Ул чорда акча булса да, кирәкле әйберен табуы авыр иде, хәзер җаның теләгән тауар тулып ята, акчага кытлык. Минем белән дуслык җепләре бәйләсә дә, аның үзен кырысрак тотарга, эреләнеп китәргә дә мөмкинлеге бар һәм тиеш тә кебек иде. Ә хәзер шул дәрәҗәдәге кешегә эләгү өчен тәмугның җиде катын үтәргә кирәк, ягъни әүвәл урынбасарлары, күпсанлы ярдәмчеләре, сәркатипләре иләгеннән уза алсаң гына, «үзенә» язылырга мөмкин икән. Әле анда да кабул итәме-юкмы, бер Аллаһ кына белә.

Гафу, гафу... Сүзем яңа кәнәфигә утырган Әкълим Мөхәммәтҗанов турында иде. Ул җитәкчелек иткән 1980-1990 елларда «Татнефть» иң тотрыклы эшләп, кара май чыгару планын арттырып үти килде. Татарстанда эшләү генә аңа тар була башлады, ул үзенең тәҗрибәле белгечләре белән Көнбатыш Себердә нефть ятмаларын эзләү һәм чыгару эшенә кушылды.

Үз биләмәсендә нефть табучы һәр берләшмәдән үзләре өчен авыл хуҗалыгы нигъмәтләрен үстерүче юнәлешләр булдыруны, анда яңа технологияне куллануны таләп итте, тирәлекне, җирне, елга, күл, аеруча чишмәләрне пычратудан саклау юнәлешендә җитди эш алып барды һәм экология өлкәсендәге казанышлары өчен СССРның дәүләт премиясенә лаек булды.

Казанда мин әле гади укытучы вазифаларын үтәп йөргән чорда да, һәр килүендә, мине эзләп таба иде. Әкълим Касыйм улы үзенең «гадилектә бөеклек» дигән карашын үзгәртмәде. Үзенә аерым игътибар, коттедж яисә кәттә кунакханә таләп итмәде. Университеттан Профсоюз урамына төшкәндә, нефтьчеләрнең берничә гадәти бүлмәдән торган тукталу урыны бар, «Татнефть»нең яңа хуҗасы гел шунда тукталды. Телефон ашамы, машинасын җибәрепме, мине кунакка чакыргач, ашказаны бизләремне кызыл, кара уылдыкларга, каклаган казга, киптерелгән иткә, затлы колбасаларга, итальян сырларына, җиләк-җимешкә, әрчелгән чикләвекләргә, һич югында тәмле кәтлитләргә әзерләп килсәм, бар хыялларым «чәлпәрәмә» килә. Өстәлдә бөтен килеш пешерелгән, парын чыгарып торган бәрәңге, берничә шешә катык йә кефир, сыер мае һәм кара «Бородино» ипие торыр. Эчәсең килсә, тышына «Татарстан» дип язылган ак аракы булыр. Мин аның бу куышында берничә тапкыр булдым. «Бөдрә чәч»нең зәвыгы үзгәрмәде.

1990 елда аны Мәскәүгә, әле таркалып бетмәгән СССРның нефть сәнәгате министрының икътисад һәм чит мәмләкәтләр белән бәйләнышлар буенча урынбасары итеп күчерәләр. Ул яңа урында да элекке Әкълим – Тимәш авылы егете булып калды. Мин Казан дәүләт университетында Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы булып эшләгән дәвердә безгә, КДУ ректоры Ю.Коноплёв, проректоры М.Госманов белән, Германиягә Мәскәү аша барырга кирәк булды.

Әкълим Касыймович Татарстан поездыннан үзе каршы алып, башкала буйлап йөртте, каядыр алып кереп сыралар эчертте, ашатты һәм машинасы безне аэропортка озатып та куйды.

Мәскәүдә дә ул татар халкының йөзенә кызыллык китермәде, тырышып, җанын биреп эшләде һәм җитмешен тутыргач, пенсиягә чыгып, Әлмәткә кайтты. Тормыш иптәше Гөлчәчәк ханым иртәрәк вафат булгач, коттеджларын сатып, ике бүлмәле фатирда гомер сөрде.

## Фаҗигадән беркем хали түгел

Әлмәттәге пенсионер тормышыннан ул нигездә канәгать иде. Уналты яшеннән үз көнен үзе күреп, шул чор хәятенең үзәгендә кайнаган, бу хакта кайбер бушбугазлар кебек кычкырып йөрмәсә дә, милләт гаме, милләт хәсрәте белән яшәгән кешенең тынычланып, күзләрен зәңгәр экранга яисә түшәмгә багып кына, яисә көрәш темпын үзгәртеп яшисе дә килгәндер. Аның фани дөньядагы соңгы «тукталышында» – җыйнак кына ике бүлмәле фатирында энекәшем, медицина фәннәре докторы Әфхәт белән дә, аерым да ике тапкыр булдым. Табиб кеше аңа киңәшләрен дә бирде.

– Берәр ярдәм кирәкмиме? – дип сорауга, ул болай җавап тотты:

– «Татнефть», «Әлмәтнефть» егетләре мине ташламыйлар, өй янына гараж төзетеп куйдылар, матди яктан да ярдәм итеп торалар, күбесе заманында миннән тормыш дәресләре алган кешеләр, – диде ул, ярдәм итү ягына басым ясагач. Шул хакта сүз кузгалгач, аның беркайчан да кесә калынайту артыннан кумаганлыгын да искәртеп үтәсе килә.

Әзергә-бәзер яшәргә өйрәнгән кеше өчен мөһим нәрсәне – вакытында ашау-эчү мәсьәләсен дә хәл иткәннәр икән үзе үстергән хезмәттәшләре.

– Әлмәт нефть-газ берләшмәсе мине карап, көненә өч тапкыр пешереп, ашатып китүче бер ханымны эшкә алды. Стажы да бара.

Сөйләшә киткәч, ашын әзерләп, өен җыештырып йөрүче ханымның заманында Алабуга пединститутының чит телләр факультетын тәмамлаганлыгы мәгълүм булды.

Соңрак Әкълим Касыйм улының ул ханымга өйләнергә дә исәбе булганлыгы ачыкланды. Әмма, билгеле булганча, иң якын кешеләрнең арасын бозучы афәт – мал-мөлкәт бүлешү, нәфес җан җылысыннан көчлерәк, якыннары аның бу теләген хупламыйлар (фатир, гараж, затлы машина бар бит әле). Кем белә, бәлки ханым үзе баш тарткандыр. Кичке ашын ашаткач, караучысы өенә кайтып китә, төнлә Әкълим дусны йөрәге уята, ул даруын алырга дип кулын суза һәм шул килеш җан тәслим кыла. Кыскасы, 2004 елның 21 июлендә тынгысыз йөрәге тибүдән туктый.

Галәмәт зур эшләр майтарган, меңнәр белән идарә итеп, дөньяның тупсасына тибеп яшәгән затлар да гомерләренең соңгы мизгелендә иң гади игътибарга: бер йотым суга, бер сәдәф даруга, Коръән сүзенә мохтаҗлыкта үлә ала икән.

Гыйбрәтле язмыш. Караучы хатын янында булып, вакытында дару төймәләрен авызына каптырса, суын бирсә, беразга булса да, гомерен озайтыр, һич югы үлеме дә болай ук аяныч булмас иде.

Татар халкының гореф-гадәте, Ислам диненең кануннары буенча, газраил җанын алганда, янында якыны булырга, су йота алмаса, каз канаты белән иреннәрен чылатып торырга тиеш.

СССР һәм Татарстан югары советларының депутаты, әллә ничә орден-медаль иясе, РСФСРның нефть һәм газ сәнәгатенең атказанган хезмәткәре, әллә ничә шәһәрнең мактаулы гражданины, татар халкының горурлыгы, соңгы сулышын алганда, бер кашык суга лаек булмасын инде? Шул фактны күңелдән сызып ташлап булмый: легендар шәхесләрнең тормыш юлы сәер генә тәмамлана. Беркемгә үпкәләп тә, гаепләп тә булмый. Ул вакыттагы Татарстан Президенты М.Шәймиев премьер-министрның урынбасары Равил Моратов җитәкчелегендәге комиссиягә күмүне оештыруны йөкләде. Мин дә

катнаштым һәм, дусты буларак, татарча (бердәнбер) чыгыш та ясадым. Әкълим Мөхәммәтҗановны соңгы юлга озату бик югары, тантаналы дәрәҗәдә барды.

Казаннан килгән комиссия әгъзалары кунак-кунак уйнап калдылар, без улым Булат белән акрын гына юлга чыктык. Күңелдә нәрсәдәндер канәгатьсезлек, хакимияттән килгән кешеләргә битарафлык өчен рәнҗү хисе калды. Шулай моңланып, уйланып кайтканда, безне ДАИ машинасы туктатты. Күмүне «оештырган» комиссия аэропортка вертолёт белән кайткан да, аларның эскортына без юл бирергә тиеш икәнбез. Туктап көтеп тордык, кая барасың!

Милләте өчен җанын ярып бирергә әзер Мөхәммәтҗановлар дәвере яшьнәп узып китеп, кырыс базар, исәп-хисап чорына кергәнбез. Киләчәктә ни күрәсебезне бер Алла гына белә. Тик Әкълим дустым, төшләремә кереп, мине интектермәсен, безне көтеп, тыныч кына йокласын иде. Ул аңа лаек!

## Шәхес дәвамчыларында яши

Иң әүвәл сүзне «Шәхеснең көче нәрсәдә?» дигән сорауга җавап эзләүдән башлыйсы килә. Бу сөальгә төрлечә: ул үз халкы рухи һәм матди яктан үссен өчен игелекле эшләр башкарсын, туганнарына, дусларына ярдәм итсен, ата-анасының фатихасын алсын, балаларын әби-бабаларыбыз йоласында тәрбияләсен кебек бик күп гонсырларны атап булыр иде. Әйтелмәгәннәрдән иң әһәмиятлесе: көнчелекне белмәгән олылык, кешелеклелек һәм үзеңә лаеклы алмаш әзерләп калдыру. Бу яктан, гадәти калыпларга сыймаган Әкълим Мөхәммәтҗанов ифрат киң күңелле шәхес иде һәм җегәренең бер өлешен үзенә әхлакый якын, эшенә, халкына бирелгән алмаш әзерләүгә бирде. Аны «Татнефть» берләшмәсенә хаким итеп күчергәч (андагы чикләнмәгән мөмкинлекләрне иңләгәндә, «хаким», хәтта «хөкемдар» сүзе дә бәяләмә буларак туры килә кебек, ялгышсам, гафу итәрсез), Алабугага якын танышын, фикердәшен, үзеннән берничә елга гына яшьрәк Марс Җәләтовны җибәрде. Ул Мөхәммәтҗанов кебек киң колачлы, ярдәмчел булмаса да, минем «тегендә» хәбәр итү мөмкинлегемне уйлап булса кирәк, институтны ярдәменнән ташламады, бер үтенечемне дә, мөмкин булган тәкъдирдә, кире какмады. Бер мәсьәләдә хәтта тирәнгәрәк тә кердек. Физика кафедрасы белән берләшмә нефтьне судан һәм тоздан арындыру ысуллары буенча фәнни-гамәли эзләнүләр алып бардылар. Шул эштә катнашкан хезмәткәрләр, белгечләр өчен өстәмә түләү дә иде бу килешү. Тупланган акчага институтның кирәк-ярагына бер «Жигули» машинасы да юнәттек.

Мәскәүнең нефть-газ сәнәгате министрлыгында Әкълим Мөхәммәтҗанов шикелле белгечкә ихтыяҗ тугач, аңа мәркәзгә күчәргә туры килде. Теләп киттеме ул анда, юкмы, бар җаваплылыкны өстемә алып, кистереп җавап бирә алмыйм. Мәгәр иң авыр, четерекле, капиталистик мөнәсәбәтләргә кергән 1990-2000 елларда ул министрның турылыклы, эшчән урынбасары булып хезмәт итте.

Мәскәүгә, министрлыкка күчергәч, үз кәнәфиенә әүвәл белгечлеге буенча нефтьче, соңгы вакытта горком сәркатибе вазифаларын башкарган, ифрат игелекле, йомшак табигатьле Ринат Галиевне тәкъдим итә. Аның Әлмәт төбәгендә яшәүче язучыларның, аерым алганда, Баулы районының Кызылъяр авылында туып-үскән, ярдәмгә мохтаҗ Фәнис Яруллинның үтенечләрен бер даим дә онытмавы, бар мохтаҗлыкларын үтәп баруы турында тәгаен беләм. Ул вафат булгач, урынны Мөхәммәтҗановта баш инженер буларак тормыш

мәктәбе узган Шәфәгать Тәхәветдинов биләде. Аның белән Нурлат Сабан туенда очрашып танышсак та, якыннан озаклап аралашырга туры килмәде. Аңлавымча, ул мәгълүм киртәләрдән читкә чыкмый торган чын технарь иде. Бигрәк тә, Казанга күчкәч, аның белән аралашырга ихтыяҗ да булмады.

Хәзерге «Татнефть»нең хуҗасы Наил Маганов белән элемтәгә кереп карадым, чөнки Мөхәммәтҗановлар гаиләсенең бу фамилиягә мөнәсәбәтләре яхшы икәнен белә идем. Гөлчәчәк ханым аларны бик еш искә алуы хәтер сандыгында. «Магановлар чит илдә йөреп кайтканнар, аларга барып, бик озак сөйләшеп утырдык. Күңелле булды». Яисә: «Магановлар чакырганнар иде, шунда барырга җыенабыз»...

Фикер сөрешеннән аңлашылганча, сүз Наил әфәнденең атасы Өлфәт Маганов һәм аның гаиләсе турында бара иде. Нәкъ шуңа күрә, Әкълим Мөхәммәтҗановларны, аларның дусларын искә алу Наил Магановны кызыксындырыр, дип, бәлки наив хөкем йөртептер, аның белән элемтәгә кереп карадым, «танышлыгым», профессор Вахит Хаков әйтмешли, кампитр аша ярдәмчеләре, сәркатипләре белән аралашудан узмады. Рус телендә басылган ике томлыгымны бүләк итеп җибәргәч, ул вакытта ябык «Ак Барс» ширкатендә эшләгән хатыным Фәүзиягә, бер килүендә, китаплар турында уңай фикерен әйтеп калдырган.

Наил Магановның «Сәет Сакманов» трилогиясенә һәм берничә бәян белән хикәяләремә, «Замана балалары»ның ике кисәгенә юл уңаенда биргән бәясе минем өчен сөенечле булды. Ифрат тыгыз тормышта яшәүче сәнәгать кешесенең әдәбият белән кызыксынуы, аның күңел киңлегенә, мәрхәмәтле булуына ишарә ясый торган фал. Әлбәттә, өлкән Маганов, аның гаиләсе, Әкълим Мөхәммәтҗановка мөнәсәбәте турында фикер алышып утырасы килсә дә, барысы Аллаһ кулында, дип, бәянда телгә кергән башка «каһарманнарымның» әдәбиятка, гомумән, сәнгатькә мөнәсәбәте турында бераз сүз куертып алу зарур һәм урынлы дип саныйм. Әйтик, Әкълим Мөхәммәтҗановның төп сыйфатын – бер урыс сүзен дә катнаштырмыйча гаҗәеп саф, әдәби телдә сөйләвен ассызыкларга кирәктер. Аның җырга, гомумән, музыкага мөкиббән кеше икәнен искәрткән идем. Мәсәлән, ул – Илһам Шакиров, Рәшит Ваһапов, Әлфия Авзалова кебек бөек җырчыларыбызны җиргә иңгән фәрештәләргә тиңләп яшәде. Ул елларда Алабугага иң еш килә торган җырчы Хәмдүнә Тимергалиева булды. Әкълим ага артистны җирләрендә нефть чыгарылган колхозларга, совхозларга алып барып та концертлар куйдыртты.

Мин аны, мөмкин булган чикләрдә, хәзерге әдәбият, үзем өйрәнгән, Алабугада булгалаган С.Хәким, И.Юзеев, Ш.Галиев, М.Мәһдиевләр иҗаты белән таныштырырга тырыштым. Бер концерттан соң Сибгат абый белән бик озаклап әңгәмә корып утырганы хәтердә.

– Яраткан шагыйрең кем? – дигән соравыма хәйләкәр елмаюына төрелгән көтелмәгәнрәк җавап алдым.

– Бу соравыңа, кемнедер рәнҗетмәс өчен, җавап бирмим. Ә яраткан шигырьләрем бар. Менә сиңа бер өзек, – дип, кулын җилкә дәрәҗәсенә күтәреп, укып китте:

Югаргы басма мәгърур: «Мин югары, сез түбәнсез, – ди.
Ничек гали минем урным, түбәндәгеләр, күрәмсез?» – ди.
Бер адәм килде дә шул чакта әйләндерде баскычны:
Түбәндәге басмалар менде, югарысы түбән төште.

Тукай иҗатына мөкиббән хәлдә, шигырьләрен шактый анализлаган кеше буларак, «Баскыч» шигыреннән китерелгән өзекне таныдым. Поэзия белгече исемен күтәреп йөреп, өзекнең кайсы шигырьдән икәнен белмичә, ким-хур булуың бик тә мөмкин икән. Үзе үк өстәп тә куйды.

– Үткән гасыр башында язылган шигырь безнең хәзерге тормышыбызны үзәккә алган диярсең! Менә мин хәзер биектә утырам! Алабуганың (миңа төрттерү җаен да кулдан ычкындырмыйча), ректордан кала иң бай, иң мөхтәрәм кешесе. Иртәгә Казаннан йә Мәскәүдән килгән берәр түрә баскычны әйләндереп куярга мөмкин. Масаеп, борынны күтәреп йөрсәң, буровойга гади эшче булып китүең ихтимал. Тормыш куляса – бер әйләнә, бер баса, диләрме әле, мин анысына да әзер.

Һәм кинәт җилкәсен турайтып, күзләрен офыкка төбәп, кулын тагын да югарырак күтәреп, сөйләп җибәрмәсенме:

– Есть аул вблизи Казани, по названию Кырлай.
Даже куры в том Кырлае петь умеют... Дивный край!

– Тукай «Шүрәле»сендә Кырлай урманнарын күтәрә, ә ул Алабуганың Шишкинны рухландырган нарат урманнарын күрсә, ничекләр язган булыр иде.

Кыскасы, тирәнгә кермичә, шулай әдәбият, җыр сәнгатебез, хәтта педагогика мәсьәләләре турында «Онегин каенлыгы»нда йөргәндә сөйләшүләр еш кабынып китә торган иде. Сәнәгатьченең нигез белеме педагогик көллият булу аны зыялыларга, халыкка якынайтып торучы бер «баскыч» иде.

Аны алыштырган Марс Җәләтовның урта белемне саф татар мәктәбендә алуы, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Әпсәләмов кебек язучылар иҗатыннан хәбәрдар булуы татарча затлы сөйләшүеннән сизелеп тора иде. Яраткан шагыйре Такташ икәнлеге ачыкланды. Ул аңа үз бәясен дә бирде.

– Ул – күкләр, фәрештәләр, газраилләр, таң кызлары, кылычы канга баткан баһадирлар белән уртак тел тапкан шагыйрь. Ул... ул... татар поэзиясенең Зевсы, ягъни алласы.

Алабугадан аны Әлмәт нефть берләшмәсенә күчерделәр, кем әйтмешли, лаеклы ялга чыккач, ул «Татнефть» «генералының» киңәшчесе вазифаларын башкарды.

Хәзер менә шул олы затларга алмашка килгән Маганов Наил Өлфәт улын да үз милләтенә, аның гореф-гадәтләренә турылыклы, дөнья сере – китапта, дип ышанган шәхесләрнең берсе, дәвамчысы кебек кабул итәм. Нинди халык баласы икәнен онытмыйча, элгәреләрнең җанлы традицияләрен үстереп яшәвен теләп, бәяныма нокта куям. Әлегә...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ТАБЫШМАКЛЫ ГОМЕР ИЯСЕ

Кырлай авылыннан Җаек (Уральски) каласына алырга килгәндә, «мин ян тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә» укып утыра идем», – дип язып үтә Г.Тукай үзенең «Исемдә калганнар» әсәрендә.

*Һәр китапларның арасында*
*Сөеп укыганым «Газизә».*
*Салкын йөзләрдин, җаман сүздин*
*Бәнем җан гынаем да бик бизә.*

1860 елларга караган бер кульязмада әнә шундый юллар бар. Биредә дә сүз шул ук «Рисаләи Газизә» китабы турында бара.

Филология фәннәре докторы, профессор Габдрахман Таһирҗанов: «Рисаләи Газизә», кульязма килеш бик күп таралудан тыш, әллә ничә тапкырлар басылган да, һәм ул дистәләрчә мәртәбәләр нәшер ителгән «Кыйссаи Йосыф», «Кисекбаш», «Бәдәвам», «Нәсихәт-әс-салихин», «Рәүнәкъ-әл-ислам» китаплары белән бергә авыл мәдрәсәләрендә дәреслек булып хезмәт иткән»[1], – ди.

Г.Рәхим белән Г.Газиз дә аны «безнең татарның бик яратып укый торган китапларыннан берсе»[2], – диләр. «Казан утлары» журналының 1966 елгы 1 нче санында Н.Исәнбәт язуына караганда, бу китап Таҗетдин Ялчыгол углы тарафыннан язылган. Монда хата киткән: Минзәләбаш авылын Татар Җиреклесе, Кызыл Чапчак, Мәлем авылларында, дип уку кирәктер.

Кем соң ул Таҗетдин Ялчыгол?

Аның турында элек тә, хәзер дә матбугатта мәгълүматлар чыгып тора. Ул Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин кебек мәшһүр галимнәрнең игътибарыннан читтә калмаган. Әдәбиятчылардан Г.Рәхим, Г.Газиз аның иҗатын өйрәнгәннәр. Соңгы чорда А.Фәтхи, М.Госманов, Х.Миңнегулов, М.Әхмәтҗанов, М.Гайни-Лабити хезмәтләрендә Таҗетдин Ялчыгол иҗаты чагылыш таба. Башкортстанда Ә.Харисов, И.Галәүетдинов һәм башкалар аның хакында, әсәрләренең теле турында язып чыктылар.

Г.Ибраһимов аны «ике халык арасыннан чыккан», ягъни татар һәм башкорт халкы арасыннан күтәрелгән әдипләр рәтендә искә ала[3]. Г.Рәхим һәм Г.Газиз тарафыннан төзелгән «Татар әдәбияты тарихы»нда аның турында күп мәгълүмат бирелсә дә, аларның шактый төгәлсезлеген күрсәтергә кирәк. Мәгълүм булганча, Таҗетдин Ялчыгол үзен «Рисаләи Газизә» китабында «аз азыклы, күп языклы Көдәй халкының галиме», дип атый. Шуннан чыгып, Г.Рәхим белән Г.Газиз «Көдәй» Таҗетдиннең «ихтимал мулла булган авылының исемедер»[4], – диләр.

Профессор Г.Таһирҗанов та, «Кәди халкының» дигәндә, бу сүз артына сорау билгесе куя. Әхнәф Харисов китабында әлеге сүз юл хәрефеннән башланган «гидай» сүзенә әверелгән. Монда инде «гидай» – теләнче, хәерче, саилче, ярлы дигәннәрне аңлата, ягъни Таҗетдиннең ниндидер ярлы, хәерче халыкның галиме дип аңларга тиеш булабыз.

Чынлыкта исә, Көдәй – бер ыруның исеме. Мәсәлән, XVII-XVIII гасырларда бу ыру дүрт нәселне: Төрекмән Көдәй, Урман Көдәй, Шайтан Көдәй һәм Бәләкәй Көдәй нәселләрен берләштергән. Берничә йөз ел элек бу ыру Әй елгасы буенда яшәгән әйлеләр составына кергән. Әйле ыруының шәҗәрәсенә караганда, Т.Ялчыголның дистәләгән төп бабасы әнә шул Әй елгасы буенда тереклек кылган.

Аның хакында безгә мәгълүм биографик мәгълүматлар бай булмаса да, алар бу

[1] Таһирҗанов Г. Әдәби багланышлар һәм аларның нәтиҗәләре // Казан утлары. – 1975. – №10. – Б.131.
[2] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. – Казан, 1925. – Б.156.
[3] Ибраһимов Г. Әдәби тел мәсьәләсе яңадан күтәрелә // Кызыл байрак. – 1923. – 8 май.
[4] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. – Казан, 1925.

шәхесне асылда аңлау һәм аны үзе яшәгән иҗтимагый шартларга куеп, шул чор сыйныфларының ихтыяҗлары белән бәйләнештә караганда, тормышының төп мәгънәсен дөрес билгеләү өчен җитәрлек, дип әйтә алабыз.

Тормыш төрле һәм катлаулы булган кебек, тарихи шәхесләрнең дә язмышы катлаулы һәм төрле. Кайчакта шулай була ки, аларның кайберләре турында әйтелергә тиешле уңай фикерләр әйтелмичә кала, чөнки әлеге шәхесләрнең шәхси тормышларындагы кайбер нюанслар тоткарлый.

Соңгы вакытта Таҗетдин белән дә шулайрак килеп чыкты. М.Госмановның 1972 елны Казанда басылган «XVII-XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары» дигән китабында («Тәварихы Болгария» әсәренә багышланган бүлектә) язучыга карата тирән эзләнүсез бирелгән бәя нәтиҗәсендә, Таҗетдиннең «ачы бал эчеп, кинәт кенә үлүе турында»гы хәбәре – «исерек хәлендә үлгән» дигән «сенсация»гә әйләнә. Әйдәгез, асылына төшенеп карыйк. Ш.Мәрҗани аның турында болай яза: «Сәяхәте вакытында дусларыннан берәүнең йортына кереп эчәргә сорады, өй хуҗасы ачы бал китереп биреп, шуны эчеп, кинәт кенә Имәнле исемле авылда вафат булып, каберлегендә күмелде»[5]. Р.Фәхреддин Таҗетдиннең 1838 елның 26 июнендә (һижри белән 1254 ел, рәбигыль-ахир аеның 14 нче көне) үлүен генә яза[6]. Вафатының ни сәбәптән икәнен телгә алмый. Югыйсә, ул да бит Ш.Мәрҗанине кабатлый алгандыр. Мәсьәлә монда катлаулырак. Җимешле агачка таш аталар дигәндәй, үзе муллалык иткән авылдан 30-40 чакрым читтә кинәт кенә үлгәнлектән, заманында аның үлүе хакында төрле авылда төрле хәбәр таралган. Шундый хәбәрләрнең берсе: исереп, эчеп үлүе хакындагысы, Таҗетдинне күралмаган муллалар, мөәзиннәр тарафыннан күпертелеп җибәрелүе дә гаҗәп түгел. Мөгаен, әнә шундый хәбәр Ш.Мәрҗанигә дә барып ишетелгәндер. Ә инде айлар, еллар үткәч, хакыйкать өскә чыккан, һәм Р.Фәхреддин дөреслекне аңлаган хәлдә, мәсьәләне күпертеп торуны кирәк тапмаган, шуңа күрә аның кайсы авылда, кайчан үлүе турында гына хәбәр иткән.

1914 елның 27 апрелендә «Шура» журналына җибәрү өчен язылган «Мөдафәга»да (яклау язуы): «...Зәй буе тарафларына барып кайтканда, Таҗетдин Имәнлебаш дигән авылда Габдессәлам дигән бер танышына кунарга керә. Иртән намазга барып кайтканнан соң, алар чәй эчәргә утыралар. Шунда бер касә чәй эчеп, әллә нигә кәефем үзгәреп тора әле, дип, ястыкка таяна һәм озак та тормый үлеп тә китә», – дип язылган. Аны Югары Мәлем авылының имамы, Таҗетдин оныкларыннан берсе, Һидиятулла Таҗетдинов бабасының үлемен үз күзләре белән күргән Вәлид дигән кеше авызыннан үзе ишеткән буенча язган.

Менә болардан чыгып, без Т.Ялчыголның кинәт кенә үлүен әйтә алабыз. Тарихтан билгеле булганча, Таҗетдин яшәгән дәвердә, бигрәк тә төрки халыклар арасында феодализмга хас йомыклык, караңгылык, томаналык һәм дини фанатизм бик нык хөкем сөрә. Патша Россиясе алып барган реакцион сәясәт татар һәм башкорт халкындагы иҗтимагый фикер үсешен нык тоткарлый. Халык массалары реаль тормышта аз гына да бәхет чаткылары әсәрен күрмәгәч, чын бәхетне, рәхәтне – хыялый теге дөньядан өмет итә. Суфыйчылык, ишанлык кебек күренешләрнең тамыр җәюен дә нәкъ әнә шуның белән аңлатырга кирәк.

Без аның кайда һәм күпме торуы хакында, нигездә, үзе язганнарга таянып фикер йөртәбез. «Тәварихы Болгария» дигән әсәрендә («Тарихнамәи Болгар» исеме белән дә билгеле) ул үзенең шәҗәрәсен яза. Бу әсәр безгә теге яки бу дәрәҗәдәге тарихи чыганак буларак кына түгел, авторының үзе турында китергән мәгълүматлар җәһәтеннән дә кызыклы.

Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең кульъязмалар бүлегенә татар археографы С.Вахиди тупланмасыннан кергән бер кульъязмадагы (587 сакл. бер.) шәҗәрәдә Таҗетдиннең үзе турында тагын да тулырак мәгълүмат китерелгән. Кульъязмадан күренгәнчә, Таҗетдин Ялчыголның 4 малае, 3 кызы булган (Бәһаветдин, Җәлалетдин, Шәрхенетдин, Госаметдин, Бибинәфисә, Газизә, Җәмилә).

Таҗетдиннең үзе турында кайбер мәгълүматлар аның «Рисаләи Газизә» дигән китабында да бар. Бу китап 1796 елда язылган һәм үз дәверендә, күчерелә-күчерелә, халык арасында киң таралган. Ул Бохара суфые Аллаярның (1713 елда вафат) «Сөбател-

[5] Мәрҗани Ш. Әл-кыйсьмес-сани мин китаби «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». – Казан, 1900. – Б.250.
[6] Фәхреддин Р. Асар. – Оренбург, 1904. – Б.336.

гаҗизин» («Көчсезләрнең ныклыгы») исемле шигъри әсәренә комментарий (шәрех) рәвешендә язылган. Китап исламны тануга һәм тотуга, аның тарихына, ахирәткә багышланган. Бер үк вакытта бу әсәрдә дөнья тормышына, әдәп-әхлакка карата да фикерләр әйтелгән, мәсьәләне тулырак яктырту өчен, хикәятләр китерелгән. Боларны Таҗетдин үзе өстәгән. Бәлкем, нәкъ менә шуның өчен дә Ш.Мәрҗани «Рисаләи Газизә» авторының «Сөбател-гаҗизин»не ялгыш шәрехләве турында сүз алып барадыр.

Мәгълүм булганча, Аллаярның борынгы Идел буе төркисенә шактый якын, ләкин үзенә генә хас үзенчәлекләре булган «чыгтай шивәсендә» язылган бу әсәрен Утыз Имәни дә 1782 елда гарәпчә шәрехли.

Ләкин тегесе дә, бусы да киң массага рәхәтләнеп аңларлык булмый. Кешеләрнең әлеге әсәрне ана телләрендә аңлатып бирүе турында ялваруына Газизә исемле кызының үтенече дә өстәлгәч, Таҗетдин бу китапка аңлаешлы төрки телендә тәфсилле аңлатмалар бирә. Китап шул чор мәктәпләрендә тел-әдәбият дәреслеге сыйфатында кулланылып йөргән. Язылып, кырык елдан артык вакыт үткәч (хәтта Таҗетдин үзе үлеп, 9 ел узганнан соң гына), ул 1847 елда Петербургта басылып чыга. Казан император университеты типографиясендә 1850 елда нәшер ителә һәм шуннан соң Казанда күп мәртәбә (соңгысы – 1916 елда) бастырылып таратыла. Аның В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз китапханәсендә ундүрт басмасы саклана. «Рисаләи Газизә»нең язылу формасы эчтәлегенә тулысынча туры килә. Әгәр дә шигъри калыпта язылган Аллаяр тексты көйләп укыганда, илаһилык төсе алып, хискә тәэсир итсә, Таҗетдин комментарийлары аз гына булса да дөньяви фикерләүне кузгатып җибәрәләр. Бу китапның халыкта күп таралуына һәм аның яратылып укылуына әнә шул сәбәп тә инде. Чөнки ул чын мохтаҗлыкта һәм караңгылыкта яшәгән кешеләргә әзме-күпме рухи азык биргән, якты тормышка өметләрен өздермәгән.

Таҗетдин Ялчыгол проза өлкәсендә дә, шигърияттә дә шактый хәбәрдар булган. Ул, милли әдәбиятыбызда беренчеләрдән булып, татар кыллы инструментларына игътибар итә. Мәсәлән, Таҗетдиннең Сарман районында табылган бер кулъязма әсәрендә татарлар арасында киң таралган гөслә, скрипка, думбра һәм әриләнең рәсемнәрен бирүе карашларының киңлеге, татар мәдәнияте белән якыннан таныш булуы турында сөйли[7].

Таҗетдин нәселе кешеләре тапшырган иске кулъязмалар арасыннан табылган шигырьләр арасында улы Җәлалетдин хәзрәт язган бер шигырь аеруча игътибарга лаек. Ул Таҗетдин үлгәннән соң язылган. Һәр икеюллыкның беренче юлы, баш хәрефләрен бергә җыйсаң, «Вәләд Таҗетдин» дигән сүз килеп чыга. Әлеге телестихта Таҗетдингә реаль бәя бирелгән. Бу шигырьдән аның Зәй буенда берничә еллар йорт-җир белән тереклек итүе, балаларының Кызыл илдә (ягъни Кызыл Чапчакта) үскәнлеге, Таҗетдиннең исеме танылган булуы, бер үк вакытта аның диндар икәнлеге, күп китаплар өйрәнеп белем алуы һәм зур омтылыш белән дәрес бирүе әйтелгән. Шул ук вакытта дөньяны сөймәве һәм әһлене (биредә ил түрәләрен дип аңларга кирәктер) дус тотмавына басым ясалган. Бу юллар Таҗетдиннең «Рисаләи Газизә»гә язган кереш сүзендә үзе турында «адәмиләр арасында дошман тотылган, барча эшне Ходага тапшырган» дигән сүзләре белән аваздаш яңгырыйлар.

Таҗетдин Ялчыгол һиҗри белән 1240 елда Югары Мәлем авылына күчеп килгәч язган һәм «Тәфсире Сидрәт ел-мөнтәһа» дип аталган «Һәфтияк» тәфсиренең бер кулъязма нөсхәсендә шагыйрь һәм күренекле рухани Гали Чокрыйның (1828-1889) үзенең шәкертләре һәм укучылары өчен иҗат ителгән бер шигыре теркәлгән. Ул заманында шактый танылган дин әһелләрен олылап язылган. Яртысыннан күбесе Таҗетдин хәзрәт турында.

1785 елны әтисен хәзерге Мамадыш районына кергән Кече Сөн авылында җирләгәннән соң, Таҗетдин Кама аръягына чыгып, шунда төпләнеп кала. Моның үз сәбәпләре бар. Беренчедән, аңа әтисе кабере тирәсеннән ерак китмичә, йорт-җир белән яшәргә һәм елына ике мәртәбә каберен зиярәт кылырга васыять итә. «Тәварихы Болгария» әсәрендәге шәҗәрәдән күренгәнчә, «Шартларымны үтәмәсәң, әбәд разый дәгелмен» дип кисәтә әтисе. Икенчедән, бу якларда аны якынрак аңлаучы халык була. Ул башта Татар Җиреклесе (Түбән Кама районы) авылына (хәзер бу авылны Каенлы

[7] Монасыйпов Ш. Сызылып кына моң чыкканда // Казан утлары. – 1977. – №2. – Б.158.

дип йөртәләр) күчеп килә. Аннан ул Кызыл Чапчак (Түбән Кама районы) авылында яши, крестьян балаларына дәресләр бирә. Соңыннан Югары Мәлем (хәзерге Зәй районы) авылына күчә һәм муллалык итә.

Тагын моңа кадәр күтәрелмәгән бер нәрсәгә тукталып үтмичә булмый. Әдәбият тарихында Таҗетдин Ялчыгол дип мәгълүм булган бу шәхеснең фамилиясе ничек соң? Яхшыкол дигән фикерне алга сөрүчеләр дә бар. Моңа этәрүче сәбәпләрнең иң зурысы – кабер ташындагы язмалар.

Зәй районының Имәнлебаш авылы зиратындагы кабер ташында аның Яхшыкол углы икәнлеге һәм 1838 елда вафат булуы бәян ителә. «Ташка басылган бу мәгълүматлар аның үлү елын («Башкорт шәҗәрәләре»ндә һәм кайбер башка чыганакларда ул 1837 ел дип бирелә) төгәл күрсәтү белән бергә «Яхшыкол» дигән исеме турында уйландыра.

Сарман районы Игәнәбаш авылында 1975 елның җәендә табылган, хәзер Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында саклана торган кулъязма җыентыкта Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихе Болгария»се бар. Китапның кырыена: «1838 елда сәратан йолдызының 21 нче көнендә ... мәзкүр Мәлем карьясында тереклек идүче мелла Таҗетдин (бине) мелла Яхшыколый хәзрәтләре Зәй буенда маризларә *(авыруларга. – Д.Г.)* дәва идеп йөрдеке вакытында Зәй суы карбендә *(янында. – Д.Г.)* Имәнлебаш карьясында вафат булып, анда дәфен улынмышдыр», – дип язылган.

Таҗетдин Ялчыголмы, әллә Таҗетдин Яхшыколмы? Р.Фәхреддиннең «Асар»ында Таҗетдиннең тәмамланган китаплары ахырында язып беркетелгән гыйбарәләре китерелгән *(336-337 битләр)*. Анда ул Таҗетдин бине Яхшыкол әл-Болгари әл-Иштәки формасында китерелә. Бер хатында профессор Г.Таһирҗанов Таҗетдин хәзрәтнең хаттат Сәгъдетдин күчергән язмаларын күргәне булуын, анда Таҗетдин Яхшыкол, дип язылуын хәбәр иткән иде. Сәгъдетдин Таҗетдиннең замандашы һәм дусты, аның белән бергә гәпләшеп, фикер алышып яшәгән Имәнлебаш авылы кешесе булырга тиеш. Авылдашларының әйтүенә караганда, ул «атаклы китап күчерүче» булган. Зиратта әле хәзер дә Таҗетдин кабереннән 20 метр гына читтә, яше йөздән арткан куш чыршы астында «Сәгъдетдин бабай кабере» сакланган. Сәгъдетдин Таҗетдин атасының исемен яхшы белгәндер, дип әйтәсе килә. Әмма ул, Яхшыкол, Ялчыгол исемнәрен бердәй күреп, бу исемнәр киләчәктә бәхәс тудырыр дип уйламагандыр да. Ә менә 1987 елда язучының Сармашбаш авылы мулласы Н.Җәмилевтән табылган таш мөһерендә дә «Таҗетдин Ялчыкол углы» дип язылган. Бу инде яңа бәхәсләргә урын калдыра шикелле...

Таҗетдин Ялчыгол кайчан һәм кайда туган? Моңа кадәр аның 1838 елда вафат булганлыгын гына яздылар. Каберенә куелган беренче ташка 1838 елда бакыйлыкка күчкән, диелгән. Ризаэддин бине Фәхреддин «Асар» дигән хезмәтендә Таҗетдин хәзрәтнең 1768 елда дөньяга килеп, 1838 елның 26 июнендә 71 яшендә вафат булуын әйтә.


Әдип сүзләренә ышанмаска мөмкин түгел. Аның әнисе Нурҗамал ахун Габденнасыйр кызының бертуганы Таҗетдин хәзрәтнең улы мулла Һидиятулла никахында була. Ризаэддин бине Фәхреддин, әлбәттә, Таҗетдин Ялчыголның үлгән көнен бик төпченеп ачыклагандыр. Ә аның туган елы һәм кайда тууы табышмак булып калган. Хәер, Таҗетдин хәзрәтнең кайда тууы, гомумән, бернинди басма әсәрләрдә дә юк.

Танылган галимебез, филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегулов «Мәгариф» журналында *(2001 ел, №9, 19-20 б.)* болай яза: Таҗетдин Ялчыгол якынча 1768 елның октябрендә, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Әй һәм Арша елгалары арасындагы «Курмаш-елга авылында» дөньяга килә... Фәндә Таҗетдин Ялчыголның туган җирен Троицк, Орск төбәкләренә бәйләп карау да бар».

Зәй районының Иске Пәнәче авылында табылган кулъязмада Таҗетдиннең Минзәлә районы Тауасты Байлар авылында тууы күрсәтелгән. Икенче бер мәгълүмат буенча, Кукмара ягында туган, дип әйтергә мөмкин. Мин 2009 елда аның турында «Чырагы нур сибә бүген дә...» дигән китап бастырып чыгардым. Әмма, тырышып карасам да, туган авылын ачыклый алмадым. Эзләнгән эзгә төшәр, дигән дә хак икән, китап чыкканнан соң да, әлеге әдипнең туган авылы белән кызыксынып яшәдем.

Марсель Әхмәтҗанов: «Таҗетдин бине Ялчыгол 1760-1770 елларда Мулла Морат исеме белән барган азатлык хәрәкәтенә бәйле гаиләдә тәрбияләнә», дип әйтә *(Татар шәҗәрәләре. – Казан, 1995,*

*2 б.)*. Моны кире кагып булмый. Ә менә Таҗетдин хәзрәтнең соңрак буын кешеләрендә яшәп килгән бер риваятьне өстәргә булыр иде. Алар ерак бабалары Ялчыгол хәзрәтнең (әле Ялчыгол абыз, дип тә әйтәләр) Пугачёв «явында» катнашуын һәм, бу азатлык хәрәкәте бастырылгач, җәзадан качып, Кавказ ягына чыгып китүе турында сөйлиләр.



Алты томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның тәүге томында *(Казан, 1984, 443-452 б.)* М.Гайнетдинов: «Сизелә ки, әдип үз биографиясендәге халык мәнфәгате белән бәйләнгән кайбер якларын яшерергә тырыша», – ди. Нәрсәне һәм нигә яшерергә тырышкан соң Таҗетдин хәзрәт? Әлбәттә, ул этисенең XVIII гасырның икенче яртысында тарихта тирән эзләр калдырган азатлык өчен күтәрелгән халык яуларында катнашуын әйтергә теләмәгән. Аларда катнашучыларны хөкүмәт бу вакыйгалардан соң әле бик озак еллар эзәрлекләгән. Менә шуңа күрә дә, М.Гайнетдинов бик дөрес билгеләп үткәнчә, этисе үлгәннән соң да, ул «Әй буеннан» этисен, туганнарын, ыругдашларын эзләп табып, алар белән йөрешеп, аралашып яшәүне исенә дә китерми. Җир дә аңа «Әй буеннан» түгел, Тымытык тирәсеннән генә бирелгән була. Ялчыгол нәселен дәвам итүчеләр әле бик күп еллар әнә шул Тымытык тирәсендәге Чалпы авылы янында иген иккәннәр, уңыш үстергәннәр. Ялчыгол хәзрәт үзе бу якларда кирәйетлеләр кабиләсеннән булган, Нугайбәковлар фамилиясенә исем биргән Нугайбәк һәм аның уллары белән аралашып яшәгән.

Күрәсең, Нугайбәк Хәсәнов белән алар фикердәшләр булгандыр. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Пугачёв кузгалышы вакытында Нугайбәк патша армиясендә командир – старшина хезмәтендә торган. Аның отрядын баш күтәрүчеләргә каршы җибәрәләр. Әмма ул үзенең командасы белән алар ягына чыга. Хәтта 1774 елның 14 гыйварында алар Зәй ныгытмасын ала.

Восстание бастырылгач, Нугайбәкне дә кулга алалар, һәм ул асып үтерүгә хөкем ителә. Фәкать могҗиза белән генә исән кала. Мондый хәлләрдән соң Ялчыгол хәзрәткә улы Таҗетдинне ияртеп чыгып качудан гайре чара калмаган.

Дөньялар тынычлангач, алар хәзерге Татарстан җиренә кайтып утыра. Ялчыгол хәзрәт 1785 елда Кече Сөн авылында вафат була. Таҗетдин исә, Кама аръягына чыгып, авылларда муллалык итә. Ул үзенең туган ягына да баргалап тора, элекке танышлыкларын ныгыта. Кантон башлыгы Хөрмәкәй Нугайбәк улы чакыруы буенча барып, 12 нче кантонда дини йолаларның, ислам кануннарының үтәлешен күзәтә, дин әһелләрен берәм-берәм күреп тә, бергә җыеп та сөйләшүләр уздыра. Шундый ук миссияне янәшәдәге 2 нче кантонда да башкара.

Казанга, Уфага, Оренбургка юлым төшсә, беренче эш итеп архивлар ишеген ачып керәм. Шундый «командировка»ларның берсендә XIX гасырның 20 нче елларына кагылышлы кәгазьләр белән танышырга туры килде. Ниһаять, калын-калын зәңгәр кәгазь битләрендә үземне күп еллар биләп торган сорауга җавап таптым.

1820 елның 13 августында дворяннар утырышчысы Казанцев Минзәлә өязенең Минзәлә земство суды тәкъдиме буенча Таҗетдиннән сорау алу үткәрә һәм ул татарча сөйләгәннәрне русчага әйләндереп язып бара. *(Рәсемдә.)*

«Тазетдином меня зовут Якшигулов сын от роду мне 57 лет урождённый Бугульминского уезда из деревни Чалпов...» *(ассызык безнеке. – Д.Г.)*.

Казанцев белән Таҗетдин хәзрәт арасында сөйләшү менә шулай башланган. Иң мөһиме шунда: моңарчы әдипнең туган авылы, инде әйткәнебезчә, билгеле түгел иде, ә биредә аның туган авылы аермачык итеп хәзрәтнең үз авызыннан әйтелгән. Димәк, ул Чалпы (Чалпов) авылында туган. Хәзер бу авыл – республикабызның Азнакай районына караган зур гына татар авылы. Сорау алу вакытында ул үзен 57 яшьтә дип күрсәтә, димәк 1763 елда (1820 − 57 = 1763) туган була. Шулай итеп, Ялчыгол хәзрәтнең Чалпыга килүе 1760-1763 еллар тирәсенә карый.

Менә шулай: Таҗетдин Ялчыгол улының (әтисен Якшыгол, Ишигол, дип тә язалар) тәрҗемәи хәлендәге бер мөһим дата ачыкланды − әдипнең кайчан һәм кайда туганлыгын белдек. 2018 елда тууына − 255, вафат булуына 180 ел тулуын искә алсак, архивта тап булган табылдыкның әһәмияте тагын да арта төшә.

Таҗетдин Ялчыголның тәрҗемәи хәле мине һаман да кызыксындырып торды. Аның гаиләсе хакында тулырак беләсе килде. Шуңа күрә ул яшәгән авылларның тарихы белән бергә, шул чактагы җан исәбен алу материаллары белән дә танышып бара идем. Табигый ки, ул туган Чалпы авылының ревизия сказкаларын да (элек халык санын алуны язган кенәгәләр шулай аталган) өйрәндем. Нидер эзләп чапкан − кирәген тапкан, диләрме әле? Мин дә Таҗетдин Ялчыгол турындагы мәгълүматларны шул ук Чалпы авылында тутырылган ревизия сказкасында таптым.

1850 елның 21 августында үткән ревизия вакытында Чалпы авылы Оренбург губернасының Бөгелмә өязе 13 нче башкорт кантоны 13 нче йортка (юрт) караган булган. Кенәгәдәге 13-14 нче гаиләләр Таҗетдин Ялчыголның (Яхшигулов, дип язылган) ишле гаилә әгъзалары белән таныштыра. Таҗетдин хәзрәт инде 12-13 ел элек вафат булган (аны 1838 елда, дип түгел, 1837 елда вафат булды, дип язганнар: күрәсең, сказканы тутыручыга 12-13 ел элек үлде, дигәннәрдер, шуннан әлеге хата килеп чыккан). Хатыны – Биксолтан Ишмәмәтова икән. 1850 елда аңа 78 яшь булган.

Биксолтан абыстай кайсы авылда туган соң дигән сорау да тынычлыгымны югалтты. Эзләнә торгач, мин аның Таҗетдин Ялчыгол мулла булган Кызыл Чапчак авылы кызы икәнлеген ачыкладым. Әтисе – Ишмәмәт Калметов икән. Авылда Калметовлар йомышлы татарлар катламына караган. Алар Казан адмиралтействосына теркәлгән булган һәм, мөгаен, күп кенә өстенлекләрдән файдаланганнардыр.

1820 елның 13 августында дворяннар утырышчысы Казанцевның, Минзәлә земство суды тәкъдиме буенча, Таҗетдин Ялчыголдан сорау алу үткәргәнен искә алган идек инде. Монда Кызыл Чапчак авылының 27 кешесеннән сорашкан ул. Әлеге кешеләр арасында Биксолтанның әтисе һәм аның туганы да булган.

1795 елның 29 маенда Кызыл Чапчак авылында җан исәбен алу кенәгәсендә дә аларның исемнәре теркәлгән. Әйтик, бу вакытта Мөхәммәт Калметовка − 41, Морат Калметовка − 39, Ишмәмәт (Ишмәт дип язылган) Калметовка 36 яшь икән. Бу гаиләдән Зөләйха Калметова Зирекле (Ерыклы) авылының ясаклы татарына кияүгә чыккан. Мөхәммәт Калметовның хатыны − Гөлбостан Габдрахманова, балалары: Биккинә, Бикбау, Хисаметдин. Моратның хатыны − Хәлимә Рафикова, балалары: Яһүдә, Гобәйдулла, Хәбиб. Ишмәмәтнең (Ишмәт) ике хатыны булган: Бәзихә Туктамышева, Гөлзәфинә Чәбәкәева. Балалары: Салих, Халит, Әюп. Гөлзәфинә үзе Зирекле (Ерыклы) авылыннан килен булып төшкән.

Укучы сизенгәндер инде, Биксолтан абыстай да дәрәҗәле гаиләдән чыккан, үзе дә күп бала тапкан, барысын да яратып, эшкә һәм укырга өйрәтеп баккан. Таҗетдин Ялчыголга ныклы терәк, бик тә кирәк булып гомер сөргән, аның белән урыннан-урынга күчеп, ачысын һәм төчесен татып яшәгәндер.

Бу ике нәселнең уртак дәвамчылары Түбән Кама, Чаллы, Зәй, Сарман, Әлмәт, Азнакай якларында арабызда йөриләрдер, бүгенге тормышның һәр йөген безнең белән бергә сөйриләрдер.

Әдипнең табышмакларга, серләргә тулы гомере могҗизаларга да бай. Без шуларга җавап табарга, аларны ачарга бурычлыбыз.

**Дамир ГАРИФУЛЛИН.**
*Сарман*

# ӘДӘБИЯТНЫҢ ЙӨРӘК ТИБЕШЕН ТОЕП...

## ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Татар әдәбият белеме тарихында «урап узып та, кузгатып куеп та» булмый торган «нигез ташлары» – озак еллар дәвамында тулы бер юнәлешләрне колачлап барган, абруйлы фикер тудырган галимнәр бар. Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, тәнкыйтьче, мәгариф һәм фән өлкәсендә оештыручы-педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Тәлгат Галиуллин шундыйлардан.

Татар әдәбияты милли нигезләренә, халык авыз иҗатыннан килгән хасиятләренә әйләнеп кайтып, шулар ярдәмендә туган җир, ана, батырлык кебек мәңгелек кыйммәтләрне, халыкның көен-аһәңен тергезгән 1960 елларда яшь аспирант Тәлгат Галиуллинның шушы күренешләрне аңлату-шәрехләү юлындагы мәкаләләре республика матбугатында күренә башлый. «Совет әдәбияты» *(«Казан утлары», 1964, №2)* журналында басылган беренче җитди мәкаләсе Сибгат Хәким поэзиясендә халык авыз иҗаты традицияләре чагылышын өйрәнүгә багышлана. Ш.Галиев иҗаты хакындагы күзәтүләре *(«Халык – күңел көзгесе», Соц.Татарстан, 1964)* дә шушы мәсьәләгә кагыла. «Халыкныкы – халыкка кайта, халыкка хезмәт итә» фикере бу язмаларның үзәгендә булып, шагыйрьлек кыйммәте – халык мәдәнияте традицияләрен заманча югары сәнгать белән куша алуда дигән фикер ассызыклана. Мәсәлән, С.Хәким иҗатының укучыны җәлеп иткән үзенчәлеге дип дөньяга балаларча (фольклордагыча) самими караш һәм тирән фәлсәфә синтезы билгеләнә.

Теоретик проблемаларга да кагылган «Көлдерсен дә, уйландырсын да (Сатирик поэзия турында)» (1964), «Балладаларыбыз турында» (1965), «Поэманың барыр юллары» (1968), «Халык тапкырлык ярата (Татар поэзиясе турында» (1968) кебек мәкаләләрдә дә элгәреләр традицияләрен барлау, татар шигъриятенә колачлы, анда күзәтелә торган закончалыклар һәм яңалыклар ноктасыннан бәя бирү омтылышы ясала. Бер үк вакытта Т.Н.Галиуллин әдәби тәнкыйть өлкәсендә каләм сыный: монда да шигъриятнең үз материалында тирән күзәтүләргә, аерым әдипләр әсәрләрен татар поэзиясе тарихы фонында карауга өстенлек бирә. 1968 елда XX гасырның уртасы татар шигърияте һәм халык авыз иҗаты арасындагы бәйләнешләрны тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклаганда, аның инде ике дистә язмасы дөнья күргән була. 1960-1970 еллар чиге татар поэзиясенең төп үсеш тенденцияләрен өйрәнүгә караган бу тикшеренүләр соңыннан «Яңа үрләр яулаганда» (1972) һәм «Еллар юлга чакыра» (1975) исемле аерым җыентыкларында басыла.

1965 елда Алабуга дәүләт педагогия институтына эшкә китеп, анда дәрәҗәле һәм җаваплы вазифалар башкарганда да (1967-1971 елларда институтның укыту һәм фәнни эшләр буенча проректоры, 1971-1986 елларда ректор), Тәлгат Нәбиевич фәнне һәм әдәби тәнкыйтьне «ташламый». Киресенчә, яңадан-яңа тикшерү объектлары билгеләнә. Тәнкыйтьче буларак, шигърият белән чикләнмичә, ул прозага да мөрәҗәгать итә башлый. Әйтик, Э.Касыймовның «Томан аша» (1969), М.Мәһдиевнең «Фронтовиклар» (1972) романнарына этрафлы рецензияләре басылып чыга. 1960-1970 еллар чигендә Т.Галиуллинның даими игътибар үзәгендә торачак «үз» авторлары пәйда була: Ш.Галиев (1963 елдан башлап), С.Хәким (1964 елдан башлап), Р.Харис (1969 елдан башлап), Г.Латыйп (1968 елдан башлап), Х.Туфан (1970 елдан башлап), И.Юзеев (1973 елдан башлап) һ.б. Алар иҗатына һәм галим, һәм тәнкыйтьче буларак

бәя биргән язмалар даими рәвештә республика матбугатында дөньяга чыга. Аерым бер шагыйрьләр иҗатына кабат-кабат мөрәҗәгать итүен үзе үк болай дип аңлата: «Әйтик, хәзерге татар поэзиясенең танылган лидеры, әйдәп баручысы, М.Горький һәм Г.Тукай исемендәге премияләр лауреаты С.Хәким иҗаты турында бер мәкаләдә иң гомуми мәгълүматларны гына биреп була. Ул очракта кабатланудан котылуы кыен. Шуңа күрә биредә сүз аның иң соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре турында, анда да шагыйрьнең бөтен барлыгын, рухын, хисен биләгән иң мөһим юнәлешләр хакында гына барачак. Шуңа күрә бу мәкалә тулы иҗат портреты булуга дәгъва итми. Ул – татар тәнкыйтендәге соңгы ун-унбиш ел эчендә С.Хәким иҗатын тикшерүгә багышланган хезмәтләрнең, мәкаләләрнең дәвамы гына» *(«Шагыйрьләр һәм шигырьләр», 5 б.).* Нәтиҗәдә, озак вакытлар дәвамында тәнкыйтьче аерым бер әдипләр иҗатын үзгәрә баручы процесс буларак даими өйрәнеп, яңалыкларны бәяләп баручыга, бу иҗатларның «елъязмачысына» әйләнә.

Гомумән, әдәби процесс белән кызыксынып, шигърият пульсын тоеп тору – аның бөтен иҗат гомеренә хас сыйфат. Яшь шагыйрьләр иҗатын тикшерү, аларның әсәрләрен туплаган җыентыкларны күзәтү, язучыларның әдәби ел йомгакларында чыгышлар ясау, әдәбият тарихына кагылышлы аналитик, күзәтү характерындагы материаллар эшләп бару – болар барысы да күп укуны, эзләнүне таләп итә, эрудиция һәм әдәбиятны ярату хакында сөйли. Язмаларда шигъриятттәге, аерым шагыйрьләр иҗатындагы, конкрет әсәрләрдәге яңалыклар, әдәби алымнар кулланылышы, традицияләрнең дәвам ителеше, образлылык игътибар үзәгенә куела. Татар әдәбият белемендәге яңалыклар, вакыйгалар да һәрчак аның күз уңында.

1970-1980 еллар чигендә галимне милли әдәбият тарихындагы кызыксындырган, борчыган яклар монографик тема булып формалаша: совет чоры шигъриятендә реализм традицияләренең ныгуы, үсүе, үзгәрүе. Бу тема берничә китапта: «Социалистик реализм юлыннан» (1977), «Дыхание времени (вопросы становления и развития социалистического реализма в татарской советской поэзии до 1941 года)» (1979) хезмәтләрендә һәм докторлык диссертациясендә ачыла-ачыклана. Аларда әдәбият белеменең иң катлаулы мәсьәләләреннән булган иҗат методы хакында күзәтүләр дә, 1920-1930 елларда татар әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйтьнең торышын тикшерү дә, татар шигъриятендә язу ысулына караган методологик фикерләр дә, чор шигъриятенә җентекле анализ да урын таба. Аерым алганда, 1920-1930 еллар татар әдәбиятының Көнбатыш һәм Көнчыгыш поэзиясе үзенчәлекләрен яңа методологик нигездә синтезлавы хакындагы фикер дәлилләнә. Бу нәтиҗә татар әдәбияты тарихын өйрәнү өчен зур әһәмияткә ия була: ул рус әдәбияты, революцион идеяләр йогынтысын өстенлекле санауга чик куя.

Чор шигъриятен тикшерү вакытында берничә: кеше һәм җәмгыять, шәхес һәм төркем, кеше һәм хәл-әхвәлләрнең катлаулы мөнәсәбәтләре барышын күз уңында тоту кирәклеге хакындагы методик характердагы кагыйдә ассызыклана. Чор лирик героен күпьяклы тикшереп, автор аның үз вакыты кешесе, тормышка инкыйлабый мөнәсәбәтле көрәшче генә булмыйча, табигать баласы икәнлеген дәлилли. Т.Н.Галиуллин 1920-1930 еллар шигъриятенең жанрлар өлкәсендә «революция» ясавын билгели, тарихи поэтика юнәлешендә мөһим һәм дөреслеге алга таба расланган закончалыкларның асылын күрсәтә.

Хезмәтләрдәге аерым бер гомумиләштерүләр үз чоры өчен кыю һәм көтелмәгәнчә яңгырый. Әйтик, галим чор сулышын чагылдырган әсәрләрнең, мактауларның, революцион лозунглар күтәргән шигырьләрнең уртакул шагыйрьләр тарафыннан иҗат ителүен исбатлый. «Модага ияреп» язылган иҗат җимешләренең татар шигърияте йөзен билгеләмәвен талантлы авторлар иҗаты мисалында күрсәтә.

1981 елда филология фәннәре докторы дигән дәрәҗәгә ирешкәннән соң да, Т.Н.Галиуллин бер-бер артлы фәнни һәм тәнкыйди характердагы күләмле монографияләр, китаплар язуын дәвам итә. «Безнең заман – үзе җыр» (1982), «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» (1985), «Дәвамлылык» (1987), «Илһам чишмәләре» (1988), «Гомер учагы» (1991) китаплары, тәнкыйть һәм фән тарихы мөмкинлекләрен бергә үреп, әдәби-иҗат портретлары тудыру юнәлешендә язылганнар. Алар XX гасыр

әдәбияты хакында, гомумән, татар әдәбияты тарихы фонында уйланып эшләнгән. Исемнәре янында «әдәби тәнкыйть мәкаләләре» дигән аңлатма бирелсә дә, җыентыклар әдәбият тарихының актуаль мәсьәләләрен көн тәртибенә куйган фәнни монография дәрәҗәсенә ия. Хезмәтләр шартлы рәвештә аерылган ике өлешне, әдәбиятны өйрәнү мөмкинлекләрен билгеләгән теорияне һәм шуны гамәлгә ашырган тарихи язмаларны берләштерә.

Тарихи язмалар тикшерү объекты итеп сайланган иҗатчының әдәби портретын укучы күз алдына китереп бастыра. Аларда үткен каләм, төгәл сызыклар ярдәмендә образ тудыру сәләте укучыны үзенә җәлеп итә. Соңрак ике-өч сурәтләү чарасын, еш кына чагыштыру белән метафораны бер җөмлә эчендә «очраштырып», катлаулы сурәт ясый торган язучы булып танылачак Т.Н.Галиуллин шушы әдәби алымны бүген әдәбият мәйданында күренекле язучы-шагыйрьләрнең иҗат портретларын тудыру өчен файдалана. Р.Гаташ, Р.Харис, Г.Рәхим, М.Әгъләмов, М.Галиев, Х.Әюпов һ.б.ларның холык-фигылен, дөньяга һәм кешеләргә мөнәсәбәт-фәлсәфәсен, иҗатларында дәвам иткән тормыш кредосын ачкан, аларның шәхесен укучы күз алдына бастырган автор үзенчәлекле: шаян-җиңел, соклану һәм юмор катнаш интонация тапкан. Шуңа күрә иҗат портретлары каләмдәшләренә багышланган әдәби парчалар кебек тәэсир калдыра.

Язмаларның исеменә үк язучы, шагыйрь иҗатындагы төп сыйфат чыгарылган, ул инде материалны алдан ук гомумиләштереп бәяли һәм укуга «көйли». Әйтик, «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» (1985) җыентыгында шушы чорда актив иҗат иткән 10 шагыйрь иҗаты тикшерелә. С.Хәкимгә багышланган бүлек «Зур бу илем, гаҗәп киң бу дөнья» дип атала, анда татар шагыйре иҗатында дөнья хакында уйлануның лейтмотив булуы ассызыклана. Яки Нури Арсланов шигъриятен барлаган бүлек «Үз илем, үз республикам бар» дигән исем йөртә, әлеге шагыйрьнең гражданлык лирикасы, патриотик мотивлар белән өртелгән шигырьләр аша дан казануы үзәккә алына. И.Юзеев, хаклы рәвештә, «Яшьлек һәм батырлык җырчысы», дип бәяләнә.

Аннары шагыйрьләрнең иҗат үзенчәлеген тәшкил итә торган берничә сыйфат аерып чыгарыла. Әйтик: 1) «С.Хәким каләме тудырган әсәрләрнең шөһрәте, барыннан да элек, халык язмышының үзәк вакыйгаларын, борылыш моментларын кеше характеры, шәхес кичерешләре аша һәм шул ук вакытта фәлсәфи тирәнлек белән калкытып куя алу осталыгы биеклегеннән аңлатыла»; 2) «шагыйрь һәр очракта да чор рухы таләп иткән, үз эчке кичерешләренә, уйлануларына якын тематиканы һәм жанрны алга чыгара»; 3) төп темалар буларак, Бөек Ватан сугышы, туган ил-җир, туган җирдә барлыкка килгән үзгәрешләр, туктаусыз эзләнү һәм йөрәк-хис тынгысызлыгы күрсәтелә *(«Шагыйрьләр һәм шигырьләр», 8 б.)*.

Шунда ук шагыйрьләр иҗаты чорларга бүленеп, бәяләнеп уза. Мәсәлән, Р.Фәйзуллин шигъриятендә тәнкыйтьче «берсен-берсе тулыландырып, вакыты белән бәхәсләшеп, тартышып үскән өч юнәлеш, елларын тәгаен генә билгеләве кыен булган өч чор, өч этап» билгели: беренчесендә «ул укучыны тормышны гадәти булмаганча күрүе һәм тасвирлавы, чәчрәп торган метафорасы, ассоциациясе һәм гармония, көйле аһәң белән санашмаган иҗеге белән үзенә каратты», бу чорда ул – тәҗрибәләр ясаучы, традицияләрне җимерүче бунтарь; кыска шигырьләр чоры – «экспрессив тыгызлык, мәгънәви һәм стилистик куелык, образлы киеренкелек ярдәмендә тар мәйданда фикер, идея әйтеп салу, хисне ачу», философ шагыйрь; өченче чорда, «сугыш һәм иминлек, үткән һәм киләчәк, батырлык һәм куркаклык турында язылган шигырьләрендә Маяковский, Такташ, Җәлил традицияләрендә тәрбияләнгән трибун шагыйрь буларак ачыла» *(«Шагыйрьләр һәм шигырьләр», 128-135 б.)*. Р.Фәйзуллин иҗатын яратучы һәм белүчеләр өчен дә, галим-тикшерүчеләр өчен дә бу бүленеш – нигез, кире кагу мөмкин булмаган бәя.

Тагын бер мисал. Т.Н.Галиуллин, 1960-1980 елларда мәйданга чыккан бик күп талантлы шагыйрьләр белән беррәттән, Ренат Харис өчен дә «үз» тәнкыйтьчесенә, иҗатын даими күзәтеп баручы укучыга әйләнә. Яшь шагыйрь үзе хакында хәбәр иткән бер вакытта ук тәнкыйтьче аның иҗатындагы түбәндәге үзенчәлекләрне аерып чыгара: 1) бу иҗатта кешенең фикерләү рәвешенә, интеллектына үтеп керергә, тормыш диалектикасын аңларга омтылыш көчле; 2) аның лирик герое – көчле,

нык ихтыярлы шәхес, рухи дөньяны да шагыйрь элегик моң, сагыш аша түгел, бәлки «ихтыярлы» ритмнар, «мускуллы» сынландырулар, экспрессия һәм катлаулы ситуацияләр аша сурәтләргә ярата; 3) аналитик фикер, эзләнүчән хис шагыйрьгә көнитешнең төрле күренешләренә үтеп керергә юл ача: сурәтләнгән вакыйгаларга, эчке дөнья чагылышларына үзенең мөнәсәбәтен төгәл һәм ачык итеп рәсемләп бирү мөмкинлекләрен арттыра; 4) ул – шартлаулы, көтелмәгән алымнар, кыю метафоралар шагыйре, сүзгә саран һәм экономияле шагыйрь *(«Шагыйрьләр һәм шигырьләр», 153-164 б.)*. Бүген татар шигъриятендәге олы фигуралардан булган Р.Харис иҗатында шушы үзенчәлекләрнең «ярылып ятуын» күрми мөмкин түгел.

Шулай итеп, совет идеологиясенең күрсәтмәләре нинди булуга карамастан, поэзиягә якын килүдә Т.Н.Галиуллинның үз үлчәве, үз тикшеренү юлы формалаша: «Һәр иҗтимагый чорда шигъриятнең асыл кыйммәте ил тормышына, халык язмышына якынлык, гуманизмга тугрылык, кеше кичерешләрен яңача сурәтли белү һәм сәнгатьчә нәфислек белән бәяләнә. Шул сыйфатларга ия булган шигъри әсәрләр генә, еллар, гасырлар сынавын үтеп, безгә килеп җиткән, һәм һаман да матурлыгын югалтмаган» *(«Шагыйрьләр һәм шигырьләр», 3 б.)*. Әлеге дүрт кыйммәт аның тарафыннан һәр иҗатта барлана. Шуңа күрә XX гасыр поэзиясе, аның аерым сүз осталары хакында яңа хезмәтләрдә, диссертацияләр һәм монографияләрдә без Т.Н.Галиуллин карашларын үстерү белән очрашабыз. Галим чын мәгънәсендә тулы бер гасыр шигъриятен өйрәнүгә сукмак сала, киләчәк тикшеренү юлларын билгели.

1986 елда Казанга әйләнеп кайтып, Т.Н.Галиуллин башта Казан дәүләт педагогия институтының әдәбият кафедрасында, аннары Казан дәүләт университетында профессор булып эшли башлый. 1989 елда аңа татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетын оештыруны тапшыралар.

1990 еллар – хәбәрдарлык чоры – әдәбият белеме фәненә дә көчле тәэсир ясый. Билгесез исемнәр һәм әсәрләр кайта, озак вакытлар яшәп килгән концепцияләрнең идеологик заказга барып тоташа торган «йомшак» яклары ачыктан-ачык күрсәтелә. Инде әдәбият тарихын бөтен тулылыгында аңлау мөмкинлеге ачылган кебек тоела. Ләкин… бу эш алай бик ансат кына булып чыкмый. Чөнки яңача эшләү юллары табылмаган! Акрынлап яңа нигез кирәклеген, ләкин аның иске мирастан тулысынча баш тартып түгел, бәлки элгәргеләрнең эзләнүләрендәге уңышлы якларны файдаланып гамәлгә куелырга тиешлеген аңлау килә.

Т.Н.Галиуллинның «Шигърият баскычлары» (2002) һәм «Шәхесне гасырлар тудыра» (2003) китаплары әдәбият турындагы фәнгә шундый яңа караш алып килә. Әдәбият белемендәге XX гасыр ахырында тәнкыйтькә дучар булган концепцияләр әдәби барышка иҗтимагый-сәяси яктан якын килүне таләп итәләр. Хәзер инде әдәбиятның идеологик яки сәяси заказ белән генә барлыкка килә алмавын, аның үз эчке закончалыкларына буйсынып, чорның әдәби аң үзенчәлекләренә таянып хәрәкәт итүен берәү дә кире какмый. «Ләкин аны кайсы яктан тикшерү дөресрәк соң?» – бу сорау ачык кала. Т.Н.Галиуллин әлеге мәсьәләгә үз карашын белдерә, ул әдәбиятны, милли тамырлар һәм шартларга бәйле рәвештә, яшәешне танып-белү өлкәсе, милли үзаң һәм характерны сүз-сурәт ярдәмендә тергезеп күрсәтү сферасы дип саный, халык тарихындагы үзгәрешләрне исә әдәбияттагы үзгәреш нокталары буларак карый. Аның «Милли үзаң һәм шигърият» *(«Шигърият баскычлары», 3-8 б.)* язмасы әлеге карашның асылын укучыга җиткерә. «Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре» дигән язмада татар шигъриятенең аерым бер дәверләрен өйрәнү эшендә кабул ителгән кайбер фикерләргә бәя биреп, автор үз концепциясенең төп кануннарын формалаштыра.

Беренчедән, галим XX йөз башы белән 1917 елдан соңгы әдәбият арасында бернинди уртаклык булмау хакындагы озак еллар яшәп килгән караш белән килешмәвен белдерә, «ике дәвер әдәбиятларын чагыштырып караганда, тирәннән, астан агып яткан чишмәләрне, ерганакларны барлаганда, сурәтле фикерләүнең бернинди сәясәткә, өстән иңдерелгән хакимияткә бирешми торган үз эчке кануннары, уртаклыклары барын сиземләве кыен түгел» *(«Шигърият баскычлары», 10 б.)*. Димәк, милли әдәбиятның шушы эчке уртаклыкларын, күчемлелек-дәвамлылыгын күздә тотып өйрәнү зарур.

Икенчедән, сәясәт басымы әдәбиятны «заманның шәүләсе, колы» дәрәҗәсенә

төшерә. Аның күтәрелеше исә теге яки бу халык әдәбиятында талантлар, олы әдипләр булу белән бәйле. Шуңа да әдәбият тарихын өйрәнү бәя бирүдән башка була алмый, юкса төрле дәрәҗәдәге, төрле мөмкинлекләргә ия язучылар бер калыпка салыначак.

Өченчедән, Т.Н.Галиуллин моңа кадәр әдәбият белемендә тискәре бәяләнеп килгән, ләкин күп кенә әдипләр иҗатына зур йогынты ясаган дини-мифологик әсәрләрнең, модернистик һәм шәкли эзләнүләрнең махсус тикшеренүләр объекты булырга тиешлеген дәлилли. Шуның белән бергә, «социалистик реализм» кебек зур күренешне соңгы вакытта уйдырма, дип атауга да каршы чыга. Шулай итеп, әдәбиятны бөтенлектә, төрлелектә, тулылыкта өйрәнү кирәклеге көн тәртибенә куела.

1995 елда язылган бу мәкаләдә мондый юллар бар: «Күнегелгән, күп тапкырлар тәкрарланган яссылыкларга ябышып яту, шигъриятне бик тар сәяси-җәмгыяви күзлектән генә бәяләү, карашлар төрлелеген кабул итмәү, бер фикерне канунлаштыру – әдәбият фәнен, тәнкыйтьне торгынлыкның җылы, тыныч, ипле ярларыннан ерак алып китә алмас. Үткәнгә тәнкыйди карашны «авантюра», «карьера артыннан куу» кебек текә сүзләр белән өркетү, мирасның абруен төшерү, дип бәяләү чоры иртәмесоңмы үтәчәк. Безнең буынга насыйп булган өермәле вакыт туктаусыз алга хәрәкәтне, эзләнүне, уйлануны таләп итә. Үзгәрмичә мөмкин түгел» *(«Шигърият баскычлары», 18-19 б.)*. Әлеге сүзләрнең дөреслеген вакыт инде раслады.

Хезмәтләрнең 1920 һәм 1930 еллар шигъриятен, бу чорлардагы олы шагыйрьләр иҗатын күзәтү-анализлау өлеше нәзари фикерләрне гамәлдә сынау да булып тора. Әлеге эзләнүләр моңа кадәр укучыга аз билгеле мәгълүматларга таянуы һәм, шуның белән бергә, билгеләнгән вакыт аралыгындагы шигъриятне тулысынча колачлап алуы белән әһәмиятле. Т.Н.Галиуллин үзенең гыйльми өйрәнүләр объекты итеп сайланган дәвер әдәбиятына бербөтен милли-әдәби аң җимеше дип карый, сәләтләре ягыннан төрле булган әдипләрне ул шушы яктан берләштерә. Үзе тәкъдим иткән нәзари кагыйдәләрдән чыгып, татар әдәбиятындагы күчемлелекнең 1917 ел вакыйгалары белән өзелмәвен дәлилли. Мәсәлән, ул елларда М.Гафури, Г.Камал, Ш.Бабич кебек шагыйрьләр мирасында халык авыз иҗаты традицияләре чагылу игътибарга алына. Хәтта моңа кадәр татар әдәбият белеме дәшми үтә торган өлкә: 1920 еллар әдәбиятында дини-мифологик мотивларның саклануы С.Сүнчәләй, Т.Ченәкәй, Ә.Сәгыйди, Г.Харис һ.б.ларның шигырьләре мисалында күрсәтелә. Шулай итеп, галим ХХ гасыр ахырында үзе фәнгә аяк баскан бер вакытта мөрәҗәгать иткән классиклар иҗатына яңадан әйләнеп кайта, аларны заман югарылыгында тикшерүгә һәм бәяләүгә алына.

1920 еллар татар шигъриятенә кагылышлы тикшеренүләр әдәбият белемендә ачык кала килгән күп кенә сорауларга җавап бирә, татар әдәбиятындагы бер этап хакында гына түгел, милли сәнгатьнең бүгенге хәленә сәбәп булган факторлар, мәдәният тарихыбыз турындагы нәтиҗәләре белән уртаклаша. Мәсәлән, шушы чор әдәбиятына мөнәсәбәтле К.Әмири, Ә.Сәгыйди кебек аз билгеле авторлар иҗатына бәя биреп барганда, әдәбиятта беренче адымнарын ясауга ук, гражданнар сугышы вакытында башларын салган яшьләрнең исемлеге китерелә: В.Җәлал, К.Кәрипов, Ш.Бабич, Ш.Фидаи, И.Йосфи, Д.Гобәйди, Бамин (Бәдретдин Әминев) һ.б. алар. Иң яхшы әсәрләрен язарга өлгермәгән талантлы яшьләрнең сәясәт корбанына әверелүе башка бүлекчәләрдә дә игътибарга алына, татар әдәбиятының аерым бер дәверләрдәге торыш-үзгәрешләренә бүгенге караш, еш кына артык таләпчән якын килү дә искәртелә. Т.Н.Галиуллин дәвер шигъриятенә әлләни зур өлеш кертә алмаган, берничә әсәр белән чикләнгән әдипләрнең дә иҗат индивидуальлеген, шәхси мөмкинлекләрен, талант үзенчәлекләрен билгеләп-барлап бара. Галимнең үз халкы мәдәниятенә, әдәби мирасына, фаҗигале язмышларга дучар улларына хөрмәте, каләм тибрәткәндә, үзенең татар булуын һәрчак истә тотуы хезмәтнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла.

Хезмәтләрдә «татар әдәбияты поэзиядән башлана» дигән фикер берничә тапкыр кабатлана, алай гына да түгел, шушы гыйбарәнең дөреслеге исбатлана. Шигърият феномены бөтен тулылыгында һәм тирәнлегендә Т.Н.Галиуллинның фәнни фикерләү предметы булып торса да, поэзия хакында сөйләү, гомумән, әдәбиятка бәя бирү кебек яңгырый. Шигырь материалында сүз сәнгате кануннары ачыклана һәм, шуларга таянып, аерым әсәрләрне анализлау эше башкарыла, шулар аша чор әдәбиятына ачкыч табыла.

«Яктылык» (2011) җыентыгы асылда XX гасыр шигъриятен, бу чордагы олы шагыйрьләр иҗатын күзәтеп-анализлап язылган. Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Исхакый кебек XX йөз башында иҗатларының алтын чорын кичергән зур фигуралардан башлап, автор бу дәвер татар шагыйрьләренең нинди максатлар куеп иҗат итүе, кайсы алымнарга өстенлек бирүе, татар сәнгатендә нинди актуаль мәсьәләләр күтәрүе турында сөйли. Х.Туфан һәм С.Хәким иҗатлары мисалында, XX йөз башы шигъриятенең ничек итеп, кайсы иҗатчылар аша 1960 еллар буынына – Р.Фәйзуллин, И.Юзеев, Р.Харисларга килеп тоташуы күрсәтелә. Т.Н.Галиуллин татар поэзиясенең этаплары арасындагы дәвамчанлыкны да, һәр этапның үз хасиятләрен дә бик төгәл мисалларда күзәтә. Шагыйрьләрнең шәхси иҗат дөньяларын ачу ярдәмендә, чорның гомуми әдәби панорамасы, дәвер әдәбиятының уртак сулышы калкытып куела.

Хезмәтнең иң әһәмиятле бүлекләре – үзгәртеп кору елларыннан соң татар шигъриятенең торышын анализлаган язмалар. «Заман таләбе – шигърият асылы» аналитик мәкаләсе 1960-1975 еллар поэзиясенә күзәтү ясый. Монда чор шигъриятенең төп үзенчәлеге итеп «гомумкешелек проблемаларына, яшәү белән үлем, кеше гомеренең кыйммәте, яхшылык белән явызлык, гаделлек, шәфкатьлелек кебек мәңгелек проблемаларга игътибар арту» *(«Яктылык», 149 б.)* күрсәтелә. 1975-1990 еллар татар поэзиясен галим «Тынчу елларның тынгысыз шигърияте», дип гомумиләштерә. Әмма бу чор шигъриятендә милли мотивларның активлашуы, форма ягыннан исә – «реалистик һәм романтик, лирик һәм драматик, фәлсәфи һәм публицистик башлангычларның бер-берсен тулыландыруы» *(«Яктылык», 209 б.)* билгеләнә.

«Милли яңарыш чоры шигърияте» дигән язма 1990 елларны колачлый. Кызыклы һәм уйландырырлык күренешләр буларак, «хис төсмерләре кинәт алышыну, сурәтне төгәлләмичә өзү, символлар, детальләр аша гомумиләштерүгә чыгу, шигъри калыплар төрлелеге (көйләм шигыре янәшәсендә төрле үлчәүле сөйләм, интонацион шигырь үсү) борчылуны, өметсезлекне, яшәешнең мәгънәсезлеген, шәхеснең олы дөньяда ялгызлыгын, гомернең кыскалыгын чагылдыруга» буйсынуы; «чарасызлыкны ирониягә, көлүгә күчерү»; «катгый кануннар белән чикләнмәгән образлылыкка күчү»; «фәлсәфи һәм тәнкыйди рух»ның көчәюе; «үзешчән шигърият» дәррәү күтәрелеп, «шигъри сүз чүпләнү, эстетик зәвык киму, укучыга яхшыны начардан аеру кыенлашу»; «Көнчыгыш поэзиясендә алга киткән жанрлар белән артык мавыгу, Көнбатыштан кереп, үзебезнеке буларак үстерелгән баллада, сонет, триолет кебек үзенчәлекле жанрларга игътибарны» киметү; «хикмәтле сүзгә» җитәрлек игътибар бирмәү кебек күп кенә сыйфатлар күрсәтелә. Әмма, галим фикеренчә, татар поэзиясенең «үз өстенә милләтне, телен, динен, әхлагын саклау бурычларын» алуы аңа «өстәмә көч, тематик һәм хәтта стилистик киңлек бирә» *(«Яктылык», 256-257 б.)*.

Шулай итеп, Тәлгат Галиуллин – тулы бер гасыр шигъриятен өйрәнүгә сукмак салган, киләчәк тикшеренү юлларын билгеләгән галим, әдәбият тарихчысы, 1960 еллардан башлап бүгенге көнгә кадәр татар шагыйрьләре иҗатын даими һәм җентекле күзәтеп-бәяләп барган тәнкыйтьче дә. Аның әдәбият белеме өлкәсенә караган гыйльми хезмәтләре, заман ихтыяҗларына җавап биреп, фәннең бүгенге торышын исәпкә алып язылган булса, әдәби иҗаты милли әдәбиятка чор сулышын алып килде, XX гасыр ахыры китереп чыгарган психологик һәм иҗтимагый катаклизмнарны, кеше турындагы күзаллауларның үзгәрүен хәбәр итте. Әдәбият белгече, галим һәм тәнкыйтьче буларак язган хезмәтләре дә, әдәби иҗаты да үз предметын тирәннән белеп һәм аңлап бәяләве белән кадерле.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты, академик*

# ГАМӘЛЛӘРЕНДӘ – КОРЫЧ НЫКЛЫГЫ



*Илдар Гыйльфан улы Ногманов*

Элек-электән кешеләр үз тормышларын камилләштерергә тырышып яшәгәннәр. Бабаларыбыз тормыш тәҗрибәләрен балаларына, оныкларына калдырган, шуның нәтиҗәсендә кешелекнең яшәеше дә һаман яхшыруга таба барган. Кеше үзенең акыл һәм хезмәт эшчәнлеге белән тимерне, ташны, җир байлыкларын буйсындырган, үзенең тормышын алып барыр өчен ышанычлы тирәлек төзегән. Хәзерге тормыш-көнкүрешебезне тимер эшләнмәләрдән башка күз алдына китерүе дә кыен. Өйләребезнең түбәләре – калайдан, капка-коймалар – тимердән, машиналарны да «тимер атлар», дибез, ә самолётлар «тимер кошлар» булып күккә күтәрелә. Кешелек тимер белән ерак гасырлар элек үк танышып, аны эшкәртә башласа да, бүгенге югарылыкка ирешкәненә әле бер гасыр гына. Әлбәттә, тимерне күпләп җитештерү һәм аны кулланылышка кертү хакында безнең ерак бабаларыбыз матур хыял буларак кына фикер йөрткәндер. Татар халкының тимерне үз яшәешендә шактый киң кулланганлыгы да тарихтан билгеле. Аны эшкәртү традицияләре безнең осталар тарафыннан гасырлар дәвамында камилләшә һәм үз юнәлешен таба. Элек заманнарда сугышчылар өчен корал, көбәләр тимердән ясалган, кыйммәтле металлардан зәркән эшләнмәләр затлы матурлыгы белән сокландырган. Акчаны да тимерчеләребез суккан. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар халкына тимер белән эш итү гомумән тыела. Шуннан берничә гасырга сузылган өзеклек безне тимердән, тимерчелек һөнәреннән аерып тора. Заман борылышын бераз үзгәрткәннән соң гына осталарыбыз яңадан бу эшкә әйләнеп кайта башлый. Инде тимерчелек шулхәтле үсештә ки, хәзерге тормышыбыз элекке кешеләр өчен чыннан да әкият дөньясы булып күренер иде. Бүгенге көндә тимер белән эшләүче осталарыбыз һәм эшкуарларыбыз халыкның тормыш шартларын яхшырту өчен армый-талмый көч куя, зур уңышларга ирешә.

– Әйтегез әле, юкны барга әверелдереп, эш башлап җибәргәндә, Сез бу биеклеккә ирешәчәкмен, дип күз алдына китердегезме? – дигән сорауны «Казан корыч профильләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең оештыручы идарәчесе **Илдар Гыйльфан улы НОГМАНОВ**ка еш бирәләр.

– Күңелдә кешеләргә, җәмгыяткә файдасы булган эш оештыру уе бар иде. Аннары Татарстанда һәм Россиядә кулланырлык югары сыйфатлы продукция җитештерүне максат итеп куйдык, – дип җавап бирә ул кызыксынучыларга.

Бу уңышның юллары исә бер дә җиңел генә булмаган. Аның нәкъ егерме еллык тарихы бар. Апас районы Борнаш урта мәктәбенең унынчы сыйныфын тәмамлап, Казанга чыгып киткән 1984 ел – зур юлның башы. Иң әүвәл Илдар Дәрвишләр бистәсендәге төзелеш техникумының ишеген ачып керә. Йөзләгән белгечлек арасыннан



*«Казан корыч профильләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективы. Фото җәмгыять архивыннан.*

сәнәгать-гражданнар корылмалары төзелеше бүлеген сайлый. Тырыш егет аны кешеләр өчен һәрвакыт кирәкле һөнәргә саный һәм ялгышмый.

Техникумда укучы студентларның республика һәм илкүләм спорт ярышларында катнашып, зур уңышларга ирешүе дә сөендерә Илдар Гыйльфан улын. Димәк, ул бу техникумда белем алу белән беррәттән рәхәтләнеп спорт белән дә шөгыльләнә алачак. Шулай була да. Туган авылының матур табигатендә чаңгы шуып үскән көчле егет техникумның чаңгы спорты тренеры Зәки Миңнуллин җитәкчелегендә 3-50 чакрым ераклыктагы араларга исәпләнгән чаңгы ярышларында катнаша башлый. Техникум командасының алыштыргысыз әгъзасына әйләнә, чемпион дәрәҗәсенә ирешә. Бүгенге көндә инде зур оешма җитәкчесе булып та спортка мәхәббәтен киметми, киресенчә, үз оешмасы тарафыннан республикакүләм ярышлар оештырып, елына ике тапкыр спортчыларны җыя. Биш ел дәвамында Татарстан Республикасының биатлон буенча өлкән тренеры да булып тора. Ул командага килеп эш башлаганда, биатлончылар Россиядә 40-50 нче урыннарны гына алганнар. Быел исә 1 нче һәм 3 нче урыннарга чыккан спортчылары бар. 2018-2019 елгы сезонда республика данын яклап, унҗиде спортчы стартка басар дип көтелә. Аларга җиңү өчен тырышлык, чыдамлык, түземлек, бердәмлек кирәк булачак. Биатлончы теләсә нинди һава торышында, җилдә, буранда мылтык күтәреп җилдерергә тиеш. Илдар Гыйльфан улы кебек тренерлар булганда, аларның уңышларына ышанычыбыз да зур. Илдар әфәнде бу спорт төренә мәхәббәтен үз кызларына да күчергән. Алар да спортка тартылып, бүгенге көндә эти-әниләрен сөендереп, яхшы нәтиҗәләр күрсәтәләр. Гөлия Казан (Идел буе) федераль университетының психология факультетында югары белем ала. Россиянең биатлон буенча спорт мастеры, Россиянең чаңгыда йөгерү буенча спорт мастерлыгына кандидат. Алия Ижевскида А.И.Тихонов исемендәге физкультура һәм спорт институтында укый. Казанның олимпия резервы училищесында тренер. Олы кызлары Лилия дә, оныклары Диләрә дә спортны ярата. Илдар әфәнденең тормыш иптәше Кадрия ханым – аның уң канаты. Алар бердәм һәм матур гаилә булып яшиләр. Илдар әфәнденең спортка булган мәхәббәтен Кадрия ханым да хуплый. Үзе дә оешма тарафыннан оештырылган чаңгы ярышларын үткәрүдә даими катнаша.

«Чаңгы спортын, йөзү белән беррәттән, иң файдалы, кирәкле дип саныйм. Чаңгыда йөргәндә, кеше табигать белән аралаша, шуңа күрә физик чыныгу белән бергә рухи ләззәт тә ала. Бу спорт төренең тагын бер өстен ягы шунда: монда җәрәхәтләнү ихтималы юк дәрәҗәсендә. Чаңгы юлын салу да әллә ни зур чыгымнар сорамый», – ди Илдар Ногманов. Киләчәк буын сәламәт, көчле булып үссен өчен тырышучы мондый җитәкчеләребез күбрәк булсын иде.

Янә яшьлек елларына әйләнеп кайтсак, тынгысыз, яңача фикерли белә торган егетнең, югары белем кирәклекне аңлап, Казан дәүләт университетының биология-туфрак факультетына укырга керүен белербез. Монда да ул, белем алу белән бергә, спорт өлкәсендәге осталыгын арттыра. Күренекле тренерлар – чаңгы шуу буенча СССРның

спорт мастеры, Россиянең атказанган физик культура хезмәткәре Юрий Козлов һәм Буа районының Адай-Толымбай авылында туган, СССРның атказанган физкультура хезмәткәре Сабирҗан Нәфыйков остазлыгында тиз арада уңай нәтиҗәләргә ирешә. Университет, республика чемпионы булып танылa.

Эшсөяр Илдар шулай ук үзенең махсус белемле төзүче икәнлеген дә истән чыгармый. Тулай торак подвалындагы бер бүлмәне арендага алып, остаханә ачып җибәрә. Берзаман балкон рамнары өчен Бор шәһәреннән кайтарылган пыяла кирәгеннән артык була. Илдар пыяланы тиешле зурлыкта кисеп сата башлый. Бу эшкә тормыш иптәше Кадрия дә кушыла. Пыяла сорап килүчеләр арасында төзелеш фирмалары вәкилләре дә күренә: «Акчабыз юк, алмашка калай бирәбез», – диләр алар. Нишләргә?! Алыргамы? Алмаскамы? Тәвәккәллиләр. Шикләнеп башлаган эшнең ахыры хәерле тәмамлана. Калай әйбәт сатыла. Товар дефицитка әйләнә. Шуннан калайны Донбасстан, Казакъстаннан, Магнитогорскидан, Чиләбедән, Череповецтан һәм хәзерге көндә хәтта Финляндия, Кореядан да кайтарып, эшкәртеп, кулланучыга җиткерә башлыйлар. Илдар әфәнде төзегән оешма шулай һәрвакыт алга бара, яңа үрләр яулый. Бүген оешма базасында тимер эшкәртү өчен илледән артык станок бар. Алар югары сыйфатлы тимер-корыч эшләнмәләрне җитештереп һәм тиешле үлчәмнәрдә кисеп бирү өчен кулланыла. Оешмада эшләүче 157 хезмәткәр үз эшен яратып, горурланып башкара. Сыйфатлы продукция җитештергәч, сатып алучыларның рәхмәт сүзләрен ишеткәч, аларның күңелләре тагын да үсә, киләчәккә планнары да киңәя. Гомумән, монда өйдәге кебек җылы мохит булдырылган, дисәм дә ялгышмам. Хезмәткәрләрнең бергәләшеп чаңгыда йөрүе дә, бәйрәмнәрдә җыр-биюле кичәләр үткәрүләр дә нәтиҗәсез калмый. Оешманың егерме еллык тарихында хезмәткәрләр арасында дүрт пар гаилә кора.

«Казан корыч профильләре» ширкәте, эшчәнлеген киңәйтеп, Чабакса бистәсендә дә үз базасын ачып җибәргән. Монда продукциянең төрләре тагын да киңәйтелгән. Чабаксада да чаңгычылар өчен шартлар тудырылган. Елга берничә тапкыр узучы ярышларга Татарстаннан гына түгел, Россиянең төрле төбәкләреннән дә бик теләп киләләр. Илдар Гыйльфан улының чаңгы спортын үстерергә теләге дә, мөмкинлеге дә бар. Ул бу юнәлештә «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт оешмасы җитәкчесе Рифкать Миңнехановның да теләктәшлеген тоя. Казанда олимпия резервы училищесында биатлон бүлеге эшли башлавы да зур куаныч. Монда Россиянең атказанган тренеры Радик Миңнегулов тренер вазифасын башкара. Училище директоры Фәрит Әхмәдуллин, ТР спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов, Чаңгыда йөгерү һәм биатлон федерациясе президенты Илшат Фәрдиев, аның урынбасары Эдуард Галиевнең даими кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә, спортның әлеге төрендә зур уңышларга ирешербез дип уйларга җирлек бар.

Илдар Ногмановның ярдәмчел, башкаларга битараф кала алмаган шәхес булуы да күпләрдә соклану хисе уята. Ул авыл мәчетләренә, мәктәпләренә, балалар спорт мәктәпләренә дә зур ярдәм күрсәтә, күпкырлы хәйрия эше алып бара. Шуны да аерып әйтәсе килә: гомер-гомергә татар халкы үзенең эшлекле кешеләре, меценатлары ярдәме белән зур эшләр башкарып чыга алган, үсештә булган. Киләчәктә дә Илдар Ногманов һәм ул җитәкләгән оешма коллективы, халыкка ярдәм итеп, уңышларга ирешеп, күркәм эшләр башкарыр дип ышанабыз.

**Айсылу ИМАМИЕВА**

# ДАСТАННАР ВАТАНЫ СИН, СЕБЕР!

Күпкырлы милли фольклор – татар халкын белемле, тәрбияле, рухи чыдам итүдә үзе бер университет ул. Татарны татар итеп танытуда, аның милли үзаңын үстерүдә, омтылышлар тәэминатында тел-авыз иҗатының өлеше юк түгел. Хәлбуки, татар яшәгән җирлектә барлыкка килеп, әле бүген дә югалып бетмәгән фольклор әсәрләре җитәрлек. Сибелеп яткан күп кенә фольклор хәзинәләрен туплап, замандашларга һәм киләчәк буынга җиткерүнең максаты – татарлыгыбызны саклау. Халык иҗатын җыйнау, өйрәнү, халыкныкын халыкка кире кайтару миллилегебезне саклауның бер чарасы буларак кыйммәт.

Татарстан, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә фольклор экспедицияләрендә йөргәндә, шуңа игътибар ителәэ: төрле җирләрдә сибелеп яшәүче татарларның кайсы әле дә үзе әкият, кыйсса яки риваять сөйли белә, кайсынадыр, буыннан-буынга тапшырырлык дәрәҗәдә үк булмаса да, милли фольклор әсәрләре әлегә таныш, ә кемдер инде, ни кызганыч, халык иҗатын бөтенләй белми, белүне кирәк тә санамый. Ә халыкта фольклор саегу – бик аяныч хәл, чөнки сүз сәнгате бетү белән телне югалту арасы бик кыска, шуңа да этник традицияләребезне, фольклор үрнәкләрен барлап, яңартып, алар хакында еш искә төшереп тору кирәк. Фольклорга булган игътибар – туган телебезне саклау чарасы да ул.

Себер җирлегендә яшәүче татарлар тарихи яктан төрле этник компонентлар кушылмасыннан гыйбарәт. Себердә борын-борыннан көн күрүче җирле халык, XIV гасырлардан бирегә күпләп агылган бохаралылар (ягъни Урта Азия төркиләре), төрле чорларда Идел буеннан күченеп килгән татарлар һ.б. бүгенге көндә халкыбызның гаять үзенчәлекле бер катламын тәшкил итеп яши. Шуңа күрә Себер татарларының рухи культурасы, аерым алганда, фольклоры гаять кызыклы, бай, төрле яклап өйрәнүне сорый.

Себер татарлары иҗаты гасырлар буе галимнәр игътибарын җәлеп итеп килгән. XX гасыр урталарында күренекле галим, академик В.Радлов Себердәге татарлардан җыелган фольклор материалларына үзенең атаклы томнарының берсен багышлаган. Галим бастырып чыгарган әлеге томда урын алган халык иҗаты үрнәкләренең егермегә якыны – эпик әсәрләр. 1984 елда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» академик басмасының «Дастаннар» томына (төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы – Ф.В.Әхмәтова) кертелгән эпос текстларының күбесе – шушы төбәктә тупланган җәүһәрләр. Ышанып әйтә алабыз: татар дастаннары ватаны – ул Себер, халык иҗатының таҗы булган эпос жанрына карый торган әсәрләрне күпләп биргән данлыклы төбәк. Атаклы төрки «Алпамыш»ның татар версиясен тәшкил иткән «Алыпмәмшән», гасырлар буе татар күңелен тетрәндереп, телдән-телгә күчкән «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет» яисә «Күр углы» кебек гаҗәеп әсәрләрнең сөйләмә вариантлары, «Йиртөшлек», «Ак Күбәк», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» дастаннары һәм, әлбәттә, «Идегәй» үзе, иң беренче чиратта, нәкъ менә Себердә яшәүче татарлар арасында киң таралган булган.

В.Радлов яшәгән чорлардан алып бүгенге көнгәчә Себер татарларында да фольклор үзгәрешсез тормаган, әлбәттә. Төрле чорда Х.Ярми, Х.Гатина, Ф.Әхмәтова, Ф.Йосыпов, Д.Рамазанова, И.Закирова кебек галимнәр Себер татарлары фольклорына игътибар бирә килделәр. Себер татарлары иҗаты белән кызыксыну, лиро-эпик һәм лирик фольклор әсәрләрен барлап, бастырып чыгару бүген дә дәвам итә.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган фәнни экспедицияләрдә, гадәттә, халыкның барлык төр байлыгы

– буыннан-буынга тапшырыла килгән эпик һәм шигъри сүзе, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, халык медицинасы, педагогикасы, милли сәнгатебез үрнәкләре, музыкасы, бәйләү-чигү осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана, җентекләп өйрәнелә. Мондый чараның төп нәтиҗәсе – халыкта булган матди яисә рухи хәзинәләрне күреп алып, аларны бөртекләп җыйнау, реконструкцияләү һәм халыкның үзенә кире кайтару. Төмән өлкәсе Вагай районында үткәрелгән фольклор экспедициясенең максаты итеп эпик фольклор, дастаннарның бүгенге хәлен-торышын барлау мәсьәләсе куелган иде. Эпос-дастаннары, аларны көйләп-сөйләп бирүче дастанчы-чичәннәре белән дан алган Себердә эпик әсәрләр сакланганмы? Сакланышы ни хәлдә?

Шушы сораулар нисбәтеннән, Казанлы авылына килеп төшкәч тә башкарган иң тәүге эшебез авыл астанасы белән танышу булды. Астана – изгеләр зираты. (Астанә – фарсы сүзе, «бусага», «сарай ишеге төбе», «төп» дигән мәгънәләрне белдерә. – *Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан, 1965. – Б.19*). Биредә шундый исем белән атап йөртелә торган урыннар бар, дип сөйлиләр. Берничә гасыр элек Себергә бохаралылар, ягъни Урта Азия төркиләре күпләп агылган. Аларның бирегә килүенең төп сәбәбе сәүдә-икътисад мәсьәләләре булса, ислам динен таратуда да рольләре зур.

Бохаралылар, бу җирләргә килеп төшкәч, төпләнер урын эзләгән. Җирне казыйлар да чыккан туфракны казылган чокырга кабат күмеп карыйлар икән. Уңдырышлы җирнең туфрагы күпереп, өелеп калырга тиеш ди. Моңа кадәр шундый урын табылмаган, ә Казанлыда исә туфрак казылган чокырына сыймаган, мул булып артып калган. «Уңдырышлы җирләр бу», дип, изгеләр шушында төпләнеп яши башлаган (информант – Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы, Казанлы авылы, 1970 елгы).

Һәрбер астананың үзенең җаваплы кешесе була. Аны «астана хуҗасы» яисә «астана», дип йөртәләр. Бу кеше изгеләр зиратын карап-тәрбияләп тора яисә шул эшне оештыра. Астана хуҗасы булу – гади генә йөкләмә түгел, ә Аллаһыдан бирелгән әмер, борын-борыннан билгеле бер нәселгә тапшырылган бурыч дип ышана җирле халык. Бу нәсел кешесе астана йоласын үтәп яшәргә, бозыклыктан, явызлыктан, һәртөрле начар уй-гамәлләрдән азат булырга тиеш. Әгәр шушы кагыйдәдән чыкса, аның үзенә генә түгел, нәсел-нәсәбенә бәла килә. Андый очраклар да булган. Халык хәтерли, энәсеннән-җебенә кадәр сөйләп тә күрсәтә. Бүген Казанлы астанасы, ягъни астананың төзеклеге өчен җаваплы кеше – Әшрәфҗамал исемле карчык.

Моннан тыш, Төмән өлкәсендәге һәр астананың үз тотемы бар. Әйтик, бу якларда иң олы астана булган Кече Уват (халык телендә – Малай Уват) каберлегенең символы – Үгез. Казанлыда ул – Каз. Халык үзе моны Бохарадан килгән билге дип аңлата. Бу күпмедер дәрәҗәдә мәҗүсилекне, борынгылыкны чагылдырган күренеш буларак кызыклы.

Төшендә астана тотемын күргән кеше тиз арада астана хуҗасына сәдака китерергә тиеш икән. Сәдака итеп тәңкәле акча алына, ул кызыл чүпрәккә төрелә. Шуннан соң гына төш күргән адәм сәдакасын илтеп тапшыра. Тәртибе шулай. Халыкта моны «шык сәдакасы бирү» яки «шыкка төю», дип йөртәләр. «Шык» сүзенең «изгеләр каберен караучы» дигән мәгънәсе бар. *(Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. – Т.2. – Казан, 2015. – Б.497.)* Нәзере булса яисә бәла-каза килсә дә, кеше шыкка төяргә, ягъни астананы караучыга хәер-сәдака төенләргә мөмкин. Шык сәдакасын Төмән өлкәсендәге һәр астанага берәрне таратып чыгу гадәте дә бар. Астанага шык сәдакасы бирергә уеңа килгән булса, аны, һичшиксез, астана хуҗасына илтеп тапшыру мөһим.

Тарихтан билгеле ки, XIV гасырдан Көнбатыш Себердә Урта Азиядән килгән мөселманнар – шәехләр мәҗүсиләргә каршы корал тотып көрәшкәннәр. Халык үзе дә: «Бу җирләрдә бик каты сугышлар булган», – дип сөйли. Шәехләрнең кораллы гаскәрләре, исламны инде кабул итәргә өлгергән җирле халык белән берлектә, Себер олысында бохара ханнарының, татар феодалларының һәм, әлбәттә, ислам диненең йогынтысын ныгыту өчен, көрәш алып барганнар. Шушы вакыйгалар нәтиҗәсе буларак, Себердә яшәүче җирле татарлар арасында ислам таралган.

Астаналарга багышланган риваятьләрне һәр йортта беләләр монда. Күрәсең, изге гореф-гадәтләрне шулай күркәм рәвештә буыннан-буынга тапшыра киләләр. Менә,

мәсәлән, Мөгамәтуллина Мөнәвәрә Җамалетдин кызы (1933 елгы, Сөләйман авылы) Паеш астанасы турында мондый риваять сөйләде: «Бохарадан килгән муллалар җирле халыкны дингә өйрәткән. Аларны саклаган солдатлар булган. Әллә ничә йөзләп шундый кеше үтерелеп, күмелгән җирне бездә «астана», диләр. Паеш астанасы – Иртыш аша яхшылар яткан җир. Инде алар, кешенең төшенә кереп, үзләрен белдерткән. Бер хатын Паеш астанасын карап торган. Иртән, ире торганчы, яланаяк Иртышны атлап чыгып, яхшыларны зиярәт итеп кайта икән. Ире белгәнче, шулай караган астананы. Бервакыт ире күзәтә бара моны. Иртыш аша чыгып та хатынының батмавына исе китә моның. Ире күргәч, хатын балтырыннан суга бата. Шул хәлдән соң, ирем көнләшә, дип, астананы нәселендәге башка кешегә тапшыра».

Тәрбияви әһәмияте ягыннан гаҗәеп тәэсирле булып тоелган «Кәтербәт сазлыгы риваяте» дә шул ук бохара «яхшылары»на барып тоташа. Аның «Нугайдагы алтын риваяте» дигән исеме дә бар. Түмән өлкәсенең төрле авылында бу вакыйганы төрлечә сөйлиләр, әмма сюжет, мәгълүмат – бер үк, асылы – үзгәрешсез. Бу риваятьнең Казанлы авылында Хәлим Харис улы Сәгыйдуллиннан (1949 елгы) һәм Тугыз авылында Гөлҗамал Садыйк кызы Шамратовадан (1937 елгы) ишеткән вариантларының җыелма тексты түбәндәгедән гыйбарәт: «Малай *(Малый, ягъни Кече. – Л.М.)* Уват белән Большой Уват арасында кырык биш чакрым озынлыктагы, унбиш чакрым киңлектәге күл бар. Аны Олы күл, диләр. Тирәвене *(тирә-юне. – Л.М.)* Нугай кыры дип атала. Күл кырында авыл булган. Элекке заманда. Ул вакыт без дә булмаган. Бу күлдә балык тотканнар. Кәтербәт сазлыгы шул күл янында. Анда яхшылар алып килгән алтын күмелгән.

Бервакыт Нугай авылына яшь килен төшкән. Ул килентәшкә күлдән алтын чыгып утырган. Юан *(зур. – Л.М.)* чүген *(чуен. – Л.М.)* булган, имеш. Өч көн рәткә киләте бу килентәш күл буена, өч көн рәткә алтын чыгаты. Анда энҗе-мәрҗәннәр, ат сбруйлары, унике штук алтын ияр булган. Килен моны беркемгә дә әйтмәгән, байлык үземә генә булаты, дигән. Ул килентәш алтынны шулай өч көн уйната икән, карап торып.

Инде дүртенче көн баруына чүген казан да юк, алтыннар да юк. Аннан килен авылга кайтып сөйләгән: «Мин сезгә әйтмәгән идем, ул шундый-шундый урында шулай-шулай батып китте», – дигән.

Шуннан бер карт, мулланы ияртеп, күл буена төшкәннәр. Мулла китап тотып барган, аннан китап ачкан да әйткән: «Авылдан бер начар кеше чыкты, ул килеп җиткәнче алсак, җитешәбез, өлгермәсәк, алтын төпкә китәр». Алтынны чыгара башлаганнар икән дә, чыгарып бетергәндә генә мулла әйткән: теге кеше болар янына килеп җитәр, дип. «Миңа өлеш калдырыгыз», – дип кычкырган. Шуннан алтын төпкә төшкән-киткән, тотып кала алмаганнар.

Карт мулла полтар караган *(фал ачкан, баккан. – Л.М.)* һәм әйткән: «Котык токымнан *(Коелар нәселе)* ак чәчле күк күзле кыз бала туар, күз иясе *(уртасы. – Л.М.)* кызыл булыр. Унсигез яшенә җиткәч, алтын аңа чыгар, ул ала алыр байлыкны», – дигән. «Алтын аңа чыгып утырыр, курыкмаска кирәк. Алтын янына килеп, юан *(зур. – Л.М.)* пычак алып, корбан чалсын», – дип өйрәткән. «Корбан чалганда: «Байлыгым бөтен илгә, миргә булсын», – дип чәнечсен. Ул вакыт алтын батмай», – дигән.

Котык токымда, мулла әйткәнчә, чыннан да, ак чырайлы, ак чәчле, күк күзле, күз уртасы кызыл бала туа. Әмма кызга унсигез тулганда, аны алтын яткан җиргә – Кәтербәткә алып чыгучы булмый, чөнки этисе сугыштан кайтмый калган, ә эшнең рәтен белүче башка кеше юк. Шулай итеп, алтын төптә кала.

Мулла тагын әйткән була: «Әгәр дә кыз ала алмаса, Котык токымның җиде буынынача китәр: унсигез елдан унсигез елга шул ук нәселдә шундый ук бала туар. Алтын табылганчы. Җиде буынга җиткәнче, алтын табылыр. Котык токымга әйтелгән алтын бу».

Әмма шунысы да бар диләр: «Котык нәселе иманлы, шәфкатьле, изге нәсел булып дәвам итәргә тиеш. Әлеге нәсел кешесенең күңеле гел чиста, керсез булуы кирәк. Комсызларга, затсызларга Нугай алтыны чыкмайты, булмайты». Котык нәселе бүген дә яши, ди, халык аларның кемнәр икәнен яхшы белә, кызыл күзле, ак тәнле ир бала хәзер уналты яшьтә, диделәр.

Менә шундый риваять бар Себер татарларында. Моны һәм астаналарга багышланганнарын тарихи риваятьләр дип билгеләсәк, мифик чыгышлы хикәятләргә боларыннан да күбрәк юлыгырга туры килде. Урман яки Күл иясе адаштырган, яисә, белештермичә, урман иясенә – Йышка өйләнеп харап булган аучылар турындагы хикәятләр – әнә шундый әсәрләрнең бер төркеме. Йыш – Шүрәлегә охшаш образ, әмма аның гадәте кешеләрне кытыклап үтерү түгел, ә калын урман эченә алып кереп адаштыру. Йышка яки Йыш иягә (монысы ир затыннан булган урман иясе) юлыккан кеше, кая барганын абайламыйча, йөгерә-атлый урман эченә кереп китә, тәмам хәлдән тайганчы адашып йөри. Шуңа күрә Ияләрнең – урманныкымы ул, күлнекеме, йорт-кура, мунчаныкымы – ачуын кабартырга, аларга ошамаслык начар гамәлләр кылырга ярамый, чаманы югалтырга, тыелган эшне кылырга ярамый, дип белә халык. Моның шулай булуына дәлилләр китереп сөйлиләр. «Бер сунарчы күлдә йөргән. «Йиргә ятма, йоклама сунарда», дигәнне белсә дә яткан. Йоклаган. Төшенә өч кыз керә моның. Сине яраттык, диләр сунарчыга, беребезне ал, диләр. Шуннан уянып китә бу, кызны алып кайта, белми Йыш икәнен, шуның белән яшәйте. Үзе сунарга йөри. Бичәсе бу кайтуга тәмледән-тәмле ит ризыклары әзерләп куя икән һәм әйтә: «Кайтканда ишекне гел шакып кер, юкса ачуланышырбыз», – ди. Ир каян алып пешерә дип шиккә төшә. Бервакыт ишекне шакымый кайтып керә дә күрә: хатын аннан бет ала, моннан борча тота да сумсалар, пилмәннәр ясый ди шулардан. «Ишектән кердем, тәрәзәдән чыгам!» – дигән дә чыгып очкан, ди ире искәрмәстән кайтып кергәч. Дүрт баласы калган. Токымнары әле дә бар ди. Күзләре канлы, кызыл. Ул сунарчы яшәгән йорт урынына бүтән берәү дә йорт салмаган. (Информант – Мөгамәтуллина Мөнәвәрә Җамалетдин кызы, 1933 елгы, Сөләйман авылы.)

Җен карчыгы Изурчык белән төне буе җеп эрләүдә ярышкан Кече әби, пәри хатынына кендек әбисе булган корткаякка багышланган мифик риваятьләрне дә Себер татарлары ихластан бирелеп, бик мавыгып бәян иттеләр.

Аерым бер төркемдә – үлгәннән соң җиде кабер аша чыккан кан эчүче зат – Купканнарга, алар белән бәйле мажараларга багышланган хикәятләр. Аларны тыңлаганда, тын алырга да куркыта, кичке якта урамга чыгарга шикләндерә.

Кемме соң ул, нәрсәме – Купкан? «Купкан – бу дөньядан туймый китеп кузгалган кеше пулаты, – дип аңлата Себер татарлары. – Кире кайтып, кешеләрне куркытып йөрите. Каты кузгалып йөри башласа, кешеләргә зыяны арта. Бик азып киткән Купкан кешеләргә тия, аларның канын эчеп йөри башларга мөмкин». Мондый хәл булмасын дип, алдан ук чаралар күрелә икән.

Купканны басу өчен, Коръәннән уналты сүрә укый-укый, иң элек өч кат зиратны әйләнеп чыгарга кирәк. Шуннан шул ук сүрәләрне киресенә укыйсы. Бер хәрефен дә ялгышырга ярамый. Ялгыштың – беттең дигән сүз, йә үләсең, йә гомерлеккә гарип каласың. Шуныңчы укыйсы – кем кузгалган, шул алдыңа килеп басканчы. Купкан каршыңа килеп баскач, кирәкле аятьне укып, аңа урынына кереп ятарга кушасың. Шулай иткәч, Купкан каберенә кереп ята. Бу эшне укымышлы мулла гына башкара ала икән. (Информант – Пахметова Сөлҗамал Ситдыйк кызы, Тугыз авылы, 1926 елгы.)

Таңнан торып, җиде өйнең чүбен себереп, аять укып өшкертеп, зиратка алып барып, Купкан чыга торган җиденче кабер тишегенә салсаң да, Купкан басыла, имеш. (Информант – Шамратова Гөлҗамал Садыйк кызы, 1937 елгы, Тугыз авылы.)

«Кем кузгалганын белү өчен, зиратта каберләрнең комын карап цыккалы гәрәк. Кузгалган кешенең кабере өстендә комы иләктән иләнгән кебек пулаты. Әүвәл син шуны сизеп, кем кузгалуын белсәң, Купкан төнлә төшеңә керәте, беркемгә дә сөйләмәскә кушып куркыта», – дип сөйлиләр информантлар. Бу дөнья белән теге дөнья арасындагы бәйләнешкә караган гаять серле тема булгангамы, мавыктыргыч итеп сөйләнгәнгәме – бирелеп китеп тыңлап утырам. Әлеге өлкә гомер-гомергә адәм баласында зур кызыксыну уяткан, адәм акылы аңлый алмастай күренешләргә халык үз бәясен биргән, исламга, Аллаһы ярдәменә таянып, боларга карата үз җавабын да тапкан, күңелен шулай юаткан.

Әле шундый хәлләр дә булган, имеш, Купканны Коръәннән аятьләр укып басарга муллаларның гына көче җитмәгәч, бик каты кузгалып йөри башлаган берәүнең, каберен

ачып, башын чапканнар. Ул исә башын култык астына кыстырып йөри башлаган. Ахырда аның күкрәгенә казык какканнар. Аннан соң да туктамаса, андыйны яндыралар икән. Купкан турында сөйләүче ялгыш та аның исемен телгә алмый. Юкса каршыңа чыгуы бар, дип ышаналар. (Информант – Рәхмәтуллина Мәүлига Нәгыйдулла кызы, Казанлы авылы, 1902 елгы.)

«Кая соң ул купканнарыгыз, нигә миңа бер дә очрамады?» – дигән соравыма да аңлаешлы бик матур җавап алдым: «Фәрештәләрең яхшы саклый торган, димәк. Кешене саклаучы фәрештәләр аның күзенә җен-пәриләрне дә, купканнарны да күрсәтмиләр, кешене алардан саклыйлар. Аннан болай артык курыккан вакытта, йә бик ашыгып йөрүче кешегә дә андый нәрсәләр күренми. Андыйлар, кабаланып, җеннәрне таптап ук уза. Шуңа күрә бүгенге көндә кул-аягы сынык җеннәр күп һәм алар кешеләргә ачулы». (Информант – Ватутова Флёра Рәхимҗан кызы, Казанлы авылы, 1963 елгы.)

Миф, уйдырма дип бәялибез инде боларны. Әмма шул уйдырмаларга никадәр күңел аклыгы, садәлек сыйган лабаса! Юкка гына халык иҗаты аның күңел көзгесенә тиңләнми шул. Түмән өлкәсендә эпик фольклор әсәрләре барлап йөргәндә, мин шулар турында уйландым.

Әби-апалардан яшь чагында нинди уеннар уйнаулары турында сорашам. «Саргынаем», «Аралап алышмак», «Өзелешмәк», «Тилгән», «Каешлы» дип аталган җырлы-биюле уеннары Казан татарларының «Назалы», «Түгәрәк», «Тамчылы» h.б. уеннарын хәтерләтә, әмма җыр текстлары, такмаклары, көйләре үзенчәлекле:

«Яшь чакта «Саргынаем» уйный торган идек. Җитәкләшеп басасың да ер ерлайсың бер-береңә такмак-такмак:

*Сөләйманнан уң якка*
*Казанлы авыл – бай авыл.*
*Сөләйманның складына*
*Хәтирә туташ каравыл.*
*Убай юлы, Убай юлы,*
*Убай юлы канаулы,*
*Мин синең сөйгәнең күрдем –*
*Скрипка танаулы.*
*Сөләйманның буйдаклары*
*Аюның табанынтай,*
*Казанлының буйдаклары*
*Алманың сабагынтай.*

Етәкләшеп түгәрәктә әйләнәсең. Уртада бер пар тора. Такмак бетсә, бу икәү түгәрәккә чыгып өерләнә, янә ике кешене этеп уртага чыгаралар да тагын ерлайлар». (Информант – Шамратова Гөлҗамал Садыйк кызы, Малай Уват авылы, 1937 елгы.)

Авыл көенә җырлана торган әллә никадәр кыска җыр язып алынды Себер татарларыннан. Казанлы авылында Мөгамәтуллина Рабига апа Әмин кызыннан (1931 елгы) гына да шундый 80 куплет җыр теркәлде. Биредә Карагай авылында Ваби исемле кеше яшәгән, ул сукыр булган, авылдан-авылга йөреп тамак туйдырган. Аны оста импровизатор – такмак чыгаручы буларак хәтерлиләр, такмакларын да онытмаганнар. Ваби 1950 елларда дөнья куйган.

Кабат эпик фольклорга әйләнеп кайтсак, Мөгамәтали мәргән белән Кузы Нияска, аючы Хәйбуллага, Атамыш аучыга багышлап матур-матур кыйссалар сөйләделәр Себердә яшәүче татарлар. Аларда күптән түгел генә шушы җирдә яшәгән кешеләр турында сүз бара, боларның исемнәре халык теленә юкка гына кермәгән. Гаҗәеп батыр, пәһлеван, төз атуда тиңсез оста булганнары өчен онытмый аларны халык. Мөгамәтали мәргән, мәсәлән, яхшылар нәселеннән, ягъни Бохарадан килгән шәехләр токымыннан булган. Халыкта аның оста мәргәнлеге, җитезлеге, батырлыгына багышланган яисә башка мәргәннәр белән көч сынашулары хакында күп кыйссалар телдән-телгә йөри. Мәсәлән, Мөгамәтали белән күрше авыл мәргәне Кузы Нияснең төз атуда көч сынашуы турындагы кыйсса хәтердә уелып калды. «Кузы Нияс оста

чаңгычы булган. Песнең якларда аучының эте карап өргән агачтан иң яхшы чаңгы ясаганнар. Чаңгы ясарга агач сайлаганда, аучының эте кайсы агачка карап өрә, шул агачны аударганнар. Наратның озынына, яшенә, формасына карап эстәгәннәр, эт тә аңа карап өрсә, яхшы саналган. Иң елгыр чаңгы Тугыз авылыныкы – яхшылар нәселеннән Кузы Нияста икән. Кузы Нияс чаңгысының эзе калмый булаты. Оца торган чаңгылар булаты. Уват авылыннан Мөгамәтали мәргән белән урманда очрашканнар да көч сынашып карамакчы булганнар болар. Сөйләшкәннәр багып атуга (багып ату – яшертен барып ату. – Л.М.). Чаңгылар белән булганнар. Аңны (поши. – Л.М.) күргәч, Мөгамәтали мәргән мылтык төзәгән аткалы. Шулвакыт Кузы Нияс ботакны сындырган аңны кацыру өчен, Мөгамәтали мәргән ата алмый калган, аң олагып цыгып кацкан. Шуннан Кузы Нияс аңның артыннан чаңгысында куып җиткән дә атып еккан аңны, бугазлаган, аннан кайтып киткән. Кузы Нияс кацып барган аңны чаңгысында куып йитеп атып алган булаты. Өстен чыккан Мөгамәталидән. Мөгамәтали барып караган, моның чаңгы юлы булмаган, эзе күренмәгән. Халыкка кайтып сөйләгән хәлне. Халык шикләнгән Кузы Ниястан, моның суда юынуын көткәннәр. Бер кеше күргән: Кузы Ниясның култык астында канатлары бар икән, юынганда болар күренгән. Кузы Нияс карап торучы кешегә арты белән торса да, аны күргән, кыцкырган: «Беркемгә сөйләмә, сөйләсәң, петәсең!» – дигән. Аның канатын күргән кеше Кусы Нияс картаеп үлгәч, аны сөйләгән. Шуныңчы сөйләмәгән. Кузы Ниясның оца торган чаңгылары әнә шул каурый-канатларыннан булаты». (Информант – Сәгыйдуллин Хәлим Харис улы, Казанлы авылы, 1949 елда туган.)


Ауда йөргәндә, хәтәр хәлгә очрап, зирәклеге, батырлыгы, көче аркасында котылып калган Атамыш аучы кыйссасын, берүзе кырык карышлы яралы аюга (информант 1 карышны 10 см дип уйлап, дүрт метрлы җәнлекне күздә тотып сөйли) каршы чыгып, җиңү яулаган аючы Хәйбулла бабай турындагысын һ.б.ларны язып алган вакытта Себер татарлары: «Бу булган хәл, дип сөйлиләр», – дияргә онытмый. Шунысы кыйммәт: әлеге кыйссаларда халкыбызның героик дастаннарыннан килә торган рух бар. Ул – батырга дан җырлау, аның гадәттән тыш көчле булуын ассызыклау – каһарманлык. Мөгамәтали мәргән, Кузы Нияс, аючы Хәйбуллаларга багышланган шактый күләмле бу кыйссалар атаклы «Алпамыш», «Йиртөшлек», «Кадыш Мәргән» һ.б. дастаннар традициясен дәвам итәләр. Әлбәттә, кыйссаларның без язып алганнары әллә ни ерак гасырларга карамый, алай да халык иҗатының бүгенге көнгә, заманга туры килә торган иҗат җимешләре алар. Себердә яшәүче татарларның тормышы кош, җәнлек аулау белән тыгыз бәйләнештә. Менә шушы бәйләнеш аларда батыр аучы-мәргәннәр турында мавыктыргыч әсәрләр барлыкка китергән һәм, аеруча мөһиме, күргәнебезчә, мондый кыйссалар тел-авыз иҗаты буларак әле дә очрый.

Төмән өлкәсе Вагай районында яшәп ятучы милләттәшләребез белән аралашу татар фольклористикасын яңа эпик образларга, фольклорга бәйле сюжетларга баетты, туган телебезнең никадәр бай булуына янә бер кат инандырды. Халык иҗаты материаллары бар һәм күп Төмән өлкәсе татарларында. Тарих чоңгылының матди булмаган бик күп рухи байлыкны йота барганлыгы аңлашыла. Себердә яшәүче татарларның бай тарихы, борынгылыкны саклап калган җирле сөйләшләре, гореф-гадәт, йолалары белән бергә телдән-телгә тапшырыла килгән риваятьләре, мифологик хикәятләре, героик дастаннар төркеменә кертерлек кыйссалары – заман фольклорының тиңсез хәзинәләре.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре докторы*

# «НӘККАШ – БИЗӘК ОСТАСЫ УЛ...»

## НӘҖИП НӘККАШКА 70 ЯШЬ



*Татар милләтенең борынгы мәдәни мирасын барлаучы, өйрәнеп, тикшереп, яңадан халыкның үзенә кайтаручы, сәнгать традицияләрен дәвам итүче шәхесләр арасында Нәҗип Нәккаш исемле бер асыл зат бар. Әйе, беренчедән, ул – әдәбият галиме, текстолог. Архивлардагы, китапханәләрдәге борынгы кулъязмалар арасыннан «энҗе-мәрҗәннәр» табып, әдәби мирасыбызны барлап, текстологик яктан эшкәртеп, хәзерге әдәби телгә яраклаштырып, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләгән дәверендә (32 ел) дүрт китап чыгарды. Икенчедән, ул – талантлы рәссам, коммунистлар хакимияте чорында онытылырга дучар ителгән борынгы сәнгатебезнең бер төрен – гарәби каллиграфия сәнгатен тергезеп, яңартып җибәрүче. Татарда каллиграфлар күп түгел, бармак белән генә санарлык. Нәҗип Нәккаш гарәби матур язу сәнгатенең берничә төре белән берьюлы шөгыльләнә һәм һәр өлкәдә уңышлары аз түгел. Шуңа күрә дә хөкүмәтебез бу күренекле шәхесебезне «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән шәһрәтле исем, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләде. Ниятебез – укучыларны шушы сирәк һөнәр иясе белән якыннанрак таныштыру.*

**– Нәҗип әфәнде! Әңгәмәне традицион сораудан башлыйсы килә: кем, кайдан Сез, әдәбият фәненә ничек килдегез дә сәнгать өлкәсенә ничек кереп киттегез?**

– Тумышым белән Мамадыш төбәгеннән, Чулманга коя торган ямьле Берсут елгасы буена урнашкан үрле-үзәнле, елга-чокырлы, бик күп чишмәләре булган борынгы Өчөйле (рәсми исеме – Усали) авылыннан. Әтием Фәйзерахман һәм әнием Бибигайшә исемле колхозчылар гаиләсендә беренче бала булып 1948 елның август аенда дөньяга килгәнмен. Атам ягыннан бабаларым (тугыз буын) – Ырысай нәселе – игенче һәм һөнәрчеләр, балта осталары. Балта остасы булу өчен, рәссамнардагы кебек, кул белән күз арасында тыгыз бәйләнеш кирәк, шуңа күрә мин үземдәге рәсем ясау сәләтен нәселебездән киләдер, дип уйлыйм. Әтием клуб яисә ферма мөдире булып эшләгәндә, белдерүләр, плакатларны үзе яза иде. Элекке заманда фанерадан эшләнгән чемоданнар бар иде бит. Шундый чемодан тотып яңа гына армиядән кайткан Мөбарәкҗан абый (әтинең энесе) бервакыт шуның капкачын ачып җибәрде дә эчке өслегенә акварель буяу белән үзенең хәрби киемле портретын ясап куйды. Заман башка булса, уку, тәрбия эләксә, аңардан рәссам да чыгар иде, бәлки. Мин үзем дә рәссам булу өчен махсус белем алмадым. Кечкенәдән үк рәсем ясауны, матур язуны яраттым. Бишенче сыйныфтан башлап укуны тәмамлаганчы, сыйныф дивар газетасының бизәүче рәссамы идем, мәктәп һәм авыл китапханәләрен бизәүдә катнаштым. Урта мәктәпне тәмамлагач, күп балалы атам-анам гаиләсенә булышыйм дип (алты бала идек без), үзем укып чыккан мәктәбемдә җиде ел эшләргә туры килде. Рәсем дәресләрен укыттым, түгәрәкләр алып бардым, шуның өчен сәнгатькә кагылышлы барлык журналларны алдыра, китаплар туплый идем. Шулар аша үзлегемнән өйрәнергә тырыштым. Шулай итеп, рәсем ясаудан мин һичкайчан өзелеп тормадым. Үзем белән бергә эшләүче, электәге татар теле һәм әдәбияты укытучым Мәрьям апа: «Нәҗип, бу сәләтләрең белән монда йомылып калма, сиңа укырга кирәк, укырга бар!» – дип кыстый торгач, ниһаять, 1974 елда 26 яшемдә Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Беренче курстан ук Лена Таҗиева кул астында гарәп телен өйрәнә башладым. Кечкенәдән шул серле хәрефләрнең мәгънәләрен белергә

омтыла идем. Университетта «Әдәби сүз» дивар газетасын бизәүгә күп көч куйдым. Профессор Хатыйп Госман сәләтле студентларга зур игътибар бирә торган шәхес иде. Дүртенче курста укыганда, ул мине, тагын бер студент һәм ике укытучы белән бергә, Бакый ага Урманчега каллиграфия өйрәнергә йөртте. Атаклы остадан өч-дүрт дәрес алып кала алдым, ул безне каләм тотарга, матур язуның кайбер серләренә төшендерде.

Борынгы әдәбият белән кызыксынуым гыйльми тикшеренүгә – моңарчы өйрәнелмәгән урта гасырлар татар прозасын өйрәнүгә этәрде. Бу эштә иң беренче җитәкчеләрем Хатыйп Миңнегулов, Хатыйп Госман булды. Өченче курста укыганда, Хатыйп ага миңа XVIII гасырдан сакланып калган зур күләмле хикәятләр җыентыгын тикшерүне тәкъдим итте. Шул китап хакында диплом эшемне якладым һәм кулъязманы басмага әзерләү эшен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли башлагач дәвам иттем. Ул китап булып (437 битле) 1994 елда басылып чыкты. Шуннан соң «Физаиле-ш-шөһүр вә саваплы гамәлләр», «Гыйбрәтле хикәятләр» һәм «Камилә вә Димнә» проза китаплары дөнья күрде. Хәзерге вакытта бишенче китап өчен әзерләнгән хикәятләр «Безнең мирас» журналында басылып килә.

**– Элекке дини һәм әдәби мирасны халыкка кайтару – Сезнең эшчәнлекнең бер ягы. Без әле аның икенче ягын да, шулай ук борынгы мирас – бу юлы гарәби каллиграфия сәнгате белән бәйле эшчәнлегегезне беләбез. Сезнең «Нәккаш» дигән тәхәллүсегез кызыклы, аның мәгънәсе нидән гыйбарәт?**

– Бу тәхәллүсне 1991 елда журналларда тәүге эшләрем басыла башлагач та алдым. Беренчедән, Исмәгыйлев – бик таралган фамилия, мине башка Исмәгыйлевләр белән бутамасыннар, дидем. Икенчедән, минем әлеге шөгылем әдәбият белән турыдан-туры бәйләнгән. «Нәккаш» – гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, иң беренче тар мәгънәсе – «ташка уеп бизәк ясаучы, ташка язучы» дигәнне аңлата. «Нәкыш» (бизәк) сүзе дә шул тамырдан. Киң мәгънәдә бу сүз «рәссам», «график» дип тә аңлашыла.

**– Сезнең әүвәлге традицион шәмаилләргә якын эшләрегез дә һәм алардан аерылып торган, үзегезгә генә хас, яңача әсәрләрегез дә бар. Аларның үзенчәлекләрен, яңалыгын аңлатып бирсәгез иде.**

– Традицион шәмаилләрдә, гадәттә, Коръәннән аятьләр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләре, Алланың бөек исем-сыйфатлары; Мөхәммәд галәйһиссәламне данлаган сүзләр, аның сәхабәләре Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Галинең исемнәре; дүрт олуг фәрештә: Җәбраил, Газраил, Микаил, Исрафилнең исемнәре языла. Шулай ук, сирәгрәк булса да, атаклы гарәп һәм фарсы шагыйрьләренең Аллага, Мөхәммәд пәйгамбәргә, Ислам диненә багышланган хикмәтле юллары бирелә.

Мин исә үземнең шәмаилләрдә Коръән аятьләре, пәйгамбәр хәдисләре белән бергә, үзебезнең татар шагыйрьләренең дә шул эчтәлеккә туры килгән, аваздаш булган шигъри юлларын урнаштырам. Мәсәлән, Коръәндә (2 нче сүрә, 153 нче аять) сабыр итү турында шундый гыйбарә бар: «Аллаһы Тәгалә сабырлар белән бергә». Нәкъ шуңа туры килеп тора торган мәгънә Тукайның «Сөткә төшкән тычкан» шигырендә бар:

*И карындаш! Син кирәксә суга бат йә сөткә бат –*
*Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сәбат!*

Гомумән, Коръән аятьләренә һәм хәдисләргә тәңгәл шигъри юлларны Тукайдан күп табарга була. Тукайның шигъри юлларын файдаланып, кырыкка якын әсәрдән торган тулы бер цикл иҗат ителде. Нәкъ менә шул цикл һәм татар мәчетләре бизәлеше өчен дәүләтнең Г.Тукай исемендәге олы бүләгенә лаек булдым.

**– Сез каллиграфия сәнгатенең онытылган, күпләр бөтенләй белми торган төре – тугра сәнгате белән дә шөгыльләнәсез. «Герб» сүзен алмаштырган тугра төшенчәсен матбугатка, сөйләмгә кертеп җибәрүче дә, ялгышмасам, Сез булдыгыз кебек...**

– Әйе, шулай туры килде. Җөмһүриятебез туграсын иҗат итү конкурсында мин дә катнашкан идем. Профессор Марсель Бакиров идеясенә иллюстрация буларак, дәүләт туграләры ясадым. Шул сурәтләр белән аның мәкаләләре дөнья күрде, «тугра» сүзе шул вакытта таралды.

«Тугра» – борынгы төрки сүз. Ул – билге, тамга монограмма, логотип, герб дигәнне аңлата. Тамырында «ту», «тугъ» сүзе ята. Гаскәри берләшмәнең, бүлекчәнең билгесе булган әләмне, байракны шул сүз белән атап йөрткәннәр. Бу сүз безнең борынгы әдәбиятыбызда очраштыргалый. Әле язу кулланылмаган борынгы чорларда күчмә төркиләр берничә гади сызыктан оешкан бакыр, бронза, тимер туграларны утта кыздырып басып, далага көтүгә чыгарып җибәрәсе атларын һәм башка терлекләрен тамгалый торган булганнар. Һәр кабиләнең, ыруның да үз тамгасы булган. Соңрак дәвердә, төркиләр Ислам динен кабул иткәч, дин белән, Коръән белән бергә гарәп хәрефләре дә кулланылышка кереп киткәч, хан, әмир, шаһ, солтаннарның фәрман-боерыкларында, ярлыкларда, дәүләтара хатларда хөкемдарның исеме, титулы инде гарәп хәрефләре белән үзенчәлекле мәһабәт, купшы стильдә, матур монограммалар рәвешендә языла торган була. Шуны электән килгән төрки сүз белән – «тугра», дип атаганнар.

Руслардагы клеймоның синонимы булган «тавро» сүзе нәкъ менә шул төрки сүздән ясалган.

XIX гасыр урталарыннан татарлар, бигрәк тә укымышлы кешеләр, муллалар, сәүдәгәрләр үзләренең шәхси мөһерләре, китап билгеләре (эклибрис) рәвешендә куллана башлаганнар. Ә инде XIX гасыр ахырында үзеңнең туграң сурәтләнгән шәхси мөһерең булу культуралылык билгесе саналган. Казандагы Милли музейда 48 мөһердән торган, Казанда яшәгән француз рәссамы, сәнгать белгече Л.О.Сиклер тарафыннан тупланган коллекция саклана. Алар арасында классик стильгә якыннары да бар.

Гарәп хәрефе – күркәм сурәтле, сыгылмалы, тасвирый мөмкинлекләре зур булган шрифт. Хыялың бай икән, аннан күптөрле сурәтләр, бизәк-сыннар ясарга мөмкин.

**– Нәҗип Нәккашның милли архитектурабызны бизәүдәге эшләре дә игътибарга лаек...**

– Күпләргә таныш, күзгә ташлана торган каллиграфик эшем Казанның үзәгендә, Тукай мәйданындагы мәчет манарасына охшаш итеп күтәрелгән стеладагы сәгать таблоларында урын алган; рәссам-металлист И.Башмаков тарафыннан Г.Тукай шигырьләренә аваздаш итеп ясалган скульптура композициясендә иң зур яңалык шул: сәгать цифрлары урынына саннар татарча язылды. Татар саннары бер-ике иҗектән генә торганга, лаконик рәвештә түгәрәк шәкелендә килеп чыкты. Бу – дөньяда цифр урынына сүзләр язылган бердәнбер сәгатьтер, бәлки. Соңгы елларда Түбән Кама шәһәрендәге, Лениногорскидагы җәмигъ мәчетләре, Казан шәһәрендәге «Ярдәм» мәчете, Казанның Борисоглебовск бистәсендәге мәчетләрдә минем каллиграфик эскизларым буенча дизайнерлар тарафыннан «смальта» дигән декоратив материалдан бик матур, купшы мозаик паннолар ясалды. Мәрҗани мәчетенең яңа төзелгән уң як катында, хатын-кызлар өчен гыйбадәт залында минем эскиз буенча «Айәтү-л-күрси» тексты гипстан кисеп урнаштырылды.

**– Нәҗип әфәнде! Сезнең эшегезне дәвам итүчеләр – шәкертләрегез, башка хаттатлар бармы? Һәм, гомумән, Татарстанда гарәби матур язу сәнгате нинди хәлдә?**

– Аллага шөкер, Татарстанда бу сәнгать күтәрелештә! Әлфия Хәлиуллина-Исхакова, Фирдәүс Гыйрфанов, Ришат Сәләхеддинов, Рөстәм Шәмсутов, Чулпан Шәрифуллина, Гөлназ Исмәгыйлева, Роза Хуҗина, Рамил Насибуллов үзләренең матур, югары зәвыклы әсәрләре белән сокландыра. Әлеге юнәлештә иң беренче күнекмәләрен минем җитәкчелектә башлаган Татарстанның халык рәссамы 94 нче яше белән баручы В.А.Попов үзенең каллиграфик композицияләре белән дан казанды, Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә нәкъ менә шул юнәлештәге эшчәнлеге өчен лаек булды. Шулай итеп, милләтебезнең гүзәл традицияләрен дәвам итүче бу сәнгать яшәячәк әле!

**– Сезнең шәхси туграгызда очып баручы кош сурәтләнгән. Моның берәр символик мәгънәсе бармы?**

– Үземчә мин моның белән очкан кош кебек тиз үтеп китә торган фани дөньяны, шул вакыт, шул дөнья эчендәге үземне сурәтләдем. Менә шул очкан коштай тиз үтеп китә торган гомердә эз ярып, үзеңнән соң игелекле эшләр калдырып китәргә иде. Бу тугра шуңа омтылышымны аңлата...

*Әңгәмәдәш* – **Айсылу ИМАМИЕВА.**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**БАТУЛЛА**

## Әче телле Туфан

С и б г а т  Х ә к и м . Ай усал Туфанның син сөйләгән «Могикан»ы.

Б а т у л л а . Усал, Сибгат абый, усал. Туфан умырзаялар, ромашкалар, резедәләр, агылган болытлар шагыйре буларак күбрәк билгеле. Елмая торган Туфан бар. Әче телле Туфан бар. Халык арасында таралган бик усал юллары бар.

*Безнең башта, энем, зур нәрсәләр,*
*Синең башта, энем, ни исәп?*
*Күсәк икәнеңне күптән беләм,*
*Кем кулында соң син, и күсәк?*
(Табиевка)

С и б г а т  Х ә к и м . Шәп! Хе-хе! Хе-хе-хе, шәп!

Б а т у л л а . Тагын да шәпләре бар.

*Әдәбият мәйданы ул*
*Көрәш тә алыш кына;*
*Халык намусы булырга*
*Җитми шул «Намус» кына.*
(Бәширгә)

С и б г а т  Х ә к и м . Хе-хе-хе, шәп!

*1986*

## Кичәгә бәя

Тинчурин театрында «Актаныш талантлары» кичәсе булып узды. Алдагы елларда актанышлылар җыр, бию, хор белән Казан тамашачысын хәйран калдыра торган иде. Бу юлы кичә, оешмаганлыктан, сүлпән барды. Тәнәфес вакытында азнакайлы Марсель Гали, Актаныш шагыйрьләрен бер почмакка кысып, болай ди:

– Азнакай кичәсе белән моны чагыштырып булмый, «нәданнарым»! Кичәгез фәкыйрь. Эчәргә су, чәй юк... Ә сез күрдегезме – Азнакай нишләде? Ике йөз илле торт кына куелган иде табынга.

Актаныш җегетләре Ләбиб Лерон, Данил Салих, ни әйтергә белмичә, башларын түбән иеп тик тора. Аларны кызганып, Батулла ярдәмгә килә:

– Мактанма, Марчук! Президент Азнакайда туган булса, сезнең кичә дә шулай фәкыйрь узган булыр иде, – ди.

*1997*

## Тәхет вә аның варислары

Язучылар утырышында гомер буе түргә узмыйча, ишек катында гына утырырга күнеккән Батулла беркөнне түргә барып утыра. Фәрваз Миңнулла аңа әйтә:

– Нигә син түргә үрләдең әле? – ди.

– Бу – Әмирхан Еники урыны, ул кергәнче берәрсе алмасын дип утырып торам, – ди Батулла.

– Еники урынына өмет итүче язучылар да бармыни прозаиклар арасында? – дип сорый Фәрваз.

– Бар! – ди Батулла. – Марсель Гали.

– Ха-ха-ха, алай булса, синең эш бик мөшкел бит, Батулла малай! – дип көлә Фәрваз. – Ул нахал сине, мөгаен, төртеп төшерер бу урыннан.

*1990*

## Язучылар

– Ага кеше, әйтеп бирсәңче, язучылар кемнәр алар, ниндиләрен сез хөрмәт итәсез?

– Язучылар төрле була! – дигән Батулла. – Яла язучы. Әләк язучы. Отчёт язучы – алары коммунист язучылар. Бар әдәби әсәр язучы. Бар әдәби әсәр язам дип уйлап та, әдәби булмаган әсәр язучы. Бар язмый торган язучы. Бар яза торган әдипләр.

– Ничек инде ул язмый торган язучы?! Язмагач, язучы буламыни инде ул?

– Була! Язмый торган язучыларның байтагы дәреслекләрдә классиклар дәрәҗәсендә өйрәтелә.

*1990*

## Киңәш

Эльс Гадел:

– Мин Ринат Мөхәммәдинең «Сират күпере» романын сукырларга укып чыктым.

Батулла:

– Син аны чукракларга да укып чык!

*1995*

**НАЛАСАЛЫ**

## Тыгыз график...

Фән дөньясы, мәш килеп, Габдулла Тукайның юбилее уңаеннан халыкара конференциягә әзерләнә. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин гыйльми сәркатип Рөстәм Галиуллинга эш куша:

– Аксакал язучыларга шалтыратып чык әле, алар катнашмаса, конференция тулы канлы булмас, – ди.

Кушылган эш – үтәлгән эш, гыйльми сәркатип, җиң сызганып, халык шагыйрьләрен, язучыларын, Тукай премиясе лауреатларын фәнни конференциягә чакырырга тотына. Иң әүвәл Ренат Харисның номерын җыя.

– Ул көннәрдә графигым бик тыгыз, планны карамыйча әйтә алмыйм, – ди Халык шагыйре. Бераз кәгазь кыштырдаткач, ниһаять, аның авызыннан җылы сүзләр яңгырый. – Ул көнне син әйткән вакытта мин буш икән, килермен...

Аның болай да тыгыз графигына тагын бер чара өстәгән гыйльми сәркатип, җиңел сулап, Рабит Батуллага шалтырата.

– Графикны карамыйча гына әйтә алмыйм бит, ул көнне буш булмавым да бар, – ди Халык язучысы, аны тыңлагач.

Сиксәнгә җитеп килгән аксакалның бу «кыланмышына» бик гаҗәпләнә гыйльми сәркатип:

– Рабит ага, син инде үзебезнең кеше, нәрсә график-мазар дип сөйләнгән буласың?

– Ашыкма, көтеп тор, исәпләргә комачаулыйсың, – ди Батулла. Үзе исә ниндидер кәгазьләр кыштырдата, нәрсәдер саный. – Әһә! Килә алам икән! Алты көн саен авыруымның өянәге кабатлана, график буенча ул көнгә туры килми икән, рәхмәт төшкере!

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# Печән базары

*Сатирик әсәрләр*

## ПАРТИЯЛӘР ТӨРЛЕ, ТАМАК БЕР...

Юмореска

– Их бу күп партиялелек, бездерде бит тәмам. Шуның аркасында өйдә һәркөн ниндидер ыгы-зыгы килеп чыга да куя. Ник дисәгез? Мин, Камил Кәримов әйтмешли, үзем «Идинарус», хатын – Зюганов партиясендә, балалар Жириновский яклы. Ә бер ерак туганым элек сыра сөючеләр партиясенә кергән иде һәм урам буйлап сыра чөмереп йөри торгач, каядыр сеңде.

Без, исән калганнар, тырмашып-маташып дигәндәй, яшәргә омтылабыз. Дөньяга карашларыбыз төрле булса да, өйдә тәүлеккә өч мәртәбә аш бүлмәсендә, табын янында күрешәбез. Тамак ул үзе, нинди генә партиядә булсаң да, бер нәрсәгә генә – ашка табынып яши һәм, аш турында уйлап, аңа гына тугрылыклы булып кала.

Аллага шөкер, ризыкка мохтаҗлык юк – төрле партияләрдә булсак та, йорт та, сыер да, сарыклар да, ат та бар, һәм аларны төнлә чит яклардан караклар урлап китмәсен дип, мылтык та сатып алдым.

Мин, йортның хуҗасы буларак, үземә – малларга азык табыштыруны, хатынга – сыер саву, балаларга ат һәм сарыкларны карау вазифаларын билгеләдем. Тик алар тарафыннан бу вазифалар төгәл генә үтәлеп бетми шул. Аш бүлмәсендә безнең карашлар бер булса да, абзар-кура тирәсендә алар, төрле якка таралып, пыран-заран килеп бетә шул.

Нинди генә хәлләр очраса да, мин – йорт хуҗасы «Идинарус» буларак, бу партияләрнең йогынтысына бирешмим һәм әби-бабамнан калган кәсепне, мал-туар үстерүне хуплап, бердәмлекне саклап калырга тырышамын.

…Менә шулай, сәяси мөнәсәбәтләрне урнаштырам, дия-дия, кыш та үтеп китте һәм бәрәңге утырту вакыты җитте. Мин, гадәттәгечә, атны җиктем һәм: «Барлык партияләр, берләшегез! Хәзер бәрәңге утыртабыз», – дидем. Идинарус буларак, мин тәрәнгә ябышам, хатын, Зюганов партиясе буларак, ат башыннан тота, ә Жириновский партиясендәге балалар чиләкләрдәге орлыкларны буразнага салып йөрер. Чү! Чү! Оныкларны да компьютер артыннан торгызып, бакча өстенә чыгарыгыз, эшли белмәсәләр дә, карап торулары киләчәктә бердәм яшәр өчен зур дәрес булыр…

## ГЕНЕРАЛ КИЯВЕ

Булган хәл

Авылдашыбыз Фәрит, армиягә киткәч, Мәскәүдә хезмәт итә. Егет сабыр холыклы, тырыш һәм дә алтын куллы иде… Кайтырына бер ай калгач, часть командиры аны хәрби округ генералының дачасын төзергә җибәрә (элек солдатның мондый хезмәте «Дембельский аккорд» дип әйтелә иде). Бер ай эчендә солдат авылдашыбыз, генералның ышанычына кереп, аның ихтирамын яулый. Шуңа күрә дә генерал белән дачада, фатирында, генерал киемнәрен киеп тә, хәтта аның буй җиткән кызы белән янәшә утырып та фотога төшү мөмкинлекләре туа.

Хәрби хезмәтен тәмамлап кайткач, Фәрит үзенең генерал тормышына бәйле

дәрәҗәле фоторәсемнәре белән мактана, билгеле. Аны тыңлап торучылар арасында көрешергә кергән дус-ишләре, урамда әз-мәз генә сүз таратучы күрше хатыннар да була.

Бу очрашулардан соң: «Фәрит генерал кияве, генерал кызына өйләнгән, Мәскәүдә квартирасы да, дачасы да бар, вот молодец малай», – дип, хатыннар белер-белмәс хәбәр тараталар.

Авылның икенче очында хәтта: «Фәрит армиядән генерал булып кайткан», – дип тә сөйләүчеләр табыла… Ләкин, ни генә сөйләнсәләр дә, еллар үтү белән, алар һәммәсе дә онытылды. Фәрит үзебезнең авылдан тегермәнче Шәрипҗан кызына өйләнеп гомер итсә дә, аңа «Генерал кияве» дигән кушамат тагылып калды. Һәм бу кушамат аның каенатасы, тегермәнче Шәрипҗанга халык каршында зур уңайсызлыклар тудыра иде.

## ПОЖАЛЫСТЫ

Юмореска

Хәзерге «теләсә нәрсә эшлә» дигән әрсез, демократик заманда халык арасында «Пожалысты» дигән сүз, көннән-көн киң кулланыш табып, үзенә зур абруй яулый бара.

Нәрсә эшләргә маташма, нинди генә гамәл кылма, һәр җирдә сине «пожалысты» дигән сүз белән каршы алалар. Ирекле җәмгыятьтә торуыбызга шатланып туя алмыйбыз, кибет ачасың киләме, фермер хуҗалыгы ясыйсыңмы – бернинди киртә юк, һәрвакыт сиңа баш иеп, «пожалысты», – диеп каршы алалар үзеңне. Теләгәнеңне яз, теләгәнеңне әйт – һәммәсенә дә яшел юл һәм «пожалысты, пожалысты», – дип кыстаулар яңгырый да яңгырый гына.

Хезмәт урыныңда берәр низаг чыгып, «нәчәлнигеңне» сүгеп ташлыйсыңмы – пожалысты. Демократия чоры бит, пожалысты, акыр-бакыр, телең көтүче чыбыркысы кебек озая барсын. Югарыда әйткән гамәлең өчен синең телеңне түгел, бары эш урыныңны кыскартулары гына ихтимал.

Әгәр озын телең аркасында эш урының кыскартыла икән, ул вакытта сине: «Пожалысты», дип мәшгульлек үзәге (центр занятости населения) каршы ала. Монда сине: «Эш табарбыз, рәхим ит», дип каршы алалар һәм соңыннан «всегда пожалысты» дигән эш урыны тәкъдим итәләр.

Инде бу «всегда пожалысты» дигән эш урынындагы «нәчәлникне» сүгү генә түгел, аны бередә кыйнап ташласаң да, эш урының гомердә дә кыскартылмый икән. Чөнки мәшгульлек үзәге үзеңә шундый эш тәкъдим итә – бередә озын телеңне сузып, кыска хезмәт хакы алып, билеңне катырып, бөкреңне чыгарып хезмәт ит кенә, пожалысты.

Ай-һай, бу «пожалысты» дигән сүз тормышның һәр почмагына, һәр ноктасына, бизнес, сәүдә, сату итүнең түренә үтеп керде бит, җәмәгать. Мәсәлән, син хатын-кыз ди, бала табарга больницага барасың һәм сиңа анда: «Гинекологыбыз үзе дә бәби табарга шәһәргә китте, шәһәрдә баланы яхшы таптыралар икән, аның белән бергә бала табу зур бәхет, шәһәргә барыгыз, пожалысты», – дип, ягымлы гына озатып калалар үзеңне.

Инде хәзер эшләмәсәң дә, укып йөрмәсәң дә ярый, өйдә ятып торасыңмы, көмешкә куасыңмы – ул синең эш, теләсәң нишлә – пожалысты.


Әгәр инде, кәеф-сафа торгызу өчен, көмешкә куа алмасаң, ул нәрсә безнең авылда «Тыкрык Әсма»да сатыла, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ал да эч – пожалысты! Әгәр инде «Тыкрык Әсма»ның көмешкәсенә тончыгып үлсәң, бу очракта бездә бизнес нокталары ачылды. Ул-бу була калса, авылда тимерче Таһир, мал туплау нияте белән зират челтәрләре ясый, комсыз Хафиз кәфен кибете ачты, ә кабер казучы гастарбайтерлар «зират йортында» ук яши… Гомумән әйткәндә, теге дөньяга да ишекләр ачык һәм «всегда пожалысты».

**Рөстәм АРИФУЛЛИН,**
*Ульян өлкәсе Иске Кулаткы авылы*

## ЗАРИФИЗМНАР

- Мәшһүр полководецлар да үз-үзләрен җиңә алмый.
- Сыерчыкның үз җыры булмаса да, аны беркем дә плагиат дип әйтми.
- Юл тарайса – сукмакка, фикер тарайса, гайбәткә күчә.
- Күл саекса – бака, ил казнасы саекса – түрә үрчи.
- Көнчелек ялгызлыкка иң кыска юл.
- Балтаның кадере – күлдә, алтынның кадере чүлдә югала.
- Су салкыны тирәндә, хатын-кызның кемлеге биләмдә беленә.
- Бүрегең белән киңәшеп, күләгәң белән тиргәшеп булмый.
- Дәүләтне – салым, империяне золым яшәтә.
- Хәйлә – максатка ирешү өчен уйлап табылган тозак.
- Татар, түрә булса, чабатасын гына түгел, портретын да түргә элә.
- Үз парыңны табуы авыр, аның белән яшәү исә тагын да авыррак.
- Энҗенең кадере – муенда, кызның кадере – куенда.
- Көнче кеше булсаң – дусларың, кирәкле гамәл кылсаң, дошманнарың артыр.
- Алдакчыны – күзләре, имансызны сүзләре сата.
- Малың таралса – дустың, гайбәтең таралса, дошманың кими.
- Хатын-кызның чын йөзен кичен ире генә күрә.
- Көнче кеше этеннән дә көнләшә.
- Түрә баеса – хәерчеләр, галим баеса, наданнар артыр.
- Тигәнәк баш булса – гөлләр, хатын-кыз баш булса, чын ирләр бетә.
- Үрдәкле күлдә бака үрчемәс.
- Тилгән – чебешне, нәфесле яшь кызны күзләр.
- Яшь парга – көн, ялгызга төн озын.

**Фирдәвес ЗАРИФ**



# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ФУТБОЛ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ

Россиядә футбол буенча дөнья чемпионаты бара. Казанда турнирның алты уены узды. Казан-Арена стадионында Франция – Австралия (исәп 2:1), Испания – Иран (2:1), Польша – Колумбия (0:3) Германия – Көньяк Корея (0:2) командалары төркем этабы уеннарында көч сынашты. Татарстан башкаласында шулай ук финалның сигездән бер һәм чирек финал уеннары булачак. Чемпионат барган көннәрдә Казансу яры буенда «Казан» гаилә үзәге мәйданында «Фан-зона» ачылды. FIFA җанатарлар фестивале бара. Уеннар зур экран аша күрсәтелә. Шушында ук музыка тыңларга, концертлар карарга, Татарстан халык сәнгате һәм сувенир продукциясе күргәзмә-ярминкәсен күрергә, интерактив уеннарда катнашырга мөмкин. Футбол буенча дөнья чемпионатының мәдәни программасы кысаларында туксанлап махсус чара, 8 музыка һәм театр фестивале, 10 күргәзмә оештыру күздә тотыла. Кунакларга С.Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында – С.Рахманинов исемендәге «Ак сирень» VII халыкара фестивале, ТР Дәүләт кыллы квартеты концертлары, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә «Барлык флаглар да безгә кунакка килә», «Чәчәк атучы Татарстан» дигән фестивальләр, Казандагы дәүләт театрларында иң популяр спектакльләр, Казан Кремлендә «Россия. XXI гасыр реализмы», «Портрет сәнгате», «Россия халыкларының традицион мәдәнияте һәм Бөек ефәк юлы» күргәзмәләре, Татарстан Халыклар дуслыгы йортында «Күп милләтле футбол» фотокүргәзмәсе, М.Горький исемендәге мәдәният һәм ял паркында фильмнар парады, башкалабызның дәүләт музейларында «Футбол төне» һ.б. чаралар тәкъдим ителде.

## МИЛЛИ ТЕЛЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы милли телләрне өйрәнү турындагы закон проектын күп төзәтмәләр белән беренче укылышта кабул итте һәм эшләп бетерергә җибәрде. Аңа кадәр Дәүләт Думасының мәгариф һәм фән комитетында әлеге закон проекты турында зур сөйләшү булды, Мәскәүдә милли республикалар вәкилләре катнашында «Туган телләрнең гомуми белем бирү системасында үсешенең сәяси, хокукый аспектлары» дигән темага «түгәрәк өстәл» үткәрелде. ТР Дәүләт Советында туган телләрне ирекле укыту турында закон проектына каршы мөрәҗәгать әзерләнде. Бу җәһәттән башка республикалар да үз сүзләрен ирештерделәр. Хәзергә шунысы мәгълүм: милли дәүләт телләре укыту программасының төп мәҗбүри өлешендә калачак. Аларны сайлау исә ата-аналар, балалар ихтыярында. Киләчәктә укытучылар әзерләү, мәктәпләрне дәреслекләр, укыту программалары белән тәэмин итү максатында милли телләрне үстерүгә ярдәм фондын, телләрне укытуның бердәм концепциясен булдыру күздә тотыла.

## РУС ТЕЛЕ КӨНЕ

Россия Федерациясе Президенты Указы белән Пушкинның туган көне Рус теле көне буларак билгеләп үтелә. Шушы вакыйга уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, дәүләт, җәмәгать эшлеклеләре, әдәбият, сәнгать әһелләре, галимнәр шагыйрьнең Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Шушында ук шигъри митинг булды.

Пушкинның тууына 219 ел тулуга һәм Рус теле көненә багышланган тантаналы чара традиция буенча М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында үтте. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. «Рус теле һәм әдәбияты күпләр өчен рус мәдәниятенең символы булган Пушкин исеме белән бәйле. Кече яшьтән рус халкының югары әхлакый кыйммәтләрен сеңдереп, ул аларны үзенең шигърияте ндә данлады һәм бөтен дөньяга ачты. Пушкин мирасы – дөнья әдәбиятының хәзинәсе, Россия халкының казанышы», – диде ул.

ТР Президенты рус һәм дөнья мәдәниятенә бөек язучы, фикер иясе Лев Толстойның да зур өлеш кертүен ассызыклады. Аның әйтүенә караганда, Толстойның шәхесе дөньяга карашы формалашканда Казанда яшәгән чоры да үз ролен уйнаган. Без бөек язучы һәм гуманистның мирасын югары бәялибез, шуңа күрә 2018 ел Лев Толстой елы буларак игълан ителде.

Рөстәм Нургали улы якын арада Казанда Пушкин исемендәге мәдәни үзәк ачылачагын да хәбәр итте.

ТР Президенты Татарстанның рус милли-мәдәни берләшмәсе активистлары белән дә

очрашты, аларга телне саклауда һәм үстерүдә үзләреннән зур өлеш кертүләре өчен рәхмәт әйтте, эшчәнлекне Казанда гына түгел, республикабызның башка шәһәрләрендә һәм районнарында җәелдерү кирәклеген искәртте.

### КИТАП ФЕСТИВАЛЕ

Мәскәүдә «Кызыл мәйдан – 2018» дип исемләнгән зур китап фестивале булып узды. Анда Татарстан китап нәшрияты да катнашты. Безнекеләр фестивальгә 350 исемдәге китап алып килгән иде. Әлеге чара кысаларында «Сөембикә» китабын тәкъдим итү булды.

### ЗАМАН ҺӘМ БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Татар балалар әдәбияты: традицияләр һәм заманчалык» дигән темага фәнни-гамәли конференция үткәрде. Ул балалар язучылары Дәрҗия Аппакованың тууына – 120, Абдулла Алишның тууына – 110, Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиевнең тууына – 90 ел, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинга 70 яшь тулуга багышланды. Конференцияне Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор Ким Миңнуллин ачты. ТР Фәннәр академиясе вице-президенты, академик, филология фәннәре докторы, профессор Дания Заһидуллина, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург, прозаик Данил Салихов сәламләү сүзләрен ирештерделәр. Конференциядә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Равил Рахмани – «XX гасырның беренче яртысы балалар әдәбияты һәм Дәрҗия Аппакова», шагыйрь Рафис Корбанов – «Абдулла Алишның татар балалар әдәбиятын үстерүдәге роле», КФУ доценты, филология фәннәре кандидаты Нурфия Йосыпова – «Шәүкәт Галиев иҗатында балалар дөньясының сәнгати чагылышы», КФУ профессоры, филология фәннәре докторы Ләйлә Минһаҗева – «Роберт Миңнуллинның балалар өчен иҗаты (үзенчәлеге һәм осталык мәсьәләләре)», «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, язучы Айгөл Әхмәтгалиева – «Балалар әдәбияты – якты әдәбият (хәзерге балалар әдәбиятына бер караш)», Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты бүлеге мөдире Айсылу Галиева – «Татарстан китап нәшрияты – балаларга», республика балалар китапханәсе методисты Гөлназ Әһлиуллина «Татарстанның муниципаль китапханәләрендә балалар китабы белән эшләү формалары» дигән темаларга докладлар белән чыктылар. Конференциядә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин чыгыш ясады.

### ПАРКТА – КИТАПХАНӘ

Футбол буенча дөнья чемпионаты барган көннәрдә ТР Милли китапханәсе математика галиме Николай Лобачевский бакчасында «Паркта – китапханә» дигән мәдәни-мәгърифәти чара үткәрде. Аны ачу тантанасында ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Милли китапханә директоры Сөембикә Җиһаншина, Татарстан китап нәшрияты мөхәррире, язучы Галимҗан Гыйльманов катнашты.

«Паркта – китапханә» бәйрәмендә «Казан – мәдәният һәм спорт башкаласы» дигән тематик күргәзмә, «Матурлыкны үзебез тудырабыз» дип аталган истәлекле бүләкләр почмагы, китапханә бинасына «Ушаковлар йорты – тарих һәм заман» дип исемләнгән экскурсия, китап нәшер итү серләрен белүчеләр бәйгесе, спорт темасын чагылдырган открыткалар, китапчыклар, китап кыстыргычлары ясау остаханәләре, кызыклы лекцияләр, төрледән-төрле басмалар, республикада нәшер ителә торган газета-журналлар, викториналар, мастер-класслар, Сабан туе күренешләре, җыр-музыка тәкъдим ителде.

### ХАЛЫКАРА БӘЙГЕ

Украинада «Тарас Шевченко халыкларны берләштерә» дип аталган сәнгатьле уку һәм җыр халыкара бәйгесе булып узды. Анда читтән торып та катнашырга мөмкин иде. Бәйгегә 20 илдән, 157 видеоролик килеп ирешкән. Конкурста Түбән Кама шәһәрендәге 24нче лицейның V сыйныф укучысы Илнар Һидиятов, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиевнең «Нигез» повестеннан өзек укып, «Су буеннан әнкәй кайтып килә» (Луиза Батыр-Болгари көе) җырын башкарып, Гран-прига лаек булды.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән татар әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше һәм күпьеллык иҗади хезмәте өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге оешмасы» (Иҗади берлек) рәисе Данил Хәбибрахман улы Салихов «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

2018 елның 14 июнендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Һ.Такташ премиясе лауреаты **Әхмәт Саттар улы Саттаров (Әхмәт Саттар)** 79нчы яшендә вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: стихотворение Г.ТУКАЯ, исторический роман Ф.БАЙРАМОВОЙ «Гулейза», повесть Х.ИСМАГИЛОВА «Переходя Афганские горы», рассказы Г.ГИЛЬМАНОВА, Ф.ГИЛЬМУТДИНОВОЙ; стихи С.ЯКУПОВОЙ, И.САБИРОВА, Ф.ГИЛЯЗОВА.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Татарская литература – в мире»: стихи Н.ИЗМАЙЛОВОЙ, А.НУРГАТИНОЙ, К.ТАНГАЛЫЧЕВА, И.БИЕКТАУЛЫ, Ш.ШАХМАЕВА, Ф.ДАВЛЕТГАРАЕВОЙ, Р.НАСИБУЛЛИНА, А.АСКАРОВА, Р.ШАФИГУЛЛИНА, Э.КАРИМОВОЙ, Г.ИСХАКОВОЙ.*
*Литературный конкурс «Достояние»: повесть Т.ГАЛИУЛЛИНА «Беспокойные сны».*
*«255 лет со дня рождения Таджетдина Ялчыгула»: Д.ГАРИФУЛЛИН. «Обладатель загадочной жизни».*
*«Наши юбиляры»: Д.ЗАГИДУЛЛИНА. «Ощущая сердцебиение литературы…» (80 лет Т.ГАЛИУЛЛИНУ).*
*«Публицистика»: очерк А.ИМАМИЕВОЙ о руководителе ООО «Казанские стальные профили» Ильдаре Нугманове.*
*«Литературное наследие»: Л.МУХАМЕТЗЯНОВА. «Ты родина дастанов, Сибирь!» Интервью А.ИМАМИЕВОЙ с Н.НАККАШ.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*«Сенной базар»: Юморески Р.АРИФУЛЛИНА.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: учёный, педагог, писатель Таджетдин Ялчыгул.*
*Художник Рушан Шамсутдинов; Фан-зона чемпионата мира по футболу в г.Казани.*
*Фото Рамиля Галиева.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: poem by G.TUKAY, historical novel by F.BAYRAMOVA «Guleyza», story by H.ISMAGILOV «Crossing the Afghan mountains», stories by G.GILMANOV, F.GILMUTDINOVA; poems by S.YAKUPOVA, I.SABIROV, F.GILYAZOV.*
*«Relevant critique»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«Tatar literature in the world»: poems by N.IZMAYLOVA, A.NURGATINA, K.TANGALYCHEV, I.BIECTAULY, SH.SHAKHMAEV, F.DAVLETGARAEVA, R.NASIBULLIN, A.ASKAROV, R.SHAFIGULLIN, E.KARIMOVA, G.ISKHAKOVA.*
*Literary contest «Heritage»: story by G.GALIULLIN «Restless dreams».*
*«255th anniversary of Tajetdin Yalchygul»: D.GARIFULLIN. «Possessor of a mysterious life.»*
*«Our anniversaries»: D.ZAGIDULLINA. «Feeling the heartbeat of literature…» (80th anniversary of T.GALIULLIN).*
*«Journalism»: essay by A.IMAMIEVA on the head of JSC «Kazan steel profiles» Ildar Nugmanov.*
*«Literary heritage»: L.MUHAMETZYANOVA. «You are the birthplace of the dastans, Siberia»! Interview by A.IMAMIEVA with N.NAKKASH.*
*«Pages of humor»: article by M.GALIEV.*
*«Hay market»: humoresques by R.ARIFULLIN.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: scientist, teacher, writer Tajetdin Yalchygul.*
*Artist Rushan Shamsutdinov; Fan zone of The 2018 FIFA World Cup in Kazan.*
*Photo by Ramil Galiev.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* галим, педагог, әдип Таҗетдин Ялчыгол. *Рушан Шәмсетдинов картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* футбол буенча дөнья чемпионатының Казандагы Фан-зонасы. *Рамил Галиев фотосы.*